**Илсөяр Рәмиева**

# Рус, татар, төрек әдәбиятларында ханбикә Сөембикә образы

Казан – 2002

## ЭЧТӘЛЕК

**Кереш**

**Беренче бүлек**

**XVI–XIX гасырларгы рус әдәбиятында Сөембикә ханбикә образы**

1. «Казан тарихы»

2. М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы

3. С.Н.Глинканың «Сөембикә, яки Казан ханлыгының егылуы» трагедиясе

4. А.Н.Грузинцевнең «Казанның буйсындырылуы, яки Явыз дип аталган патша Иоанн Васильевич IVнең мәрхәмәтлелеге» трагедиясе

5. Г.Р.Державинның «Грозный, яки Казанны буйсындыру» операсы

6. М.С. Рыбушкинның «Иоанн, яки Казанны алу» трагедиясе

7. В.И.Лапинның «Казанның алынуы» трагедиясе

**Икенче бүлек**

**XX гасыр башы татар әдәбиятында Сөембикә ханбикә образы**

1. Әдәби-тарихи җирлек һәм татар әдипләре

2. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә Сөембикә

3. Татар тарихчылары Сөембикә турында (1903–1914 еллар)

4. Ф.Әмирхан һәм Ш.Әхмәдиев хикәяләре

**Өченче бүлек**

**Төрек әдәбиятында Сөембикә ханбикә образы**

1. Илгаз Ваһап Нәүрүзханның «Сөембикә» тарихи романы

2. Төрек вакытлы матбугаты Сөембикә турында

3. Ләбиб Каран һәм Музаффер Кая әсәрләре

**Йомгак**

**Библиография**

# КЕРЕШ

Сөембикә (1516 еллар тирәсе – 1554 елдан соң) – 1549-1551 елларда – Казан ханлыгы ханбикәсе. Нугай морзасы Йосыф кызы. Бер-бер артлы Казан ханнары Җангали (1533–1535), Сафагәрәй (1536–1549), Шаһгалинең (1553 елдан алып) хатыны була. 1551 елда улы Үтәмешгәрәй белән берлектә Мәскәүгә әсирлеккә җибәрелә. Сөембикә исеме белән төрле легендалар яши, шул исәптән, Казан Кремлендә урнашкан манара турында риваять тә бар һәм дөнья әдәбиятларында (рус, татар, төрек) аның образын үзәккә алган күп әсәрләр иҗат ителә[1].

Көнбатыш фәлсәфәчеләре Һәм культурологлары егерменче гасырны «милләтчелек гасыры» дип атадылар[2]. Бу күренеш милли нигезләргә таба борылыш, үткән тарих, халык һәм ил язмышында олы вакыйгаләрне яңача күздән кичерү, аларга заман таләбенчә бәя бирү белән бәйле. Милли аңның үсеше, милли хисләрнең яңаруы, беренче чиратта, үткән мирасны барлау, тарихи хәтерне кайтару белән тыгыз бәйләнештә тора. Дәүләтчелеген, мөстәкыйльлеген югалту сәбәпле, татар тарихы күп еллар дәвамында берьяклы гына аңлатылып килендe. Хәер, галимнәребез фикеренчә, халкыбызның тарихи фикере дә үз язмышы кебек үк, төрле сынаулар – җиңелеп җимерелүләр, дәвамлы торгынлык, кузгалып тернәкләнү белән аптыраулы һәм нәтиҗәле эзләнүләр аша үтте[3]. Патша заманында да, совет чорында да Казан ханлыгын 1552 елда кан диңгезенә коендырып, рус дәүләтенә кушу сәясәте татарларны варварлыктан коткару дип, тарихи яктан акланган уңай күренеш буларак бәяләнде. Моның шулай икәнлеген дәлилләү өчен, еш кына Ф.Энгельснең «Россия действительно играет цивилизующую роль … для башкир и татар» дигән сүзләре китерелде[4]. Шул рәвешчә, Россия империясе составына көчләп кушылган башка халыклар язмышы кебек үк, татар тарихы да рус тарихының уңай тәэсире – «благотворное влияние» дигән күләгә астында күмелеп калды.

XX гасырның соңгы чирегендә, ягъни үзгәртеп кору еллары килгәч, галимнәребез милли тарихыбызны, шул исәптән, XVI гасыр уртасында Казан ханлыгының руслар тарафыннан басып алыну кебек экспансив сәясәтен бары тик аклау һәм яклау позициясеннән чыгып аңлатудан баш тарттылар. Тарихи вакыйгаләрне аңлатуда җибәрелгән хаталар, төгәлсезлекләр, гаделсезлекләр турында соңгы вакытта рус авторлары да яза башладылар. «Действительно, – дип яза Наталья Полтавцева, – история взятия Казанского ханства Иваном Грозным, написанная с позиции интересов государства Российского, – это одна история.

---

[1] Татарский энциклопедический словарь. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 1999. – С.551.

[2] Турсунов Акбар. Национальная культура в общечеловеческой перспективе // Вопросы литературы. – 1990. – №6. – С.4.

[3] Госманов М. Галимнең дәрәҗәсе // Гайнетдин Әхмәрев. – Казан: «Җыен–ТатАрт. «Хәтер» нәшрияты, 2000. – Б. 7.

[4] Маркс К., Энгельс Ф. Сочинения. – Издание второе. – М.: Государственное издательство политической литературы,1954 – Т. XXVI. – С.241.

Она же, но поданная глазами историка противной стороны, – это, поверьте, совсем другая история»[5]. Күренгәнчә, галимә бер үк тарихи вакыйгаларга, руслар белән татарлар арасындагы канлы бәрелешләргә ике төрле бәя бирү мөмкинлегенә игътибар итә. Бу – бик әһәмиятле фикер. Хакыйкать ике яклы булу ихтималы бар дигән фикернең тамырлары бик еракка – атаклы мөселман философы Ибн Рөшд (1126–1198) карашларына барып тоташа. Дөрестән дә, татарлар белән руслар Казанның яулап алыну тарихына, милли мәнфәгатьләрне истә тотып, ике төрле күзлектән якын килергә мөмкин.

Соңгы вакытларда татар дәүләтчелек тарихындагы «алтын чор» дип саналган Казан ханлыгы дәверенә, аның канлы-яшле тарихына төрле яктан анализ биргән шактый күп фәнни хезмәтләр барлыкка килде. Ниһаять, тарихчыларыбыз милли тарихыбызны объектив яктырта башладылар.

Узган тарихка, аның күренекле шәхесләренә гадел бәя бирүгә омтылыш татар иҗтимагый-тарихи фикеренең мәгърифәтчелек дәверенә – XIX ахыры–XX гасырның башларына туры килә. Халыкка аң-белем иңдереп, аны тәрәккыяткә илтү юлларын эзләгән мәгърифәтчеләр милли тарихка мөрәҗәгать итәләр. Аларның тырышлыгы белән Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы дәверләре белән кызыксыну арта, халкыбызның бөек шәхесләре, олы затлары турында фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр языла башлый.

Татар тарихын объектив эчтәлектә өйрәнү мөмкинлеге тугач та, язучыларыбыз, аеруча прозаикларыбыз моңа кадәр «ак тап» булып килгән Казан ханлыгы чорына игътибарларын көчәйттеләр. Бу чор татар халкының милли-азатлык хәрәкәте турында язылган әсәрләрнең үзәгендә гүзәл һәм фаҗигале Сөембикә ханбикә образы тора. Гәрчә тарих фәнендә Казан ханлыгы дәвере турында чыганаклар күп булмаса да, Сөембикә ханбикә шәхесенең гасырлар дәвамында халык күңелендә саклана алуын, аның конкрет бер тарихи шәхес кенә булып калмыйча, татар милләтенең «милли азатлык һәм мөстәкыйльлек символы» дәрәҗәсенә күтәрелүе белән аңлатырга мөмкин. Аңлашылса кирәк, XX гасыр башында һәм аның азагында булып узган иҗтимагый һәм рухи яңарыш дәүләтчелегебез тарихында зур роль уйнаган Сөембикә шәхесе белән турыдан-туры бәйләнештә тора. XVI–XX гасырларда татар, рус һәм төрек телләрендә ханбикә Сөембикә турында шигырь, проза һәм драма жанрында бик күп әсәрләр иҗат ителгән. Шунлыктан бу темага язылган фәнни хезмәтләр дә бихисап. Аларны өч төркемгә бүлеп өйрәнергә мөмкин.

Беренчесе – рус әдәбият белемендә Сөембикә шәхесе һәм әдәби образы турында язылган хезмәтләр. Рус әдәбияты тарихында Сөембикә турында иҗат ителгән әсәрләрнең беренчесе – «Казан тарихы». Анда чагылыш тапкан Сөембикә образы турында беренчеләрдән булып рус галимнәре язып чыгалар. Аларның күпчелеге XVI гасырда иҗат ителгән «Казан тарихы»нда Сөембикә образының сәнгатьчә ничек гәүдәләнеше һәм ни дәрәҗәдә тарихи чынбарлыкка якын килү-килмәү мәсьәләсен өйрәнгән. Болар – Г.З.Кунцевич[6], А.С.Орлов[7], Г.Н.Моисеева[8],

---

[5] Полтавцева Н. Исторична ли история? // Вопросы литературы. – 1997. – №2. – С.62.
[6] Кунцевич Г.З. «Россиада» Хераскова // Журнал Министерства народного просвещения. – М., 1901. –

Я.С.Лурье[9], Ю.Н.Нигъмәтуллина[10] хезмәтләре. А.В.Западов[11], А.Н.Соколов[12], В.А.Бочкарев[13] кебек галимнәр дә XVI гасыр азагында – XIX гасыр башында рус әдәбиятында тарихи темага язылган әсәрләрнең образлар системасын яктырткан хезмәтләрендә Сөембикә образына тукталып үтәләр.

Икенче төркемне татар әдәбият белемендә Сөембикә турындагы әсәрләргә күзәтү ясаган, аларны анализлаган хезмәтләр тәшкил итә. Болар арасында Сөембикә образын өйрәнүгә нигез салучы һәм бу өлкәдә бүген дә актив эшләп килүче профессор Ф.Урманчеев исемен аерым күрсәтү кирәктер. Соңгы елларда Казан ханбикәсе Сөембикә образын өйрәнүчеләр рәтенә Ә.Кәримуллин[14], Н.Ханзафаров[15], Ф.Хатипов[16], Х.Әшрәфҗанов[17], Ф.Галимуллин[18], М.Зәкиев[19] кебек әдәбият һәм тел белгечләре, А.Гыйлаҗев, Р.Батулла, М.Хәбибуллин кебек язучыларның әдәби әсәрләре һәм мәкаләләре килеп кушылды. XXI гасыр башында исә Сөембикә образын рус елъязмалары һәм фольклорга мөнәсәбәттә өйрәнгән Марат Садеков хезмәте дә дөнья күрде[20].

Өченче төркемне төрек телендә язылган Н.Бинарк, М.Ф.Тугай, А.Р.Арат, Г.Чандарлыоглу, Г.Баттал-Таймас кебек галим һәм журналистларның Казан ханлыгы тарихы һәм Сөембикә турында язылган фәнни-публицистик мәкаләләре тәшкил итә.

Китапта XVI – XX гасырлар аралыгында дөнья әдәбиятында рус, татар, төрек телләрендә иҗат ителгән күп санлы фольклор үрнәкләренә, төрле жанрларда язылган матур әдәбият әсәрләренә (тарихи роман, трагедия, поэма, нәсер, шигырь, хикәяләргә) анализ ясалды.; фәнни-публицистик, әдәби тәнкыйть мәкаләләренә, тарихи планда язылган хезмәтләргә мөрәҗәгать ителде. Хезмәттәге бүлекләр саны да, хронологик принциптан

---

№11. – С.175–178; История о Казанском царстве, или Казанский Летописец. Опыт историко-литературного исследования. – СПб., 1905. – С.618; История о Казанском царстве (ее списки). – СПб., типография Императорской Академии Наук, 1901. – С.126.

7 Орлов А.С. Героические темы древнерусской литературы. – М.-Л., 1945.

8 Моисеева Г.Н. Автор «Казанской истории» // ТОДРЛ (Институт русской литературы АН СССР). – М.-Л.: АН СССР, 1953. – Т.9. – С.266–288; Казанская царица Сююнбике и Сумбека в «Казанской истории» // ТОДРЛ. – М.-Л.: АН СССР, 1956. – Т.12, – С.174–187; О некоторых источниках «Казанской истории» // ТОДРЛ. – М.-Л.: АН СССР, 1955. – Т.12. – С.186–197.

9 Лурье Я.С. Казанская история // История русской литературы. – Л., 1960. – Т.1. – С.258–262.

10 Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань: Изд-во «Фэн», 1997. – С.53-57.

11 Соколов А.Н. Очерки истории русской поэмы XVIII – первой половины XIX вв.– М., 1955; Западов А.В. Поэты XVIII века. – М., 1984; Вступительная статья // М.М.Херасков. Избранные произведения. – Л., 1961; Поэзия Державина. Автореф. дисс. на соискание ученой степени доктора филол. наук. – 1959.

12 Западов А.В. Поэты XVIII века. – М., 1984; Вступительная статья // М.М.Херасков. Избранные произведения. – Л., 1961; Поэзия Державина. Автореф. дисс. на соискание ученой степени доктора филол. наук. – 1959.

13 Бочкарев В.А. Русская историческая драма (1800–1815). – Куйбышев, 1959.

14 Кәримуллин Ә. Татар тарихына килгән әдип // Мирас. – 1997. №4. – Б. 5-10; Һади Атласи һәм аның «Сөенбикә»се // Шәһри Казан. – 1991. – 3 август.

15 Ханзафаров Н. Сөембикә манарасына – ярым ай // Соц. Татарстан. – 1990. – 11 май; Йолдызлар иле вә Сөембикә манарасы // Идел.– 1994. – №5. – Б 50-54; Манара серләрен ачармы? // Шәһри Казан. – 1997. – 15 октябрь; Хан мәчете мәчетме? // Идел. – 1997. – №11. – Б. 8-9.

16 Хатипов Ф.Романнарда Сөембикә образы // Казан утлары. – 1993. – № 12. – Б. 152-159.

17 Әшрәфҗанов Х. Язучы һәм тарих. – Уфа: «Китап», 1998. – Б. 78-85.

18 Галимуллин Ф. Сөембикә һәм Каракош шәүләсе // Шәһри КАзан. – 1993. – 4 сентябрь.

19 Зәкиев М. Татарларны гәүдәләндергән әдип // Әллүки. – 1997. – 20 июнь.

20 Садеков М.Р. Звучат лишь письмена (Татарский фольклор периода Казанского ханства в русских исторических источниках).– Казань: Изд-во «Дом печати», 2006. – 128 с.

чыгып, ягъни милли әдәбиятларның кайсысының беренчеләрдән булып Сөмбикә темасына мөрәҗәгать итүен истә тотып, өч бүлеккә бүлеп бирелде.

XVI гасырның икенче – XIX гасырның беренче яртысында Сөембикә ханбикә турында иҗат ителгән әсәрләрнең күбесе рус авторлары тарафыннан иҗат ителгән. Беренчеләрдән булып бу темага Явыз Иван яуларыннан соң ук язылган «Казан тарихы» авторы мөрәҗәгать итә. Бу ярым әдәби, ярым тарихи хезмәттәге ханбикә шәхесенә һәм әдәби образына бирелгән характеристика һәм бәяләмәләр моннан соңгы гасырларда мәйданга чыгачак төрле жанрлардагы һәм төрле юнәлештәге милли-әдәби версияләр өчен нигез сюжет вазифасын үтәячәк. Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе Сөембикә турындагы әсәрләр чылбыры XVIII гасыр азагында иҗат ителгән М.М.Херасковның «Россиада» дигән эпик поэмасы белән башланып китә. Күләме һәм эчтәлеге, образлар системасының эшләнеше ягыннан бу поэма – рус әдәбиятында Сөембикә турында язылган әсәрләр арасында иң күләмлесе һәм әһәмиятлесе. Моннан соң XIX гасырның беренче яртысында С.Н.Глинка, А.Н.Грузинцев, Г.Р.Державин, М.С.Рыбушкин, В.И.Лапинның әсәрләре дөнья күрә.

Китапның икенче бүлегендә XX гасыр башы татар әдәбиятында ханбикә Сөембикә турында язылган әсәрләр игътибар үзәгенә куела. Билгеле булганча, Казан ханлыгы руслар тарафыннан яулап алынганнан соң, татар халкының әдәбияты һәм тарих фәне көчсезләнеп кала, торгынлык дәвере кичерә. Тарих фәне мөстәкыйльлеген югалта һәм ул жанр үзенчәлеген нык үзгәрткән хәлдә, ярым әдәби, ярым фольклор язмалары рәвешендә яшәвен дәвам итә[21].

XX гасыр башында татар халкы иҗтимагый-мәдәни яңару баскычына аяк баскач та, Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында күп санлы тарихи хезмәтләр языла. Моңарчы гасырлар дәвамында халык арасында Сөембикә турында таралган риваятьләр һәм бәетләр, тарихи җырлар һәм мөнәҗәтләр кабат актуальләшеп, яңа барлыкка килгән вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрә, халыкның милли аңын тәрбияләүгә хезмәт итә башлый.

1900–1918 елларда тарихи-әдәби хәрәкәтне тикшерү Казан ханлыгы чорының мәшһүр ханбикәсе Сөембикә шәхесенә игътибарның гаять дәрәҗәдә югары булуын күзалларга мөмкинлек бирде. Кыска гына вакыт аралыгында Сөембикә турында күп санда фәнни мәкалә, проза һәм сәхнә әсәрләре, шигырьләр барлыкка килә. Бу чорда Сөембикә тарихи шәхес һәм әдәби каһарман булып кына калмыйча, татар халкының милли азатлык идеалларын үзенә туплаган **символик образ**га әйләнә.

Шуны да искәртергә кирәк, XX гасыр башында Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында иҗат ителгән әдәби әсәрләрдә документаль башлангыч өстенлек ала. Тарихи темага язган авторларның күбесе «Казан тарихы», рус елъязмалары, рус тарихчыларына нигезләнеп, «тарих сөйлиләр», Казан тарихы һәм Сөембикә турында төрле эчәлектәге мәгълүматлар бирәләр. Сөембикә шәхесен әдәби образ буларак индивидуальләштерүгә, сәнгати яктан үткенләндерүгә әллә ни игътибар ителми. Әсәрнең сюжеты, образлар системасы да

---

[21] Госманов М. Галимнең дәрәҗәсе // Гайнетдин Әхмәрев. – Казан: «Хәтер», 2000. – Б. 7.

мавыктыргыч рәвештә вакыйгаләр өермәсенә алып керми; язучының сәнгати уйдырмасына да аз урын бирелә. Документальлеккә корылган тарихи дөреслек турында сөйләү, хикәяләү авторның төп бурычы итеп куела.

Китапның өченче бүлегендә XX гасыр уртасында Төркиядә яшәүче татар зыялылары һәм төрек авторлары тарафыннан Сөембикә турында язылган кайбер әсәрләргә анализ ясалды. Кызганычка каршы, Бөек Ватан сугышы елларында, аннан соңгы чорда да СССРда яшәгән татар язучылары үзләрен борчыган милли тарих, татар дәүләтчелеге белән бәйле темаларга язу мөмкинлегеннән мәхрүм иделәр. Төркиядә яшәгән һәм иҗат иткән милләттәшләребез генә халкыбызның дәүләтчелеген кайтару мәсьәләсен Сөембикә ханбикә образына мөнәсәбәттә ачыктан-ачык көн тәртибенә куя алды.

Төрек җирлегендә Сөембикә турында милли рух белән сугарылган әсәрләрнең барлыкка килүе, берьяктан диаспорада яшәүче татарлар арасында милли идеянең каннарына сеңүе, икенче яктан, 40–60 еллардагы төрек әдәбиятының үзендә дә тарихи тематиканың бик актуальләшеп китүе белән аңлатылырга мөмкин.

Икенче бөтендөнья сугышы төрекләрнең үз тарихларына булган мөнәсәбәтләрен үзгәртә. Сугыштан соңгы дәвердә төрек тарихи романының тематик төрлелеге илдә барган авыр идеологик көрәш нәтиҗәсе һәм төрек зыялыларының милли үзаңы үсүе белән бәйле иде[22]. Ул чорларда барлыкка килгән тарихи романнар төрек җәмгыятенең төрле сәяси, идеологик эзләнүләрен һәм яңа тарихка мөнәсәбәтен чагылдыралар. Әдәби әсәрләрнең бер өлеше Кемаль революциясе нәтиҗәләренең уңай якларын яктыртса, икенчеләре милли тарих – борынгы бабалар, ханнар, солтаннар тормышын идеаллаштыруны алга сөрә. Әдәбиятта төп игътибар Түлбәнтче Фәридун «Госман уллары» (1950), «Солтан Сөләйман Кануни» (1956), Шакир Зыя «Фатих солтан Мәхмүт» (1959), Кемал Таһир «Дәүләт ана» (1967) кебек авторлар тарафыннан язылган тарихи-биографик әсәрләргә юнәлтелә. Бу повесть һәм романнарның исемнәреннән күренгәнчә, аларның төп темасы госманлы империясе тарихын, аның солтаннары образларын яктыртуга, төрек халкының милли-азатлык хәрәкәте һәм милли каһарманнары язмышын гәүдәләндерүгә багышлана. Төрек авторларының тарихи әсәрләре белән янәшәдә татар һәм төрек язучылары тарафыннан ханбикә Сөембикә турында иҗат ителгән әсәрләр, фәнни-публицистик эчтәлекле мәкаләләр дә мәйданга чыга.

Төркия җирлегендә иҗат ителгән Сөембикә ханбикә образы гомумтөрки тарихның бөек каһарманы булып формалаша. Аның мөкатдәс образы татар халкының милли тарихындагы иң фаҗигале мизгелләр хатирәсе буларак изге ана, милли азатлык өчен көрәш-тартыш символы рәвешен ала. Төрки халыклар өчен исә ханбикә Сөембикә шәхесе гомумтөрки бердәмлек идеяләрен үзендә гәүдәләндергән тирән символик мәгънәгә ия булган мәһабәт образ рәвешендә калкып чыга.

---

[22] Сафронова Л.В. Из истории развития турецкого исторического романа // Советская тюркология. – Баку, 1984. – С. 26.

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

## XVI–XIX гасырлар рус әдәбиятында Сөембикә ханбикә образы

### 1. «Казан тарихы»

Рус әдәбиятында XVI гасырның икенче яртысы – XIX гасырның беренче яртысында Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләре турында дистәгә якын әсәр иҗат ителә. Бу катлаулы һәм фаҗигале вакыйгаләрне чагылдырган әсәрләр арасында «Казан тарихы»[1] (1564–65 елларда язылган) аеруча үзенчәлекле урын тота.

«Казан тарихы»ның тулы исеме – «Сказание вкратце от начала царьства Казанскаго и о бронех, и о победах великих князей московских со цари казаньскими, и о взятие царства Казани, еже ново бысть». Рус тарихчылары һәм әдәбиятчылары аның исемен кыскартып «Сказание о Казанском царстве», «История о Казанском царстве», «Казанский Летописец», «Казанская история» дигән исемнәр белән дә атап йөртәләр. Безнең китапта ул «Казан тарихы» дип аталачак.

«Казан тарихы»н өйрәнүне рус тарихчысы Василий Николаевич Татищевның (1686–1750) башлап җибәрүе мәгълүм. Ул аны үзенең «Россия тарихы» исемле хезмәтенең (История Российская; дүрт томы 1768–1784 елларда, тарихчы вафатыннан соң гына басыла) чыганаклары исемлегенә кертә. XX гасыр башында Г.З.Кунцевич, «Казан тарихы»н тикшереп, «История о Казанском царстве» (1905) исемле җитди хезмәт яза. Бу галим «Казан тарихы»н елъязмалардан хикәяләүгә күчүне башлап җибәргән ярым тарихи чыганак, ярым әдәби әсәр буларак өйрәнергә тәкъдим итә.

XX гасыр урталарында «Казан тарихы» текстын матбугатка әзерләгән Г.Н.Моисеева кереш мәкаләсендә әлеге әсәрнең авторлыгы, чыганаклары, Сөембикә ханбикә шәхесенең анда тарихи яктан һәм сәнгатьчә гәүдәләнеше турында шактый җентекле күзәтүләр ясый.

Татар әдәбият белемендә һәм фольклористикасында исә «Казан тарихы»н тикшерү эшен профессор Фатих Урманче башлап җибәрде. Галим Сөембикә ханбикә турында байтак кына мәкаләләр бастырды, «Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә» исемле китап та язды[2].

---

[1] Казанская история // Подготовка текста, вступит. статья и примечания Г.Н.Моисеевой; под. редакцией В.П.Адриановой-Перетц. –М.-Л.: Изд-во АН СССР., 1954.

[2] Урманче Ф. Кыйсса-и Сөембикә // Мәдәни җомга. – 1995. – 1 сентябрь; Сөембикә бәете // Казан утлары. – 1997. – №8. – Б. 161-170; «Казан тарихы»нда Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 27, 28, 30 июнь; Гүзәл ханбикәнең ачы язмышы // Ватаным Татарстан. – 1994. – 21 декабрь; Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный // Әллүки. – 1996. – 16 авг.; Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә. – Казан: Тат.кит.нәшр., 1997.

«Казан тарихы»ның авторы кем булу турында галимнәрнең әле бүген дә уртак фикергә килгәннәре юк. Төрледән-төрле фаразлар яшәсә дә, күпчелек тарихчылар, әдәбиятчылар аның авторы егерме ел гомерен Казанда үткәргән (1532–1552) дин әһеле Иоанн Глазатый булырга тиеш дигән фикерне алга сөрәләр. Башка төрле караштa торучылар да бар. Авторның үз сүзләре буенча, ул гөнаһлары өчен Казанга әсирлеккә эләгеп, Сафагәрәй ханга бүләк ителә («Грех ради моих случи ми ся плененну быти»)[3]. Хан бу кешегә әйбәт мөгамәләдә булганга күрә («И взят мя царь с любовию к себе служити, во двор свои постави мя пред лицем своим», 44 б.), аның якыннары да бу әсирне кирәгеннән артык саклыйлар, үз итеп өлгерәләр («...велможи же его паче меры брежаху мя», 44 б.). Әсәр авторы Казанда яшәгәндә татар телен үзләштерә, хәтта ислам динен дә кабул итә. Ханлык җимерелгәч тә, ул яңадан христиан диненә кайта, чукындырыла («Царь же мя крести, вере христове причте», 44 б.). Патшага турылыклы хезмәт иткән өчен, Иван аңа җир дә бүлеп бирә («…мало земли ми уделом дасть. И нача служити ему верно», 44 б.). Моңа нигезләнеп, Г.Н.Моисеева «Казан тарихы»ның авторы дин әһеле Иоанн Глазатый булмыйча, гади бер дворянин, аның Казанда рус дәүләтенең яшертен сәяси вазифаларын үтәүче кеше булу ихтималын да искәртә: «...выполнял какие-то ответственные поручения при сменявшихся казанских царях. ...и «удел», видимо, была награда за какие-то старые услуги»[4].

«Казан тарихы» авторы заманында аңа билгеле булган бөтен тарихи чыганаклардан – рус елъязмалары, хан ярлыклары, илчелек хатлары, разряд китаплары, кенәз һәм боярларның шәҗәрәләре; шулай ук Иван Грозный чорына караган «Царево государево послание...» һәм «Царственная книга» кебек хезмәтләрдән файдаланган[5]. Автор патша даирәсенә бик якын торган кешеләр генә кулланган «Летописец начала царства» һәм Иван Пересветовның публицистикасы белән дә таныш булган, дип яза Г.Н.Моисеева[6].

Моннан тыш автор Казанда яшәгәндә Сафагәрәй ханның үзеннән, аның якыннарыннан ишетеп белгән бай мәгълүматларны, шәхси күзәтүләрен дә чагылдырган («И слышах словом от самого царя изо уст многажды и от велмож его», 44 б.). Г.Н.Моисеева фикеренчә, «Трактовка возникновения Казанского ханства построена не на русских письменных или устных источниках, а на казанских преданиях и легендах правящей верхушки из среды татар»[7]. Әсәр тукымасында Казан татарларының бәетләре, риваятьләре чагылыш табу бу фикернең дөреслеген раслый булса кирәк.

Г.Н.Моисеева «Казан тарихы»н әдәби хикәя, В.М.Жирмунский әдәби-публицистик повесть дип саный. Автор исә үзе аны «яңа төр повесть» дип атый («Красныя убо новыя повести сия», 43 б.). Д.С.Лихачев фикеренчә, «Казан тарихы» – XVI гасыр рус әдәбиятының идеаллаштырылган биографизм чорына караган, елъязмалардан килә торган иске

[3] Казанская история. – М.-Л. – 1954. Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.
[4] Моисеева Г.Н. Автор «Казанской истории» // Труды ОДРЛ. – М.-Л., 1953. – Т.9. – С.280.
[5] Казанская история. – М.-Л. – 1954. – С. 44.
[6] Моисеева Г.Н. Автор «Казанской истории» // Труды ОДРЛ. – М.-Л., 1953. –Т.9. – С.284-285.
[7] Шунда ук. – С.281.

монументаль стильне экспрессив башлангыч белән кушкан, үзендә бер-берсенә капма-каршы булган принципларны, карашларны, теорияләрне художество элементлары белән бергә оештырган эклектик әсәр[8].

Рус әдәбиятының «икенче монументализм» дәвере сәхифәләрен ачып җибәргән «Казан тарихы»на беллетристик, публицистик рухта язылган бик күп тарихи һәм хәрби эчтәлекле әсәрләр тәэсир ясаган. Г.З.Кунцевич[9], Г.Н.Моисеева, Я.С.Лурье, А.С.Орлов, Й.Г.Нигъмә-туллина кебек әдәбиятчылар аңа патша Иван IV мөрәҗәгатьләре, «Сказание о князьях Владимирских», Нестор-Искандерның «Повесть о взятии Царьграда», «Повесть о разорении Рязани Батыем», «Александрия», «Троя тарихы» кебек әсәрләрнең йогынтысы булуын бил-геләп үтәләр.

XVIII гасырдан башлап В.Н.Татищев, К.Н.Бестужев-Рюмин, Г.Перетяткович кебек рус тарихчылары «Казан тарихы»н тарихи чыганак буларак файдаланалар. Ә XIX йөз башы галимнәре С.М. Соловьев, В.В.Вельяминов-Зернов, С.М.Шпилевский, Д.И.Иловайский һәм башкалар бу әсәрне тарихи чыганак буларак куллanудан баш тарталар, йә булмаса, аның белән бик сак эш итәргә чакыралар. Күренекле тарихчы М.Худяков та «Казан тарихы»ның тарихи дөреслектән ерак булуына, кирәгеннән артык автор фантазиясе белән баетылуына игътибар итә. С.Алишев[10], Р.Фәхретдинов[11], И.Измайлов кебек татар тарихчылары «Казан тарихы»на тарихи дөреслек җитмәү, тәнкыйди караш кирәклеге турында язалар. Ф.Урманче, «Казан тарихы»н рус елъязмалары белән чагыштырып, «…кайбер өзекләре дөреслеккә туры килә. Шулай да аңа җитди төзәтмәләр кирәк»[12], дигән фикердә тора.

Шулай да, «Казан тарихы» турында нинди генә каршылыклы фикерләр әйтелмәсен, ул – Казан ханлыгының руслар басып алганчыга кадәрге тарихын шактый гына тулы яктырткан бердәнбер чыганак булып тора. Моны галимнәр үзләре дә таныйлар. «История заключает в себе ряд сведений, которых нет в других источниках. Особенно ценны те, которые сообщаются на основании татарских источников»[13]. Казан татарларының бәетләренә, риваятьләренә, тарихи җырларына мөрәҗәгать итеп әсәр язу ул заман рус әдәбияты өчен яңалык булган. Бу ягы белән «Казан тарихы» рус елъязмаларыннан да, тарихи һәм әдәби повестьлардан да аерылып торган.

«Казан тарихы» рус җирләренең Батый хан тарафыннан басып алынуы турында хикәяләү белән башланып китә, ике дәүләт арасында еш кына булып торган сугышлар, үзара ызгышлар тарихы сөйләнелә. Исеменнән үк күренгәнчә, әсәрдә Казан ханлыгын, аның тарихын яктыртуга бик зур урын бирелә. Казан шәһәренең нигезе 1177 елда Болгардан

---

[8] Лихачев Д.С. Человек в литературе древней Руси. – М.: Наука, 1970. – С.97.
[9] Кунцевич Г.З. История о Казанском Царстве, или Казанский Летописец. Опыт историко-литературного исследования. – СПб., 1905. – 618 с.
[10] Алишев С. Тарихыбыз язылган, укып белергә кирәк // Татарстан яшьләре. – 1994.. – 8 февр.; Казанны алу // Шәһри Казан. – 2000. – 13 окт.
[11] Фәхретдинов Р.Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. – Казан: Мәгариф, 1996. – 209 б; аныкы ук. Сөембикә һәм Сөембикә манарасы // Азат хатын, 1990. – №10. – Б. 12-13.
[12] Урманче Ф. Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1997. – Б. 146.
[13] Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве. – СПб., 1905. – С.571.

килгән патша – Саин тарафыннан салына дип әйтелә. Казан Кремлендә археологлар ясаган ачышлар, алар тапкан акчалар Казан шәһәренең 1177 елдан күп элек нигезләнүе хакында сөйлиләр. Хәер, XX гасырның азагында язылган хезмәтләрдә Казан шәһәренең барлыкка килүе «Казан тарихы»ндагыча XII гасыр азагында Болгардан күчеп килгән Алтынбәк һәм Галимбәкләр исемнәре белән бәйләп яктыртыла иде.

Казан шәһәренең нindирәк урын-жиргә урнашуын яктыртуга, аның байлыкларын һәм матурлыгын күрсәтүгә «Казан тарихы»нда кайбер тасвирлар да багышланган: «Место пренарочито и красно велми, и скотопажитно, и пчелисто, и всяцеми земными семяны родимо, и овощами преизобилно, и зверисто, и рыбно, и всякого угодья много, яко не мощно обрести другаго такова места во всей Русской нашей земли» (47 б.).

XVI гасырның беренче яртысында рус дәүләтенең тышкы сәясәте Казан ханлыгына карата кискен үзгәреш кичерә. Моңа кадәр ике дәүләт арасында булып узган бәрелешләр вакытында руслар татарлар яшәгән җирләргә бернинди дә дәгъва белдермәгән булсалар, 1540 еллардан башлап, рус дәүләте Казан ханлыгын басып алу һәм аны үзенә буйсындыруны максат итеп куя. «Казан тарихы» авторы фикере буенча, Явыз Иван Казан ханлыгына каршы сугышны басып алу нияте белән түгел, ә рус халкы мәнфәгатьләрен күздә тотып, аларны урдалылар, «явыз татарлар» изүеннән, талау-кимсетүләреннән азат итүне, христиан динен һәм чиркәүләрне «нәҗесләүдән» коткаруны үзенең төп бурычы дип игълан итә. Чынбарлыкта исә рус хөкүмәтенең башка милләт халыкларын басып алу сәясәте чиркәүнең изге хәер-фатихасы белән башкарыла. «Казан тарихы» башыннан алып ахырына кадәр дини идеологиянең рус дәүләтчелеген ныгытудагы тәэсирен күрсәтү фикере белән сугарылган. Тарихчы И.Измайлов язганча, «обосновывается программа захвата Казани прямо и откровенно: «Да слышал про ту землицу, про Казанское царство... про нее говорят, применяют ее подрайской землей угодием великием»[14]. Димәк, башка дин тотучы халыклар – мөселман һәм мәҗүсиләрне буйсындыру, алар яшәгән «подрайский» җирләрне басып алу, православие динен тарату изге эш дип игълан ителә һәм рус җәмәгатьчелегенең барлык катламнары тарафыннан яклана.

Бу чорда христиан диненең дәүләт һәм халык тормышына йогынтысы никадәр зур булганын күз алдына китерү өчен Адам Олеарийның истәлекләренә мөрәҗәгать итү дә җитә: «..в его время всех церквей считалось до двух тысяч. Эта цифра вполне достоверна. У каждого пятого дома в Москве можно встретить часовню. Олеарий в указанное число включил и часовни»[15]. М.Худяков фикеренчә, 1542–1553 еллар – рус дәүләтенең вак дворяннар, сәүдә капиталы мәнфәгатьләрен күздә тотып, «клерикаль сәясәт» алып барган чоры. «Все реформы, – ди ул, – все вопросы практической жизни получают направление от высшего духовного авторитета...»[16]. Бу яулап алу, чукындыру сәясәтенең төп идеологы – Иван Пересветов, ә аны тормышка ашыручы Иван IVнең «рухи атасы» – митрополит

[14] Измайлов И. «Казанское взятие» и имперские притязания Москвы // Мирас, 1992. – №10. – С.57.
[15] Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве. – СПб., 1905. – С.227.
[16] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М., 1991. – С.125.

Макарий җитәкләгән хөкүмәт. Бөек мәмләкәтчелек идеяләре «Казан тарихы» авторына да зур йогынты ясый. Ул да «Мәскәү – Өченче Рим» дигән идеология тарафдары: «И возсия ныне стольный и преславный град Москва, яко вторый Киив, …и третий новый великий Рим» (57 б.). Кайчандыр варварлар, җирле халыклар тарафыннан җимерелгән Беренче Рим, төркиләр тарафыннан яулап алынган (1453) Икенче Рим – Константинополь (Истанбул) урынына «Казан тарихы» авторы да, басурманнарны (мөселманнарны) буйсындырып, «Мәскәүне Өченче Римгә» әйләндерү турында хыяллана. Шул сәбәпле, китаптагы бөтен вакыйгаләр дини-фәлсәфи күзлектән чыгып анализлана, барлык җиңүләр һәм уңышсызлыклар Аллаһының ихтыяры нәтиҗәсе итеп аңлатыла. Мәсәлән, Зөя каласы салыныр алдыннан Иван Грозныйның төш күрүе, изге Сергий Радонежский ярдәме белән бәйле могҗизалы савыгу күренешләре, рус солдатларына һәм патша Иванның үзенә Никола-чудотворец образының могҗизалы ярдәм итүе, көрәзәчеләрнең Казан алыначак дип юраулары – болар барысы да православие диненең бөеклеге турындагы фәлсәфә белән бәйләп карала. Шулай ук Казан алыныр алдыннан күкләрдән искәртүче «яхшы фал» – «знамение» килү дә яулап алу сәясәтен аклауга һәм яклауга хезмәт итә. Имеш, мондый илаһи кисәтү Иерусалим һәм Царьград (Константинополь) алыныр алдыннан да күренгән була.

Казан ханлыгын тарих сәхнәсеннән алып ташлаган очракта гына рус дәүләте тулы мөстәкыйльлегенә ирешә алачагын Иван яхшы аңлый. Алтын Урдага салым түләп яткан урыслар Казанга да Батый хан заманнарындагыча («по уставу древних времен»)[17] салым түләүне дәвам иткәннәр. Шуңа күрә дә әсәрдә Казан ханлыгы Алтын Урданың варисы («Казань – новая Орда», 53 б.) итеп карала һәм бу фикер моннан соң язылган рус әдәбияты әсәрләрендә дә кабатланып килә (М.М.Херасков, С.Н.Глинка, А.Н.Грузинцев һ.б.).

«Казан тарихы» әсәренең төп каһарманнары – Иван белән Сөембикә. Әсәрдә алар турында байтак мәгълүмат бирелә. Анда Иванның тәхеткә утыруы, үзен бөтен Россия патшасы итеп танытуы, «мятежник» боярларга каршы аяусыз көрәше, үзенчә гадел идарә урнаштыруы тасвирлана. Иң беренче булып Иван Казанны алу өчен хәзерлек эшләре башлап җибәрә. Бу максатка ирешү өчен хәрби системаны үзгәртү, аны камилләштерү өстендә эшли башлый: даими армия булдыра, утлы корал белән коралланган яшь солдатлар корпусын оештыра, артиллерия «наряд»ын – тупчыларны көчәйтә.

Иван IV әсәрдә мөмкин булган бөтен уңай сыйфатларны үзенә туплаган идеаль образ итеп бирелә. Ул – акыллы һәм гадел идарәче («велми премудр», 73 б.), батыр сугышчы һәм хәрби җитәкче («…и храбр, и серд, и крепкорук, и силен телом, и легок ногами, аки пардус», 73 б.). Боларның барысы да урта гасыр рус әдәбияты өчен хас эпитетлар, чагыштырулар ярдәмендә сурәтләнә. Төрек солтаны да Иванның чикләнмәгән хакимиятенә, акылына мактау сүзләре яудыра; рус дәүләтенең данын һәм көч-куәтен танып, хәтта аннан шүрләп, хат-мәдхия җибәрә: «Воистинну ты еси самодержец и царь мудрый, верный и волный божий

[17] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М., 1991. – С.120.

слуга. Удивляет бо нас и ужасает превеликая твоя власть, и слава» (73 б.). Урта гасыр рус әдәбиятындагы традиция буенча, андагы тарихилык принцибы геройны, аерым алганда, тарихи шәхесне бары тик уңай яктан гына тасвирлауны таләп итә иде. Шуңа күрә «Казан тарихы» авторы да Иванны һәрьяктан идеаллаштырып гәүдәләндерә.

Хәер, дошман як ханбикәсе дип исәпләнгән Сөембикә образын сурәтләгәндә дә, «Казан тарихы» авторы якты буяулардан, уңай бәяләмәләрдән баш тартмый. Ул аның искиткеч гүзәллегенә һәм акылына мәдхия җырлый, «красносолнечну, мудру» (78 б.) дип атый. Андагы кебек чибәрлекне Казан кызларында гына түгел, Мәскәүнең бояр һәм кенәзләре хатын-кызлары арасында да очрату кыен булган дип яза автор: «Бе бо царица образом красна велми и в разуме премудра, яко не обрестися такой лепоте лица ея во всех в казанских женах и в девицах, но и во многих в руских на Москве, во дщерях и в женах в болярских и во княжнах» (99 б). Сөембикәнең матурлыгы, акыллылыгы, зирәклеге, гадел ханбикә булуы турында кат-кат диярлек әйтеп үтелә. Сафагәрәй ханның биш хатыны булып, шулар арасында Сөембикә иң яратканы, иң сөеклесе була: «...и всех любимее первых жен» (78 б.).

«Казан тарихы» авторы хикәяләвенә караганда, Сафагәрәй хан үзе үлгәндә ил белән идарә итү эшләрен улы Үтәмешгәрәйгә васыять итеп калдыра. Ә Сөембикә исә, улы бераз үсеп җиткәнчегә кадәр, биш ел буе ханлык белән идарә итеп тора (92 б.). Чынлыкта исә, ул Казан ханлыгы белән биш ел түгел, ә бары тик 1549–1551 елларда гына идарә итә[18]. Ханның башка хатыннары исә, һәммәсе дә үз аталары йортларына кире кайтып китәргә тиеш булалар.

Сөембикә Казан ханлыгы белән бик авыр тарихи шартларда идарә итә башлый. Төрле сәяси фирка-төркемнәрнең каршылыгы; русларның кыска гына вакыт эчендә ныгытылган Зөя кальгасен салып куюлары; моның нәтиҗәсе буларак, Тау ягы чирмешләренең (мариларның) рус патшасына баш иеп, Россиягә кушылулары ханлык белән идарә итүне бик тә катлауландыра. Казан эчендә тәхет өчен киеренке сәяси көрәш, төрле ызгыш-талашлар башлана, кечеләр олылар сүзләрен тоту түгел, аларны тыңлаудан да баш тарталар. Тиз арада үсеп чыккан Зөя каласын күреп торган казанлылар аптырап, куркып калалар: «Что сотворихом? почто не убрегохомся? как уснухом? как оболсти нас Русь лукавая, аки во сне?» (92 б.) дип, Сөембикә белән киңәшәләр. «Казан тарихы» авторы шушы урында Сөембикә образын дәүләт эшлеклесе һәм сәясәтче буларак та гәүдәләндерә башлый.

Сөембикә, «аки лютая лвица», үзенең дәүләтен саклап калу, аны ныгыту эшенә керешә. Ханбикәне арыслан образы белән чагыштыру соңрак башка рус һәм татар авторлар әсәрләрендә дә очрый. Алар аша бу образ Наилә Бинаркның төрек телендә язган хезмәтләренә дә үтеп керә. Сөембикә Казанны ныгытырга, төрле яклардан гаскәр тупларга боерыклар бирә; Әстерхан, Нугай, Азов һәм Кырымга ярдәм сорап чапкыннар җибәрә; гаскәрне һәм каланы ныгыту өчен дәүләт казнасыннан тиешле алтын һәм көмешләрне дә тота: «Она бо, аки лютая лвица,

[18] Урманче Ф. «Казан тарихы»нда – Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 27 июнь.

неукротимо рыкаше, веляше им в Казани осаду крепити и вои многих на помощь отвсюду збирати, отколе поидут к ним, от Нагаи, и от Асторокани, и от Крыма, и от Азова, аще недостанет столиких своих вои на противление Руси, и давати им царьския казны злата и сребра без скупости наима, елико хотят», (93 б.). Русларны Казан ханлыгы җирләреннән куып җибәрү, Зөя каласын татарлар кулына төшерүне ханбикә үзенең төп бурычы итеп куя.

«Казан тарихы» авторы фикеренчә, казанлылар Сөембикә боерыкларын үтәмиләр, фикри бердәмлек булмау аларны җиңелүгә этәрә: «и бысть между всех пря и несогласие во едину мысль, и за сие погибоша», (93б.). Казанлыларның бер төркеме Мәскәү яклы булып, икенчеләре Кырым ягында торып, Казан тәхетенә Сафагәрәйнең олы улы Бүләкгәрәйне утыртырга телиләр. Ләкин Сөембикә һәм аның Нугайдагы туганнары тәхетне үз кулларында саклап калу уе белән яшиләр. Бу четерекле сәяси төенне җайлырак чишү бурычы Сөембикәгә йөкләнә. Сафагәрәй үлеп, өч ай үткәч кенә, Казанда хөкүмәт оешып җитә, аның белән идарә итү вазифасы Кырымнан килгән хәрби отряд җитәкчесе Кошчак угланга йөкләнә. Яңа оешкан хөкүмәтне сыйфатлап, М.Худяков болай ди: «Соединение в одном лице высшей должности в государстве с командованием ханской гвардии является весьма характерным для эпохи регентства царицы Сююн-Бике»[19]. Русларга каршы сугышларда берничә тапкыр батырлык күрсәткән, Сафагәрәй ханның сәясәтенә турылыклы булып калган шәхесне ханбикәнең үзенә якынайтуы, аның белән киңәш тотуы - табигый күренеш, билгеле. Батыр һәм оста хәрби җитәкче булган Кошчакны автор «Муж зело величав и свиреп» (93 б.») дип сыйфатлый. Кошчак углан илдә берникадәр дәрәҗәдә тынычлык урнаштыра ала. Ләкин Сөембикә һәм Кошчак арасында барлыкка килгән мәхәббәт турындагы уйдырма хәбәр Казанда гына таралу түгел, Мәскәүгә кадәр килеп ишетелә. «Казан тарихы» авторы сүзләре буенча, Кошчак, Үтәмешгәрәйне үтереп, Сөембикәгә өйләнеп, үзе хан булырга җыена дигән гайбәт сүзләре дә тарала. Сөембикә дә Кошчакның хисләрен җавапсыз калдырмый имеш: ялкынлы мәхәббәт хисләреннән исергән Сөембикә аз гына да Кошчакның йөзен күрмичә яши алмый диелә («не можаше ни мало быти без него, не видя лица его, огненными плотми распалаема», 93 б.). «Казан тарихының» «азгын мәхәббәт» турындагы бу өлешен авторның уйдырмасы дип аңларга кирәк. Бу турыда М.Худяков түбәндәге фикерне әйтә: «Есть основания не доверять этому сообщению, и в нем легко можно видеть не исторический факт, а обычный вымысел автора, обладавшего неистощимой фантазией»[20]. Академик Д.С.Лихачев та нәкъ менә XVI гасыр рус әдәбияты әсәрләрендә тарихи шәхеснең холкын, характерын халык телендә йөргән төрле имеш-мимешләргә нигезләнеп аңлату, шуңа нигезләнеп әсәрләр язу күренгәли башлый дип аңлата[21].

Рус елъязмаларын тикшергән рус галиме Г.З.Кунцевич аларда Кошчак угланның, зур ихтыяр көченә ия булган шәхес булганлыгы һәм Мәскәүгә озатылып, анда җәзалап үтерелүе

---

[19] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М., 1991. – С.118.
[20] Шунда ук.– С.118.
[21] Лихачев Д.С. Человек в литературе Древней Руси. – М.: Наука, 1970.

турында гына мәгълүмат бирелә дип яза[22]. Димәк, күренекле галимнәр әйткән бу фикерләргә таянып, тарихчы М.Худяков белән фольклор белгече Ф.Урманче фикерләрен куәтләп, без дә Сөембикә ханбикә белән Кошчак углан арасындагы бу «азгын мәхәббәт» турындагы «гайбәт башка һәм җитди чыганаклар белән расланмый»[23], дип әйтә алабыз. Кызганычка каршы, Сөембикә белән Кошчак мәхәббәте турындагы бу уйдырма, гасырлар аша үтеп, бүген дә рус телендә иҗат ителгән әсәрләрнең сюжетына, вакыйгалар агышына нигез итеп салына.

Ханбикә Сөембикәнең Кошчак угланга гашыйк булуы «Троя хикәятләре»ндәге гүзәл Еленаны, аның язмышын хәтерләтә. «Казан тарихы»ндагы Сөембикә ханбикәнең язмышы күп ягы белән Елена язмышына аваздаш.

Сөембикә ханбикә һәм аның уң кулы Кошчак Казанны һәм ханлыкны саклап калу өчен кулыннан килгән бөтен эшне эшләсәләр дә, Иван җитәкчелегендәге руслар Казан ханлыгын басып алу планын эзлекле рәвештә алып баруларын дәвам итәләр: Казанга алып бара торган бөтен елга юлларын үз кулларында тоталар, каланы блокадага алалар һәм Казаннан ерак түгел бер урында Зөя каласын торгызып куялар[24].

Казан ханлыгының рус гаскәрләре божрасы эчендә калуы илдәге сәяси каршылыкны тагы да кискенләштерә, сәүдәләр туктала, башка җирләрдән ярдәм килүгә ышаныч та калмый. «Казан тарихы» буенча, Кошчак шәһәрне калдырып чыгып киткәннән соң, Казан морзалары, соңгы көнебез килеп җитте диеп куркып, руслар белән тату яшәүне күздә тотып, Шаһгалине үзләренә хан итеп чакыру, ә Сөембикәне аңа кияүгә бирү уена киләләр. Сөембикәнең атасы һәм туганнары, мондый фикерне куәтләп, бу хакта күп мәртәбәләр Явыз Иванга мөрәҗәгать итәләр. Йосыф мирза исә ничек булса да Казан тәхетенең кызы Сөембикә кулында калуын һәм нугайлыларның да Казан ханлыгы белән идарә итүдә катнашуын тели. Барысы да Шаһгалине Казанга хан итеп китерү, Сөембикәне аңа хатынлыкка бирү фикере белән яши башлый. Шаһгалигә кияүгә чыгып булса да, ханбикә ничек тә Казанда калырга, ил белән идарә итүдә катнашырга тели. «Казан тарихы» фикеренчә, Казанга хан итеп Шаһгалине китерү фикере Сөембикәгә дә охшый. Аның исеменнән казанлылар Шаһгали белән киңәшергә, сөйләшергә тиеш булалар: «...и поидоша от царицы болшие велможи и уланове, князи и мурзы казанския во Свияжский град ко царю Шигалею и к воеводам» (95 б.). Казанлылар, Зөя каласына барып, Шаһгалине Казанга хан булып килүен, ә Сөембикәне үзенә хатынлыкка алуын үтенеп сорыйлар: «…не мстиши нам, и царицу нашу возмешь за себе, то все царьство наше и со всеми нами повинна ти будет» (95 б.). Шаһгали, воеводалар белән киңәшеп, казанлыларның бу тәгъдимен кабул итә һәм Казанга хан булырга һәм Сөембикәне үзенә хатынлыкка алырга ризалаша.

Сөембикә, Кошчак, Шаһгали турында очы-очка ялганмаган мондый мәгълүматлар «Казан тарихы»нда шактый гына. Моны Сөембикәнең Шаһгалине агуларга җыенуы күренешендә дә сиземләргә мөмкин. Шаһгалигә кияүгә чыгып, ничек булса да, Казанда

---

[22] Кунцевич Г.З.История оКазанском царстве. – СПб., 1905. – С.336.
[23] Урманче Ф. «Казан тарихы»нда – Сөембикә // Ватаным Тататстан, 1995. – 27 июнь.
[24] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М.:Инсан, 1991. – С.129.

калырга теләгән ханбикәнең булачак ирен агулап үтерергә теләве логик яктан үзен аклап бетерми.

Дөрес, бөтендөнья фольклорында һәм әдәбиятында агулау мотивы – шактый киң таралган традицион бер әдәби алым. Ф.Урманче язганча, «ул борынгы грек мифологиясеннән башлап, төрки-монгол эпосы аркылы үтә һәм безнең мәшһүр «Идегәй» дастанына килеп җитә»[25]. Бу эпизодка «Казан тарихы» авторы татарларның «колак сөенчесе» дип аталган, ягъни кәләшләрнең кияүләренә бүләк итеп кием, түбәтәй, намазлык, кесә сәгате кебек әйберләр бирү йоласын нигез итеп алганга охшый. Шул ук вакытта Сөембикәнең Шаһгалигә җибәргән киеменең агулы булып чыгуы грек мифологиясендәге атаклы Медея образын да хәтерләтә.

Сирәгрәк булса да, агулы эчемлек эчерү мотивы рус халык әкиятләрендә һәм җырларында да күзгә ташлана. Мәсәлән, грекларның Олегны агулы ризык биреп үтерергә теләүләре турында рус халык җырларында да бәян ителә: «И вынесоша ему брашна и вино и не пря его; бе бо устроено с отравою»[26]. Рус, татар фольклорындагы һәм язма әдәбиятында шактый еш очраган бу алымнан «Казан тарихы» авторы да яхшы хәбәрдар булган, аннан үзенчә иҗади файдаланган.

Агулы ризык һәм кием җибәреп, үзен үтерергә теләгәне өчен ачуланган, ярсыган Шаһгали Сөембикәне Иван янына Мәскәүгә озатырга карар кыла: «И разгневася на ню царь, и ят царицу и к Москве посла ю, яко прелютую злодеицу, со младым лвищем, сыном ея» (96 б.). Казанлылар үзләре дә бөтен ханлык юкка чыкканчы, бер ханбикәне генә биреп котылыйк дип, Сөембикәне әсирлеккә жибәрергә ризалык бирәләр («...яко да не все царьство погибнет единыя ради жены. ...вправду она сего достойна изгнания», 96 б.).

Күренә ки, «Казан тарихы» авторы Сөембикәнең Казаннан җибәрелү сәбәбен ике дәүләт арасындагы сәяси көрәш нәтиҗәсе итеп түгел, ә бик гади генә – Шаһгали белән Сөембикә арасында килеп чыккан бер аңлашылмаучанлык дип кенә аңлата һәм «тарихи чынбарлыктан гомумән читкә китә һәм үзенең шовинистик карашлары басымы астында бөтенләй булмаган нәрсәләр турында сөйли»[27].

Тарихи фактлар бу вакыйгаләрны башкача аңлаталар. Кошчак углан каланы калдырып киткәч тә, ханлык белән идарә итү өчен вакытлы хөкүмәт төзелә. Ул тынычлык турында сөйләшүләр алып бару өчен, Мәскәүгә илчеләр җибәрә. Сөйләшүләр вакытында Иван казанлыларга өч төрле шартның үтәлүен мәҗбүр итеп куя:

1) Шаһгалине хан итеп билгеләү;

2) Үтәмешгәрәй ханны, аның анасы Сөембикәне һәм кырымлыларны руслар кулына тапшыру;

3) бөтен рус тоткыннарын азат итү[28].

---

[25] Урманче Ф. «Казан тарихы»нда – Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 28 июнь.
[26] Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве. – СПб, 1905. – С.376.
[27] Урманче Ф. «Казан тарихы»нда – Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 28 июнь.
[28] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: Инсан, 1991. – С.135.

Казан шәһәрен алганчы ук, Явыз Иван Сөембикәнең руслар кулына тапшырылуын таләп итә. Г.Н.Моисеева язганча, «Иван IV дал согласие вести переговоры при условии выдачи казанского царя и царицы и «крымцев всех достальных и детей их»[29].

Безнең көннәрдә күп кенә кешеләрдән «менә, сатлыкҗан, куркак татар ирләре Сөембикәне русларга үзләре биреп җибәргәннәр» дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Татарның асыл затлары ничә еллардан бирле Казанда яшәгән, халыкның сөекле ханбикәсен үз теләкләре белән русларга биреп җибәрмәгәннәр, билгеле. Г.З.Кунцевич кебек абруйлы галим дә бу турыда искәртүне кирәк дип тапкан: «...казанцы, при условии брака сами первые не отдавали царицу Москве»[30]. Сөембикәне руслар кулына тапшыру, Мәскәүгә озату Явыз Иван тарафыннан куелган катгый шарт булып торган. Равил Фәхретдинов та шул ук фикерне әйтә: «Русское правительство, – ди ул, – потребовало принять в Казань ханом Шах-Али, а Сююмбике со своим сыном отправить в Москву. В случае невыполнения казанцами этого договора и немедленноно ввести в Казань войска»[31].

Явыз Иван Сөембикә кебек шәхеснең халык арасында да, башка дәүләтләрнең идарәчеләре арасында да тоткан абруеның никадәр зур булганлыгын яхшы аңлаган. Шуңа күрә дә ул Мәскәүгә солых сорап килгән татар илчеләренә Сөембикәнең русларга тапшырылуын мәҗбүри шарт итеп таләп итә алган. Иван Казан ханлыгы белән тартышның әле моның белән генә бетмәячәген сизенгән. Казанда калдырган очракта Сөембикәнең русларның басып алу сәясәтенә каршы торырлык, бөтен төркиләрне бер байрак астына туплый алырлык көчкә ия булганлыгын рус патшасы бик әйбәт аңлаган. Атасы Йосыф мирза да кызы Сөембикәгә зур ышанычлар баглый, берничә тапкыр кызының атасы йортына кире кайтарылуын сорап, Иванга хатлар да яза. Соң булса да, тарих тәгәрмәченең кая таба хәрәкәт иткәнлеген абайлап өлгергән Йосыф мирза, кызы Сөембикәнең зур сәяси көчкә ия булуын аңлый башлый: «Для борбы с Русским государством нужно знамя, и Юсуф видел его в бывшей царице Сумбеке», дип яза Г.Н.Моисеева[32]. Атасының үтенечләренә дә карамастан, Иван Сөембикәне Казан тәхетендә калдыру түгел, аны хәтта Нугай иленең башкаласы Сарайчыкка да җибәрми, Мәскәүдә үз янында тота: «Иван Грозный понимал, какой вред может принести Сумбека, если ее отпустить в Сарайчик»[33]. Ханбикәнең Шаһгалигә хатынлыкка бирелүе дә Казан ханлыгы алынгач, тәхет тирәсендә ыгы-зыгылар бераз сүрелә төшкәч кенә мөмкин була.

Шигалей, ягъни Шаһгали «Казан тарихы» әсәрендә уңай образ итеп бирелгән. Яшьтән үк русларга тугрылыклы хезмәт иткән бу Касыйм ханы ничә мәртәбәләр Казанга хан булып килсә дә, татарлар аны «сатлыкҗан» итеп кенә кабул итәләр. Шаһгали Иван патшага рус воеводаларыннан да тырышыбрак хезмәт итә, аларга караганда да тугрылыклы булып кала:

---

[29] Моисеева Г.Н. Казанская царица Сююн-Бике и Сумбека «Казанской истории» // ТОДРЛ. – М.-Л.: АН СССР, 1956. – Т.12. – С.180.
[30] Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве. – СПб., 1905. – С.371.
[31] Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа и Татарстана. – Казань: Магариф, 2000. – С.228.
[32] Моисеева Г.Н. Казанская царица Сююн-Бике и Сумбека «Казанской истории» // ТОДРЛ. – М.-Л.: АН СССР, 1956. – Т.12. – С.184.
[33] Шунда ук. – С.184.

«яко ин никто же таков во всех царех служащих самодержцу, и вернейше везде верных наших князей и воевод, служаще нелестно, за хрестияны страдаше весь живот свой до конца» (138 б.).

Җаны-тәне белән русларга хезмәт иткән бу кешенең кыяфәтен тасвирлаган тарихи чыганаклар да сакланып калган. Урыс елъязмачысы аны болай тасвирлый: «Оный Шеяль (Шаһ Гали) зело был взору страшного и мерзкого лица и корпуса, имел уши долгие, на плечах висящие, лице женское, толстое и надменное чрево, короткие ноги, ступни долгие, скотское седалище». Сигизмунд Герберштейн Шаһ Галине инглиз бульдогы белән чагыштыра[34]. Адам Олеарий Шаһгалинең милли сәяси кыйбласы турында түбәндәге күзәтүләрен китерә: «Хотя этот человек и был татарской нации, однако, он все-таки был более люб, привязан и верен московскому великому князю. Татары были недовольны им»[35].

«Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур» исемле китабында профессор Й.Г.Нигъмәтуллина «Казан тарихы»н өч бүлеккә бүлеп тикшерә. Аныңча, Сөембикәнең әсир ителүенә һәм Казанның руслар тарафыннан камалуына кадәрге урыннар беренче бүлекне тәшкил итә. Сөембикәнең ире Сафагәрәй кабере янында елау-сыктавын, аның Казан каласы белән саубуллашу турындагы юллары беренче бүлекнең кульминацион, эмоциональ киеренке рухта язылган өлеше дип әйтеп була.

Борынгы рус әдәбияты әсәрләрендә еш очрый торган елау-сыктаулар (плачи) геройның психологик халәтен гәүдәләндерүдә аеруча зур әһәмияткә ия: «Слезы, рыдания, плачи – обычны в изложении исторических событий», ди Д.С.Лихачев[36]. «Казан тарихы»нда елау-сыктауларның өч төре чагылыш тапкан. Казан халкының сөекле ханбикәсе белән саубуллашып елавы – шуларның беренчеседер. Сөембикәне Мәскәүгә алып китәр өчен Казанга воевода Василий Серебряный (тарихи чыганакларда Петр Серебряный. – *И.Р.*) җитәкчелегендә 3000 кораллы сугышчы һәм 1000 укчы килә. Рус воеводасының «сине алырга килдек, Казан ханбикәсе» («волная царица казанская», 97 б.), дигән сүзләренә Сөембикә: «Тәңренең иреге, Мәскәү патшасының теләгәне булсын», дип горур җавап бирә дә янында басып торучы кол-кәнизәкләр кулына һуштан язып егыла. Бу хәбәрне ишетүгә сарайда булган бөтен халык кайгыдан таштай катып кала, ә аннан аңына килеп елый башлый: «…и пусти глас свой с великим плачем и подвизающе с собою на плач и то бездушное камение», (97 б.). Хатыннарның һәм гүзәл кызларның битләрен тырнап, чәчләрен йолкый-йолкый, кулларын тешли-тешли елавы хан сараена кадәр ишетелә. Елауга түрәләр, аксөякләр дә кушылып, бөтен хан сарае елау-сыктау белән тула. Бу кайгылы хәбәр казанлылар арасында тиз арада таралып өлгереп, халык та хан сараена килеп, бу елауга кушыла. Яраткан ханбикәсен югалтудан курыккан казанлылар, кулларына ташлар алып,

---

[34] Ризаэтдин Фәхретдин. Казан ханнары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – Б. 126.
[35] Олеарий Адам. Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию и обратно. – СПб., 1906. – С.370.
[36] Лихачев Д.С. Человек в литературе древней Руси. – М.:Наука, 1970. – С.87.

Сөембикәне алырга килгән русларны кыйнап ташларга җыеналар. Ләкин Казан башлыклары халыкны зур фетнәгә илтүче бу адымнан тыеп калалар.

Сөембикәгә юлга хәзерләнү өчен ун көн вакыт бирелә. Бу ун көн эчендә казнада булган алтын, көмеш, дары, зиннәтле савыт-саба, урын-җир, ханлыктагы кием-салым, хәрби коралларның барысының да исәбе алынып, унике көймәгә тутырыла һәм яңа төзелгән Зөя каласына таба озатыла: «...и высла ис Казани преже царицы со инем воеводою в новыи град» (98 б.).

Елауларның икенчесе – Сөембикәнең Казаннан китәр алдыннан ире Сафагәрәй кабере белән елап саубуллашуы. Аның бу сыктавы борынгы төркиләрнең сугышларда ирләрен югалткан, тол калган хатын-кызларның битләрен тырнап, чәчләрен йолкып, бәргәләнеп, такмаклый-такмаклый елауларын хәтерләтә. «Казан тарихы»ндагы Сөембикә сыктауларын тәрҗемә иткән, аларны тикшергән галим Ф.Урманче «Сөембикә елауларының гаять тә югары дәрәҗәдә торган әдәби әсәрләр булуы»[37] турында әйтеп үтә. Сыктау текстының эчтә-леген тикшергән М.Садеков андагы мотивларны «Казан тарихы» әсәренә татар бәетләреннән үтеп кергән дип аңлата: «Итак, основное содержание плача автор «Казанской истории» перенял явно из татарского баита»[38]. Бу фикергә өстәп шуны әйтәсе килә: төрле халыклар фольклорында һәм язма әдәбиятында очрый торган елау-сыктаулар геройның эчке кичерешләрен, психологик халәтен чиктән тыш арттырып, гиперболалар ярдәмендә бик тә экспрессив, эмоциональ сурәтләүгә корылган. Тематик яктан бу елауларда төрле милләтләр, хәтта бер-берсе белән бөтенләй аралашмаган халыклар өчен дә уртак моментларны күзәтергә була. В.П.Адрианова-Перетц язганча: «В плачах самых разнообразных народов, никак между собою не связанных общением, повторяется просьба к умершему встать, сказать еще хоть слово, посмотреть на своих близких; высказывается желание лучше самому умереть, чем хоронить близких, лучше не родиться, чем переживать такое горе; повторяются вопросы – зачем покинул нас, чем был недоволен; обращаются молиться за покинутую семью, и.т.»[39].

Рус галимнәре (Г.З.Кунцевич, Г.Н.Моисеева, Я.С.Лурье, А.С.Орлов) «Казан тарихы» әсәрендәге Сөембикә сыктавының тематик һәм образлылык ягыннан Александр Македонскийның хатыны Роксана, Дмитрий Донскойның хатыны Евдокия елаулары белән бик тә охшаш булуына игътибар итәләр. Евдокия сыктавының XVII гасырга кадәр рус язучылары өчен патша хатыннарының кайгы-хәсрәтләрен сурәтләүдә үрнәк, өлге булып торуы билгеле[40]. Ф.Урманче Казан татарлары фольклорындагы Сөембикә сыктавының тексты безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән дип саный. «Казан тарихы» әсәрендә бирелгән «Сөембикә сыктаулары» – безнең халык иҗатында кайчандыр мөһим урын алып торган җанрның

---

[37] Урманче Ф. Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1997. – Б. 157.
[38] Садеков М. Плач ханши Сююмбике // Эхо веков. – 1998. – №1/2. – С.19.
[39] Адрианова–Перетц В.П. Слово о житии вел.князя Д.И., царя руськаго // Труды ОДРЛ. T.V. М.-Л.: АН СССР, 1947. – С.79.
[40] Шунда ук. – С.80.

бердәнбер үрнәкләре»[41], дип искәртә ул. Галимнең бу фикере белән килешергә кирәк. Сүз дә юк, Сөембикә сыктауларын типологик яктан рус фольклоры һәм әдәбияты үрнәкләре белән чагыштырырга мөмкин. Ләкин, ничек кенә булмасын, «Казан тарихы»ндагы сыктауларның нигезендә төрки-татар фольклоры ята. Аларның фаҗигале эчтәлеге, эстетик-этик яктан сәнгати гәүдәләнеше Сөембикәнең Казаннан аерылган мизгелләрендәге эчке кичерешләренә бик туры килә. Әлегә кадәр авторлыгы ачыкланып бетмәгән рус телендә беркетелеп калган бу елау-сыктаулар XX гасыр башы татар бәетләрендә, риваятьләрендә, мөнәҗәтләрендә шул ук хосусиятьләр белән кабат-кабат калкып чыгачак, халкыбызның тарихи хәтерен яңартуга, милли аңын уятуга һәм тәрбияләүгә хезмәт итәчәк.

Ике сәгать дәвам иткән бу елауда Сөембикә Сафагәрәйгә сөекле иренең гомере бик иртә өзелүе («Почто рано заиде красота твоя ото очию моею под темную землю!»), ә үзенең кулында сабый бала белән ялгыз калуы («Увы мне, меня вдовою остави, а сына своего сиротою младенца»), рус илендәге дошманнар кулына әсир итеп җибәрелүе («…сведому бываему в плен иноязычными воины на Русь»), ханбикәнең үзен дә хан янына каберлеккә алуын сорап ялваруы («Приими, драгий царю мой, юную и красную царицу свою»), бу фани дөньяда бер ялгызы гына калырга теләмәве («Несть никого же. Увы мне, кому тамо печаль мою возвещу») турында ачынып зарлана (98–99 б.).

Ханбикәнең сыктавын ишетеп торган, аның ачы фаҗигасен йөрәге аша үткәргән халык, углан, морзалар, хәтта аны алырга килгән воеводалар да елый башлыйлар. Хәлсезләнгән Сөембикәне күтәреп алгач та, ханбикәнең елаудан шешенеп беткән күзләрен, тырналудан канаган йөзләрен күргән воевода да каушап кала. Чөнки әкияти матурлыгы, акыллыгы, зирәклеге халык телендә дастан булып сөйләнелгән Сөембикәнең йөзенә үлем төсе кергән була.

Кайгы-хәсрәттән төсе-бите киткән ханбикәне рус воеводасы: «Әле син бик яшь, чәчәк аткан кызыл гөлдәй сылусың, әле генә өлгереп пешкән җиләксең»[42], дигән кебек сүзләр белән көйләп тә, юатып та карый («…ты же млада, аки цвет красный цветяся или ягода винная, сладости наполнена», 100 б.).

Ханбикәнең иң әйбәт сыйфатларын гына хәтерләгән халык («…и поминающе ея разум и премудрость», 100 б.) аның Мәскәүгә көчләп җибәрелү кайгысыннан җәй дәвамында канлы күз яшьләре түгә. Сөембикә төрле социаль катлаулар белән уртак тел таба алырлык, татар феодаллары һәм гади халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы үрнәк идарәче, гадел патша итеп тә сурәтләнә: «…и к велможам честь, и ко середним и ко обычным милование, и дарование, и ко всему народу брежение велие» (100 б.). Хушлашу вакытында бөтен халык Сөембикә каршында тезләнеп баш ия, сөекле ханбикәсен соңгы юлга озата. Ханбикә дә халкын олылап, баш иеп саубуллаша, хушлаша. Гаҗәп матур Казаны («предивная Казань, 43 б.»), аңа

[41] Урманче Ф. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1997. – Б. 152.
[42] Урманче Ф. «Казан тарихы»нда – Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 30 июнь.

тугрылыклы халкы белән саубуллашканны сурәтләгән битләр Сөембикә язмышының иң кульминацион, иң фаҗигале сәхифәләрен тәшкил итә.

Сөембикәне әле кайчандыр ул Идел буена ял итәргә чыгарга яраткан, очар кошлардай тиз йөрешле, алтын-көмешләр белән бизәлгән көймәсенә утырып алып китәләр. Ханбикәне көймәнең нәкъ уртасында бөтен-тирә як манзарасы күренеп торырлык итеп пыяладан эшләнгән, алтынлап чигелгән тукымалар белән бизәлгән бер бүлмәдә алып баралар. Аның белән кәнизәкләрдән 70 хатын һәм 30 кыз да алына. Барча халык: ирләр, хатыннар ханбикәне алып киткән көймә күздән югалганчыга кадәр озаталар. Сөембикәне Мәскәүгә озату күренешләре XVIII гасыр азагында язылган М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында яңа сурәтләр, алымнар белән кабат күз алдына китереп бастырылачак.

Ханбикәнең Казан шәһәре белән саубуллашып елавы үзе генә дә берничә бүлекчәдән тора. Монда Сөембикәнең шәхси фаҗигасеннән бигрәк, Казан ханлыгының үткән данлыклы юлына тарихи анализ ясала, «иҗтимагый-фәлсәфи фикерләргә мөрәҗәгать ителә»[43]. Ханбикәнең Мәскәүгә китүе, башыннан таҗы төшүе, аның белән бергә Казан ханлыгының да даны югалуы дип аңлатыла. Таҗсыз, хансыз ил ялгыз калган тол хатын (»…и яко жена худая вдовая явльшися осиротевши, 101 б.») һәм ауда үтерелгән җәнлек («..аки зверь, неимуще главы, 101 б.») белән чагыштырыла. Казан шәһәренең шөһрәте Вавилон һәм Рим дәүләтләренең данлыклы тарихы белән дә янәшә куела («…аще бо вавилонския стены имел еси и римския превысокия столпы», 101 б.). Бу юлларда Казан ханлыгына, аның данлыклы үткән тарихына мәдхия җырлау ишетелә. Сөенбикә фикеренчә, дәүләт иминлегенең нигезен шәһәр диварлары, күп санлы гаскәр, хәрби җитәкчеләр түгел, ә акыллы һәм гадел хан идарәсе генә тәэмин итә. «Кайда китте синең даның, шаның, бөеклегең, гүзәл кала?», ди ул. Бу урында үзеннән-үзе шагыйрь Габдулла Тукайның түбәндәге шигъри юллары искә төшә: «Ханнарга иреште хизан / Җылый, җылый бирделәр җан / Сөембикә дә Чыңгыз хан / Нә дәүләт калды да, нә шан!».

Күнелле бәйрәмнәрең, халкыңның моңлы җырлары, күңел ачулары, шат биюләре урынына хәзер инде халык ыңгырашуы, сыктавы, туктаусыз елавы гына калды, ди Сөембикә. Кайчандыр бал һәм шәраб елгалары ташкын булып аккан урыннардан хәзер инде халкым каны елга булып ага, күз яшьләре туктаусыз түгелә. Сөембикәнең, соңгы кешеңне үтереп бетергәнчегә кадәр урыс кылычы баш очыңнан аерылмаячак, дигән күрәзәчел сүзләре дә яңгырый. Бу юлларга мөнәсәбәттә рус галиме Н.Полевой Сөембикә елавының рус плачларына якын торуы турында искәртеп үтә: «Сумбека могла плакать еще хитрее и словоизвилистее; но это совсем не восточный язык: она не могла ни говорить о винных потоках, ни упоминать о Римских стенах и Вавилонских столпах»[44]. Чыннан да, галимнең бу фикере белән килешмичә булмый.

---

[43] Урманче Ф. «Казан тарихы»нда – Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 30 июнь.
[44] Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве. – СПб, 1905. – С.381.

Сыктавының соңгы өлешендә Сөембикә үзен кол итеп алып китүче русларга, патша Явыз Иванга, хатынлыкка алып булса да, үзен Казанда калдырырга теләмәгән Шаһгалигә нәфрәт катыш каргыш сүзләре яудыра. Сөембикәнең Казанын, халкын яратуы шулкадәр көчле ки, ул чит җирдә яшәү урынына әле күптән түгел ире белән бергә идарә иткән ханлыкта үлүне мең тапкыр кулайрак күрә. Мәскәүгә мәсхәрәле, хурлыклы әсирлеккә барасы килми ханбикәнең, шуңа да ул бу якты дөньяны калдырып китәргә дә әзер. Ләкин саклап торырга куелган сакчы аны бу адымнан тотып кала. Беркем дә, бернинди сүзләр дә Сөембикәне юата алмый. Ханлык таҗын һәм халкын югалткан ханбикә олы хәсрәт дәрьясына чума, Мәскәү юлының буеннан-буена елау-сыктау авазлары ишетелеп торгандай була.

«Казан тарихы» авторы хикәяләвендә гасырлар дәвамында ике күрше дәүләт арасында дошманлык яшәп килүе, русларның ата-бабалары бу җирләр өчен күп кан коюы турында сөйләнелә. Шул фикерне раслар өчен автор татарларны явыз дошманнар дип атый, аларны «поганый», «варвары» кебек эпитетлар белән сыйфатлый. Әсәрдә аеруча рус халкының күпләп үтерелүе, чиркәүләрнең талануы, хатын-кызларның мәсхәрәләнүе турындагы юллар бик тә тасвирлы һәм тәэсирле итеп бирелгән. Татарларны дала ерткычлары белән чагыштырып, тискәре итеп күрсәтергә омтылу рус укучысында аларга карата зур нәфрәт уятуга хезмәт иткән.

Гомумән алганда, «Казан тарихы» авторының татарларга карата мөнәсәбәте шактый катлаулы. Бер яктан, ул татарларны русларның кан дошманнары итеп сурәтли, икенче яктан, аларның акыллы һәм намуслы («премудрейшие и честнейшие», 43 б.) кешеләр булуын ассызыклый. Алай гына да түгел, урыны-урыны белән ул, гиперболик алымнарга мөрәҗәгать итеп, сугышта, батырлыкта бер татар сугышчысының йөз руска каршы тора алуын да искәртеп үза («...един бо казанец бияшися со сто русинов, и два же со двема сты», 131 б.). Аныңча, казанлылар руслар белән көрәштә җиңелергә мәҗбүр булсалар да, алар – батыр сугышчылар. Казан өчен барган сугыш эпизодларын тасвирлауга автор «О падении храбрых казанцев» дигән махсус бүлек тә багышлый (155–157 б.).

Казан каласын саклауда хатын-кызларның да ир-егетләр белән иңгә- иң торып, батырларча сугышулары, һәлак булганнарны алыштырулары турында автор бер соклану белән яза кебек: «...во убитых вместо и избежавших из града, прибираху высокорасленныя жены и девица силныя, и теми число наполняху и множаху и учеваху их копейному бою и стрелбе и битися со стены, и воскладаху на них пансыря и доспехи. Они же яко юноша бияхуся дерзостно, но страшиво естество женские, и мяхко сердце их...» (135 б.). Татар хатын-кызлары турында мондый уңай фикер әйтеп калдыру «Казан тарихы» авторы өчен үзенә күрә бер гуманистик адым булып тора.

Тарихи чыганаклар буенча, Казанга каршы оештырылгән хәрби яудан соң, Шаһгали Касыйм шәһәренә кайта. Аңа Казанны ирекле тапшыру вакытында, ягъни 1552 елның февралендә, руслардан нәрсә сораса, шуларның бөтенесен дә үтәргә сүз бирелә: «чего у

государя похочет, тем его государь пожалует». Казан яулап алынгач та, Шаһгалинең бөтен теләкләре үтәлә. Иван Мещера якларындагы бик күп авылларны Шаһгалигә бүләк итә һәм Сөембикә дә аңа хатынлыкка бирелә[45]. «Казан тарихы»нда Сөембикәнең Касыймда яшәү еллары, аның соңгы көннәре турында бик аз мәгълүмат китерелә. Алар түбәндәгеләр: Мәскәүгә алып кителгәч тә, ханбикәгә христиан динен кабул итәргә тәкъдим ителә, ләкин ул чукынудан баш тарта, соңрак Шаһгалигә кияүгә бирелә. Сөембикәнең гаебен истә тотып, Шаһгали аның тормышын тәмугъка әйләндерә. Соңгы көннәрен ул ялгызлыкта, караңгы бер бүлмәдә ябылуда үткәрә, олы яшьтәге ирле-хатынлы коллар аңа хезмәт итәләр. Улы Үтәмешгәрәй чукындырыла, исеме Александр дип үзгәртелә.

Йосыф морза, оныгы Үтәмешгәрәйнең һәм кызы Сөембикәнең кире Нугай иленә кайтарылуын сорап, күп тапкырлар Иванга мөрәҗәгать итсә дә, бу үтенечләрнең барысы да Иван тарафыннан кире кагыла. Үтәмешгәрәйне көчләп чукындырып, теленнән биздереп, ә Сөембикәне Шаһгалигә кияүгә биреп, Иван кырымлылар белән нугайлыларны Казан тәхете өчен тартышлардан мәңгегә ераклаштыра һәм Сөембикәне Касыйм шәһәрендә «ирекле» коллыкта тоту мөмкинлегенә ирешә.

«Казан тарихы»нда гәүдәләнгән Сөембикә әдәби образ буларак күбрәк эмоциональ, экспрессив сурәтләү чаралары аша бирелеп, аның характеры бик катлаулы шәхси һәм иҗтимагый сынаулар, авыр кичерешләр аша уза. Алда әйтеп үтелгәнчә, Иван тулысынча уңай образ булса, дошман як дип исәпләнгән ханбикә холкының «тискәре» яклары да күрсәтелә. Автор, тарихи дөреслектән ераклашып, Сөембикә тормышындагы кайбер вакыйгаләрга үзенең субъектив аңлатмасын бирә. Мәсәлән, Сөембикәнең рус яуларына каршы Кошчак белән киңәшеп хәрәкәт итүе шул заман Казан ханлыгы өчен бик тә әһәмиятле булган сәяси зарурият итеп түгел, ә кинәт кабынып киткән «азгын мәхәббәт» итеп аңлатыла. Ханбикәнең Казаннан китү сәбәбе дә Шаһгали белән ике арада килеп чыккан шәхси каршылык итеп кенә күрсәтелә. Боларның барысы да «Казан тарихы» авторы иҗат иткән Сөембикә образының реаль ханбикә шәхесенә туры килеп бетмәве турында сөйли. Әсәрдә Сөембикәнең сәясәттә тоткан урынына, аның дәүләт эшлеклесе буларак зирәклегенә шулай ук аз игътибар бирелгән.

Ләкин ничек кенә булмасын, «Казан тарихы» авторы дошман як патшабикәсе дип исәпләнгән Сөембикәне кара буяуларга гына төреп бирми. Ул ханбикәнең гүзәллегенә, акылына, батырлыгына мәдхия укый; казанлыларның аңа булган олы ихтирамын Мәскәүгә озату күренешендә бик тә тәэсирле һәм үтемле итеп тасвирлый. Елъязма авторы Сөембикәнең ил һәм халык язмышында тоткан урынының зур булуын читләтеп үтә алмый, аны таныргa мәҗбүр була. Татар тарихына объектив анализ биргән күренекле галим М.Худяков та «Казан тарихы» авторының Сөембикәне шул гасырның үзәк фигурасы итеп гәүдәләндерүе турында әйтеп уза: «Сююн-Бике выступает, как центральная фигура эпохи»[46].

---

[45] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: Инсан, 1991. – С.169.
[46] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: Инсан, 1991. – С.183.

Татар ханбикәләренең дәүләт белән идарә итүдә катнашулары табигый булып саналган, дип яза В.В.Григорьев: «Правление женщины не составляло какого-либо исключения в татарских государствах»[47]. Сөембикә дә акыллы һәм зирәк сәясәтче булган, Казан ханлыгының икътисади-хәрби куәтен нығыту буенча байтак эшләр башкарган. Шуңа күрә дә Сөембикәнең Казан ханнары арасында күренекле урынга куелуы тарихи яктан үзен һичшиксез аклый.

1521–1550 еллардагы Казан ханлыгы милли аңның югары үсеше, туган илне ярату хисләренең тулаем җитлеккән һәм формалашкан булуы белән характерлана[48]. Ләкин тарих сәхнәсенә дини һәм бик тә экспансив нигезгә корылган, үзәкләштерелгән рус дәүләте килү, аның яулап алу сугышлары нәтиҗәсендә Казан ханлыгы җимерелә, яшәешен туктатырга мәҗбүр була.

Рус галиме А.С.Орловның язуына караганда, «Казан тарихы» әсәре тәэсирендә русларда Казанны алу җырлары барлыкка килә; мәҗлесләр вакытында Иван IV аларны бик тә тыңларга ярата торган булган[49].

«Казан тарихы»нда сурәтләнгән Казанны алу вакыйгаләре, Иоанн (Иван), Сөембикә, Шаһгали, Кошчак, Кол Шәриф һәм башка тарихи шәхесләр турындагы мәгълүматлар дөнья әдәбиятында XX гасыр азагына кадәр яңадан-яңа сюжетлар, образлар иҗат итү өчен чыганак вазифасын үтәделәр. Андагы мәгълүматлар хаталары, төгәлсезлекләре белән бергә күп кенә фәнни хезмәтләрдә, әдәби әсәрләрдә гасырлардан-гасырларга кабатланып килә. «Казан тарихы» тәэсирендә рус әдәбиятында мәйданга чыккан беренче күләмле әдәби әсәр – М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы. Соңрак та «Казан тарихы» рус, татар, төрек һәм башка милләт халыклары әдәбиятларында ханбикә Сөмбикә турында дистәләгән поэзия, проза, драма әсәрләренең тууы өчен төп чыганак вазифасын үти торган таяныч нокта булып кала.

## 2. М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы

«Казан тарихы»нда сурәтләнгән Казан ханбикәсе Сөембикә образына бәйле вакыйгаләр XVII–XIX гасырлардагы рус әдәбиятында да чагылыш таба. Казан ханлыгының җимерелүе һәм Сөембикә язмышы турында әсәрләр язу бу чор рус әдәбиятында үзенә күрә бер традиция рәвешен ала. Бу тема шактый тулы гәүдәләнгән әсәрләрнең күренеклесе – М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы (1779).

Күпкырлы иҗат мирасы калдырган М.М.Херасков рус әдәбиятында мәгърифәтчелек идеологиясе хакимлек иткән чорда яши. Мәгълүм булганча, мәгърифәтчелек Европа һәм рус әдәбиятларында дүрт әдәби юнәлешкә һәм иҗат ысулына – классицизм, сентиментализм,

[47] Шунда ук. – С.182.
[48] Шунда ук. – С.123.
[49] Орлов А.С. Героические темы древней русской литературы. – М.-Л.: АН СССР, 1945. – С.116.

романтизм, реализмга нигез булган[50]. Рус әдәбият белемендә М.М.Херасков исә классицизм юнәлеше вәкиле итеп карала. Классицизм үзенең бөтен эчтәлеге, пафосы белән рус дәүләтендәге абсолют монархия, дәүләтчелек идеяләрен ныгытуга хезмәт итә. В.В.Ванслов язганча, «Классицизм был органически связан с абсолютной монархией, с утверждением дворянской государственности. «...Классицизмом же он был назван потому, что ведущую роль в нем играли мифологические (классические) сюжеты»[51].

М.М.Херасковның «Россиада» исемле поэмасының нигезендә рус халкы тарихында һәм язмышында империя буларак оешу дәверен әзерләгән тарихи бер күренеш – Казан ханлыгын яулап алу вакыйгасе ята. Поэма ни өчен «Россиада» дип аталганын М.М.Херасков болай дип аңлата: «Воспевая разрушение Казанского царства со властию державцев Ордынских, я имел в виду успокоение, славу и благосостояние всего Российского государства, знаменитые подвиги не только одного государя, но и всего Российского воинства, и возвращенное благородство. Почему сие творение и Россиадою названо»[52].

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында үзәкләштерелгән рус дәүләтенең ничек итеп мәйданга чыгуын, Казан ханлыгының җимерелүен руслар өчен бөек бер борылыш һәм зур әһәмияткә ия булуын күрсәтү төп максат итеп куелган. Александр шигыре («александрийский стих») белән алты буынлы ямб рәвешендә язылган һәм 12 җырдан торган бу поэма түбәндәге юллар белән башланып китә:

Пою от варваров Россию свобожденну,
Попранну власть Татар и гордость низложенну[53].

Беренче юллардан ук русларның Казанны яулап алуы, Россияне «варварлар»дан азат итү, рус халкы өчен тыныч тормыш башлану («спокойных лет начало»), якты таң ату («светлая заря») итеп бәяләнә. Иван Грозный җитәкчелегендәге рус гаскәрләре тарафыннан Казан ханлыгының басып алынуын М.М.Херасков Россия дәүләтчелегенең һәм рус милләтенең киләчәктә үсеше өчен зур әһәмияткә ия булган тарихи вакыйга дип саный.

М.М.Херасков тарихи-героик эчтәлекле поэма жанрында тарихи дөреслек белән язучының фантазиясе аерылгысыз рәвештә бергә үрелеп барырга тиеш дип аңлый. Ул «Россиада»ны чын, тарихи вакыйгаларга нигезләнеп иҗат ителгән дип исәпли: «Повествование сие творение расположил я на исторической истине...» [54].

Чыннан да, автор шул замандагы тарих фәнендә билгеле булган, үзе таба алган тарихи материалларга, рус елъязмаларына нигезләнеп эш иткән. «...сколько мог сыскать печатных и письменных известий...»[55], дип тә искәртә ул. Өстәвенә, М.М.Херасков Казаннан да бик күп материаллар алдырган: «...присовокупил к тому небольшие анекдоты (кечкенә хикәяләр. –

[50] Валицкая А.П. Русская эстетика XVIII века. – М.: Искусство, 1983. – С.225.
[51] Ванслов В.В. Эстетика романтизма. – М.: Искусство, 1966. – С.195.
[52] Херасков М.М. Россиада. – СПб., 1895. – С.3.
[53] Херасков М.М. Россиада. – СПб., 1895. – С.7. Киләчәктә бу поэмадан өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.
[54] Херасков М.М. Избранные произведения. – Л., 1961. – С.179.
[55] Херасков М.М. Россиада. – СПб., 1895. – С.7.

*И.Р.*), доставленные мне из Казани бывшим Начальником университетских гимназий в 1770 году»[56]. «Россиада» поэмасында чагылыш тапкан тарихи мәгълүматлар язучының Казан тарихын шактый яхшы белүе хакында сөйли. Ләкин шул ук вакытта поэмада уйдырмага, вакыйгаләрне тасвирлаганда автор ихтыярына зур урын биргән. М.М.Херасковның укучыларга булган мөрәҗәгатен китереп үтик: «Но да памятуют мои читатели, что как в эпической поэме верности исторической, так в дееписаниях поэмы искать не должно. Многое отметал я, переносил из одного времени в другое, изобретал, украшал, творил и созидал»[57].

«Россиада» поэмасының «Казан тарихы»на нигезләнеп иҗат ителүе турында да әйтеп үтәргә кирәк. Моңа А.Западов дигән әдәбиятчы да игътибар итә: «В освещении фактов, – дип яза ул, – Херасков опирался на исторические источники, главным образом на «Казанский летописец», однако идейная концепция принадлежит автору и должна быть оценена по достоинству»[58].

«Казан тарихы» белән «Россиада» арасындагы охшашлык сюжет сызыгының, аерым образлар, сәнгати чараларның бирелешендә аеруча ачык күзгә ташлана. Мәсәлән, «Казан тарихы»нда әйтелгән байтак фикерләр, сөйләнгән вакыйгаләр, андагы әдәби алымнар М.М.Херасков поэмасында яңабаштан кабатлангандай була. Мәсәлән, рус халкының татарлар изүе астында яшәве, боярлар думасы җыелу, Явыз Иван җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Казанга таба юл алуы, мари, мордва халыкларының Иванга баш июләре һәм, ниһаять, Казанны алу өчен барган сугыш күренешләре, ике әсәрдә дә изге Радонежскийй образы бирелү, Сөембикә ханбикәнең ире Сафагәрәй һәм Казан каласы белән саубуллашуы, җылау-сыктау урыннары, таҗ образының сурәтләнеше «Россиада» поэмасының авторы билгесез дип исәпләнгән «Казан тарихы» әсәре тәэсирендә иҗат ителүен дәлилли.

М.М.Херасков Сөембикә образын сурәтләгәндә күпмедер дәрәҗәдә тарихи дөреслеккә туры булып калырга да тырыша. Шул ук вакытта ул, рус дәүләтчелеге һәм рус милли идеясе таләпләренә туры китереп, реаль ханбикә образына бөтенләй туры килмәгән сыйфатларны да тага. Моның шулай икәнлегенә Й.Г.Нигъмәтуллина да игътибар итә: «Нам представляется, – ди ул, – что М.Херасков в оценке «казанских событий» и исторических лиц, точнее, образа Сююмбике, менее объективен, чем автор «Казанской истории»[59].

«Россиада» поэмасында тарих һәм тормыш дөреслеген дә байтак табып була, авторның үз уйдырмасына да зур урын бирелә. Рус тәнкыйтьчеләре кайбер вакыйгаләрне реаль тарихтагыча сурәтләмәгән өчен М.М.Херасковны хата җибәрүдә, тарихны белмәүдә дә гаепләгәннәр: «Так от чего же происходит такая ошибка Хераскова? – От незнания истории», ди бер тәнкыйтьче[60]. Шулай ук ул М.М.Херасковның Алтын Урда белән Казан

---

[56] Херасков М.М. Избранные произведения. – Л., 1961. – С.179.
[57] Шунда ук. – С.179.
[58] Западов А. Вступит. статья // М.М.Херасков. Избранные произведения. – Л., 1961. – С.33.
[59] Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казан: Фән, 1997. – С.100.
[60] Россиада, как поэма ложно-классическая // Херасков М.М. Россиада. – СПб., 1895. – С.270.

ханлыгын бер дәүләт итеп күзаллавын һәм бутап язуын да тарихи дөреслектән читләшү дип саный: «Золотая Орда и Казанское царство – по его мнению – есть одно и тоже; оттого-то взятие Казани почитал он совершенным освобождением России от татарского ига»[61].

Казан ханлыгын Алтан Урда империясенең дәвамы итеп карауны «Россиада»га кадәр язылган «Казан тарихы»нда да күзәтергә мөмкин: «И нача изнемогати (во) время то и Великая Орда усиляти Золотая, и укреплятися вместо Золотыя Орды Казань – новая Орда...»[62]. Казан ханлыгын Алтын Урда варисы итеп карау, татарларны русларның мәңгелек дошманы итеп күрсәтү рус әдәбиятында шактый еш күзәтелә торган күренеш дияргә мөмкин. Г.Н.Моисеева сүзләре белән әйткәндә, «...переход от борьбы за освобождение от Золотой Орды к покорению ее наследника – Казанского царства»[63] рус тарихында дәвамлы тоташ бер чылбыр итеп күзаллана. Г.Кунцевич «Халык мәгарифе министрлыгы журналы»нда бу поэма уңае белән «Россиада» поэмасының нинди тарихи чыганакларга нигезләнеп язылуы турында әйтеп уза: «Можно предпологать не без основания, что он пользовался и Царственной книгой, и Степенной книгой и, может быть Курбским»[64]. Шуңа күрә дә М.М.Херасковны тарихны белмәүдә гаепләү урынсыз дип таба автор.

Классицизм әдәбияты мәгърифәтчелек идеологиясенә, аеруча аның акыл турындагы фәлсәфәсенә таяна. Классицизм дәверендә «әдәбиятта акыл культы урнаша, ягъни барлык нәрсә кеше башыннан уйлап чыгарылган һәм дәүләт мәнфәгатен яклый торган кагыйдәләр белән үлчәнә...»[65]. М.М.Херасковның «Россиада» әсәре дә шундыйрак дәүләти карашларны алга сөрә. Анда да, мәгърифәтче язучылардагы кебек, идеаллаштырылган уңай Иоанн образын һәм аның фикердәшләрен сурәтләүгә зур урын бирелгән. Аларның күбесе – тарихи җирлектән алынган, прототиплары булган реаль шәхесләр.

XIX–XX гасырларда язылган мәкаләләрдә «Россиада» поэмасының төп каһарманнары кемнәр булуы турында бәхәсләр күтәрелми. Тәнкыйтьчеләрнең барысы да әсәрнең төп герое булып Явыз Иван тора дип тәкърарлыйлар. Барысы да «Россиада» поэмасындагы Иван образының акыллы, батыр, христиан диненә тугрылыклы патша итеп гәүдәләнүенә игътибар итәләр. Дөрестән дә, әсәрдәге Иоанн, ягъни Иван образы классицизм әдәбияты кануннары буенча иҗат ителгән. Ул – акыллы һәм батыр патша. Иоанн һәрвакытта да үз иле, үз халкы турында кайгыртучанлык күрсәтә. Бу – аның өчен мәҗбүри канун: «Мой первый есть закон – Отечеству услуга» (34 б.). Өстәвенә, ул христиан диненә бик тә тугрылыклы. Автор бу хакта: «Глубоку мысль сию питай всегда о Боге» (173 б.).

«Россиада» поэмасында буеннан-буена рус дәүләте Казан ханлыгына, православие ислам диненә, Иоанн патша ханбикә Сөембикә образына каршы куеп сурәтләнә. Сүз дә юк, диннәр бәрелешендә һәрвакыт христиан диненә өстенлек бирелә. Руслар, христиан динен

[61] Шунда ук. – С.270.
[62] Казанская история. – М.-Л., 1954. – С.53.
[63] Шунда ук. – С.6.
[64] Кунцевич Г. «Россиада» Хераскова // Журнал Министерства народного просвещения. – 1901. – №11. – С.175-178.
[65] Нуруллин И.З. Әдәбият теориясе. – Казан.: Тат.кит.нәшр., 1977. – Б.82.

тотучылар башка халыкларга яктылык илтүчеләр итеп тасвирланалар. Шуңа күрә, христиан Иван, аның фикердәшләре, сугышчылары образлары кояш, ай, йолдыз, нурлар образлары белән чагыштырыла. Мәсәлән, Иоанның йөзе нурлар сибеп, галәмгә тереклек бирүче шәрык кояшына тиң:

Был солнцу Иоанн восточному подобен (23 б.).

Әсәрдә М.М.Херасков берничә урында Мөхәммәд пәйгамбәр һәм Корьән образларына да мөрәҗәгать итә. Алда әйткәнебезчә, ислам тәгълиматы, аның пәйгамбәре караңгылык символы итеп сурәтләнә. Мәсәлән, Казанга каршы беренче тапкыр сәфәргә чыккан Иоанн күз алдына Мөхәммәд пәйгамбәр үч алырга җыенган куркыныч елан кыяфәтендә килеп баса («Как страшный змий…; …дышало мщением», 151 б.). Ләкин автор Мөхәммәд пәйгамбәр авызыннан Явыз Иванга карата гаепләү сүзләре дә әйтә. Ул аның киләчәктә якыннарын, кайчандыр үзенә ярдәм иткән фикердәшләрен үтереп бетерәчәге; Россиянең тиранына әйләнәчәге, хәтта үз улын да үтерәчәге турында күрәзәчелек итә:

Владение твое во ужас превратится,
И будешь ближних ты и подданных страшиться;
Ты искренних рабов безвинно умертвишь;
Своим ты именем вселенну устрашишь;
Вельможы и народ тебя возненавидят,
Тираном нарекут, в тебе врага увидят;
Ты сына умертвишь!... (151 б.)

«Россиада» поэмасы белән танышып чыккач та, анда авторның Россия белән Казан ханлыгы арасындагы мөнәсәбәтләрнең, Иоанн белән Сөембикә эш-гамәлләренең христиан һәм ислам диннәре, яктылык белән караңгылык, изгелек белән явызлык тартышы итеп гәүдәләнүенә бик тә зур урын бирелгәнлеге ачыклана. Аллаһы Тәгалә ризалыгы һәм әмере белән яктылык, изгелек тарафдарлары булган христиан руслар җиңәләр, караңгылык тарафдарлары – мөселман татарлар тәмугъның – Аидның иң кызу түбән катламына – тартарга озатылалар.

Поэмада рус патшасы Иоанн үзенең һәр адымын акыл белән үлчәргә тырышучы, халкы өчен янып-көеп яшәүче, ә ханбикә Сөембикә исә аның киресе итеп тасвирлана. Сөембикә «коварная», «гордая», «развратная», «притворная», «лютая змея» эпитетлары белән сыйфатлана. Поэманың беренче җырында ук рус җирләренә килгән афәтләрдә, кан коюларда Сөембикә гаепләнә. Имеш, Алтын Урда яулары вакытындагы кебек, ул да руслар яшәгән җирләргә талаулар, үтерүләр, көчләүләр оештырган, Мәскәү бистәләрен утка тоткан, христианнарны кылыч аша үткәргән. Казандагы рус әсирләре каны да мәкерле Сөембикә аркасында түгелгән.

Уже велением коварныя Сумбеки

В Казани полились Российской крови реки (10 б.).

Россия кебек зур илнең үзен дә Сөембикә кан елгаларына батырган: «Я кровь российскую реками проливала» (42 б.) дип, автор аны казанлылар алдында мактандыра да. Имеш, Сөембикә дошман русларга бихисап корбаннар китерү бәрабәренә халкына да, үзенә дә, улы Үтәмешгәрәйгә дә руслардан ярлыкау сорый:

За жертвы таковы награды я хочу:

Народу, сыну я спасения ищу (43 б.).

Бактың исә, Сөембикә күрше рус дәүләтенә карата гына түгел, үз халкына – казанлыларга карата да арыслан кебек куркыныч һәм кансыз икән («Таков является свиреп и грозен лев», 49 б; «Как львица злобствует», 53б.). Күренә ки, ханбикәне арыслан белән чагыштыру да тискәре образ итеп сурәтләүгә хезмәт итә.

Сөембикә көндез дә, төнлә дә, өндә дә, төштә дә Казан ханлыгының җимерeләчәге, башындагы таҗының төшәчәге турында кисәтелә. Һәр урында аның колагына «Патшалыгыңнан каласың бит» дигән тавышлар да ишетелә. Күз алдына канлы йөзләр, туралган кеше гәүдәләре килә. Әмма бу кисәтүләрнең берсе дә ханбикәгә тәэсир итми. Ул патшалык дәрәҗәсен дә, тәхетне дә, таҗны да бары тик үз шөһрәте, үз шәхси мәнфәгатьләре өчен хезмәт иттерә. Казан халкы «Руслар килә, нишлибез?» дип чәчен йолкыганда да, Сөембикә дошманнарга каршы тору, булачак сугышлар, халык чуалышлары, хакимият тирәсендәгеләрнең хыянәте турында уйларга да теләми. Аның җанын мәхәббәт хисләре биләп алган. Ул Таврия кенәзе Османга үлеп гашыйк булган. Осман образының прототибы – Сөембикәнең сарай гвардиясе башлыгы Кошчак углан. Сөембикә «Халкыма, улыма котылу эзлим» дисә дә, үзе турында гына уйлый, ханбикәлек дәрәҗәсен генә ярата («любила царский сан»), үзе өчен генә яши.

Сөембикәнең матурлыгы да, арыслан кебек куркусыз булуы да – бары тик явызлык һәм бәхетсезлек чыганагы. Аның мәхәббәт хисләрендә яну-көюләре дә азгынлык күренеше итеп бәяләнә. Казан ханлыгының язмышы кыл өстендә торган вакытта да ул иле һәм хәтта үзе утырган тәхет, кигән таҗы турында уйламыйча («Забвен любезный сын, забвен венец и трон», 53 б.), азгын мәхәббәт хисләренә бирелә («Печальны следствия любви, любви развратной», 95 б.).

М.М.Херасков әсәрендә Казан ханлыгындагы тарихи шәхесләр образлары барысы да пычратылган, тарихи дөреслектән ерак торучы геройлар итеп бирелгән. Дин башлыгы Сәет кебек, ханбикә Сөембикәнең дә барлык адымнары, гамәлләре икейөзлелеккә корылган. Автор фикеренчә, Сөембикә – кара көчләр символы. «Караңгылыкта туган» «азгын» мәхәббәте белән ул казанлыларны азаплый; грек мифологиясендәге явыз хатын Фурия кебек үлемгә дучар ителгән татарларның «канын кайната» («палящa смертных крови»).

«Россиада» поэмасында Сөембикәнең чибәрлеге «явыз матурлык» икәнлеге турында байтак фикер куертыла. Билгеле, М.М.Херасков ханбикәнең гүзәл хатын-кыз булуы турында яхшы белгән. Шуңа күрә ул Сөембикәне еш кына грекларның төрле исемнәр белән атап йөртелгән матурлык алиһәсе Афродита – Киприда образы белән чагыштыра («Славуща некогда Кипридою у греков», 40 б.). Ләкин, автор фикеренчә, татарларның гүзәл ханбикәсе холкы белән грекларның диңгез дулкыннарының көмеш күбекләреннән туган матурлык һәм мәхәббәт алиһәсе Афродита түгел. Аның әхлагы йөзе бөтенләй икенче төрле: «все портит, расстравляет». Сөембикә үзенең гамәлләре белән арыслан тиресе ябынып йөрүче, кулында сугыш чукмары булган Омфаланы хәтерләтә. Омфала, грекларның атаклы Гераклларына хатын-кыз киеме кидереп, өч ел дәвамында аны үзенә кол кебек эшләргә мәҗбүр иткән, кимсеткән, мыскыллаган. Омфалага ярсулы ачу саклаган Геракл кебек казанлылар да Сөембикә кыланышларыннан ярсыйлар («Такою был Иракл к Омфале распален», 40 б.).

Османга, ягъни Кошчакка гашыйк Сөембикә үзен дә, улы, таҗы, тәхете, патшалыгы булган ханбикә икәнлеген дә, тиздән руслар белән татарлар арасында сугыш булырга тиешлеген дә оныта. Мәхәббәт хисләренә бирелгән Дидона кебек, ул кабул ителмәгән мәхәббәттән үз-үзен үтерү дәрәҗәсенә җитә. Сөембикә грекларның Афродитасы-Кипридасы кебек матур, әмма хәйләкәрлектә, мәкерлелектә Гомер поэмасындагы Одиссейны әсир иткән, көндәшен куркыныч, ямьсез диңгез җанварына әверелдергән Цирцеяга тиң («Киприда красотой, а хитростью Цирцея», 41 б.). Аның күкрәге тулы – агулы уклар; ул – арыслан кебек явызлана алучы, ир-егетләрне алдаучы, вәсвәсәләндерүче зат та.

Туганын да, улларын да, агулы күлмәк бүләк итеп көндәшен дә үтергән Колхида патшасы Медея сыман, Сөембикә дә мәхәббәттән акылы томаланып, шундый адымнарга барырга мөмкин. Үлгән ире Сафагәрәй шәүләсенең киңәшен тотып, Сөембикә Алейга кияүгә чыгарга риза була. Йөрәге Османга тартылганын белеп, Сагрун коткысына да бирелеп, Алины үтерү фикеренә дә килә, аны юк итү нияте белән Зөя каласына агулы бүләк-күлмәк тә җибәрә. Берара ханбикә Казан ханлыгы белән идарә итү вазифасын Алейга тапшырса да, ул – барыбер тотрыксыз, икейөзле, үчле, мәкерле, акыл белән эш итүдән ерак; аның йөрәгендә Османга булган шашкын мәхәббәт патшалык итә.

Шуңа күрә дә М.М.Херасков мәхәббәт хисләреннән акылы томаланган Сөембикә образын, грек мифологиясендәге бүләккә агулы гидра – елан канына манчылган хитон (плащ) җибәреп, көндәшен үтергән Деянира образы белән янәшә куя. Чөнки татар ханбикәсе дә «Россиада» поэмасында бик тә уңай итеп тасвирланган геройга – Алейга агулы күлмәк җибәрә.

Әсәрдә Сөембикә образы «Илиада» поэмасы герое Пелей улы Ахиллны үзенә гашыйк иткән, Агамемнон белән Троя шәһәре янында озак елларга сузылган сугышларга сәбәп булган, лелеглар патшасының әсирлеккә төшкән чибәр кызы Брисеида белән янәшә куела.

Язучы татар ханбикәсен бөтендөнья тарихы анналларында мәңгеләштерелгән, Рим императоры Гай Юлий Цезарьның башын әйләндергән, мәхәббәтен яулаган, акыллы, җиде

тел белгән, оста сәясәтче, Мисыр патшасы гүзәл Клеопатра белән чагыштырырга да батырчылык иткән:

На Ниловых брегах была такая зрима,

Когда вздыхал на них преобразитель Рима (40 б.).

Рус укучысының милли горурлыгына тел-теш тидермәү максатыннан булса кирәк, китерелгән ике юллыкта Клеопатра белән Гай Юлий Цезарь исемнәре турыдан-туры телгә алынмый. Алар турында сүз барганлыгын, бары тик гүзәл Нил елгасы ярларында Брисеида кебек тагын берәү бар иде, аның өчен «Римны үзгәртеп коручы ямансулый», мәхәббәт утында яна иде, дигән җәенке метафора аша гына чамалыйбыз. Ә, гомумән алганда, татар ханбикәсе Сөембикә белән Клеопатраны янәшә кую М.М.Херасков өчен отышлы һәм үзенә күрә бер батыр адым да иде. Ләкин язучы үзен битәрләргә урын калдырмый; боргалана-сыргалана Сөембикәне бары тик тискәре яктан сыйфатлавын дәвам итә. Борынгы Египетның мәшһүр Птоломейлар династиясенең атаклы патша бикәче Клеопатра төсле, Сөембикәгә дә мәхәббәтсез ханлык таҗын кидерү авыр; күз явын алырдай зиннәтле киемнәр дә аның гайрәтен чигерә, мәхәббәт ләззәтләре булмаган җир тормышы да аңа кирәкми:

Вещая: тягостны короны без любви,

Противна без нея блестящая порфира,

И скучны без любви блаженствы здешня мира (40 б.).

Шул рәвешчә, Сөембикә образын тасвирлаганда М.М.Херасков һәрвакыт грек мифологиясеннән алынган образ-сурәтләргә мөрәҗәгать итә. Аның Сөембикәсе, бер яктан, грек алиһәләре кебек гүзәл, икенче яктан, холкы, кылган гамәлләре белән шул ук грекларның авыр кичерешләр дулкынында кайнап, янып, гайре табигый адымнарга барган хатын-кызлары Киприда-Афродита, Кирка-Цирцея, Деянира, Дидона, Медея, Омфала һәм башка образларны хәтерләтә.

Гүзәл Сөембикә холкындагы икенче начар сыйфат – ул аның икейөзлелеге. Язучы аның бу сыйфатын һәрчак «притворная» дип тамгалый. Казанлылар алдында чыгыш ясаганда, ханбикә, бер карасаң, бик тә дөрес сүзләр әйтә, ә икенче яктан уйласаң, туган ил, аның патшалары турындагы патриотик сүзләрне үз мәнфәгатьләренә хезмәт иттерә. Мәсәлән, казанлыларның Сөембикәгә кемне ир итеп сайларга дигән киңәш-җыелышында тарихка мөрәҗәгать итә, үткән заманнарда төрки-татар бабаларыбызның борынгы Греция һәм Рим кебек көчле дәүләтләрне калтыратып торуын искә төшерә; дөньяның әле бүген дә Атилла белән Чыңгыз кебек легендар хөкемдарларның үз дошманнарына курку салуы, аларның батырлыкларына соклану хисләре яшәве турында сөйләп уза. Сөембикә кайчандыр көчсез булган русларга без, татарлар, ясак түләттек, ирекләреннән мәхрүм иттек, аларны буйсындырып тоттык, бүген дә тарихтагы борынгы скифлар кебек аларга каршы сугышырга кирәк дип, казанлыларны батырлык күрсәтергә чакырса да, аның бу ялкынлы мөрәҗәгатенең төбендә Османга булган мәхәббәт ята

имеш. Ул ничек кенә булса да, казанлылардан «Синең ирең Тавриядән килгән баһадир Осман булырга тиеш, Казан ханлыгы белән ул идарә итәргә тиеш» дигән фикерне ишетергә тели. Ләкин Сөембикәнең бу хактагы уй-фикерләре, астыртын башкарган эшләре тормышка ашмый. Аның бу планына дин башлыгы Сәет Һәм Сагрун да каршы чыгалар. Бу очракта әсәрдә Сагрунның прототибы булып Казан ханлыгы тарихындагы мәгълүм шәхес – Чапкын булуын да искәртеп үтәргә кирәк.

Татар галимнәре һәм М.Худяков кебек рус тарихчыларының хезмәтләрендә Сөембикә Казан ханлыгы мәнфәгатьләре турында кайгыртып яшәүче акыллы ханбикә итеп сурәтләнә. М.М.Херасков иҗат иткән Сөембикә образы исә реаль, тарихи җирлектән ераклашкан. Автор татар ханбикәсенең кансызлыгына, мәкерлелегенә, икейөзлелегенә, азгынлыгына басым ясый. Сөембикә образы ни өчен кара буяулар белән гәүдәләнә – бу хакта рус галимнәре дә уйланганнар, билгеле. Алар фикеренчә, Сөембикә образы мисалында язучы шул заман рус тормышын, аеруча Екатерина II нең әхлакый бозыклыкларын күрсәтергә тырышкан. Рус тарихчылары Екатерина II заманы өчен фаворитизм күренеше хас булуы турында язалар. Алар, Сөембикә холкындагы тискәре сыйфатлар аша язучы, читләтеп кенә булса да, Екатерина II заманындагы фаворитизмны, рус патшабикәсенең яман гадәтләрен фаш итәргә тырышкан, диләр. Мәсәлән, К.Валишевский Екатерина II заманында фаворитизмның чәчәк атуын ассызыклап, патшабикәнең дистәләгән фаворитлары – сөяркәләре булуын искәртә. «На этот раз, – ди ул, – во главе государства встала женщина страстная и безудержная... Екатерина II насчитывала их (фаворитов. – *И.Р.*) десятками»[66]. Әдәбиятчы А.Западов та Сөембикә образы үрнәгендә М.М.Херасковның шул замандагы рус дәүләте патшасы һәм идарәчеләре даирәсен гәүдәләндерүе турында әйтеп уза: «Живописуя разложение в среде казанских руководителей, Херасков косвенным образом критиковал русские придворные круги во главе с императрицей»[67].

Безнең уебызча, М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында Екатерина II нең атаклы фавориты, дәүләт эшләрендәге иң уң кулы Г.А.Потемкинга (1739–1791) карата да тәнкыйть сүзләре әйтелә. Аңа патшабикәнең дәүләт белән идарә итүдә чиксез хокуклар бирүен, генерал-фельдмаршал дәрәҗәсенә күтәрүен сарай даирәләре, дворяннар өнәп бетермәгәннәр. Кырымны Россияга кушуда күрсәткән тырышлыклары өчен Екатерина Г.А.Потемкинга «Таврия кенәзе Потемкин» дигән титул да бирә.

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында гәүдәләнгән ханбикә Сөембикәнең «үз Таврия кенәзе» – Осман (Кошчак) бар. Ул да Казан ханлыгына Кырымнан – Тавриядән килгән; ул да ханлыкта гвардия башлыгы вазифасын башкара. Екатерина II кебек, Сөембикә дә Осман белән мәхәббәт уеннары уйнарга тели. Рус патшабикәсе үз дәүләтендәге крестьяннарны рәхимсез изгән һәм Пугачев җитәкчелегендәге халык чуалышларына этәргән кебек, Сөембикә дә вакыты-вакыты белән казанлыларга карата җинаятьчел адымнар ясый.

---

[66] Валишевский К. Роман императрицы. Екатерина II. – М.-СПб.: «ИКПА», 1990. – С.536.
[67] Западов А. Творчество Хераскова. Избранные произведения. – Л., 1961. – С.35.

Халык аның Османны үзенә ир итеп сайлап алырга, тәхеткә якынайтырга теләвен кабул итә алмый. «Таврия кенәзе Потемкин» белән Осман биографиясе арасында охшашлык барлыгын М.М.Херасков яхшы аңлаган. Шул охшашлыкны истә тотып, Сөембикә белән Осман турындагы сюжет сызыгын М.М.Херасков Екатерина II фаворитизмы тудырган әхлакый бозыклыкларны, рус дәүләтендәге иҗтимагый–сәяси каршылыкларны тәнкыйть итүдә файдаланган. Шуңа күрә авторның Сөембикә «фавориты» Осман турындагы тискәре бәяләмәләрне бер үк дәрәҗәдә «Тавриянең якты кенәзе Потемкинга» да карый дип фаразлап була:

Смущали душу в ней (Сумбека. – *И.Р.*), не брани, Князь Осман,
Прекрасный юноша, но гордый и коварный,
Любовью тающий, в любви неблагодарный;
Осман, Таврийский Князь, был нравами таков,
Как лютая змея, лежаща меж цветов (41 б.).

Объектив дип исәпләнгән тарихи чыганакларда һәм тормыш дөреслегенә корылган әдәби әсәрләрдә Сөембикә шәхесенең төп өч сыйфатына: матурлыгына, акыллыгына, батырлыгына басым ясала. Белгәнебезчә, Сөембикә кан коючы да, хәйләкәр һәм азгын хатын да булмаган. А.Западов фикеренчә, М.М.Херасковның Казан ханбикәсенә грек мифологиясе хатын-кызларына хас булган тискәре сыйфатларны ябыштырып куюы очраклы хәл түгел. Автор Сөембикәгә Киприда, Цирцея, Медея, Дидона, Омфала, Фурия, Брисеида кебек мифик образлар өчен хас тискәре сыйфатларны тагып, Екатерина II заманындагы фаворитизм күренешләрен тәнкыйть итә: «Это она (т.е. Екатерина. – *И.Р.*) «Киприда красотой, а хитростью Цирцея» не сумела предотвратить ужасов крестьянской войны и пренебрегала советами просвещенных дворян, ищет опоры в новом любовнике, предоставив Потемкину неограниченные административные права»[68] – дип яза А.Западов.

Рус тарихчылары һәм әдәбиятчыларының Сөембикә образы ярдәмендә М.М.Херасков Екатерина II эшчәнлегенә, дәүләти дәрәҗәдә киң таралган фаворитизм дигән яман гадәткә тәнкыйть уклары яргыта дигән фикерләр белән килешмичә мөмкин түгел. Моның М.М.Херасков биографиясе белән бәйле объектив сәбәпләре бар. Мәгълүм булганча, М.М.Херасков бөтендөнья масоннары әгъзасы була. Екатерина II исә масоннарның үзенә карата нинди дә булса явыз эш эшләүләреннән шикләнеп яшәгән. Шикләнү нәтиҗәсе булса кирәк, М.М.Херасков Мәскәүдә әйбәт кенә эшләп ятканда, күз-колак булыр өчен, аны Петербургка мәҗбүри күчереп тә куйган. Язучының эшчәнлегеннән риза булмаган патшабикә озак та үтми, бернинди пенсиясез, яшәү өчен чыганаксыз калдырып, аны отставкага озаткан. Нәкъ менә Екатерина II белән арасы бозылган елларда М.М.Херасков үзенең «Россиада» исемле күләмле әсәрен яза да, «кәкре атып, туры китерә-китерә»,

[68] Западов А. Творчество Хераскова. Избранные произведения. – Л., 1961. – С.35.

Сөембикә, Осман һәм башка образлар ярдәмендә шул заман рус дәүләтенең идарәчеләре өчен хас кимчелекләрне фаш итә.

Дөрес, поэма белән танышып чыккан Екатерина II үзе өчен зарарлы фикерләр күрми. Патшабикә М.М.Херасковны яңадан Мәскәүгә, кайчандыр ул җитәкләгән университетка куратор итеп кайтарып җибәрә.

Классицизм әдәбияты геройларның эш-гамәлләрен акыл белән үлчәсә дә, ул аларның психологик кичерешләрен күрсәтүгә билгеле бер урын бирә. Н.А.Гуляев язганча, классицистлар кеше психологиясен ил һәм дәүләт кайгысы рәвешендә гәүдәләндерүдә аеруча зур уңышка ирештеләр[69].

«Россиада» поэмасында Иоанның да, Сөембикәнең дә эчке кичерешләрен тасвирлауга шактый гына игътибар ителә. Һәр ике каһарманның да эчке кичерешләре, дәүләтчелек идеясен күздә тотып, акыл белән үлчәнә. Классик әсәрләрдәгечә, Иоанн образы берьяклы итеп бирелә, аның һәр яктан да үрнәк патша булуына басым ясала. Сөембикә образына килгәндә исә, язучы аны икенче төрлерәк сәнгати чаралар ярдәмендә сурәтли. Бер яктан, автор шәхси мәнфәгатьләрен генә алга сөргән, мәхәббәттән исергән татар ханбикәсе кебек булмагыз дип, үгет-нәсыйхәт бирә. Икенче яктан, Сөембикәнең Казан ханлыгы алдындагы җаваплылыгын Османга гыйшкы белән каршылыкка кертеп, әсәрдә акыл белән хиснең бәрелешенә корылган, классицизм өчен генә хас булган бик тә үзенчәлекле психологизм барлыкка китерә.

М.М.Херасков Сөембикә образын, классицистларча рус патшасы Иоаннга каршы куеп, никадәр генә мәкерле, азгын, икейөзле итеп күрсәтергә тырышмасын, барыбер ул ханбикәнең Казан ханлыгын рус явыннан коткарып калу өчен күрсәткән уңай адымнарын сурәтләүдән баш тартмаган. Бер генә мисал: әсәрдә Сөембикәнең Алейга кияүгә чыгарга ризалык бирүе дә ханлыкны юкка чыгудан, җимерелүдән саклап калу өчен эшләнә.

Әдәбият галимнәренең барысы да диярлек «Россиада» поэмасын классицизм юнәлешенә бәйләп өйрәнә һәм аның мәгърифәтчелек әдәбиятындагыча акыл культына корылган әсәр булуына басым ясый. Чыннан да, әсәрнең эчтәлегенә, күтәрелгән мәсьәләләргә, образлар системасының бирелү үзенчәлегенә күз ташлагач та, анда Иоанн һәм Сөембикә образларын гәүдәләндерүдә классицизм әдәбияты өчен хас мәгърифәтчелек принципларының өстенлек алуы күзәтелә.

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы рус әдәбиятында мәгърифәтчелек идеологиясенә нигезләнеп берничә төрле әдәби юнәлеш һәм иҗат ысуллары мәйданга чыккан заманда дөнья күргән. XVIII гасырның беренче яртысында башланып, тамырланып үсеп киткән классицизм озак та үтми сентиментализм һәм предромантизм (романтизм алды) кебек иҗат ысуллары белән үзара керешеп, үрелеп яши башлый. Рус әдәбият белемендә бу хакта җитди генә хезмәтләр бар (В.М.Жирмунский, Н.А.Гуляев, Г.В.Москвичева, А.Н.Соколов, В.В.Ванслов һ.б.). «В конце XVIII – в начале XIX вв. русский классицизм, – ди

---

[69] Гуляев Н.А. Теория литературы. – М., 1977. – С.208.

В.Я.Бахмутский, – испытывает воздействие сентименталистских, предромантических идей»[70]. Классицизмның сентиментализм, предромантизм кебек әдәби агымнар белән мөнәсәбәткә керүе XVIII гасыр азагында язылган М.М.Херасковның «Россиада» поэмасындагы сәнгатьчә фикерләүне дә үзенчәлекле иткән, аны үзгә сыйфатлар белән баеткан. Чыннан да, әсәр күз яшьләре белән сугарылган һәм аларның әдәби-эстетик вазифасы да төрледән-төрле. Байтак очракта бу елау күренешләре ярдәмендә автор классицизм геройларының дәүләтчелек идеяләренә бәйле рухи халәтләрен чагылдыра. Геройларның эчке дөньясын «кирәгеннән артык төчеләндереп, күз яшьләре белән бирү, сыкраулы ыңгырашулы авазларны ишеттерү»[71], шатлыктан да елау, теләсә-теләмәсә дә, классицист язучы дип исәпләнгән М.М.Херасковны сентиментализмга якынайтты. «Классицисты, – дип яза Н.А.Гуляев, – стремились воздействовать не только на разум, но и на чувства, тем самым выходили за пределы рационалистической эстетики»[72]. Акыл кысаларыннан чыгу, дөрестән дә, классицизм әдәбиятына зур үзгәрешләр алып килә. В.В.Ванслов язганча, бу үзенә күрә акыл культына корылган классицизмга карата «җитди удар» була. «Серьезный удар, – ди В.В.Ванслов, – классицизму нанесли деятели эпохи Просвещения, защитники сентиментального направления»[73].

«Россиада» поэмасының иҗат ысуллары һәм алымнары буенча катлаулы әсәр икәнлеген Сөембикә образы мисалында да күзәтеп була. Күз яшьләре белән сугарылган психологизм классицистлардагыча ханбикәнең дәүләтчелек идеяләренә – Казан ханлыгына мөнәсәбәттә дә, сентименталист һәм романтик язучылардагыча, мәхәббәт хисләренә бәйле рәвештә дә гәүдәләнә. Сөембикәнең күз яшьләре күбрәк Таврия кенәзе Османга мәхәббәт һәм нәфрәт хисләрен чагылдыра.

Сөембикә, Осман Эмираны онытса, аны гафу итәргә, түккән бихисап күз яшьләрен онытырга да әзер («Забвению предаю потоки слез моих», 51 б.). Османның Эмираны юксынып, сагынып җырлаган җырын ишеткәч тә, аның күз яшьләре елга булып ага. Осман хәзинәләрен урлап, Эмира Россиягә качты, дигән Сагрунның ялган хәбәрен ишеткәч тә, Сөембикә күз яшьләренә буыла («Сумбека залилась при сих речах слезами», 94 б.). Османның «Мәхәббәтеңне кабул итмәгән өчен миңа җәза бир» дигән үкенүле уй-хисләрен белдергәч тә, Сөембикә елый-елый сөйгәне кочагына атыла, ыңгырашып, каты сыктап, үбеп, аның яратуын кабул итә:

Сумбека, во слезах, взирая на него,
Поверглась в томныя объятия его:
Живи! Осман, живи! Стоная возопила,
Лобзанием сей мир с Османом подкрепила (95 б.).

---

70 Бахмутский В.Я. Классицизм // Литературный энциклопедический словарь. – М.: Сов. энциклопедия, 1987. – С.158.
71 Ганиева Р.К. Сентиментализм // Әдәбият белеме сүзлеге. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1990. – Б. 160.
72 Гуляев Н.А. Теория литературы. – М.: Высшая школа, 1977. – С.208.
73 Ванслов В.В. Эстетика романтизма. – М., 1966. – С.195.

Осман да елый һәм үзенең күз яшьләре белән Сөембикә күкрәген чылата («Осман, льющий слез потоки...; И грудь Сумбекину слезами оросил», 95 б.).

«Вөждансыз казанлылар»ның Алла каршында тәүбә итә-итә аны Мәскәүгә озату хәбәрен ишеткәч тә, Сөембикә кайгы-хәсрәт дәрьясына бата, ул түккән күз яшьләренең игечиге булмый:

Какой был стон, тоска, коликое рыданье,

Когда услышала Сумбека о изгнанье (196 б.).

Сөембикәнең Казан белән аерылышу күренешен калган рус авторлары да «Россиада» поэмасындагыча тасвирлыйлар. М.М.Херасков никадәр генә Россиянең патриоты булмасын, автор буларак, ул Казан ханбикәсенең фаҗигасен аңлаган, йөрәге аша үткәргән булырга охшый. Югыйсә, Сөембикә хәсрәте турында язарга көчем җитми, иңрим, ыңгырашам, кулымнан каләмем төшә, дигән кебек тә экспрессив эчтәлекле юлларны укучыга җиткермәс иде:

Печаль ея вещать мне сил не достает;

Помедлим!... Я стеню... перо из рук падет (196 б.).

Мәскәүгә коллыкка озатылу хәбәрен ишеткәч тә, Сөембикә үлем түшәгендәге кебек бәрелә-сугыла, үкси, ыңгыраша («Еще рыдающа в одре она лежала», 197 б.), аның битендәге алсулык юкка чыга, күзләрендәге яшәү нурлары сүнә, йөрәге таш булып ката. Ул үлем җәзасы турындагы карарны тыңлаган әсир кебек, ярым үле кыяфәттә дөньяга карап тора:

Как пленник, внемлющий о смерти приговор,

Сомкнула страждуща полуумерший взор (197 б.).

Казан шәһәре, аның янындагы калкулыклар, таулыклар белән дә Сөембикә елап бәхилләшә; дерелдәгән иреннәре белән шәһәр диварларын үбә, такмаклый-такмаклый иңри, сулкылдый:

Любезный град! Прости, простите, стены, горы! (199 б.).

Сөембикә елау-сыктаулары «Казан тарихы»ндагы елау-плачлар белән шактый охшаш. «Россиада» поэмасында да Сөембикә әсирлеккә озатылу, ире Сафагәрәй белән гүрдә янәшә ята алмау, таҗ һәм тәхеттән мәхрүм калу хакында бәргәләнеп сыктый. Хәсрәтле күз яшьләре түккән Сөембикә хәлсезләнеп сарай хезмәтчеләре өстенә ава.

«Казан тарихы»ндагы кебек, М.М.Херасков поэмасында да Сөембикәнең Казан ханлыгының җимереләчәге, казанлыларның күз яшьләре һәм каннары елга булып агачагы, ә аны әсирлеккә куучыларның язмышлары тагы да бәхетсезрәк тәмамланачагы турында күрәзәчел хәбәр (прогнозлар) бирелгән. Ханбикәнең Казан белән аерылышканда өзелеп–өзелеп елаулары аны әсирлеккә җибәрүчеләргә каргыш, ә киләчәк буыннарга кисәтү буларак

та яңгырый. Мине Казаннан куучылар миннән дә бәхетсез булачак, ди ул. («Мои гонители меня несчастьней будут!» (201 б.). Шул ук вакытта «Казан тарихы» белән «Россиада» поэмасында бирелгән елаулар арасында аермалыклар да күзәтелә.

«Казан тарихы»нда Сөембикә Идел буйлап Мәскәүгә таба күтәрелгәндә, аның карамагындагы кешеләрнең берсе дә ханбикәне күз яшьләреннән тыя һәм тынычландыра алмый. М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында Сөембикәне әсирлеккә озату күренеше икенчерәк әдәби ысуллар ярдәмендә, тагы да тәэсирлерәк, көчлерәк экспрессив чаралар белән бирелгән.

М.М.Херасковның классицизм үрнәге дип саналган «Россиада» поэмасында сентиментализм өчен хас сыйфатлар булу үзеннән-үзе әсәр тукымасына тагы бер яңа элемент – романтизм алды әдәбияты өчен хас сыйфатларны китереп керткән. Н.А.Гуляев язганча: «Есть группа сентименталистов, в произведениях которых понимание жизни сочетается с романтическим типом творчества» [74]. М.М.Херасков поэмасының кайбер урыннарында иҗтимагый тормыштан бигрәк геройларның эчке кичерешләрен сурәтләүгә игътибар игелә. Моны аеруча Казан ханбикәсе Сөембикәнең рухи дөньясын, аеруча аның мәхәббәт хисләрен гәүдәләндергән очракларда күзәтергә мөмкин. Мәсәлән, Сөембикәне әсирлеккә алып китү турында сөйләгәндә, язучы классицизм һәм сентиментализм кебек иҗат ысуллары өчен хас алымнардан баш тарта, романтизм әдәбиятына хас сәнгати чараларны да куллана башлый. Романтик алымнар белән язылган урыннарда Сөембикә шәхесенә автор бәяләмәсе дә, эстетик үлчәм дә үзгәрә. Моңарчы бары тик кара буяулар белән генә сыйфатланып килгән татар ханбикәсе якты буяулар ярдәмендә гәүдәләнә башлый. Аңа карата «гүзәл» дигән эпитет та кулланылышка керә.

«Россиада» поэмасында Сөембикә образы берничә мәртәбә романтик җирлеккә куеп яктыртыла. Шуларның берсе – ханбикәнең җир астыннан давыллы утлар ыргылган, күкләрдә яшеннәр уйнаган бер мизгелдә ерткыч хайваннар улаган, чинаган, өрәкләр белән тулган, еланнар ысылдаган, дөбердәү, бәрелү-сугылу тавышлары ишетелгән кара урмандагы бик куркыныч каберлеккә бару күренеше. Әмма Сөембикә каберлеккә аяк баскач та, давыллы куркыныч кара урман тынып кала, аңа рухи теләктәшлек күрсәтә:

Умолк звериный рев и шум бурливых вод (57 б.).

Автор Сөембикә образын романтикларча җанландырылган кара урман, каберлек, үлекләр белән сөйләшү кебек гайре табигый шартларга куя. Аның өзгәләнә-өзгәләнә елаулары да табигать күренешләре ярдәмендә ассызыклана: «Завыл ужасный вихрь, земля кругом дрожала» (62 б.).

Каберлектәге мүкләнеп беткән, калын чирәм катламы астында ятучы табутлар да Сөембикә кайгысын тыныч кына кабул итә алмыйлар. Сөембикәнең рухи халәтен тасвирлаганда, М.М.Херасков предметларны да, табигатьне дә сынландыра, кеше җаны

[74] Гуляев Н.А. Теория литературы. – М.: Высшая школа, 1977. – С.223.

белән сугарып бирә. Бу исә әсәр тукымасына романтик эчтәлекле психологизмны кертеп җибәрү өчен мөмкинлекләр ача.

Казан тәхетенең руслар кулына күчәчәген алдан күргән Сафагәрәй күләгәсе татар ханнары табутларын яндырып юк итәргә куша, чөнки ул әрвахлар рухларының икенче мәртәбә «үлемгә дучар ителүен» күрергә теләми.

Классицистик стильдә язылган «Россиада» поэмасына романтик алымнар башлыча Сөембикәнең мәхәббәт хисләрен чагылдырганда кертеп җибәрелә. Казан ханбикәсе Сөембикә табигатьнең үзе кебек матур. Аның гүзәллеге сокландыргыч роза чәчәге генә түгел. Сөембикәнең утлы, нурлы күзләре – зур ихтыяр көченә ия булган ир-егетләрне дә үзенә әсир итәрлек матурлык.

Гашыйклык уенын уйнаучы Сөембикә Алейны шулкадәр сокландыра, кызыктыра ки, ул аның йөрәгенә бал булып та, агу булып та тама: «Во грудь Алееву вливали мед и яды» (79 б.).

Сөембикә белән Алей кайда гына, кайчан гына очрашмасыннар, автор Алейның ханбикәгә мөнәсәбәте саф булуга басым ясый. Ханбикә исә моның капма-каршысы. Дөресрәге, ул Алейга карата каршылыклы хисләр дулкынында чайкала. Юкка гына әсәрдә Сөембикә мәхәббәтенең икейөзлелеккә корылган алдау һәм Алей өчен агу икәнлегенә искәртеп үтелми. «Россиада» поэмасының жанр таләпләре буенча, Сөембикә, Казан ханлыгы белән Рус дәүләтенең тыныч яшәвен тәэмин итәр өчен, дин башлыгы Сәет, Алей дусты Гәрәй, кенәз Сагрун – Чапкын, ире Сафагәрәй хан шәүләсе киңәшләрен дә тотып, вазифа үтәргә – Алейга кияүгә чыгарга тиеш. Бу фикер әсәрнең «Өченче җыр»ында ук ике мәртәбә Сөембикә аңына иңдерелгән иде инде.

Поэмада Сөембикә Алей белән никахлашырга тиеш дигән фикер дистәләрчә мәртәбә кабатлана. Автор уенча, моның тарихи мәҗбүрият икәнлеген Сөембикә дә яхшы күзаллый. Шул максатка ирешү өчен ханбикә үзенең матурлыгын эшкә җиңә, арысландай Алейны мәхәббәт җәтмәсенә куып кертә, «юаш корбан тәкәсенә» әверелдерә.

Үз чиратында ике таҗны – үзен дә, Казан тәхетен дә Алейга бүләк иткән Сөембикә – рус-татар мөнәсәбәтләрен тыныч хәл итү тарафдары. Моның өчен ул Тау ягы җирләрен Мәскәүгә бирергә дә, руслар белән ант эчәргә дә риза.

Билгеле, авторның Алей белән Сөембикә авызыннан әйттерелгән сүзләрдә бер дөреслек бар. Ул да булса, ханбикәнең күрше руслар белән тыныч яшәргә омтылуы. Чынбарлыкта исә, аек акыллы Сөембикә русларга Тау ягын тапшыру, Мәскәүгә салым түләп тору тарафдары булмаган. Әсәрдәге «Казанның гади халкы Алейны ихлас ярата» («Алея подлинно Казанска чернь любила», 89 б.) иде дигән сүзләре дә тарихи дөреслектән ерак торган фикер буларак кабул ителергә тиеш.

«Россиада» поэмасында гәүдәләнгән Сөембикә белән Алей мөнәсәбәтләре тоташ уйдырмадан тора. Кылган гамәлләре, ямьсез тышкы кыяфәтле Алей – Шаһгалинең Сөембикәдә бары тик җирәнү, күрә алмау хисләре генә уятканлыгы мәгълүм. Киресе

булганда, фольклорга һәм әдәби әсәрләргә Сөембикәнең Алейны агуларга тырышуы турындагы мотивлар үтеп тә кермәс иде.

Сөембикәгә өйләнеп, Алей Казан тәхете белән идарә итә башлый. Ул Казан ханлыгы белән дә гадел идарә итәргә, кешелекле хан булырга омтыла; Сөембикә әмере белән төрмәгә ыргытылган дошманы – көндәше Османга да азатлык бүләк итә («Ты враг мне, я тебе свободу возвращаю», 88 б.).

Сөембикә Казанга хан итеп Алейны сайласа да, аның йөрәге белән икенче бер мәхәббәт патшасы – Осман гына идарә итә:

Но царствовал Осман над сердцем у нее (89 б.).

Казан ханлыгында Сөембикә, Алей һәм Османга каршы астыртын эшләр алып баручы явыз кеше – Сагрун. Ул Алей ислам диненең дошманы, Мәскәү өчен татарлардан салым түләтергә җыена, дигән ялган хәбәрләр тарата.

Сагрун үзенең мәкерле планнарын тормышка ашыру эшенә алына. Иң элек ул аралары бозык булган Сөембикә белән Османны килештерә, ханбикәдән Алейны үтертергә дигән ризалык ала һәм бу юнәлештә казанлылар арасында эш тә башлап җибәрә. Шушы урында автор Казан шәһәренең нигезенә эт башы салынып калынган дигән халык легендасын китереп кертә. Аның иҗади уйдырмасы буенча, Казан шәһәренең нигезенә үтерелгән рус кешесе башы салынган. Сөембикә белән Сагрун моны начарга юрыйлар, бу хәл киләчәктә Казанга руслар хуҗа булырга тиешлеген күрсәтүче билге дип кабул итәләр. Шунлыктан алар кала нигезендә калдырылган христиан башын Алей башы белән алыштырырга җыеналар. Бу планны тормышка ашыру максатыннан төнге җыелыш җыела. Хөкүмәт исеменнән тәкъдим ителгән хартиядә Алей башын Казан шәһәре нигезенә салырга дигән карар кабул ителә. Ләкин казанлыларның бу яшерен төнге җыелышта кабул ителгән карарлары тормышка ашмый кала. Гәрәй исемле дусты тарафыннан кисәтелгән Алей Казаннан Зөягә чыгып кача.

«Казан тарихы»ндагы кебек, М.М.Херасков әсәрендә дә Алей явыз Иванның дусты, русларга турылыклы шәхес итеп бирелгән (« Алей – друг Отечества, верный царь»). Казан алынгач та, Иоанн һәм рус гаскәрләре тантана иткән минутларда, Алей үзен бик тыйнак тота. Ул үзенең татарларны җиңүгә керткән өлеше өчен бернинди ганимәт тә, алтын-көмеш тә, хәрби трофей да сорамый. Явыз Иоанн-Иваннан бары тик «бер табыш», бер бүләк – гүзәл, акыллы татар ханбикәсе Сөембикәне үзенә хатынлыкка бирүне генә үтенә:

В корысть прошу одну Сумбеку, Государь!… (267 б.).

Икенче мәртәбә Алей белән Сөембикә Зөя каласында очрашалар. Бу вакытта инде Сөембикә казанлылар тарафыннан Иоаннга әсирлеккә бирелгән була. Ахыр чиктә Сөембикә Мәскәүгә озатыла.

Сөембикәне әсирлеккә алып китү турында сөйләнгән унынчы бүлектә автор татар ханбикәсен романтик буяулар белән гәүдәләндерә, аны гүзәл Сөембикә дип атый («Вы зрели

шествие прекрасныя Сумбеки», 197 б.). Сөембикәнең Идел буйлап әсирлеккә китү күренеше грек мифологиясеннән алынган кечерәк сюжетлар һәм образлар ярдәмендә бик тә матур һәм тәэсирле итеп бирелә. Сөембикә энҗеләр белән бизәлгән патшалык скипетры, ягъни эмблемасы булган колесницага утырган. Ә аны озатып баручы атлар белән акыллы һәм гадел, тынычлык яратучы нимф Нерей идарә итә. Ханбикә исә грек алиһәләре кебек тантаналы рәвештә башындагы яулыгын йомшак җилләрдә җилфердәтеп, тантаналы туй мәҗлесенә баручы Фетиданы хәтерләтә. Ә тирә-якта тритоннардан яңгырап торган быргы авазлары һәм гүзәл сиреналарның матур җырлары ишетелә. Җилкәннәре алтын тукымалар белән капланган, Сөембикә утырып барган көймәләргә елга да, кояш та, ай да соклана.

Ләкин Сөембикәнең елга буйлап сәяхәте язучы хыялындагыча романтик идиллиядән генә тормый. Бу мәҗбүри сәфәр җан сыкравы, күз яшьләре белән сугарылган. Автор үзе дә моны искәртә: «Со стоном пение повсюду раздавалось» (201 б.). Ләкин шулай да автор Сөембикәнең әсирлеккә китүен күбрәк романтик буяулар белән бизәп бирә. Хезмәтче кол-кәнизәкләр Сөембикәнең никадәр күңелен юатырга тырышмасыннар, ул күз яшьләренә күмелеп, Казан якларында ерактан күренеп торган урман белән саубуллаша. Шул ук вакытта аны Алейга бик үк турылыклы булмаган мәхәббәте өчен үкенү хисләре дә биләп ала; Киприда-Афродитаның мәхәббәт очкыннарын чәчеп йөри торган Эрос Сөембикә йөрәгендә Алейга карата мәхәббәт ялкыннары да кабыза. Ханбикәнең Алейга булган гаделсезлекләре онытылып киткәндәй була: акылы дә үз халәтенә кайтып, хәсрәтле кичерешләре дә онытылып, киләчәккә өмет чаткылары уяна.

«Россиада» поэмасындагы Сөембикә образы бик тә каршылыклы итеп гәүдәләнгән. Рус патшасы белән янәшә куелганда, ул тискәре каһарманнарга тартымлык күрсәтә, дәүләтчелек идеяләрен алга сөргән Иоанның антиподы итеп бирелә; Казан ханлыгына зыян китерүче «азгын мәхәббәт» иясе итеп сурәтләнә. Бу рәвешчә, акыл белән хисләр культын антиномия рәвешендә бирү классицизм әдәбияты кануннарына да каршы килми. Мәгърифәтчеләрчә акыл культына басым ясап, М.М.Херасков Иоанн кебек тарихи шәхеснең Россия тарихындагы урынын югары бәяли. Таврия кенәзе Османга гашыйк Сөембикә образы мисалында автор «менә, татар ханбикәсе кебек булмагыз» дип, укучыга үгет-нәсыйхәт бирә һәм тәнкыйтенең укларын тагын да ераккарак – Екатерина II заманындагы фаворитизм күренешләренә юнәлтә.

Алей белән Сөембикә образына нисбәттә дә Сөембикәнең хисси дөньясы тотрыксыз, таркау итеп чагылдырыла. Мәсәлән, ул Таврия кенәзе Османга әле мәхәббәтен белдерә, әле гыйшкын кабул итмәгән өчен аны богауга салдыра, әле Алей ярдәме белән зинданнан азат та иттерә. Сөембикәнең хисләре айкау-чайкау булу сәбәпле, Осман көндәше Сагрун тарафыннан үтерелә. Бу соңгысы исә, ничек кенә булса да, Сөембикәне үз кулына төшерү турында хыяллана. Уйдырма образ – баһадир Сагрун белән Асталон үзара сугышып, җәрәхәтләнеп, бер-берсен атларда куышып, Казанка елгасында батып үләләр.

«Россиада»дагы Сөембикә образы сентиментализм әсәрләрендәгечә табигать баласы, хисләр колы гына итеп сурәтләнми. Мәсәлән, ханбикәнең үз язмышын Алей белән бәйләргә мәҗбүр булуның сәбәпләре классицистларча – казанлылар алдында торган бурычны үтәү кебек – фаҗигале зарурият рәвешендә аңлатыла.

Казан ханлыгы язмышында төрле фиркаләр арасында барган тартыш-ызгышларның авырлыгы Сөембикә җилкәсенә төшкәнне М.М.Херасков шактый объектив бәяли алган. Әсирлектә ханбикәнең Зөядә Иоанн белән очрашу күренеше дә, аерым-аерым уйдырмаларны, мәсәлән, аның христиан динен кабул итүен исәпләмәгәндә, чынбарлыкка шактый якын тора дип исәпләргә була. Иоанн Сөембикәне патшаларга тиеш ритуал буенча бик тә тантаналы рәвештә кабул итә, әмма Казан ханбикәсе, рус патшасының да, аның кенәзләренең дә аякларына егылып, сәлам бирми. Аның җавабы бик горур: «Я узница твоя, но я была Царица!» (203 б.). Сөембикә үзенең рус патшасына дошманнарча нәфрәтле булуын да яшерми: «О пагубе твоей и день и ночь радела» (203 б.).

Ханбикә Иоаннга рус дәүләтенең татарларга карата хәрәкәтләре ничек булса, мин шуны эшләдем, илемне юк итәргә теләүчеләргә кылыч күтәрдем, дип җавап бирә. Ул үз Ватанын ихлас яраткан, ә менә бүген аның иминлеге өчен иркен дә, бәхетен дә, тәхет-таҗын да югалткан. Шуңа күрә Сөембикә үзен гаепсез дип саный, ә гаепле дип санаганда – бу туган ил каршындагы «изге гаеп»: «И если я винна, свята вина моя» (203 б.).

Иоанн Сөембикәне «Твой сын – сын будет мой, ты будь сестра моя» (203 б.), дип каршы ала. Кансызлыгы, мәрхәмәтсезлеге белән дан тоткан Иванның мондый кешелекле җавабы, беренчедән, М.М.Херасковның Иоанн образы мисалында классицистларча идеал патша образы тудыру максаты белән аңлатылса, икенчедән, әсәр авторына гуманистик карашларның чит булмавы турында сөйли.

Сөембикәнең Алейны ир һәм хан итеп Казанга алып кайту һәм Ханбикәнең Мәскәүгә әсирлеккә озатылу күренешләре Аурупа корольләре һәм Россия императорларының бик тә тантаналы рәвештә сарайдан чыккан һәм кайткан кортежлары рәвешендә грек, рим, православие дине мифологиясеннән алынган купшы образ-сурәтләр, гүзәл архитектура үрнәкләре, зиннәтлелек, тантаналылык үзләре генә дә поэмада барокко элементлары да булу турында сөйли.

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы – рус тарихының абсолютизм, империя булып формалашу дәверенә караган бик күп иҗтимагый-сәяси мәсьәләләрне чагылдырган әсәр. Поэмада Көнчыгыш Европа җирләрендә барган зур үзгәрешләр: рус дәүләтенең экспансив сәясәте, Кырым һәм Казан татарлары белән сугышлары, рус армиясенең коры җир һәм Идел буенча Казанга таба коточкыч көч булып хәрәкәт итүе, Казан шәһәре өчен барган канлы бәрелешләр, рус гаскәриләренең шәһәрне талавы, татарларның актык кешеләренә кадәр каһарманнарча сугышулары, шаһит китүләре гәүдәләнгән.

Мәскәү белән Казан арасындагы ямьсез, рәхимсез бәрелешләр поэмада «яктылыкка илтүче» христиан дине, «караңгылыкка – тәмугъка илтүче» ислам дине тартышы рәвешендә

дә чагылдырылган. Бу рус-татар мөнәсәбәтләренең үзәгенә ике тарихи шәхес, ике патша – Явыз Иван белән татар ханбикәсе Сөембикә образлары куелган.

«Россиада» – дәүләтчелек идеяләрен алга сөргән классицизм әсәре. Әмма ул саф килеш кенә бирелмәгән. Анда үгет-нәсыйхәткә корылган классицистик эчтәлектәге реализмнан тыш сентиментализм, романтизм һәм барокко өчен хас сыйфатлар да беркадәр чагылыш тапкан.

«Россиада» поэмасы – М.М.Херасков иҗатының таҗ әсәре. Анда авторның иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи-эстетик, әдәби карашлары да шактый тулы чагылыш тапкан. Юкка гына замандашлары М.М.Херасковны XVIII гасыр рус әдәбиятының «старостасы» дип атамаганнар.

## 3. С.Н.Глинканың «Сөембикә, яки Казан ханлыгының егылуы» трагедиясе

Рус әдәбиятының «алтын чоры» дип саналган XIX гасырның беренче яртысы рус тарихының әһәмиятле вакыйгаләрын тасвирлауга багышланган дистәләрчә әсәрләр барлыкка килү белән дә үзенчәлекле. Бу әсәрләрдә күбрәк рус халкының тарихи үткәне, Алтын Урда чоры вакыйгаләре, поляк-швед интервенциясенә каршы көрәш, Иван Грозный җитәкчелегендәге рус гаскәрләренең Казанны басып алуы һәм Петр Беренче заманнарындагы вакыйгаләр турында сөйләнә. 1802 елда күренекле рус тарихчысы һәм язучысы Н.М.Карамзин үзенең «О случаях и характерах в Российской истории, которые могут быть предметом художеств» дип аталган мәкаләсен яза[75]. Программа характерында булган бу мәкаләдә автор Казанны яулап алу, патша Михаил Федорович Годуновны сурәтләү һәм Полтава сугышы вакыйгаләрен Россия тарихындагы иң әһәмиятле чорлар рәтенә кертә. Казан ханлыгы җимерелү белән рус дәүләте монгол-татар изүеннән котылып, үзенең азатлыгына ирешә алды, дип аңлата тарихчы. Бу уңай белән рус дәүләтчелеге тарихында олы борылыш башлап җибәргән Явыз Иван һәм аның антиподы булган Сөембикә образына да игътибар арта. Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе Сөембикә язмышы мотивлары рус әдәбиятында яктыртуга лаек тема һәм мотивлар рәтенә кертелә. Татар ханбикәсе турында бер-бер артлы берничә әсәр язылу шул хакта сөйләсә кирәк.

Казан ханлыгын басып алу һәм Сөембикә ханбикә шәхесе белән бәйле вакыйгаләргә күренекле тарихчы Н.М.Карамзин рус тарихына караган хезмәтендә дә игътибар итә. «Казан тарихы» әсәре традициясен дәвам иттереп, ул гүзәл Сөембикәне Кошчак углан белән «кәеф-сафа» коручы ханбикә итеп күрсәтә («то веселилась со своим любовником, крымским уланом Кощаком, ненавистным народу»)[76].

[75] Карамзин Н.М. Избранное. – М.: Детская литер., 1990. – С.11.
[76] Карамзин Н.М. Завоевание Руси монголами. – СПб., 1889. – С.61.

Бу чорларда язылган рус драма әсәрләренең төп персонажлары – Ватанга фидакяр хезмәте һәм олы мәхәббәте белән дан казанган тарихи шәхесләр[77]. XIX гасырда иҗат ителгән әсәрләрдә, шул исәптән С.Н.Глинканың «Сумбека, или Падение Казанского царства» (1806) дигән биш пәрдәлек трагедиясендә Сөембикә төп образ булып үзәккә куелды.

Сергей Николаевич Глинка (1755–1847) – унтугызынчы гасыр башында тарихи драматургия өлкәсендә зур эшчәнлек күрсәткән рус язучысы. Ул – күп кенә драма әсәрләре, повесть, шигырьләр, мемуарлар авторы. 1812 елдан башлап рус патриотизмы белән сугарылган «Русский вестник» дигән журнал чыгара. 1817–1823 елларда «Рус тарихы» дигән күләмле хезмәт тә яза. Замандашлары фактларны яктыртуда фәннилек һәм объективлык җитешми дип, аның бу хезмәтен тәнкыйтьләп тә чыгалар. Греция һәм әрмән халкы тарихы турында компилятив характерда булган хезмәте дә бар. С.Н.Глинка тарафыннан язылган әдәби әсәрләр, фәнни хезмәтләр күп санлы булуына карамастан, аларның күбесе бүгенге көндә онытылган һәм зур әдәби кыйммәткә ия түгел дип исәпләнә.

Шигъри формада язылган «Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясе М.М.Херасковның «Россиада» поэмасына иярү, җавап-нәзыйрә рәвешендә иҗат ителгән. Бу турыда автор трагедиянең кереш өлешендә дә искәртеп уза: «Восхитясь им (Россиадой. – *И.Р.*) и я дерзнул идти к Парнасу: Внимая Мельпомены гласу[78]». Чыннан да, әдәби Парнаска – шагыйрьләр җәмгыятенә «юл тоткан» С.Н.Глинка «Россиада» поэмасында катлаулы язмышы белән аерылып торган Сөембикә тавышына да колак сала, аны үз әсәренең төп каһарманы итеп сайлап ала. Шуңа күрә дә ул иҗади эшкәртү өчен М.М.Херасков поэмасының татар ханбикәсе турындагы өченче, дүртенче, өлешчә бишенче һәм тугызынчы «җыр»ларны сайлап ала.

С.Н.Глинка «Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясен 1806 елда язып бетерә, һәм ул әсәр 1807–1824 еллар аралыгында берничә мәртәбә Петербург һәм бер мәртәбә Мәскәү сәхнәләрендә уйнала. Авторның үз истәлекләренә караганда, 6 декабрьда ул бу әсәрен күтәреп, 84 яшьлек М.М.Херасков янына китә. Очрашу вакытында С.Н.Глинка М.М.Херасковның хатыны Елизавета Васильевнаның да Сөембикә турында трагедия яза башлавы, инде аның өч бүлеге тәмамланганы турында әйтеп үтә. Пимен Араповның язуынча, заманында С.Н.Глинканың «Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясе сәхнәдә зур уныш белән барган. Ханбикә Сөембикә ролен атаклы артистка Е.С.Семенова башкару бу әсәр белән кызыксынуны тагы да арттырган.

«Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясендә дә М.М.Херасков әсәрендәге персонажлар – Казан ханбикәсе Сөембикә (Сумбека), Таврия кенәзе Осман, аның сөеклесе Эмира, дин әһеле Сәет (Сеит), Сагрун һәм Асталон катнашалар.

---

[77] Бочкарев В.А. Русская историческая драматургия (1800–1815) // Ученые записки. – Куйбышев: Педагогический институт, 1959. – Вып.25. – С.462.

[78] Мельпомена – грек мифологиясендә сәнгать турындагы тугыз музаның берсе, трагедия жанрын үз канаты астына, үз яклавына алучы. Бу очракта «мельпомена» моңлы җыр мәгънәсен аңлата.

С.Н.Глинка трагедиясе проблематикасы, жанры, иҗат ысулы, композицион төзелеше ягыннан М.М.Херасковның «Россиада» поэмасыннан шактый аерылып тора. Шуңа күрә ул мөстәкыйль идея-эстетик кыйммәткә ия булган әсәр рәвешендә кабул ителергә тиеш. «Россиада» поэмасында идеаллаштырылган классицизм әдәбияты өчен хас алымнар белән гәүдәләнгән Иоанн образы С.Н.Глинка әсәрендә юк. Киресенчә, анда төп образ итеп Иоанның антиподы – Казан мәликәсе Сөембикә образы алынган. Әсәрнең сюжет сызыгы ханбикә белән Осман арасындагы мәхәббәт интригасы тирәсендә корылган.

М.М.Херасковның классицизм ысулында язылган «Россиада» поэмасындагы төп конфликт шәхси һәм җәмгыяви каршылыктан гыйбарәт иде. Икенче төрле итеп әйткәндә, анда Сөембикәнең мәхәббәт хисләре Россиянең дә, Казан ханлыгының да дәүләти мәнфәгатьләренә туры килеп бетми. Шул сәбәпле автор татар ханбикәсен бик тә авыр рухи камилләшү баскычлары аша уздыра, хәтта тарих чынбарлыгын бозып, Сөембикәне Алей белән бергәләп, «саф православие» динен дә кабул иттерә.

Сөембикә образына карата сәнгати дөреслек «Россиада» поэмасының аерым бүлекләрендә генә ялтырап китә. Анда иҗтимагый тормыш белән рус язучысының сәнгатьчә уйдырмасы бары тик бер үзәк мәсьәләдә – русларның татарларга карата нәфрәтен сурәтләүдә тәңгәл килә.

С.Н.Глинка әсәрендә исә, М.М.Херасков поэмасындагы кебек, Казан татарларына карата нәфрәт хисләре юк. Әмма бу шигъри трагедиянең һәр пәрдәсеннән бары тик тарихи тәңгәллекне эзләү урынсыз булыр иде. Язучы үзе дә тарихи темага язган әсәрләрендә тарихи дөреслеккә турылыклы булуны максат итеп куймый: «Трагический писатель – не историк, следовательно, от него нельзя требовать исторической точности», – дип искәртә ул икенче бер әсәренә – «Михаил, князь Черниговский» дигән трагедиясенә язылган кереш бүлектә[79]. Ләкин С.Н.Глинка үзе шулай дип белдерсә дә, аның әсәрләрендә тормыш дөреслеге бер дә юк икән дигән сүз түгел. Сөембикәнең рус дәүләте алып барган татар җирләрен яулап алу сәясәтенә каршы чыгуы һәм сатлыкҗан Алейга (Шаһгалигә) тискәре мөнәсәбәт күрсәтүе белән автор тарихи чынбарлыкка шактый якын тора.

«Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясе гасырлар чигендә иҗат ителә. Бу – рус әдәбиятында классицизм юнәлеше сентиментализм белән алмашынган, ә сентиментализм исә романтизмга киң ишекләр ачкан бер чор. Шуңа күрә С.Н.Глинка әсәрендә төрле әдәби агымнар, юнәлешләр өчен хас сыйфатларның бергә килеп очрашуы – зарури күренеш.

Сентиментализм юнәлешендә иҗат ителгән әсәрләрдә кешенең характеры аның әхлакый йөзе һәм хис-кичерешләре аша чагылдырыла. С.Н.Глинканың Сөембикәсе төрле каршылыкларга (эчке – Сагрун һәм тышкы – руслар) карамастан, үзенең мәхәббәтен саклап калырга тырыша. Ләкин ханбикә буларак ул үзенең халкы һәм җәмгыять каршында торган бурычларын үти алмый. Әсәрнең бер-ике урынында С.Н.Глинка мәгърифәтче

---

[79] История русского драматического театра. – М.: Искусство, 1977. – Т.1. – С.90.

классицистларча мәхәббәт хисләренең акылны томалавы, йөгәнләве турында сөйләсә дә, трагедиядәге конфликт башлыча романтизм әдәбиятындагыча хәл ителә. Сөембикә, Осман, Эмира кебек сөю утында янган, вөҗдан газаплары кичергән геройлар үзләренең яшәешләрен нәкъ романтик фаҗигаләрдәгечә – үлем белән тәмамлыйлар.

Алдагы бүлектә язганыбызча, инде XVIII гасырның азагында ук рус әдәбияты романтизмга борыла. Әмма бу романтизм әле XIX гасыр башында да башка әдәби күренешләр белән аралашып, үзара керешеп яши. Әдәбиятчылар А.М.Гуревич һәм Ю.В.Манн «Своеобразие романтизма в России определялось и общей особенностью развития русской литературы как художественного явления в начале XIX века: формированность ее движения обусловила «набегание» и совмещение различных стадий, которые в других странах переживались поэтапно» [80] дип язалар. Хәер, рус тарихи драматургиясе буенча чыккан хезмәтләрдә С.Н.Глинка әсәренең иҗат ысулы турында башка төрлерәк карашлар да бар. «Трагедия «Сумбека, или Падение Казанского царства» является в основном классицистическим произведением, – ди В.А.Бочкарев, – отразившим вместе с тем и веяние сентиментализма» [81] . Аныңча, пьесадагы мәхәббәт турындагы карашлар классицизм әдәбияты рухында гәүдәләнгән. «Следуя твердо установившейся в драматургии классицизма традиции, – дип яза В.А.Бочкарев, – автор основал все действия трагедии на любовной интриге. Охваченная любовной страстью к Осману, Сумбека противится выходу замуж за Алея и губит этим свое царство. В пьесе имеется та гиперболизация любви, которая отличала многие классицистические трагедии»[82].

Трагедия жанрындагы хәрәкәтне, сюжет үстерелешен, вакыйгаләр агышын мәхәббәткә бәйләп күрсәтү бер классицизм әдәбияты өчен генә хас сыйфат түгел. Мәхәббәт темасына язылган әсәрләрне урта гасырларда да, яңа заман әдәбиятларында да күпләп очратырга мөмкин. Ләкин һәр чор, һәр әдәби юнәлеш, һәр иҗат ысулы мәхәббәт темасын үзенә хас дөньяга карашлар һәм сәнгати алымнар ярдәмендә чагылдыра.

Безнеңчә, С.Н.Глинканың «Сумбека, или Падение Казанского царства» («Сөембикә, яки Казан ханлыгының егылуы») трагедиясендә мәхәббәт классицизм әдәбиятындагыча гына бирелмәгән. Әсәрдәге Сөембикә мәхәббәтенең гиперболик алымнар белән күпертелеп бирелүе дә, В.А.Бочкарев раслаганча, классицизм файдасына сөйләми. Шундый ук гиперболик сурәтлелекне һәм реалистик, һәм романтик әсәрләрдә күпләп табарга мөмкин. С.Н.Глинка трагедиясендәге төрледән-төрле шартлы алымнар һәм арттырулар бар. Әмма андагы бу гиперболик сурәтләрнең барысы да **романтизм** ысулы файдасына хезмәт итә.

«Сумбека, или Падение Казанского царства» әсәрендә татар ханбикәсенең рухи дөньясын романтизм әдәбиятындагыча сурәтләү очраклы түгел иде. XIX гасыр башы рус әдәбиятында ирекле мәхәббәт темасына бик күп романтик әсәрләр языла: «…было модной в

---

[80] Гуревич А.М., Манн Ю.В. Романтизм в России // Литературный энциклопедический словарь. – М.: Сов. энциклопедия. – 1987. – С.336.
[81] Бочкарев В.А. Русская историческая драматургия (1800–1815) // Ученые записки. – Куйбышев, 1959. – С.423.
[82] Шунда ук. – С.420.

литературе начала века темы свободы чувств, права решать вопросы любви и брака по «выбору сердца»[83]. Рус романтизм әдәбиятының үсеп китүенә Ауропада француз буржуаз революциясеннән соң киң колач белән үсеп киткән романтик әдәбиятның да зур этәргеч ясаганы мәгълүм.

С.Н.Глинканың романтик трагедиясе дә башыннан алып ахырына кадәр Сөембикәнең Османга булган гыйшкы, аның кабул ителмәгән мәхәббәттән өзгәләнүләре турында сөйли. Сөембикә хезмәтчеләреннән торган хор мәхәббәткә – «Галәм Җанына» фәлсәфи эчтәлекле мәдхия уку белән башланып китә:

Любовь! Любовь! Душа вселенной!

Воззри! Сколь силен твой закон [84].

Трагедиянең тукымасына лирик яңгырашлы җыр-музыка килеп керү, Сөембикә мәхәббәтен җир кешеләре мәхәббәте кысаларыннан галәм киңлекләренә чыгара һәм романтик уй-хыяллар, хис-тойгылар дөньясына алып китә.

Трагедиядә Сөембикә, Осман һәм Эмира – өчесе дә гашыйклар. Бу каһарманнарның үзара мөнәсәбәтләре мәхәббәт өчпочмагын тәшкил итә һәм аларның җирдәге тормышы да хисси кануннар белән генә үлчәнә. Алар өчен ярату хисләре акылдан күп дәрәҗәдә өстен тора. Шул мәхәббәт ялкынында үзләрен яндырудан, корбан итүдән дә курыкмыйлар алар. Сөембикәнең мәхәббәте шул кадәр көчле ки, ул Таврия кенәзе Османны Аллаһы дәрәҗәсенә күтәрә, илаһияткә сыгынган кебек, аның алдында баш ия («В Османе божество оно мне представляет», 17 б.). Ханбикә өчен «Осман – Алла» дигән пантеистик фикер әсәр тукымасында берничә мәртәбә кабатлана.

Осман сүзләре белән әйткәндә, С.Н.Глинканың ханбикәсе үзе дә, жаннарны әсир итәрлек, ул кешеләр белән жирдә генә түгел, ә теге дөньяның тәмугълары белән дә идарә итәрлек куәткә ия булган һәм язмыш тарафыннан хакимият биеклекләренә күтәрелгән хатын:

Природой ты пленять все души сотворенна,

Судьбиною наверх величья вознесенна,

И смертными, родясь, всесильно управлять,

Ты можешь власть свою и в тартар простирать (17 б.).

Әмма Сөембикә үз хакимиятен җир өстенә дә, җир астына да таратырга теләми. Ул тәхетен дә онытып, бары тик Осман җанына гына хуҗа булырга тели («нужна власть над твоей душой»). Шуңа күрә ул хан булырга теләгән Алейны да куып җибәрә.

Фаҗигадә Сөембикәнең тышкы кыяфәте, матурлыгы турында тасвирлар күренми. Ләкин хатын-кыз буларак аның каршылыклы эчке дөньясы бик тә тулы һәм җанлы итеп күз алдына

---

[83] История русского драматического театра. – М.: Искусство, 1977. – Т.1. – С.92.
[84] Глинка С.Н. Сумбека, или Падение Казанского царства. – М., 1806. – С.1. Киләчәктә бу трагедиядән өзекләр, мисаллар, астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

китереп бастырыла. Трагедиянең буеннан-буена С.Н.Глинка Сөембикәнең язмыш корбаны булуына басым ясый. Ә язмыш мәсьәләсе – романтик әдәбиятның үзәген тәшкил итүче мотивларның берсе.

Язмыш Сөембикәне дә ханбикә иткән. Ул Казанга тәхет эзләп килмәгән, ә ата–аналар ихтыяры һәм боерыгы буенча чит мәмләкәткә кияүгә бирелгән («К престолу я судьбой была осуждена», 23 б.). Менә хәзер ул, таҗ һәм ханбикә киемнәрен киеп тә, чиксез хакимият иясе булып та, гади хатын-кыз бәхетеннән мәхрүм. Осман белән очрашу Сөембикәдә яшәүгә өмет тудыра. Озак еллар хисләрсез яшәгән ханбикә Османга үлеп гашыйк була. Ул үзенең тәхетен дә, мәхәббәтен дә Таврия кенәзенә тәкъдим итә. Ләкин Осман Сөембикә сөюен җавапсыз калдыра. Алай гына да түгел, аны үзе өчен үлем дип кабул итә.

Осман да автор тарафыннан Сөембикә кебек үк хис кешесе итеп сурәтләнгән. Ул да үзенең сөеклесе Эмирасына булган мәхәббәтен тәхет һәм матди байлыклардан өстен куя. Эмира – Осман өчен яшәү мәгънәсе, галәм зурлыгына тиң мәхәббәт («Твое мне сердце трон, твоя любовь вселенна»). Сөембикә өчен дә Османга булган мәхәббәтнең бер мизгеле мәңгелеккә караганда да кадерлерәк («Вечность ничто перед мигом любви»). Күрәбез ки, каһарманнарның мәхәббәте романтик язучылардагыча, бөтен табигать, галәм киңлекләренә чыгарыла. Ханбикәнең Османга булган мәхәббәтен халык та, сарай тирәсендәге хәрбиләр дә (Сагрун, Асталон), дин башлыгы Сәет тә аңларга теләмиләр. Шуңа күрә Сөембикә мәхәббәте һәркайда кире кагыла. Османны сөюе, Алейны кабул итмәве өчен ул бертуктаусыз гаепләнә. Османның Сафагәрәй хан урынын алачагын ишеткәч, табигать тә дулый – күк күкри, Казансу ярлары дулкынланып, селкенеп куя («При сем слове ударяет, гром и берега реки Казанки колеблются», 35 б.).

Трагедиядәге табигать күренешләре һәрвакыт җанландырылып һәм өч катламга – күкләргә (яшен яшьнәү, күк күкрәү), җир өстенә (кара урмандагы зират, Кама буе, Казан суы, калкулык) һәм җир астына (тәмугъ) бүлеп бирелә. Аларның төп функциясе – Сөембикә җанындагы хисләр киеренкелеген гәүдәләндерү.

Романтик С.Н.Глинка Сөембикәне тулысы белән хис-тойгылар колы итеп тасвирлый. Рус гаскәрләренең Казанга яу белән килүенең сәбәбен дә автор ханбикәнең кирәгеннән артык дәртле, масаючан, үзсүзле, горур табигатьле булуы белән аңлата:

Неодолимое души ея киченье,
К стенам сим привлекло России ополчение.
Для ней один закон – порыв ея страстей!
Страшись... (46 б.)

Халык та Сөембикәнең Осман белән мавыгуын хупламый («Упорностью твоей народ разогорчен», 53 б.). Автор фикеренчә, гади халык идарәчесез яши алмый. Югыйсә, ул Сагрун кебек үзенең мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүче явыз кешеләргә ышанырга, аларга ияреп китәргә мөмкин. Бу урында трагедиягә М.М.Херасков поэмасында булмаган бер мотив – халык белән хакимият каршылыгы мәсьәләсе килеп керә. Популистик

мөрәҗәгатьләр белән Сагрун халыкны Сөембикә идарәсенә каршы фетнә күтәрергә чакыра, үзе тәхеткә килергә омтыла. Аныңча, халык ризасызлыгы Алла ризасызлыгына тиң. Бу фикер әсәрдә «Друзья! Народа глас – есть голос божества» рәвешендә әйтелә. Тискәре Сагрун образы исә романтик әдәбиятта шактый киң таралган җинаятьче тибын хәтерләтә[85].

Рус әдәбиятчылары С.Н.Глинканың халык хәрәкәтләренә каршы чыгуын аның монархиягә турылыклы, искечә фикерләргә яратучы язучы булуы белән аңлаталар: «…консервативно настроенный Глинка относится ко всем проявлениям активности и самостоятельности народа с нескрываемой враждебностью»[86]. Иҗтимагый-сәяси карашлары ягыннан трагедия авторы монархист булырга мөмкин. Әмма шуны да искә алмый булмый: еш кына романтик әсәрләрдә халык һәм хакимият мөнәсәбәтләре антиномия рәвешендә бирелә. Алай гына да түгел, кайбер романтик язучылар (элек, совет чорында, аларны реакцион романтиклар дип атыйлар иде) халыкка түбәнсетебрәк карап, аның Сагрун кебек ялган шигарьле кешеләргә ияреп, сарык көтүе кебек, фетнә юлына басуларын һәлакәт юлы дип санадылар.

Сагрун коткысы аркасында Сөембикәгә каршы чыккан халык дин әһеле Сәет тарафыннан тәнкыйтьләнә. Аныңча, халык хәрәкәтләре коллык алып килә, иксез-чиксез бәлаләр генә тудыра.

Төрле кисәтүләргә, үгет-нәсихәтләргә, юрауларга игътибар бирмичә, Сөембикә Османга кияүгә чыгарга карар кыла. Аның бу адымына бөтен галәм каршы килгән очракта да, ул үзенең мәхәббәт хисләрен саклап калырга омтыла («Но от души моей тебя не отдалю», 23). Ахыр чиктә Сөембикәнең Османны яратуы романтикларча гәүдәләнгән мәхәббәт һәм нәфрәт каршылыгы рәвешен ала.

Ханбикә Сөембикә белән сарайдагы кол кәнизәк Эмира Османның мәхәббәте өчен актык сулышларына кадәр тартышалар. Бер яктан, үзен яратмаган өчен, сөеклесен зинданнан коткарып, бергә качарга теләгәне өчен көнләшү утларында янган Сөембикә Османны әле төрмәгә салырга, әле үтерергә, мәетен аяклары астына ыргытып, таптарга да тели. Икенче яктан, ул һәрчак Османны яратуын таный, аңа булган мәхәббәтеннән ваз кичә алмый («Страх, ревность и любовь терзают разум мой», 17 б.). Мәкерлелек, хыянәт корбаны булган Осман һәлакәтеннән соң Эмира да, Сөембикә дә үз-үзләрен чәнчеп үтерәләр.

С.Н.Глинка фаҗигасендә Казан ханлыгы тарихының соңгы көннәре гәүдәләндерелеп, ханлык сәяси, хәрби яктан бик авыр хәлдә кала. Ул тиздән руслар тарафыннан яулап алынырга тиеш. Күкләрнең дә карары шундый. Моның Аллаһы Тәгалә тарафыннан җибәрелгән афәт икәнлеген фаҗига геройлары да таныйлар. Мәсәлән, ун көн буена Кама буйларында изге әүлиялар рухлары белән аралашып кайткан Сәет тә, Казан егылачак, Сөембикә әсир төшәчәк, ди («Падет, падет Казань, падет!», 19 б.).

Казанны җиңелүдән, җимерелүдән коткару мөмкинлеге дә бар. Ул – Сөембикә йөрәгеннән Османны алып ыргыту, аны шәһәрдән куу. Әмма Сөембикә изге рухлар кушуы

---

[85] Ванслов В.В. Эстетика романтизма. – М.: Искусство, 1966. – С.72.
[86] Бочкарев В.А. Русская историческая драматургия (1800–1815) // Ученые записки. – Куйбышев, 1959. – С.420.

буенча, Алейны тәхеткә утыртып, ә сөеклесе Османны куу белән генә Казан ханлыгын саклап калу мөмкинлегенә ышанмый.

Сөембикә татарларның дошманы, русларга дус булган Алейны һич тә үзенә ир итеп кабул итә алмый («Тот враг отечества, кто друг его врагам», 22 б.). Куе кара нарат агачлары үсеп утырган зиратка килгәч тә, Сәет Сөембикәне кабат «туры юлга» күндерергә тырыша, Алейны Казан идарәчесе итеп кабул итәргә кирәк дигән киңәшен бирә («Прими Алея днес в правители Казани», 58 б.). Ләкин Сөембикә ханлыкка Алей килгәндә генә казанлыларны һәлакәттән коткарып була дигән фикерне кабул итәсе килми. Аныңча, дошманнарга баш ию – таҗ кигән башлар өчен оят. Алейны ханлыкка кабул иткәнче, тәкъдирдә Ханбикә өчен үлем хәерлерәк. Дин әһеле Сәет Сөембикәнең бу сүзләреннән куркып кала, аның исәнлеген теләп, тезләнеп дога кылырга тотына.

С.Н.Глинка сурәтләгән Сәет образы М.М.Херасковның «Россиада» поэмасындагы кара буяулар белән бирелгән мөселман дине вәкиле Сәет образыннан нык аерылып тора. С.Н.Глинканың Сәете – уңай образ. Ул М.М.Херасковтагыча варвар, азгын, караңгылык таратучы, хатыннар артыннан сөйрәлеп йөрүче икейөзле дин әһеле итеп тә күрсәтелми. Ул үзенең төп вазифасын халыкны да, хөкемдарларны да туры юлга күндерүдә күрә. С.Н.Глинканың трагедиясендә сурәтләнгән Сәет тәхеттә утыручы Сөембикә ханбикәгә киңәш-тәкъдимнәр бирү белән генә чикләнә. Аныңча, бәхеткә илтүче юл – Алланың берлегенә һәм барлыгына ышану, иманлы булу, хакимият һәм шәригать кануннарын үтәп, кешелеккә хезмәт итү. Бу турыда Сәет кыска гына болай ди: «Бог, вера и закон – вот к счастью пути!» (32 б.). Сәет ил башлыклары чыгарган кануннарны изге дип саный, аларны да тайпылышсыз үти («Я свято чтил всегда величие короны», 21 б.). Күренекле галим В.В.Ванслов фикеренчә, кеше, халык һәм канун мәсьәләләре – романтик әдәбияттагы үзәк проблемаларның берсе[87].

Дин башлыгы Сәет кенә түгел, үлгән ире Сафагәрәй рухы да Сөембикәгә ханлыкка хуҗа итеп Алейны кайтарырга куша. Аныңча да, Сөембикә Османны шәһәрдән куып җибәрмәгән очракта, Казан ханлыгын да, ханбикәнең тәхетен дә инкыйраз көтә:

Исчезнет твой народ, падет твоя держава!
Казань должна удар последний получить (61 б.).

Әмма Сөембикә Сафагәрәйнең бу куркытуларына да, өркетүләренә дә буйсынырга теләми:

Нельзя судьбины злой, исполнить мне устава,
Нельзя твоим словам покорною мне быть! (61 б.)

Кара төндә урмандагы зиратта Сөембикә шөһрәт яратучы мәкерле гаскәр башлыгы Сагрун белән дә очраша. Икейөзле Сагрунның төп максаты – төрле ялганнар белән халык арасында

[87] Ванслов В.В. Эстетика романтизма. – М.: Искусство, 1966. – С.68-71.

ыгы-зыгы тудыру, тәхеткә үрмәләү. Ул Сөембикәгә: мине синең янга Осман җибәрде, бүгенге көннән башлап, Таврия кенәзе үзенең йөрәк ялкынын сиңа гына багышлаячак, дигән ялган хәбәр алып килә. Бу җылы хәбәргә ышанган Сөембикә, шәһәр тышын руслардан сакларга, алар белән сугышырга дип, Сагрунны җибәрә. Ә шәһәрнең эчке диварларын саклау эше Османга тапшырыла. Шул арада ханбикә янына сөйләшү өчен Свияжскидан рус илчеләре килеп төшә. Алар да Казанда кан коярга теләмибез, шәһәрдә тынычлык булсын өчен Алейны үзеңә ир итеп кабул ит дигән шартыбызны үтә, диләр. Илчеләрнең икенче шарты – Османны шәһәрдән куу, Казан ханлыгын Россия кануннары буенча яшәргә һәм хурлыклы ясак түләргә мәҗбүр итү. Әмма Сөембикә бу хурлыклы шартларны кабул итүдән баш тарта. Аныңча, ханбикә буларак, ул үзенең тәхете белән дә, хәтта гомере белән дә саубуллаша ала. Әмма ул беркайчан да Казан ханлыгын русларга ясак түләүче сыйфатында күрергә теләмәячәк:

Что никогда Казань рабою не была,
Алей, твой Царь и все противники Казани,
Не могут преклонить меня к позорной дани (69 б.).

Бу очракта да Сөембикә үз ватанын, үз халкын яклаучы буларак чыгыш ясый. Рус илчеләре Сөембикәне никадәр куркытсалар да, ханбикә алар әмеренә буйсынмый, халкын ясак түләүче сыйфатында да күрүдән баш тарта:

С престолом, с царством я и с жизнью разлучуся,
Но данницы во мне не будете вы зреть! (69 б.)

Илчеләр Казан диварлары янында, ягъни Свияжскида, татарларны юк итәргә әзер рус кораллары бар бит дип, никадәр генә янамасыннар, рус патшасының хәрби куәте һәм аның турылыклы дусты Алей (Шаһгали) исеме белән никадәр генә өркетмәсеннәр, Сөембикә үз сүзләренә турылыклы булып кала. Ханбикә аларның Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча Казан Мәскәүгә буйсынырга тиеш дигән сүзләренә: «Хыялланыгыз, сез генә инде күкләрнең яраткан халкы», дип дорфа җавап бирә («Мечтайте, что народ любимый вы небес!», 70 б.).

Шул рәвешчә, илчеләрнең ультиматумы казанлылар тарафыннан кабул ителми. Сөембикә Россия белән Казан ханлыгы арасында уртак тел табуга, үзара сөйләшүләр алып баруга каршы түгел. Ләкин ул, патшабикә буларак, рус илчеләренең татарларга бу рәвешле тупас ультиматум куюларын җинаять дип саный. Аныңча, мондый хурлыклы килешүне кабул иткәнче, үлем артыграк («Пусть гибну, коль в себе спасенья не сыщу», 71 б.).

Сөембикәнең бу сүзләреннән соң рус илчеләре күкләргә каршы барасың дип, укларын сындырып, ягъни Казан ханлыгына каршы сугыш вәгъдә итеп, Свияжскига кайтып китәләр. Күкләр тәмугъ белән, дошманнар сугыш белән янаган авыр минутларда да Сөембикә Османга булган ышанычын югалтмый. Әмма шул мизгелдә Сөембикәгә Осман Эмираны зинданнан коткарды һәм аны урлап качты, дигән хәбәр килеп ирешә. Ханбикә таштай катып

кала, аннан акрынлап кабынып китә, «минем җанымда тәмугъ» дип бәргәләнә, өзгәләнә башлый.

Сөембикә Османга булган мәхәббәтен дә онытмый, аңа карата нәфрәтле һәм үчле кичерешләреннән дә арына алмый. Авыр кичерешләр, тау-ташлар ишелгәндәй, ханбикә өстенә өелеп кенә тора. Аңа Сагрунның руслар кылычыннан, ә Османның Асталон кулыннан һәлак булуы турында хәбәр килеп ирешә.

Осман үтерелгәч тә, Сөембикә үзенең язмыш сәгате сукканлыгын, яшәвенең мәгънәсе калмаганлыгын яхшы аңлый. Әмма ул үлемнән куркып дерелдәми дә, киресенчә, аны куанып кабул итә («В пределы смертные с восторгом устремлюсь!», 78 б.).

Трагедиянең кульминациясендә Сөембикәнең шәхси фаҗигасе ил фаҗигасе белән аерылгысыз рәвештә бергә үрелеп бирелә. Җан газапларыннан котылу өчен бердәнбер чара – ул үлем, дигән катгый карарны кабул иткән вакытта, русларның җир астын шартлатуларыннан Казан диварларының бер өлеше җимерелә һәм аннан рус гаскәрләре күренә. Бу куркыныч күренешне күреп алган Сөембикә «халкым, Казаным минем аркада һәлак була» дип җиргә тезләнә һәм егыла, казанлыларга ярдәм кулы суз дип, Аллага ялвара башлый. Хәлсезләнгән Сөембикә тирә-юньдә кан елгалары акканны күрә, илереп кычкырган, ыңгырашкан авазларны ишетә. Аның күз алдына тәмугъ утларыдай Казан ханлыгының фаҗигасе килеп баса. Ә тәмугъ-тартардан аңа Османның чакыруы ишетелгәндәй була. Сөембикә саташа, Осман рухы белән сөйләшә, бәхәсләшә, инде безне бары тик тәмугъ кына кавыштыра ала дип, үз-үзен хәнҗәр белән чәнчеп үтерә. Шул фаҗигале минутта Казан Кремле диварлары каты җимерелә, рус гаскәрләре сарай мәйданына ыргылып керә, ханлыкның соңгы саклаучысы – Асталон да руслар кылычыннан һәлак була.

С.Н.Глинка трагедиясендә романтик шартлылык та, мистик һәм фантастик сурәтләр дә җитәрлек. Шәхси һәм җәмгыяви каршылыкларны хәл иткәндә каһарманнарның рухлары галәм киңлекләренә дә күтәрелә, тәмугъ-тартарга да төшеп китә, Аллага да сыгына, күкләрдән кисәтү дә ала, күрәзәчелек тә итә, изге урыннардагы әрвахлар, зиратлардагы патшалар күләгәсе (өрәге) белән дә киңәшләшә, аралаша. Язучы кулланган бу алымнарның барысы да бер максатка – ханбикә Сөембикәнең рухи азатлыкка булган омтылышын гәүдәләндерүгә хезмәт итә.

С.Н.Глинканың төрледән-төрле шартлы әдәби алымнарга мөрәҗәгать итүен әсәрдәге тарихилык принцибына зыян китерү дип санаучы әдәбият галимнәре дә бар: «Уделив большое внимание мистическому и фантастическому элементу, – ди В.А.Бочкарев, – автор трагедии проявил в то же время беззаботность в отношении историзма»[88]. Тарихи вакыйгаләрне, Сөембикәнең эчке дөньясын әдипнең шартлы алымнар белән «чагылдыруы ваемсызлык» күрсәтү галәмәте түгел иде, билгеле. Киресенчә, романтиклар матур әдәбиятта тарихилык принцибын бозучылар түгел, аны башлап җибәрүчеләр һәм нигезләүчеләр

---

[88] Бочкарев В.А. Русская историческая драматургия (1800–1815) // Ученые записки. – Куйбышев, 1959. – С.422.

булдылар[89]. Шуңа күрә дә В.А.Бочкаревның: «За исключением имен действующих лиц, некоторых названий и отдельных связанның с историей ситуаций – в трагедии нет ничего исторического » дигән фикере белән һич тә килешәсе килми.

С.Н.Глинка трагедиясендәге тарихи дөреслекне чагылдырган кайбер детальләрне, мәсәлән, Казан диварларының җимерелү күренешен сурәтләүне, В.А.Бочкарев театраль эффект артыннан куу дип исәпли. «Изображение в конце пьесы разрушение части Казанской стены автор включил в свою трагедию, надо думать, не для создания исторического колорита, а в погоне за эффектным театральным зрелищем»[90]. Казанны яулап алу тарихын күзаллаган тәкъдирдә галим бу сүзләрне язмас иде, билгеле.

Калкулыкта урнашкан Казан Кремле диварларының немец инженеры А.М.Бутлер җитәкчелегендә махсус шартлатучылар – минерлар төркеме тарафыннан төрле капкалар ягыннан берничә мәртәбә җимерелүе – тарихи мәгълүм факт. Җир асты казылмаларына куелган дары мичкәләрен шартлату нәтиҗәсендә диварларда бик тә зур ике аралык барлыкка килә. Шул җимерекләр аша рус гаскәрләре ханлыкның сарай мәйданына ыргылып керә. С.Н.Глинка әсәрендә бу детальләр тарихи яктан дөрес чагылыш тапкан. Шуңа күрә авторны тарихи колоритны бозуда гаепләү мөмкин түгел. Казанны яулап алу күренешен тасвирлаганда С.Н.Глинка М.М.Херасков тәҗрибәсенә таянган. Аның «Россиада» поэмасында Кремльдәге һәр капка, тирә-юндәге калкулыклар, җир-сулар, авыл шәһәрләр үз исемнәре белән аталып бирелгән.

Трагедиянең буеннан-буена төрледән-төрле мәгънәви вазифа башкаручы һәм кабатланып килүче бер образ бар. Ул – тартар (тәмугъ) образы. Бу сурәт ярдәмендә Сөембикә образы, аның психологиясе үзгәрештә гәүдәләнә; Казан ханлыгындагы вазгыять һәм аның киләчәге турында прогнозлар бирелә; сюжет һәм конфликт күтәренке халәттән фаҗигалелеккә таба хәрәкәт иттерелә һәм үстерелә. Әсәрнең беренче битләрендәге тартар образы ярдәмендә Сөембикә хакимиятенең көч-кодрәте ассызыклана: «Ты можешь власть свою в тартар простирать» дигән мактау сүзләренә ханбикә кирәгеннән артык ышана. «Тәмугъны да тыңлата алам» дип масайган Сөембикә өчен Османның мәхәббәтен яулап алу бик тә гади итеп күзалланган проблемадан олы бер трагедиягә әверелә.

Сине тартар газаплары көтә дип, Сөембикә Османны никадәр генә өркетмәсен, ул ханлык таҗын кияргә теләми, сөеклесе Эмирага турылыклы булып калуын дәвам итә. Кара урман зиратындагы тәмуг капкаларын ачып, вафат булган патшалар рухын уятып, яшен яшьнәтеп, күк күкрәтеп тартар белән сөйләшү, киңәшү, көрәзәчелек итү, кисәтүләр ишетү дә Сөембикәгә мәхәббәт төенен чишәргә, Казанны руслар явыннан коткарып калырга ярдәм итми. Трагедия финалындагы караңгы тартар образы Казан ханлыгының, аның соңгы

[89] Ванслов В.В. Зачатки историзма в эстетике и проблемы народности // Эстетика романтизма. М.:Искусство, 1966. – С.210-232.
[90] Бочкарев В.А. Русская историческая драматургия (1800–1815) // Ученые записки. – Куйбышев, 1959. – С.422.

мәшһүр ханбикәсе Сөембикә кояшының батуын – инкыйразын гәүдәләндерүче куркыныч эчтәлекле романтик символга әверелә.

Күренә ки, С.Н.Глинка трагедиясенең эчтәлеге, анда күтәрелгән мәсьәләләр, образлар системасы – барысы да романтик эстетика кануннары буенча бирелгән. Әсәр геройлары язмышының фаҗига белән очлануы да романтизм ысулы файдасына сөйли. Романтик язучы С.Н.Глинканың казанышы – әсәрнең төп образы Сөембикәне капма-каршы хисләр бәрелешендә һәм характер буларак үзгәрештә сәнгатьчә гәүдәләндерә алуы. Автор ханбикәнең мәхәббәттә азатлыкка омтылышын да кире какмый, киресенчә, аны яклый. Ул Сөембикәне кечкенә бер микрокосмос итеп кенә түгел, олы бер макрокосмос итеп сурәтли. Ханбикә мәхәббәтен Галәм Җаны (Мировая душа) белән чагыштыру шул турыда сөйли.

С.Н.Глинка трагедиясендәге конфликт һәм чишелеш тә тулысы белән романтик язучылардагыча хәл ителә. Автор әйтергә теләгән төп фикер түбәндәгедән гыйбәрәт: Казан ханлыгының һәлакәте – ханбикә Сөембикәнең Османга булган шашкын мәхәббәтеннән һәм нәфрәтеннән туган рухи тотрыксызлык, бәргәләнүләр, өзгәләнүләр һәм югары көчләр тарафыннан билгеләнгән язмыш богауларыннан котыла алмау нәтиҗәсе.

Әйе, дәүләт белән Сөембикә идарә иткән чор татарлар өчен катастрофа булса, Казан ханлыгын җимергән урыслар өчен, Н.М.Карамзин язганча, тарихи бөеклекләргә күтәрелгән бәхетле бер заман иде: «Таланту русскому всего ближе и любезнее прославлять русское в счастливое время, когда монарх и само провидение зовут нас к истинному народному величию»[91].

«Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясенең әһәмияте шунда: әсәрдә С.Н.Глинка Сөембикә образына нисбәттә руслар белән татарлар арасындагы дәүләти-иҗтимагый, сәяси-хәрби мөнәсәбәтләрнең фаҗигалелеген дә, тарихи барышның асылын да күпмедер дәрәҗәдә гаделлеккә хилафлык китермичә гәүдәләндерә алган.

## 4. А.Н.Грузинцевнең «Казанның буйсындырылуы, яки Явыз Иван дип аталган патша Иоанн Васильевич IVнең мәрхәмәтлелеге» трагедиясе

Казан ханлыгының җимерелү вакыйгаләре хакында, Сөембикә ханбикә язмышы турында тагын бер әсәр (С.Н.Глинка белән бер үк вакытларда) А.Н.Грузинцев тарафыннан иҗат ителә. Александр Николаевич Грузинцев (якынча 1779–1819) – чыгышы белән грузин дворяннары нәселеннән. Аның «Покоренная Казань, или Милосердие Царя Иоанна Васильевича IV, проименованного Грозным»[92] («Казанның буйсындырылуы, яки Явыз дип аталган патша Иоанның мәрхәмәтлелеге») трагедиясе 1810 елда басылып чыга. Заманында

[91] Карамзин Н.М. Избранное. – М.: Детская литер., 1990. – С.11.
[92] Грузинцев А.Н. Покоренная Казань, или Милосердие Царя Иоанна Васильевича IV, проименованного Грозным. – СПб., 1810.

ул берничә мәртәбә Мәскәү һәм Петербург сәхнәләрендә куела. Ләкин тора-бара автор үзе дә, аның Казан ханбикәсе турында язылган трагедиясе дә онытыла. Рус әдәбиятчылары пьесаның кыска гомерле булуын инде XIX гасыр өчен актуальлеген югалткан, искергән иҗат ысулы – классицистик рухта язылуында күрәләр: «Связав с юных лет свою творческую судьбу с отживающим литературным течением, писатель сам обрек на забвение свои произведения, тщательно выписанные по законам классицизма»[93]. Дөрестән дә, А.Н.Грузинцевның күпчелек әсәрләрендә грек мифологиясеннән алынган сюжетлар нигезендә, Ломоносов һәм Херасков кебек классицист язучылар традицияләре дәвам иттерелә. Александр шигыре белән язылган «Казанның буйсындырылуы...» трагедиясенең «Россиада» поэмасы тәэсирендә иҗат ителүен А.Н.Грузинцев үзе дә билгеләп үтә. Аның өчен М.М.Херасков үрнәк алырлык ихтирамга лаек язучы булган. Югыйсә, ул «Рассуждение о драматических жанрах» исемле мәкаләсендә «Россиада» поэмасын классицизм әдәбиятының югары баскычы дип саналган антик чор һәм француз әдәбияты әсәрләре белән чагыштырмас иде: «Когда бы мы, россияне имели таких трагиков, какого имеем эпического творца Россиады, то я поставил бы наш театр в равенстве с греческим и французским»[94].

А.Н.Грузинцевның «Казанның буйсындырылуы...» трагедиясе сюжет сызыгының яңача бирелеше белән Сөембикә турында язылган башка рус авторлары әсәрләреннән аерылып тора. Сюжет икенче төрлерәк шәрехләнсә дә, ул шулай да үзенең эчтәлеге, күтәрелгән мәсьәләләр буенча М.М.Херасков поэмасының яңа бер вариантын хәтерләтә. «Россиада»да русларны талаган, изгән, кан диңгезенә батырган өчен Иоанн татарлардан үч алу максатын куя, А.Н.Грузинцев әсәрендә бу мотив саклана, әмма аңа тагын бер яңа мотив – Казан ханлыгын җимергән өчен Сөембикәнең Иоанны үтерергә җыенуы өстәлә. Һәр ике әсәрнең дә геройлары – Иоанн да, Сөембикә дә, классицизм әдәбияты кануннарындагыча, үз дәүләтләре, үз халыклары алдында торган дәүләти бурычны үтәүчеләр итеп гәүдәләнәләр.

А.Н.Грузинцев трагедиясендә, «Россиада» поэмасындагыча, Сөембикә белән Иоанн антиподлар итеп бирелгәннәр: ханбикә – явыз, үчле, ә рус патшасы – мәрхәмәт иясе. Моңа әсәрнең ике катлы итеп бирелгән исеме дә әйтеп тора. М.М.Херасковта төп рольне Иоанн уйнаса, «Казанның буйсындырылуы ...» әсәрендә төп игътибар Сөембикәгә юнәлтелә. Пьесаның өч күренешендә Сөембикә образы бирелү шул хакта сөйли.

Әсәр рус коралының бөек җиңүе – Казанның җимерелүе, ханлыкның даны, шөһрәте тарих чүплегенә себерелеп түгелүе («Казань покорена, исчезла наша слава», 1 б.)[95], аның ханбикәсе Сөембикәнең әсир ителүе белән башланып китә. Иоанн ике йөз ел дәвам ителгән рәнҗетү һәм түгелгән славян каны өчен татарлардан үч алган. Көнчыгыш иленең кызыл ае инде сүнде, баеды, дип горурлана үзенең җиңүе белән Явыз Иван. Ул канәгать: рус халкы һәм православие дине өчен үч алынган, бөтен көнчыгышның иң матур шәһәрләреннән саналган Казан җимерелгән,

---

[93] Русские писатели 1800–1917. – М.: Большая Российская энциклопедия, 1992. – С.51.
[94] Грузинцев А.Н. Рассуждение о драматических творениях // Новости русской литературы. – 1802. – Ч.4. – С.168.
[95] Киләчәктә бу трагедиядән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәteләчәк.

морзалар каны елга булып аккан, Иоанн үзенең патшалык вазифасын үтәгән. «Казанның буйсындырылуы...» трагедиясенең беренче күренешендә Иоанн гаскәрләренең Казанны ничек итеп хәрабә-чүл хәленә китерүләре, кан диңгезенә батырулары турында тасвирлар бар. Казандагы биналар шартлатылган, диварлар ауган; Сөембикәнең яугирләре, сугышчан полклары юкка чыгарылган, шәһәр янгыннар көле астында калган; чокырлар мәетләр белән тулган. Эдигәр дә, Сөембикәнең туганнары да һәлак булган, абыйсы мәетләр өстенә авып, атлардан таптатып издерелгән, кабергә дә иңдерелми калган. Татар кешесенең олысы-кечесе, ирләр, хатыннар, балалар – барысы да кылычтан үткәрелгән бу сугышта («Ни возраст лет, ни пол им не был пощаден», 1 б.) ханлыкның патшабикәсе Сөембикә дә коллыкка төшкән.

Илгә-җиргә шундый коточкыч афәт килгән көннәрдә Сөембикә сеңлесе Эмирага: «Мин Алей белән кавышу сөенеченә ирешә алырмынмы икән?» дигән, һич тә башка сыймаган сорау бирә. Сеңлесе ханбикәнең шундый олы фаҗига вакытында «җинаятьче» Алейга гыйшык тотуына гаҗәпләнә, аны «мескен», «бәхетсез» дип саный. Ире Сафагәрәй үлгәч тә, Сөембикә йөрәгендә мәхәббәт утларын кабызучы Алей була. Аның белән язмышын бәйләргә дә ханбикә риза. Аларга никах укыган вакытта, тәхетне үз кулларына төшерергә теләгән морзалар фетнә күтәрәләр, Алейга богау салалар. Үзен яраткан Алейны азат итү өчен Сөембикә дошманнарының канын коя, күпләрне һәлак итә.

Казан ханлыгы яулап алынгач, дәүләтсез, тәхетсез, таҗсыз калган, сак астына алынган Сөембикә: «язмыш миңа бәлки мәрхәмәтле булыр, тантаналы рәвештә мине Алей белән кавыштырыр әле» дигән өмет белән яши. Алей гыйшкы исә ханбикәгә тәхетен коткару, Иоаннан изге үч («праведное мщение») алу өчен юл ачачак. Алей миңа турылыклы булганда, россияннардан, Иоаннан үч алырга мөмкин булачак дигән фикер әсәрдә еш кабатлана.

Үч алу мотивы А.Н.Грузинцев әсәренең буеннан-буена иллегә якын диярлек мәртәбә кабатлана. Иоанн, Сөембикә, Эмира, Алей, Кырым ханы, Курбский, Троекуров кебек геройлар һәм персонажларның һәрберсе үч алу мәсьәләсе белән мәшгуль. Үч алу мотивына М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында да, С.Н.Глинканың «Сумбека, или Падение Казанского царства» трагедиясендә дә шактый зур урын бирелә. А.Н.Грузинцевның «Казанның буйсындырылуы…» әсәрендәге Сөембикә өчен Явыз Иваннан үч алу төп максатка әверелә. Ханбикә үзен Иоаннан үч алырга лаек һәм хокуклы дип саный. Үз татарлары тарафыннан күп гаделсезлекләр күрсә дә, дошман руслар кулында кол булып яшәү Сөембикә өчен үлемнән артык. Вакыты-вакыты белән ул яшәү һәм үлем турында фәлсәфи фикерләргә дә бирелә («Жизнь – небесный дар», 27 б.). Җир-суларын, дәүләтенең байлыкларын югалткан ханбикә өчен җир йөзендә авыр йөк булып яшәү дә кыен («Всего лишилась я, осталось только мщенье», 27 б.). Әмма әле аның җирдә зур бер эше – Иоаннан үч аласы бар. Үлгән ире Сафагәрәй, шәһит киткән туганнарының рухлары, хәтта җимерелгән тәхет тә Сөембикәне үч алырга чакыра. Ул үзен йә тәхеттә, йә табутта булырга тиеш дип кенә күзаллый; үлсәм дә, Россия дигән илнең терәген – Иоанны үзем белән бергә өстерәп мәңгелек дигән караңгылык

дөньясына алып китәм, ди. Иоанн күкрәгенә нәфрәтле хәнҗәр кадау – Сөембикә өчен изге гамәл.

А.Н.Грузинцев Сөембикәсе дә М.М.Херасков поэмасында гәүдәләнгән ханбикә образы белән аваздаш. «Россиада» поэмасындагы Сөембикә дә Иван һәм руслар каршында нинди дә булса гаебем булса, ул – изге гаеп, ди («И если я винна, свята вина моя», 203б.). А.Н.Грузинцевның ханбикәсе дә туганнарының түгелгән каны өчен үч алуны изге бурыч дип саный һәм аның Алланың хәер-фатихасы белән башкарылачагы турында әйтә:

Кто мстит за кровь родных, тот свой свершает долг,

И справедливу месть благославляет Бог (10 б.).

Алей Сөембикәне әсирлек язмышына буйсынырга, Иоаннан үч алу фикереннән кире кайтырга үгетләп тә карый, ләкин хөкемдарлык таҗы башыннан көчләп салдырылган ханбикә үч алу теләгеннән беркайчан да кире чигенмәячәк («Сумбеку гордую могли венца лишить, Но пламень мщения не в силах потушить, Мой дух непоколебим», 38 б.).

Сөембикәнең нәсел агачы тамырлары да нык. Ул тарихта тирән эз калдырган борынгы «скиф халкына», «Батый ботагына» барып тоташа. Шул ук вакытта ханбикә үзенең кан тамырларында атаклы нугай мирзасы Йосыф каны акканлыгын да онытмый.

Заманында Сөембикә бәхетенә бөтен галәм сокланган, гаҗәпләнгән. Ул Шәрекъ илләренең иҗтимагый-сәяси тормышына да йогынты ясаган Казан ханбикәсе булган. Көчле патшалар да аның алдында калтырап торган («Блаженству моему дивилась вся вселенна. Восток судьбу внимал из уст моих, Тряслись пред мной Цари на тронах громовых», 55 б.). Шундый ук фикер М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында да бар иде. Патша Иван да анда Шәрекънең гүзәл шәһәрен җимердем дип мактана.

Сөембикәнең уй-фикерләрен, хисси дөньясын, вакыйгаләргә мөнәсәбәтен сурәтләгәндә, А.Н.Грузинцев классицизм эстетикасы кануннары буенча эш итә, даими рәвештә аның характерындагы бер сыйфатка – рус патшасы Иоаннан үч алырга омтылуына басым ясый. Бу үч алу мотивы һәлакәткә дучар булган Казан ханлыгын торгызу, аның дәүләтчелеген кире кайтару, башка татар урдаларының (дәүләтләренең) коллык чылбырын киеп йөрүләренә юл куймау максатыннан эшләнә дип аңлатыла. Сөембикә – батыр, горур, акыл-лы, зур ихтыяр көченә ия. Аның бу сыйфатларын ике җәй Казан белән сугышкан дошманы Иоанн да таный («Всегда дивился премудрости жены», 21 б.). Рус патшасы Сөембикәнең акылына гына түгел, аның сугыш вакытындагы рухи батырлыгына да, полклар белән идарә итү осталыгына да соклана: «Но мужеством души ты правила полками» (21 б.).

Җиңелгән дәүләтнең патшабикәсе булса да, Сөембикә, күз яшьләре түгеп, дошманнарын сөендерергә җыенмый. Җимерелгән ханлык өчен Иоанн «әҗерен түләячәк» – кылыч аша үткәреләчәк:

Увидишь, Иоанн, не слезы, а меч в деснице,

И смертью своей он мзду воздаст царице (6 б.).

Рус классицизмы әсәрләрендәгечә, А.Н.Грузинцевның Сөембикәсе ата-бабалардан калган мирасның, төрки-татар тарихы чылбырындагы абруйлы урынының юкка чыгуын теләмәгән горур, масаючан, уй-фикердә һәм гамәлләрдә кыюлык, җәһәтлек күрсәтүче ханбикә итеп гәүдәләнә.

С.Н.Глинка әсәрендәге Сөембикә мәхәббәт ялкынында янып язмышка, тәкъдиргә буйсынса, А.Н.Грузинцевта исә ул акылы, ихтыяр көче ярдәмендә язмышын үзгәртергә омтыла, үч алу юлы белән руслар коллыгыннан котылу, югалткан дәүләтчелеген кайтару өмете белән яши. Сөембикә аңлы рәвештә хәвефле юлдан бара, хәтта үлсә дә, максатына ирешергә тели. Бу сыйфатлары белән ул Н.М.Карамзинның «Марфа–посадница, яки Новгородны буйсындыру» (1802) повестендагы Мәскәү патшасы Иван III деспотизмына каршы чыккан, Новгород шәһәренең мөстәкыйль идарәсе, азатлыгы өчен соң чиккә кадәр көрәшкән көчле рухлы рус хатыны Марфа образын хәтерләтә[96].

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында Иоанн акыл иясе, Сөембикә хис кешесе итеп, капма-каршы куеп чагылдырылган иде. А.Н.Грузинцев трагедиясендә бу антиномия беркадәр үзгәреш кичергән: акыл белән эш итү Сөембикәгә, хисләр ялкынында яну Алейга күчерелгән. Әмма әле бу ханбикә хис-кичерешләрдән бөтенләй азат дигән сүз түгел. Ул да Алейны ярата, әмма бу – салкын акыл белән үлчәнгән, дәүләтчелек мәнфәгатьләренә буйсындырылган мәхәббәт. Кыскасы, Сөембикә классицизм кануннарындагыча акыл белән эш итә, Ватан, ханлык алдындагы бурыч таләп итсә, ул Алейга булган мәхәббәтеннән ваз кичәргә дә риза («Но если честь велит, любовь преодолею, Последую во всем лишь должности моей», 25 б.). Кирәк икән, ул Казан ханлыгын азат итәргә вәгъдә биргән, үзе бер дә яратмаган Кырым ханы белән «противный брак»ка – никахлашуга да барачак Сөембикә, бу мәҗбүриятнең Казан ханлыгы белән Кырымны берләштереп, русларга каршы чыгу, Алтын Урда империясен аякка бастыру, киләчәк буыннарга төрки-татарларның шанлы тарихын кайтару максатыннан эшләнәчәген дә әйтә. Бу очракта да Сөембикә, классицизм әдәбияты геройлары кебек, акыл белән үлчәнгән ихтыяри адымга әзер.

Сөембикә турындагы башка әсәрләрдәге кебек, А.Н.Грузинцев трагедиясендә дә Алей (Шаһгали) Иоанның дусты, фикердәше, булышчысы итеп сурәтләнә. Татарлар тарафыннан ике мәртәбә Казаннан куылган Алей авыр вакытларда рус патшасы янына барып сыена. Иоанн аңа хөрмәт күрсәтә, ярдәм итә, «хәзинәләреннән дә өлеш чыгара», үзенә тиңләшә язган хөкемдар итеп күрсәтә («Едва не равен был ты Росскому царю», 54 б.). Казанны алганда зур батырлыклар күрсәткәне, руслардан да артык сугышканы өчен Иоанн Алейга зур бүләкләр бирергә җыена. Ул Алейның «изге уты»н – Сөембикәгә мәхәббәтен дә таный, ихтирам итә, ханбикәне сеңлесе кебек хөрмәт итәргә җыена («Сумбеку буду я, моей чтить сестрой…», 22 б.); сезгә бергә яшәр өчен Нижний град билгеләнде, ди.

---

[96] История русской литературы XI–XX веков. – М.: Наука. – 1983. – С.136.

Җаны-тәне белән русларга бирелгән Алей Сөембикәне дә ярата, алай гына да түгел, чын мәгънәсендә мәхәббәт авыруы белән авырый. Баштарак Алей Сөембикәнең Иоаннан үч алырга теләвен һич тә аңларга теләми, аның «үч алу утын сүндерергә, үзе белән бергә бәхетле булырга» чакыра. Сөембикә руслардан кем үч ала, шуңа кияүгә чыгам дигән ультиматум куйгач, Алей дусты Иоанн белән ханбикәгә сүнмәс дәрте арасында бәргәләнеп яшәргә мәҗбүр ителә. Ул беркайчан да Иоанның аңа эшләгән яхшылыкларын онытмаячак, кабер капкасы ябылганда да рус патшасы алдында үзен әхлакый бурыч иясе итеп тоячак. Ахыр чиктә Алей Сөембикәгә булышырга, Иоаннан үч алуда катнашырга ризалык бирә һәм, нәтиҗәдә, классицизм геройлары кебек, ерып чыга алмаслык конфликтка дучар ителә. Чөнки аңа Сөембикә гыйшкыннан баш тартса да – «табут», хыянәт юлына басып, дусты Иоанның җанын кыйса да – үлем. Ханбикә теләк-әмерен үтәргә вәгъдә биргән Алей коточкыч вөҗдан газаплары кичерә, Иоанны үтерә калса, шул ук хәнҗәр-кылыч белән үзе дә якты дөнья белән саубуллашырга җыена:

Клянусь, что Иоанн падет мечем сражен,
И сей же будет меч, во грудь мою вонзен (39 б.).

Сөембикә исә бу хакта икенче төрле фаразлый: дошманы үлгән тәкъдирдә, ул Алейны мәхәббәте белән коткарып калачак.

Рус патшасын хөрмәтләгән, татар ханбикәсен чын күңелдән яраткан Алей үч алу планнарын тормышка ашыра алмый, кырымлылар белән бергә фетнә күтәрүдә катнашучы буларак тотыла, җәзалау өчен Иоанн каршына китереп бастырыла. Дустына хыянәтен Алей бик авыр кичерә. Ул инде гаебе өчен җәзага да әзер. Шул мизгелдә Иоанн янына Сөембикә килеп керә, Алейны үч алырга этәрүче, өндәүче үзе икәнлеген танып, бары тик аңа гына җәза бирүен үтенә. Бу җинаятькә баруның сәбәпләрен Сөембикә Иоаннга Казан ханлыгы, аның халкы мәнфәгатьләрен яклау теләге белән ясалган адым иде, дип аңлата.

Күренә ки, А.Н.Грузинцев трагедиясенең кульминациясендә дә классицизмга хас этик карашлардан чыгып, дәүләтчелек идеаллары яклана. Әсәрдәге конфликт кырыс рәвештә чишелешкә якынайганда да, Иоанн белән Сөембикә үзләренең бер-берсенә кылган явызлыкларын, салган зыяннарын дәүләти мәнфәгатьләрне саклаудан туган шәхси гражданлык бурычы итеп аңлаталар. Классицист язучының этик идеалы патшаларның бер-берсен фаш итә торган монологларында ачык гәүдәләнгән. Мәсәлән, Сөембикә Иоанны, кан диңгезенә батырып, Казан ханлыгын яулап алуда, туганнарын үтерүдә, таҗын салдыруда, чәчәк аткан, балкып торган дәүләтендә бары тик хәрабәләр генә калуда, тырыш хезмәт җимеше булган матур биналарның, әллә ничә гасырлык шәһәр диварларын җимерүдә, кыр-яланнарда ерткыч хайваннарга азык булып мәетләр аунап ятуда, ач күзле рус сугышчыларының халыкның алтын-энҗеләрен талауда, үзенең гүзәл бизәкләр, кыйммәтле ташлар белән эшләнгән тәхетен, элгәреге Казан ханнарыннан мирас булып күчкән хәзинәләрне, ханлыктагы гражданнар байлыгын көймәләргә төяп Мәскәүгә озатуда гаепли. Иоанн да Сөембикәгә

шундый ук озын гаепләү һәм аклану монологы белән җавап бирә. Имеш, Россия патшасы урдалылар кылган явыз гамәлләргә җавап кына биргән. Алар славяннарның канын түккән, ике гасырлык коллыкка дучар иткән, Казанга әсирлеккә алып киткән. Ә Иоанн Батый, Аксак Тимер, Туктамыш, Мамай, Купчуг, Сафагәрәйләрнең рус җирләренә афәтле яулары, таланган Мәскәү, җимерелгән Кремль ташлары, пычратылган храмнар, ташка орып үтерелгән картлар, миләре чәчрәп чыккан яшь балалар өчен үч кенә алган. Иоанн исә үзенең дошманнарына карата сугыш кырында гына рәхимсезлек күрсәткән. Явызлык чыганагы, үлем (табутлар) гына өләшүче Казан көлгә әйләндерелгәч, анда Россия байраклары җилферди башлагач, ул тар-мар ителгән татарлардан үч алудан баш тарткан; Сөембикәне дә богаулап әсир итмәгән, үзенә тик патшабикә итеп, аңа кадер-хөрмәт күрсәтергә әмер биргән.

Иоанн белән Сөембикә кан дошманнары һәм сәяси антиподлар гына түгел. Патшалар, тарихи шәхесләр буларак, аларны берләштерә торган бер нокта бар. Ул – Иоанның Россия, Сөембикәнең Казан ханлыгы мәнфәгатьләре өчен тырышулары, сугышулары. Сүз дә юк, абсолют монархия тарафдары булган А.Н.Грузинцев Иоанның сәяси-дәүләти программасын тулырак тасвирлый. Рус патшасының бөтен уй-фикерләре, эш-гамәлләре Россияне «кыргый» халыклар һөҗүменнән коткаруга, рус дәүләте биләмәләрен Ак диңгездән Босфорга, Кавказга кадәр киңәйтүгә, ныгытуга, һәркайда «рус рухы»н тормышка ашыруга юнәлтелгән. Шуны искәртеп үтәргә кирәк: автор Ак диңгез, Босфор, Кавказ кебек географик атамаларны юкка гына әсәр тукымасына кертеп җибәрмәгән. Трагедия иҗат ителгән елларда Россия Төркия (1806–1812) һәм Швециягә каршы (1808–1809) уңышлы гына сугышлар алып бара. Грузияне (1801) һәм Финляндияне (1809) үз биләмәләренә куша.

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасындагыча, Н.А.Грузинцевның Иоанны да – идеаль образ. Ул – акыллы, гадел, шәфкатьле идарәче, рус халкын коткаручы, хуҗа, ата итеп сурәтләнә («спаситель», «отец», «владетель Россов», 44 б.). Һәр рус кешесе Иоанн өчен йөз мәртәбә җанын бирергә әзер. Ил, халык файдасына хезмәт итүче үрнәк патша образы рус классицизмының барлык чорлары һәм үсеш баскычлары өчен хас булды. Бу үзәк темага А.Н.Грузинцев та турылыклы булып калды. Идеаль Иоанн образы ярдәмендә ул рус тарихында, фәлсәфәсендә киң таралган көчле һәм «мәгърифәтле идарәче» («просвещенный монарх») турындагы карашларны алга сөрә. Чыннан да, аның акыллы Иоанны М.М.Херасков, С.Н.Глинка әсәрләрендәге рус патшасы образы белән чагыштырганда күпкә шәфкатьлерәк, игелеклерәк, гаделрәк. А.Н.Грузинцевның Сөембикәсе дә Иоанның антиподы итеп кенә сурәтләнмәгән, ул рус патшасына тиң идарәче дип бирелә. Бу фикер Иоанн исеменнән дә («Тебя всем чтить велел, как бывшую Царицу», 59 б.), Сөембикәнең үзе тарафыннан әйтелгән сүзләр белән дә раслана («Владычица была я равная ему», 8 б.).

Рус патшасының явызлыкка яхшылык белән җавап бирүе трагедия геройларын катарсис кичерергә мәҗбүр итә. Алар Иоанны үтереп үч алу кебек җинаятьнең әшәкелеген, кабахәтлеген аңлап, вөҗдан газаплары кичерәләр, гөнаһлары өчен тәүбә итәләр, рухи чистарыналар, язмышларына буйсыналар.

А.Н.Грузинцев трагедиясенә Иоанн образына бәйле рәвештә гуманистик тенденцияләрнең килеп керүе XVIII йөз ахыры – XIX башында Россия империясендә яшәгән рус булмаган халыкларга мөнәсәбәтнең азмы-күпме уңай якка үзгәреш кичерүе һәм аларга карата түземле булырга кирәк дигән чакыруларның әдәбиятта чагылышы иде. Галимнәр моның сәбәпләрен гасыр башында тәхеткә утырган (1801) Александр I идарәсенә иллюзияләр баглау белән дә, Аурупа иҗтимагый-фәлсәфи фикеренең рус әдәбиятына көчле йогынтысы булу белән дә бәйләп карыйлар.

А.Н.Грузинцев трагедиясе рус әдәбиятындагы классицизмның өченче чорында, аның бик тә көчле мәгърифәтчелек идеологиясе йогынтысын татыган дәвердә языла. Бу андагы геройларның кискен рәвештә уңай һәм тискәре образларга бүленеп, ике сюжет сызыгына корылуында да, идеаль Иоанн образының әхлакый мәсьәләләр белән тыгыз үрелеп бирелүендә дә, конфликтның бик тә сүлпән чишелеш – үгет-нәсыйхәт белән тәмамлануында да күзгә ташлана.

Кайбер сюжет элементларын, әдәби-эстетик фикерләрне А.Н.Грузинцев М.М.Херасков поэмасыннан иҗади кабул итә. Автор Софоклның «Антигона» трагедиясеннән алынган конфликтны рус-татар сәяси мөнәсәбәтләре җирлегенә уңышлы гына күчерә алган. Ләкин «Казанның буйсындырылуы…» әсәрендә М.М.Херасковтагыча грек мифологиясеннән алынган образ-сурәтләр белән мавыгу юк: фабулага караган бик күп чигенешләр (Иоанн гаскәренең Казанга коры һәм су юлы белән килүе, пустынник белән сөйләшүе, Сәетнең Кама буенда изге рухлар белән аралашуы, Сөембикәнең зиратка баруы һәм башка күп эпизодлар) алып ташланылган, төрледән-төрле иҗат ысуллары һәм алымнарының үзара керешеп килүе дә күзәтелми. Трагедиянең буеннан-буена классицизм әдәбияты өчен бик тә әһәмиятле булган дәүләтчелек белән тарихи шәхеснең үзара мөнәсәбәте ничек булырга тиешлеге мәсьәләсе гәүдәләнә.

А.Н.Грузинцев трагедиясе дә уйдырмаларга бай. Әмма анда М.М.Херасков белән С.Н.Глинка әсәрләрендәгечә, төп тарихи дөреслек – руслар белән татарлар арасындагы дәүләти, сәяси, хәрби конфликт, мәгърифәтчелек карашлары белән йомшартылып бирелүгә карамастан, күпмедер дәрәҗәдә обьектив чагылыш тапкан.

## 5. Г.Р.Державинның «Грозный, яки Казанны буйсындыру» операсы

Гавриил Романович Державин (1743–1816) – чыгышы белән Казаннан ерак түгел (35 чакрым чамасы) Кармачи авылында көн күргән морза Нарбеков нәселеннән. Булачак шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе офицер Роман Державин гаиләсендә дөньяга килә. Бүгенге көнгә кадәр Державин турындагы хезмәтләрдә, дәреслекләрдә шагыйрь Казан губернасының Лаеш өязендәге бер утарда туган дигән белешмә бирелә. Бу фикер Державин әсәрләренең

тугыз томлыгын төзүче һәм аңа комментарийлар язучы академик Я.К.Грот тарафыннан әйтелә[97]. Ул исә Державинның кайда тууы турындагы мәгълүматны картлар сөйләгән истәлекләргә («воспоминания старожилов») таянып теркәгән. Шагыйрь исә үз тормышы турындагы язмаларда («Записки») «Гавриил Романович Державин родился в Казани, от благородных родителей, в 1743 году, июля 3 числа» дип язып калдыра. Крайны өйрәнүче галимә А.Гарзавина Державинның туган урынын «бутаучы» итеп академик Я.К.Гротны исәпли. Шагыйрь һәрвакыт Казанны «родной», «родимый» эпитеты белән атап, Казан тирәсендәге утарларын «Казанские имения» дип кенә атаган[98]. Казан гимназиясенең директоры Ю.И.фон Каниц Петербургка Казан тарихы, андагы театр эшчәнлеге турында материаллар җибәргәндә Казанны «ваш родимый город», «ваша обновленная родина является такою красивою, живописью», дип язган[99].

Шагыйрь 1759–1762 елларда яңа гына ачылган Казан гимназиясендә белем ала. Гимназиядә уку елларында Болгар дәүләтенең башкаласы булган Шәһри Болгарга археологик экспедициягә җибәрелә[100]. Үзенең истәлекләрендә бу экспедиция-сәяхәт турында Г.Р.Державин «кайбер корылма-хәрабәләрнең, ягъни хан сараеның, мунчаның һәм җир асты биналары белән тоташтырылган манараның планы төшерелде һәм тышкы күренешләренең рәсеме ясалды. Бакыр, көмеш вә алтын акчалар, йөзекләр, балчыктан ясалган төрле савыт-сабалар табылды һәм Казанга алып кайтылды» дип язып калдыра. Яшь вакытта Болгарда үткәрелгән археологик экспедицияләр вакытында алган тәэсирләр соңрак Державинның әдәби әсәрләрендә дә чагылыш таба.

А.С.Пушкин билгеләп үткәнчә, татарча уйлаган, фикер йөрткән («его гений думал по-татарски») Г.Р.Державин бик яратып татар җырларын тыңлаган. Державинның хатыны Д.А.Дьякова, иренең Казанны сагынып моңсуланган вакытларында, арфада уйнап, Идел буен хәтерләтә торган татар җырларын бик еш башкара торган булган[101]. Туган ягы һәм яшьлек еллары узган Казаны турында Г.Р.Державин «Арфа» (1798) дигән шигырь дә иҗат итә. Анда ул Казан турында болай дип яза:

О колыбель моих первоначальных дней!
Невинности моей и юности обитель!

Әсәрнең буеннан буена Казанга – «туган бишеккә», «Ватан»га, «кадерле туган илгә» ярату, сагыну хисләре белдерелә. Әйе, Державин егерме яшенә кадәр Казанда яшәгән, арфа моңнары исә аңа биредә үткәргән «алтын елларын» дип искә төшергән:

Как весело внимать, когда тобой она
Поет про родину, отечество драгое,

[97] Гарзавина А. Читая Державина (Державин и Казань) // Державин. История и современность. – Казань: Изд-во КГУ, 1993. – С.230.
[98] Шунда ук, – 231 б.
[99] Шунда ук, – 232 б.
[100] Тәрҗеманов Җ. «Бакыр бабай» // Ватаным Татарстан. – 1993. – 3 июль.
[101] Шунда ук.

И возвещает мне, как там цветет весна,

Как время катиться в Казани золотое!

Рус әдәбиятчылары Державинның «Отечества и дым нам сладок и приятен» дигән юлларын Россиягә – Олы Ватанга карата мәхәббәт, патриотик хисләрен белдергән афоризм-әйтем рәвешендә искә алалар. Чынбарлыкта исә, «туган җирнең төтене дә тәмле (татлы)»[102] дигән канатлы сүзләрне Державин Казанга карата әйткән:

Звучи, о Арфа! Ты все о Казани мне!

Звучи, как Павел в ней явился благодостен!

Мила нам добра весть о нашей стороне:

Отечества и дым нам сладок и приятен[103].

Күренекле тарихчы А.Х.Халиков фикеренчә, чыгышы буенча Державинның әтисе генә түгел, әнисе дә Казан татарларыннан булгандыр дип фаразларга мөмкин. «Таким образом, – ди ул, – мы можем считать, что не только по отцовской, но и по материнской линии Державин имел предков татарского, а, может быть, и казанско-татарского происхождения»[104].

Туган төбәк белән бәйле уй-фикерләр, образ-сурәтләр шагыйрьнең бик күп әсәрләрендә очрый. Аның татар шагыйре Габдесәлам шигырьләре белән кызыксынуы, аның тугыз бәетен русчага тәрҗемә итүе очраклы күренеш булмаса кирәк[105].

Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе Сөембикә язмышы да Державинның игътибарын җәлеп иткән. 1779 елда ул «Стихи о Сумбеке» дигән кыскача гына бер шигырь дә яза. М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы белән бер үк елны дөнья күргән бу шигырьдә Сөембикә рус әдәбиятында урнашкан традиция буенча «хәйләкәр», «мәкерле» эпитеты белән сыйфатланса да, Державин аны сихри көчкә ия булган ханбикә дип атый. Сөембикәгә бирелгән бу сыйфатлар соңрак авторның икенче бер әсәрендә дә чагылыш таба.

Казан губернасының тарихы белән кызыксынган һәм аны өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән Державин «Грозный, или Покорение Казани» (1814) дип аталган опера да язып калдыра һәм анда беркадәр урын Сөембикә образына да бирелә. Жанры буенча, милли героик опера дип исәпләнгән «Грозный…» әсәрен ул гомеренең соңгы елларында иҗат итә. Державин үзе дә бу «Грозный…» операсын иҗатындагы әһәмиятле әсәр дип саный һәм аны рус халкының милли тарихын яктырткан героик әсәрләр рәтенә кертә: «А паче героической

[102] Садретдинов Ш.А. Татарские стихи в архиве Державина // Г.Р.Державин: Личность, творчество, современное восприятие. – Казань, 1993. – С.43.
[103] Державин Г.Р. Арфа // Г.Р.Державин. История и современность. – Казань: Изд-во КГУ, 1993. – С.3.
[104] Халиков А.Х. Г.Р.Державин и его татарские предки // Г.Р.Державин: Личность, творчество, современное восприятие. – Казань, 1993. – С.55.
[105] Миңнегулов Х., Садретдинов Ш. Әдәбият: Урта мәктәп һәм гимназияләрнең 9 нчы сыйныфы, урта махсус уку йортлары, педагогия училищелары, колледж һәм лицей укучылары өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 1994. – Б. 176.

каковых природных еще почти у нас нет»[106]. Дөрестән дә, «Грозный…» операсы – Державинның милли героик эчтәлекле бердәнбер әсәре. Моннан тыш аның опера драматургиясенә караган тагы җиде әсәре бар. Ләкин, шуңа да карамастан, К.А.Кокшенева язганча, «собственно оперой – «отечественной героической оперой» – Державин назвал только «Грозного»[107].

Державин опера драматургиясе өчен әсәрләр язу белән мавыккан елларда патша Александр I бертуктаусыз яулап алу сугышлары алып бара. Төркия (1808–1809), Швеция (1806–1812) белән бәрелешә; Финляндия, Бессарабия, Польша кенәзлеге, Грузия, Әзербайҗан җирләрен Россия империясе составына куша; 1812 елгы Ватан сугышында французларны да җиңеп чыга. Россиянең империя буларак чит халыклар җирләрен яулап алу хисабына киңәюгә юл тоткан экспансив сәясәте Державинның «Грозный…» операсында да чагылыш тапкан:

Что север, юг, восток в едину слил державу,
И Россов утвердил величие и славу (638 б.).

«Кереш» сүздә билгеләп үтелгәнчә, бу героик операның эчтәлеге билгесез рус авторының «Казан тарихы»на һәм Казан татарларының бәет-легендалары, риваятьләренә таянып иҗат ителгән: «Содержание ея, – ди автор, – я взял из казанской истории и тамошняго края татарского баснословия»[108]. Рус укучысына аңлаешлы булсын өчен әсәрдә бирелгән астөшермәләрдә Казан ханлыгы тарихына бәйле күп кенә аңлатмалар бирелә; Шәһри Болгар, Кокшайск, Зөя каласы, Кабан күле, Казанка елгасы, Болак, Арча кыры турында этно-географик мәгълүматлар китерелә. Шулай ук Державин Казан ханлыгында яшәгән башка милләт халыклары турында да сөйләп ала; Елан тавында яшәгән аждаһа турындагы легенда белән дә таныштыра; Казан ханлыгының күренекле ханнарыннан берсе булган Сафагәрәй ханның нindirәк шәхес булуына да туктала.

М.М.Херасковның «Россиада» поэмасындагы сюжет сызыгын Державин өлге итеп кабул итми. Иҗади эш итеп, ул бөтенләй үзгә яңа бер әсәр тудырырга тырыша. Опера жанрына мөрәҗәгать итү дә оригинальлеккә омтылыш белән аңлатылса кирәк. М.М.Херасков поэмасыннан ул бары тик сихерче Нигрин һәм үзләренең гүзәллекләре һәм сихри матур тавышлары белән диңгезчеләрне әсирлеккә төшереп, һәлак итә торган мифологик Сирена образларын гына ала.

В.Тредиаковский, М.Ломоносов, А.Сумароков иҗатлары тәэсирендә әдәбиятка килгән Г.Р.Державин «Грозный…» операсындагы образлар системасын борынгы грек трагедияләренә ошатып гәүдәләндерергә тырыша. Операның эчтәлеген ул, 1812 елгы рус-француз сугышы вакыйгаләренә аваздаш иттереп, урда гаскәрләрен француз

[106] Кокшенева К.А. Героическая опера Г.Р.Державина // Г.Р.Державин: личность, творчество, современное восприятие. Тезисы докладов. – Казань, 1993. – С.22.
[107] Шунда ук.
[108] Сочинения Державина / С объяснительными примечаниями Я.Грота. – СПб.: Издание Императорской АН., 1867. – Т.4. – С. 582.

сугышчыларына, сихерче Нигринны Наполеон Бонапартка, Еланны тәмугъта яшәүче һәм утлы зәһәрен рус халкына чәчүче демонга (иблис), Иоанны Александр патшага охшатып иҗат итәргә теләве турында да искәртеп уза.

Әсәрнең исеменнән үк күренеп торганча, төп герой итеп Грозный – Явыз Иван алынган. Ул классицизм әдәбияты геройларына хас сыйфатлар белән гәүдәләнә. Аның бөтен уй-фикерләре рус дәүләтчелеген ныгытуга, киңәйтүгә юнәлтелгән. Кылган гамәлләре һәм барлык уй-фикерләре көчле Россия дәүләтен империя итеп төзүгә кайтып кала:

Что был царь Грозный,

Который вкруг соседей усмирил,

Россию расширил (637 б.).

Классицист язучылар һәрвакытта диярлек үз геройларын идеаллаштырып бирергә омтылдылар. Державин сурәтләгән Иван да киң күңелле, мәрхәмәтле («великодушный»), диндар кеше («прибежный к Богу»), батыр сугышчы, рус халкының бөек атасы һәм яклаучысы итеп сурәтләнә. Ул һәрвакыт Россия дәүләтенең киләчәктәге даны турында уйлый («Но я о будущем величии помышляю», 589 б.).

М.М.Херасков заманындагыча, әле Державин «Грозный» операсын язган елларда да акыл культына нигезләнгән мәгърифәтчелек идеяләренең тамырлары нык һәм көчле иде. Шул сәбәпле, Державин Иванны акыл иясе итеп тә сурәтли. Болай итеп гәүдәләндерү классицизм әдәбияты таләпләренә дә, мәгърифәтчелек әдәбияты карашларына да туры килә иде.

Замандашларының язуына караганда, Державин бик тә гадел һәм туры сүзле кеше булган. Холкының шушы сыйфаты аркасында аңа күп кенә кыенлыклар да кичерергә туры килгән. Әмма шуңа да карамастан, Державин акны ак, караны кара дип язуын дәвам иткән. Күпмедер дәрәҗәдә классицизм әдәбияты традицияләренә каршы килеп, ул Явыз Иван образын тискәре яктан да сыйфатлый. Державин сурәтләгән рус патшасы Казан ханлыгын һәм анда яшәгән татарларның бер кешесен дә калдырмый кырып бетерү, шәһәрләрен җимерү, яндыру, көлгә әверелдерү уе белән яна. Операның башында ук ул бу теләген белдереп, Шаһгалигә болай ди:

Хочу, чтоб наказаний

Ты зрителем Казанцев был

И зрел, как рушил зданьи,

Как град сей вспепелил,

Как в нем чтоб человека

И следа ты не зрел

И целаго дни века

В развалинах лишь ветр свистел[109].

---

[109] Сочинения Державина / С объяснительными примечаниями Я.Грота. – СПб.: Издание

Җимерелгән биналар, манаралар хәрәбәләре арасыннан бары тик сызгырган, ыжгырган җилләрне Державин яшьлегендә Болгарга археологик экспедиция вакытында үз күзләре белән күреп, үз колаклары белән ишетеп кайткан иде. Монголлар тарафыннан җимерелгән Болгар хәрабәләре, Болгар җилләре олыгайган Державинга тагын бер тарихи афәтне – Явыз Иван җимергән Казан каласын искә төшерә («В развалинах лишь ветер свистел»).

Югарыда мисал итеп китерелгән өзек Явыз Иванның исеме җисеменә – кылган гамәлләренә ничек туры килгәнлекне дә, Россиянең империя булып оешып килгәндә Казан ханлыгын яулап алу сәясәтенең нинди коточкыч яман күренеш булганлыгын да күзалларга ярдәм итә.

Реаль чынбарлыкта Иванның казанлыларга җәза бирү турындагы бу программасы тулысы белән тормышка ашырыла. Гүзәл мәчетләре, бай китапханәләре, гөрләп торган сәүдә үзәкләре, мәйданнары, бакчалары булган шәһәр яндырыла. Китаплар көле генә тирә-юнгә алтмыш чакрымга җил белән оча, тарала; гаскәриләр батырларча яуда шәһид була; ир җенесенең күбесе суеп үтерелә, исән калганнар әсирлеккә алып кителә, рус иле «Казан ятимнәре» белән тула.

Бу ерткычлыкны автор Явыз Иваннан, классицизм әдәбияты кануннары таләп иткәнчә, Россиянең дәүләтчелек мәнфәгатләрен, рус халкының якты киләчәге, туачак буыннарның бәхетен тәэмин итү максатын күздә тотып эшли («Но кто счастливые потомству дни кует», «В моих единых днях Россиян силу я в потомстве созидаю», 589 б.). Татарларның дәүләтләрен, идарәчеләрен, халкын юк итүне бурыч итеп куйган Явыз Иван белән Шаһгали дә бәхәскә керә:

Народ всегда порабощенный
Готов рвать цепи наложенны,
И скованный не тверд из разных руд сосуд (589 б.).

Державин язганча, буйсындырылган халык иртәме-соңмы коллык богауларын өзеп, азатлыкка чыгарга омтыла. Төрле мәгъдәннәрдән (рудалардан) кушылып ясалган савыт чыдам булмаган, тиз ватылган кебек, төрле милләт халыкларын көчләп берләштергән дәүләт-империя дә озын гомерле була алмый. Иван патша исә яулап алынган халыкларны руслар белән бергә кушып, аларның милли үзенчәлекләрен юкка чыгару уе белән яши. Бүгенге фәндә аңа «казанда эретү» («плавильный котел») эффекты диләр. Дусты Шаһгали дә Иванның милләтләрне юкка чыгару планына гаҗәпләнә һәм үз-үзенә мондый сорау бирә: «Но ежели его в один состав сольют?» (589 б.). Анынча, халыкларның диннәрен, гореф-гадәтләрен, әхлак кануннарын үзгәртү бары тик тираннар кулыннан килә торган гына эш дип җавап бирә:

---

Императорской Акад. наук, 1867. – Т.4. – С. 590. Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

Ах, государь! ах! Вер, прав, нравов перемену
Удобен предпринять один только тиран (589 б.).

Яулап алынган, буйсындырылган халыкларны көчләп чукындыру, руслаштыру, аларның каннарын бутау, телләрен, гореф-гадәтләрен, диннәрен оныттыру сәясәтенең аяныч нәтиҗәләргә китерәчәген Державин да сизенгән һәм аңлаган. Чыгышы белән татарлардан булган шагыйрь боларның барысын да йөрәге аша үткәргән. Дәүләт эшлеклесе вазифасын үтәгәндә ул Россиядәге бик күп тарихи-сәяси вакыйгаләрнең шаһиты булган, тәрҗемәче С.Хәлфин белән бергәләп Пугачев хәрәкәтендә катнашучыларның эшен тикшергән; Екатерина II белән бергә Казанга да килгән, бу хакта шигырьләр дә язган. Патшабикәнең Идел буенда яшәүче табигатьләре белән бер-берсенә охшамаган егермеләп кавемнең «энергиясен бергә кушып», аларны «Шәрекъне яулап алуда» файдалану һәм Россия чикләрен тагы да киңәйтү планнары белән таныш булган[110]. Губерналар белән идарә иткәндә дә, Екатерина II нең яшерен киңәшчесе вазифасын үтәгәндә дә, халык хәрәкәтләрен тикшергәндә дә – һәркайда Державин Россиянең кануннар нигезендә идарә ителүен таләп иткән. Шуңа күрә «Грозный» операсында Шаһгали авызыннан милли-колониаль изү сәясәтенә каршы шөбһәле фикер әйттерүгә, Иван кебек тираннар сәясәтенә ачыктан-ачык ризасызлык белдерелүгә һич тә гаҗәпләнергә кирәк түгел.

Операдагы башка геройларга килгәндә, Державин үзенең элгәрегеләре кебек, Шаһгалине рус патшасының дусты, колы, ярдәмчесе итеп сурәтли. Иван да Шаһгалигә «…друг, раб мой верный» (585 б.) дип мөрәҗәгать итә. Автор тарихи дөреслекне берникадәр сакларга тырышып, Казанны буйсындыргач та, Казан тәхетен Шаһгалигә кайтарып бирә. Шаһгали исә Иванга гүзәл Сөембикәсез бу дәрәҗә һәм байлыкларның рәхәте булмаячагы турында сөйли һәм ханбикәнең үзенә кире кайтарылуын сорап, патшага мөрәҗәгать итә («Но, государь, я без нея сих благ не ощущаю», 635 б.). Иван, ханбикәнең үзенә карата эшләгән явызлыкларын гафу итеп, Сөембикәне Шаһгалигә кайтарып бирә. Ләкин бу гафу кылу авыр бер шарт үтәлгәндә генә тормышка ашырырга мөмкин: Сөембикә һәм барлык урдалылар, ягъни татарлар христиан диненә күчәргә тиешләр:

Но сердце ты ея и орд всех переплавь:
Бывь христьянин сам, быть христьянами заставь (636 б.).

Явыз Иван, Екатерина II, Александр I кебек рус патшаларының мөселманнарны көчләп чукындыру («заставить»), «рус казанында кайнатып, эретеп яңадан тудыру» («переплавить») сәясәте турында сөйләп, Державин Россия империясендә яшәгән халыклар өчен милли-дини изүнең, шовинистик мөнәсәбәтләрнең соң дәрәҗәгә җиткерелүен сәнгати чаралар белән гәүдәләндерә алган.

---

[110] Михайлова С. Аминова А. Г.Р.Державин и первая Казанская гимназия // Г.Р.Державин. История и современность. – Казань: Изд-во КГУ., 1993. – С.246-248.

Операдагы башка геройларның урыннары беркадәр үзгәртелә төшкән. Эмира – Сөембикәнең хезмәтчесе, кәнизәк кыз түгел. Ул – Казан ханлыгының кануни варисы – Батый хан улы Саин кызы. Ә менә Эдигирей – Казан тәхетенә утыру хыялы белән йөрүче патша улы. Казанда хан булу өчен аңа Эмираны үзенә карату, аңа өйләнү зарур.

Башка рус авторлары әсәрләрендәгечә, Державин да Осман белән Эмира арасындагы мәхәббәт сызыгын дәвам иттерә. Бу сюжет ярдәмендә ул йөрәк кушуы буенча кияүгә чыгу һәм мәхәббәт иреге мәсьәләсен күтәреп чыга. Державин операсындагы Эмира үзенә башкалар сайлаган кешегә – Эдигирейга кияүгә чыгарга риза түгел. Ул Османга булган мәхәббәте өчен көрәшә алырлык зур ихтыяр көченә ия хатын-кыз итеп сурәтләнгән. Бу яктан караганда, Эмира белән Османның мәхәббәте классицизм әдәбияты кануннарындагыча кеше һәм җәмгыять, дәүләт кысалары белән генә чикләнеп калмый. Ул, романтик әдәбияттагыча, «шәхес азатлыгы» рәвешен алып, галәм киңлекләренә чыгарыла:

С тем возмогут ли сравниться,
Что любовью нам дариться?
Сладость душ, сердец, очесть,
Восхищение небес! (603 б.)

Явыз Иван да Осман белән Эмираның ирекле мәхәббәткә булган омтылышларын яклап чыга. Мондый фикерләр Державинның «Грозный» операсында романтик элементларга да өлеш чыгарылу турында сөйли. Ә менә әсәрнең азагында Осман белән Эмира образлары классицизм әдәбиятындагыча гәүдәләнә. Иван патшага тугърылык күрсәткән, Казанны алу тантанасында катнашкан бу геройлар Кырым ханлыгы белән идарә итәргә кайтып китәләр.

Операда Осман белән Эмираның мәхәббәт тарихы Казан тәхете өчен көрәшкә әйләнә. М.М.Херасков, С.Н.Глинка, А.Н.Грузинцев әсәрләре геройлары Осман, Сагрун, Асталоннар да Сөембикә мәхәббәте өчен үзара тартышып, ханбикә белән бергә Казан тәхетенә утыру өчен бәрелешкәннәр иде. Алардагы Сагрун образын Державин исеме ике компоненттан төзелгән Эдигирей (Идегәй һәм Гәрәй) образы белән алыштыра. Нугай якларыннан килгән бу шаһзадә ничек кенә булса да Эмираны үзенә каратып, Казан тәхетенә хуҗа булырга омтыла. Шундый ук ният белән кырымлы Осман да Эмирага мәхәббәттә турылыклылык саклый. Автор Казан тәхете тирәсендә булган ыгы-зыгыларны, төрле фиркаләр арасындагы сәяси талашларны Сөембикә, Эмира, Осман, Эдигерей кебек геройларның мәхәббәт өчен үзара тарткалашулары рәвешендә гәүдәләндерә. Осман образында Кырым партиясенең, Эдигерей образында Нугай төркеменең, Шаһгали мисалында Мәскәү тарафдарларының Казан тәхете өчен алып барган көрәшләре чагылыш таба. Операның башында ук Шаһгали Иванга Казан эчендәге бу таркаулыктан файдаланып калырга киңәш бирә:

Ты видел, государь, меж ими прю?
Всяк к своему склонял тебя царю.
Ты можешь обратить их в пользу несогласье (596 б.)

Сүз уңаеннан шуны да искәртеп үтәргә кирәк, үзенең акыллы киңәшләре, тугърылыклы булуы белән Шаһгали образы алдагы рус авторлары әсәрләрендә очраган рус патшасының ярдәмчесе, киңәшчесе һәм якын дусты Адашев чалымнарын хәтерләтә.

«Грозный…» операсындагы образлар системасы классицизм әдәбияты кануннары буенча гәүдәләнгән. Андагы күпчелек геройлар – патшалар һәм ханнар нәселеннән. Мәсәлән, Иван – росслар патшасы, Сөембикә, Сафагәрәй, Шаһгали – Казан ханнары. Эмира – бөек җиһангир Чыңгыз нәселеннән. Эдигирей да чыгышы белән ханнар нәселенә барып тоташа. Осман Нугай шаһзадәсе итеп бирелә. Микулинский белән Серебряный кебек хәрби җитәкчеләр образлары да классицизм әдәбияты кануннарына туры килә. «Фәнни ачышлар» иясе, Казан диварларын шартлатканда үзе дә һәлак булган Розмысл образы шулай ук хәрбиләргә якын тора. «Грозный…» операсындагы идарәчеләр һәм хәрбиләр образлары, классицизм әдәбияты кагыйдәләре таләп иткәнчә, статик халәттә сурәтләнгәннәр. Кыскасы, Иоанн кебек геройлар әсәрнең башыннан азагына кадәр Россия дәүләтен ныгытучы һәм рус халкы турында кайгыртучанлык күрсәтүче уңай геройлар рәвешендә күзалланалар. Ә менә Сөембикә образына нисбәттә мондый турысызыклылык күзәтелми.

Автор ханбикәне мәхәббәт һәм хыянәт утларында яну, өзгәләнүләр кебек психологик кичерешләр, рухи чистарынулар аша үтәргә мәҗбүр итә. Державинның Сөембикә образына карата мөнәсәбәте каршылыклы һәм катлаулы. Әсәрнең беренче өлешендә Г.Р.Державин Казан тәхетеннән куылган, сөеклесе Осман тарафыннан да хыянәткә юлыккан Сөембикә образын сурәтли. Тәхетеннән куылган ханбикәне Кырым патшасы улы Осман да яратмый, аның хисләренә җавап бирми. Казан тәхете турында хыялланган Османга таҗын югалткан Сөембикә кирәк тә түгел. Шуңа күрә ул ханбикәнең мәхәббәт турындагы теләк-омтылышларын канәгатьләндерергә җыенмый. Ә Сөембикә исә, төрле хәйлә-сихер юлы белән булса да, Османны үзенә карату һәм аның белән берлектә Казан ханлыгы белән идарә итү турында хыяллана. Үзенең өмет-хыялларын тормышка ашыруда ярдәм сорап, ул сихерче Нигринга мөрәҗәгать итә. Әмма ул да ярдәм кулы сузудан баш тарткач, Сөембикә хәйлә-мәкер юлына аяк баса. Матурлыкта тиңе булмаган Эмираны рус патшасы Иванга биреп җибәреп, ул көндәшен Османнан һәм Казан тәхетеннән ераклаштырырга тели.

Ханбикә бер Эмирага каршы гына көрәшми. Операның барлык геройлары диярлек Сөембикәгә каршы чыгалар. Казан тәхетенә дәгъвә белдерүче Осман, Эдигерей, Эмира, Шаһгали кебек геройларның барысы да ханлыкның аяныч хәлгә төшүенең сәбәпләрен Сөембикәдән эзлиләр. Мәсәлән, Шаһгали өчен дә Сөембикә – елан кебек мәкерле, хыянәтчел хатын:

Змия сия, ласкав, точила;

Но ныне, вижу, изменила!

Неверная жена! (597 б.)

Казан тәхете тирәсендә бөтерелгән бөтен геройлар йомшак, көчсез, гаугачыл итеп тасвирланганнар. Казан ханлыгын рус гаскәрләреннән сакларга кирәк булган минутларда да алар берләшә алмыйлар.

Операның башында Сөембикә үз сүзле, каты күңелле, хәйләкәр, мәкерле итеп тасвирланса, икенче яртысында исә авторның аңа карата мөнәсәбәте үзгәрә. Ханбикә күп вакыйгаләрнең асылын аңлап, катарсис кичерә һәм соңлап булса да Казанын, тәхетен яклау эшенә керешә. Бу очракта аның эш-гамәлләре классицизм әдәбияты геройларын хәтерләтә башлый.

Төрле ысуллар – чибәрлеге, гүзәллеге һәм хәйлә, тылсым ярдәмендә Иванны ханлыкны басып алу фикереннән кире кайтара алмагач, рус гаскәрләре Казан капкасы төбенә килеп баскан сәгатьләрдә Сөембикә тәхетне саклау эшенә үзе керешә. Ләкин тәхет тирәсендәге даирәләр һәм халык тарафыннан яклау табалмаган ханбикә, Казан тәхетен дошманнардан коткарып калу өчен ярдәм сорап, сихерче Нигрингә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була:

То, сильный волхв! Ты сей обиды не сноси,

Отечество спаси (628 б.).

Нигрин исә Сөембикәгә, Сафагәрәй хан кабере янына барып, аннан ярдәм сорарга кирәклеген әйтә. Казанны руслар явыннан саклап калу уена килгән Сөембикә көндәше Эмираны да, аның мәхәббәт хисләрен кире каккан Османны да гафу итә («И узников моих прощаю», 628 б.). Алар бергәләшеп рус гаскәрләренә каршы торырга хәзерләнәләр («И освободим Казань, 629 б.).

Казанны саклаучылар алдында авырлыклар моның белән генә бетми әле. Казан ханнары күмелгән изге каберлеккә керү өчен опера геройларына (Сөембикә, Нигрин, Эмира, Осман) рухи сафлану – катарсис баскычлары аша үтәргә туры килә. Аларны бөтен тирә-ягы ут белән чолгап алынган куе урман каршы ала. Ә бу ут аша Сөембикәгә тугърылыклы, изге нияттә булган кешеләр генә үтә алалар. Эш-гамәлләре, уй-фикерләре белән рус патшасы Иван ягына авышкан һәм Сөембикә каршы чыккан Осман белән Эмира, бу ут аша чыга алмыйча, кире чигенергә мәҗбүр булалар («Неверен мне Осман и недруг мне Эмира», 630 б.). Геройларны бу рәвешчә ут белән сынау алымын автор утка табынучылар диненнән – Авестадан алган. Зәрдәштилек диненең йогынтысы бик күп халыкларның борынгы йолаларында күзәтелә. Аның ерак гасырлардан килгән эзләре төрки халыкларда да, рус-славяннарда да сакланып калган. Утка табыну йоласы русларның фольклор әсәрләрендә, гореф-гадәтләрендә, дини бәйрәмнәрендә күзәтелә. Державин операсында да геройларның рухи дөньясы изге ут ярдәмендә сынала, тикшерелә. Шул рәвешчә, операда классицизм әдәбияты өчен традицион «Ватанны коткару» идеясе (бу очракта Казанны руслар явыннан саклап калу) әкияти-фантастик, дини-мистик эчтәлектәге шартлы алымнар ярдәмендә гәүдәләндерелә.

Ләкин Нигрин киңәшен тотып Сафагәрәй ханның күләгәсе белән сөйләшүләр дә,

Сафагәрәй күләгәсе белән Явыз Иван арасындагы көч сынашулар да Казан ханлыгын руслар һөҗүменнән коткарып кала алмый. Иван җитәкчелегендәге баскынчылар тарафыннан Урта Иделдәге татар дәүләте җимерелә.

Г.Р.Державин иҗат иткән Сөембикә образы реаль ханбикә образыннан бик ерак тора. Автор аны прототибына – реаль шәхескә якынайтып түгел, ә күбрәк әкият геройларына охшатып тасвирлаган. Державин үзе дә тарихи дөреслеккә якын килүне максат итеп куймаган. Аныңча, опера жанрында иҗат итүчеләр, әсәрнең әдәби ягына күбрәк игътибар итеп, тарихи чынбарлыктан читләшергә дә мөмкин: «смело уклоняться от естественного пути и даже совсем его выпускать из виду…»[111].

Классицизм әдәбиятында мифологик элементларга зур әһәмият бирелә. Державинның «Грозный» операсында да мифологик, фантастик элементлар тулып ята. Әсәрнең башыннан алып азагына кадәр татар мифларыннан, риваятьләреннән алынган аждаһа образы кабатланып килә. Шуны да әйтергә кирәк: руслар үзләре өчен явыз көч дип исәпләгән урдалылар, ягъни татарларны аждаһа образы ярдәмендә символлаштырганнар. Шул сәбәпле татар ханбикәсе образы елан белән чагыштырыла. Берничә урында автор, комментарийлар бирә-бирә татарлар арасында киң таралган аждаһа турындагы легендалар белән таныштыра. Аждаһа Казанның «изге сакчысы» итеп тә бирелә. Хәтта Явыз Иван образын да автор Казан тирәсендә яшәгән аждаһа белән көрәштерә. Имеш, Елан тавындагы аждаһаны җиңгән тәкъдирдә генә Иван Казанны ала алачак:

Без чародея
Не можешь ты змея,
О царь! Победить,
Казань покорить (595 б.).

Елан-аждаһа тотемының татар ханнары гербында гәүдәләнүен дә искә төшереп, Державин бу хакта түбәндәге аңлатманы биреп үтә: «В гербе казанском изображается змей некоего страннаго вида» (626 б.). «Грозный» операсында тылсым иясе, күрәзәче, сихерче Нигрин образы булу һәм Сөембикәгә дә дәрвиш киемнәре кидерү – классицизм рухында бирелгән образлар системасының романтик алымнар белән дә сурәтләнүе турында сөйли.

Гомумән алганда, Державин иҗаты рус әдәбиятында бик тә үзенчәлекле һәм гаҗәеп күренеш дип исәпләнә. Рус галимнәре аны бик күп әдәби ачышларга нигез салучы дип атыйлар: «Поэт выступает предтечей многих художественных достижений и открытий, которые будут сделаны русскими писателями в XIX веке»[112]. Шуңа күрәдер инде, «Грозный» операсы белән танышып чыккач та, әсәрнең икенче яртысын бөтенләй икенче кеше яздымы икән әллә дигән сорау да туа. Чөнки Казан ханлыгын басып алучыларга каршы

---

[111] Кокшенева К.А. Героическая опера Г.Р.Державина // Г.Р.Державин: личность, творчество, современное восприятие. Тезисы докладов. – Казань, 1993. – С.22.
[112] Герлован О.К. Сказка-романс Г.Р.Державина «Царь-девица» // Г.Р.Державин: личность, творчество, современное восприятие. Тезисы докладов. – Казань, 1993. – С.12.

көрәштә Сөембикә белән сихерче Нигрин кинәт кенә рус әкиятләре геройларына, дөресрәге Кыш бабай һәм Кар кызы образларына әверелеп китәләр. Ак чәчләрен тузгыткан Сөембикә белән Нигрин киң һәм иркен чиркәү поплары киемнәрендә болытларга утырган килеш рус сугышчылары өстенә салкын бәс һәм буран җибәрәләр: «Нигрин и Сумбека в белых, широких ризах с седыми волосами, летая на облаках, бросают, первый из чалмы, а вторая из мохнатой муфты (или рукава) иней на воздух и на землю, напуская тем на Русских стужу и метел» (632 б.).

Сихер көченә ия булган Сөембикә күрәзәчелек тә итә ала. Әсәрнең башында ук ханбикә рус патшасы Иван белән очрашу вакытында якын киләчәктә Иван патшаның Казан ханлыгын басып алачагы турында юраулар ясый:

Нет! Нет! Побьет Москва,

Так глас везде гремит народный (593 б.).

XVI гасырда язылган «Казан тарихы»нда да Сафагәрәй ханның хатыннарыннан берсе тиздән Мәскәү патшасының Казан ханлыгын җиңәчәк дип күрәзәчелек итә. Бу мотивны Державин да әсәр тукымасына кертеп җибәрә һәм аны Сөембикә исеме белән бәйли.

«Грозный, или Покорение Казани» операсының азагы могҗизалылык һәм тылсым белән тулы рус халык әкиятләре мотивлары белән баетылган, романтик рухта язылган әдәби әкияткә охшап кала. Шул рәвешчә, классицизм рухында язылган әсәр тукымасына кабат романтик элементлар килеп керә.

Әсәрдә бик тә күп очраган мифологик, фантастик элементлар, бер яктан, классицизм әдәбиятындагыча бирелсәләр, икенче яктан, бу шартлы образ-сурәтләр әсәрдәге романтик фонны һәм халәтне көчәйтә төшәләр. Елан тавындагы аждаһа, татар ханнары күмелгән нарат урманы, сихерче Нигрин, Кыш бабай һәм Кар кызы образларына мөрәҗәгать итү – болар барысы да авторның сәнгатьчә фикерләвен романтизмга якынайта. Державинның классицистик иҗатында романтизм элементлары булуына әдәбиятчылар да игътибар итәләр: «В конце 18 – начале 19 веков русский классицизм испытывает воздействие сентиментализма и преромантизма, что сказывается в поэзии Державина…»[113].

Оригиналь сюжет һәм образлар системасы тәкъдим иткән Державин «Грозный» операсын традицион чишелеш белән тәмамлый. Казан ханлыгын җиңгән Явыз Иван тантана итә. Аңа каршы чыккан Сөембикә ханбикә дә гафу ителә. Державин иҗат иткән Явыз Иванның бу шәфкатьле адымнары А.Н.Грузинцевның «Буйсындырылган Казан, яки Явыз дип аталган Иван IV патшаның мәрхәмәтлелеге» әсәрендәге шәфкатьле, хәтта үзенең кан дошманнарын да гафу итә алу көченә ия булган Иоанн образын хәтерләтә. Бу – бер яктан, әдәби традиция булса, икенче яктан, Державин иҗаты өчен хас бер үзенчәлек белән дә аңлатыла. Ул Явыз Иванны «росслар» турында кайгыртучы, дошманнарына карата каты

[113] Бахмутский В.Я. Классицизм // Литературный энциклопедический словарь. – М.: Сов. энциклопедия, 1987. – С.158.

куллы тиран-патша итеп кенә сурәтләмичә, аны классицист һәм мәгърифәтче язучыларча, кирәк чакта мәрхәмәтле дә була алган акыллы һәм идеаль патша образын да иҗат итә. Шуңа күрә Иванның кырыслыгы да тарихи зарурият итеп аңлатыла («Он должен зло карать, хотя бы и невольно», 637 б.).

Гомумән алганда, Державинның «Грозный» операсы – классицизм кануннары буенча иҗат ителгән әсәр. Әсәргә язылган керештә бу турыда автор кат-кат үзе дә басым ясый, аның Ватанга, хәрби батырлыкларга һәм башка изге эшләргә һәйкәл буларак язылуын искәртә. Державинның үз сүзләре белән әйткәндә, операда – «…любовь к отечеству к воинским подвигам и прочим героическим добродетелям»[114].

«Грозный» операсының эчтәлегенә, проблематикасына, образлар системасына беркадәр күзәтү ясагач та, Казанда туган, үскән, ә инде беркадәр соңрак танылган шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе булып киткән Г.Р.Державинның татар халкының фольклорын, яшәү рәвешен, тарихын, аның рус дәүләте белән иҗтимагый-сәяси мөнәсәбәтләре үзенчәлеген, шул замандагы вәзгыятьне бик тә яхшы белгәнлеге күзәтелә. Чыгышы белән татарлардан булган, ә бөтен гомерен рус дәүләтенә турылыклы хезмәткә багышлаган, христиан динендәге язучы Сөембикә образын ничек гәүдәләндерергә тиеш иде соң дигән сорау туа. Билгеле, моңа классицистлар кебек турысызыклы гына фикер йөртеп җавап бирү мөмкин түгел. Әдәбиятчы Г.А.Лесскис фикеренчә, Державин үзенең дөньяга карашларында «алтын урта»ны чагылдырырга омтылган. «Державин стремился, – ди ул, – разрешить характерную для классицизма коллизию «долга и страсти» на основе компромисса, выражением которого был принцип и золотой середины»[115]. Бу фикер белән, бәлки, килешергә дә кирәктер.

## 6. М.С.Рыбушкинның «Иоанн, яки Казанның алынуы» трагедиясе

Казан ханлыгы һәм аның мәликәсе Сөембикә язмышы турында чираттагы әсәр 1814 елда Рыбушкин Михаил Самсонович (1792–1849) тарафыннан иҗат ителә. Сигез яшьлек вакытында гаиләсе белән Сембер шәһәреннән килгән М.С.Рыбушкин Казан университетында белем ала, аны бетерү белән үк кандидат дәрәҗәсенә лаек була. Казан тарихын өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән бу галим Казан төбәгенең «беренче журналист»ы һәм «краевед-энтузиаст»ы дип аталып йөртелә.

Күренекле шагыйрь, тәрҗемәче Н.М.Ибраһимов белән танышу һәм ул оештырган әдәбият яратучылар түгәрәгенә йөрү М.С.Рыбушкинның әдәби сәләте уянуга, студентларның кулдан язылган журналларында беренче шигырьләре (1812) барлыкка килүгә

[114] Сочинения Державина / С объяснительными примечаниями Я.Грота. – СПб.: Издание Императорской Акад. наук, 1867. – Т.4. – С. 581.
[115] Лесскис Г.А. Державин Гаврила Романович // КЛЭ. – М.: Сов. энциклопедия, 1964. – Т.2. – С.596-598.

сәбәп була. 1813 елда ике трагедия дә язып өлгертә. Шуларның берсе – «Иоанн, или Взятие Казани»[116] дигәне бер елдан соң, ягъни 1814 елда басылып та чыга.

М.С.Рыбушкин аңа кадәр язылган рус авторлары – М.М.Херасков, А.Н.Грузинцев, С.Н.Глинка әсәрләренә таянып, шул ук сюжет нигезендә һәм шул ук геройлар катнашында биш бүлектән торган чәчмә әсәр иҗат итә. Сюжет сызыгының үстерелеше һәм Сөембикә образының сәнгатьчә гәүдәләнеше буенча аның фаҗигасе С.Н.Глинка әсәренә бик якын тора.

Әсәрнең кайсы иҗат ысулы белән язылуы турында да кистереп әйтеп булмый. Әсәрдә классицизм һәм романтизм юнәлешләренең бергә катнашуын, үзара тыгыз үрелеп бирелүен күзәтергә мөмкин. Трагедиядә классицизм әдәбиятлары өчен хас дәүләтчелек идеяләре – идарәче һәм халык, дәүләт иминлеге, халык һәм дәүләт файдасына хезмәт итү кебек фикерләр яңгырый. Шуңа күрә рус патшасы Иоанн да хәрби җитәкчеләр Курбский, Палецкий һәм якын дусты, киңәшчесе Адашев катнашында узган бер җыелышта рус халкының әсирлек чылбыры йөртүендә рус кенәзләренең үзара ызгыш–талашлары сәбәп булды, ди. Иоанн илне берләштереп, ике йөз ел дәвам иткән бу әсирлек чылбырын өзү, рус халкын коллыктан азат итү кебек фикерләрне алга сөрә.

М.С.Рыбушкин трагедиясендә тасвирланган Иоанн образы М.М.Херасков белән А.Н.Грузинцев әсәрләрендә сурәтләнгән рус патшасы образының дәвамы булып тора. Ул, яшь вакытларындагыча кәеф-сафа коруларын ташлап, бушка үткән гомеренә үкенеч белдереп, илне берләштереп, халкын урдалылар коллыгыннан азат итүне үзенең олы максаты итеп куя. Байлыкта коенып, ваемсыз идарәче булып яшәгән Иоанны дөрес юлга бастыруда аның акыллы, тәҗрибәле киңәшчесе Адашев зур эш башкара. Патшаның төшенә кергән изге карт та рәнҗетелгән бабалары рухын онытмыйча, Казанны буйсындыруны таләп итә («Поди в Казань и покори ее», 45 б.). Рус дәүләтенең терәкләре булган Серебряный, Курбский, Палецкий кебек хәрбиләр россиялеләр беркайчан да Ватаннарына хыянәт итмәделәр һәм итмәячәкләр дип, патшаны христиан дине, үткән тарих, Ватан өчен татарлардан үч алырга өндиләр («Защитим отечество – или смерть, или независимость», 33 б.). Алар тәэсирендә «тормышымнан башка бернәрсәне дә югалтмыйм» дип («кроме жизни более не потеряем», 35 б.), Иоанн Казанга каршы яу чыгарга, гаскәре белән үзе дә турыдан-туры сугышта катнашырга карар бирә. Аның бу катгый карары Адашевны борчуга сала. Ул Иоаннга көмәнле хатыны Анастасия һәм туачак баласы хакына сугышның эченә кермә, Казанны алуны хәрбиләргә тапшыр, дип ялвара. Классицизм геройлары рухында иҗат ителгән Иоаннга хатыны, баласы гына түгел, рус илендәге һәр кеше кадерле, ул аларның барысы өчен дә үзен корбан итәргә әзер: «Но не все ли подданные дети мне?» Не должен ли я умереть за них?» (36 б.), – ди ул.

---

[116] Рыбушкин И.С. Иоанн, или Взятие Казани. – Казань: типография университета, 1814. – С.110. Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

Казанга каршы сугышның бик тә җаваплы сул канатына Иоанн үзенең турылыклы дусты Алейны билгеләргә җыена. Аның бу карары дәүләт киңәшчесе Адашевта, хәрбиләр Серебряный, Курбский белән Палецкийларда шик уята, бәхәскә дә сәбәп була. Алар фикеренчә, бары тик россиялеләр – руслар гына Ватанга турылыклы була ала. Бу турыда хәрби җитәкче Серебряный болай ди: «Я Россиянен, а Россиянен никогда не был изменником!» (32 б.). Алейга килгәндә исә, «ул – мөселман, татар», хыянәт юлына басарга мөмкин. Шуңа күрә дә Адашев : «Почему полагаться на татарина – вот Россияне, вот истинные герои» (38 б.); «Я никогда не верил ему, Алей – татарин», – ди ул (47 б.).

Христиан динен мөселманлыкка, рус менталитетын татарларга каршы кую теге яки бу дәрәҗәдә Сөембикә турында әсәрләр язган күпчелек рус авторларында очрый. Әмма М.С.Рыбушкин трагедиясендә бу аеруча күзгә ташлана. Ул беренчеләрдән булып диярлек «татар» этнонимын кулланышка кертә.

Сөембикә турында язган башка рус авторлары кебек, М.С.Рыбушкин Иоанн образын классицистларча идеаллаштырып бирә. Ул – чын мәгънәсендә дәүләт мәнфәгатьләре турында кайгыртучы, таркау рус җирләрен бергә җыйнаучы, самодержавиене ныгытучы, дошманнарын гафу итә белүче зур ихтыяр көченә ия булган, һәрдаим Аллага сыгынучы патша. Ул үзенең якыннары, дуслары турында кайгыртучанлык күрсәтү белән бергә, дошманнарына карата да шәфкатьлелек күрсәтә белә: Сагрунны җәзаламый, үзенә буйсынырга гына куша. Хәрабәләр астында калып һәлак булган Сөембикәнең мәете табылган очракта, аны патшаларга лаек хөрмәт белән җир куенына тапшыру кирәклеген әйтә: «Если найдется тело ее, должно предать его земле с должною почестью – Сумбека была Царица!» (99 б.). Мондый уңай әхлакый сыйфатларга ия булган Иоанн А.Н.Грузинцев әсәрендәге патша образына бик тә якын тора.

Казанны яулап алганда һәлак булганнарның исемнәрен мәңгеләштерү йөзеннән һәйкәл – Храм төзүне дә Иоанн үзенең изге бурычы дип саный: «Соорудим Храм над трупами падших за Отечество Россиян во имя Бога Спасителя. Пусть всякий Росс, возрев на него в изумлении скажет: Силен Бог правды!» (110 б.). Трагедия менә шундый Казан җимерелү – «татар иго»сыннан котылу, илаһи гаделлекнең җиңүе дигән тантаналы сүзләр белән тәмамлана.

М.С.Рыбушкинның «Иоанн, яки Казанның алынуы» трагедиясе басылып чыккан көннәрдә 1552 елгы сугышта һәлак булган рус шәһитләренә һәйкәл салына башлаган була. Архитектор Н.Ф.Алферов проекты буенча эшләнгән бу һәйкәл 1816–1823 еллар аралыгында төзелеп бетә.

Трагедиядә Сөембикә һәм аның Османга булган мәхәббәт линиясе романтик хис–кичерешләр белән баетылган. Мәхәббәт тойгылары белән генә яшәгән, Османга булган мәхәббәт хисләрен җиңә алмаган Сөембикә автор тарафыннан «слабая женщина», «несчастная», «легковерная» эпитетелары белән сыйфатлана. Үзенең дәүләт белән идарә итүдә көчсезлеген, соңгы көннәренең якынлашуын сизенгән, уңга-сулга бәргәләнгән

Сөембикә Османга үзенең мәхәббәтен дә, тәхетен һәм таҗын да тәкъдим итә. Ул хис кешесе: «люблю и для любви сей жертвую троном», ди (52 б.). Ләкин алда тикшерелгән барлык әсәрләрдәге кебек үк, Осман Сөембикәнең мәхәббәтен кабул итми. Осман Сөембикә тәрбияләп үстергән Эмираны ярата. Аның уенча, ике ирдән соң өченчегә кияүгә чыккан ханбикәдә чын мәхәббәт хисләре була алмаячак. Сөембикәнең үз шәхси бәхете турында уйларга хокукы да юк, чөнки ул дәүләт башлыгы, аның төп вазифасы – ханлык һәм халык иминлеген тәэмин итү. Мәхәббәте өчен тәхетен, таҗын вәгъдә иткән Сөембикәгә Осман нәкъ классицизм геройларыча җавап бирә: «Когда венценосная глава не печется о благе подданных, а ищет блага личных, тогда щастие ее не может назваться щастием» (3 б.). Иоанн Зөя каласына килеп туктаган, Казан өчен куркыныч янаган минутларда да Сөембикә Осман турында гына уйлый. Аның мәхәббәте шулкадәр көчле ки, бураннар котырып, яшеннәр яшьнәп, дөньяның асты өскә килсә дә, ул үзенең Осман белән кавыша алачагына сукырларча ышана («Люблю и для любви сей жертвую троном», 52 б.). Сөембикәнең мәхәббәт колы булып яшәве тискәре нәтиҗәләргә дә китерә: Казан халкы гыйсъян күтәрергә җыена, ханбикә исемен телгә алудан курка башлыйлар («Казанская чернь готова ежечасно сокрушить трон твой; повторяет с ужасом имя твое», 4 б.). Осман Сөембикәне гедонизмга – тән ләззәтенә өстенлек бирүдә гаепли. Ватан һәлакәт алдында, ә Сөембикә бер минутлык тән мәхәббәте турында баш вата. Бу фикер «погибающее Отечество» «минутное удовольствие» антитезасы рәвешендә чагылыш таба.

Христиан дине фәлсәфәсе буенча, чын мәхәббәт үзеңнән бигрәк башкаларга, якыннарыңа юнәлтелгән булырга тиеш. Татар ханбикәсе кебек халкың турында оныту, үз-үзеңне генә ярату, тән ләззәте өчен генә яшәү – азгынлык, ялгызлык һәм һәлакәт билгесе. Философ Николай Бердяев бу хакта болай дип яза: «Настоящая любовь есть всегда любовь к другому, разврат же есть любовь к себе… Разврат же есть глубокое одиночество, смертельный холод одиночества»[117]. Әсәрдә Сөембикә дә нәкъ менә шундый ялгызлык халәте кичерә. Язучы С.Н.Глинка сурәтләгән Сөембикә кебек, М.С.Рыбушкин ханбикәсе дә: «Так! Все вооружилось против меня. Небо и земля возстали против меня. Кто жь будет моим защитником» (10 б.), дип үрсәләнә.

М.С.Рыбушкинның «Иоанн, яки Казанның алынуы» трагедиясендәге Сөембикә образы нәкъ Н.Бердяев тәкъдим иткән мәхәббәт фәлсәфәсе кысаларына кертеп утыртылган. Ханбикәне Кошчак-Османга булган мәхәббәт колы һәм корбаны итеп гәүдәләндерү XVI йөздә иҗат ителгән «Казан тарихы»ннан ук килә. Аннан соң язылган әсәрләр дә Сөембикәне Казан ханлыгын һәлакәткә илтүче «блудная царица» итеп гәүдәләндерү үзенә күрә бер традиция рәвешен ала.

Романтик әсәрләргә хас булганча, Сөембикәнең гомере үлем белән очланачагына трагедиянең беренче битләрендә үк ишарәләнә. Сөембикә кая гына бармасын, нинди генә адымнар ясамасын, Кама буеннан кайткан дин башлыгы Сәет тә, зираттагы Сафагәрәй рухы

[117] Бердяев Н. Философия творчества, культуры и искусства. – М.: Искусство, 1994. – Т.2. – С.81.

һәм башка әрвахлар да Казан ханлыгына җимерелү, ә ханбикәгә фаҗигале үлем киләчәге турында күрәзәчелек итәләр. Күренә ки, Сөембикә образын гәүдәләндергәндә, автор аңа дини-мифик буяулар да өсти, аны шартлы романтик хәлләр эчендә дә тасвирлый.

Сөембикә Казан ханлыгының санап бетергесез ыгы-зыгысы эчендә кайный, авыр иҗтимагый-сәяси, хәрби шартларда үз бәхетен табарга омтыла. Автор аның уй-фикерләрен, эчке дөньясын, кылган гамәлләрен төрледән төрле әдәби-эстетик чаралар белән катлаулы һәм каршылыклы итеп ачарга тырыша.

Образлар бирелешендәге мондый фикер төрлелеге, агымнар һәм иҗат ысуллары чуарлыгы Осман образында да күзәтелә. Алда тикшерелеп үткән барлык әсәрләрдәге кебек, М.С.Рыбушкин трагедиясендә дә Осман Сөембикәнең мәхәббәтен кабул итми, Эмира белән бергә калуны өстенрәк күрә. Шул адымы белән ханбикәнең ачуын уята. Сөембикә, Османның үзен яратмаганын белсә дә, аны йөрәгеннән алып ташлый алмый. Осман ничек кенә булса да Сөембикәне үзеннән ераклаштырырга, биздерергә тели, аңа шәхси бәхет турындагы уйларын онытып, аны классицистларча бары тик үз халкы турында кайгыртучанлык күрсәтергә чакыра. Аныңча, хөкемдарлар бәхете аңа буйсынганнар мәнфәгатен күзәтүдән гыйбарәт: «Щастие владык не зависит ли щастия подданныхъ (2 б.). Үзенә килгәндә исә, Осман сөеклесе Эмира белән бергә яшәр өчен дөнья читенә дә китәргә әзер. Төгәлрәк итеп әйткәндә, автор бу ике гашыйкның бер-берсенә омтылышын руссочыл рухта яктырта. Османны Сөембикә сараендагы байлык, зиннәтле, ялтыравыклы тормыш һич тә кызыксындырмый. Аның хыялы – табигый хисләр, саф мәхәббәт белән табигать кочагында Эмирасы белән бергә бәхетле яшәү: «Скроемся из сих ненавистных мест: от взоров ненавистной мне Царицы в непроходимые леса и будем жить в уединении» (26 б.).

Эмира да мәхәббәттә рухи азатлыкка омтыла. Аныңча, бер-береңне ярату һич тә җинаять түгел: «…разве любовь есть преступление» (22 б.). Мондый фикер трагедиядә Шәрекъ, Гареб ренессанс әдәбиятыннан килеп кергән булса кирәк. Кыскасы, М.С.Рыбушкинның «Иоанн, яки Казанның алынуы» трагедиясендә Сөембикә белән Османның мәхәббәт тарихы нигездә романтик эчтәлектә сурәтләнгән һәм күпмедер дәрәҗәдә классицизм, барокко, руссоизм, ренессанс әдәбияты өчен хас идеяләр һәм алымнар белән үрелеп бирелгән.

«Иоанн, яки Казанның алынуы» трагедиясендә Сагрун образы тулырак чагылыш тапкан. Шул ягы белән дә әсәр башка рус авторлары әсәрләреннән аерылып тора. Трагедиянең исеме Иоанн образы белән бәйле булса да, һәр пәрдәдә диярлек телгә алынган һәм катнашкан Сагрун әсәрдәге төп геройларның берсенә әверелә. Автор Сагрун образын Ауропа һәм рус әдәбиятларында еш күзгә чалына торган явыз романтик герой итеп тасвирлый. Ул – хирыс кешесе. Аңа Казан ханлыгының тәхете, таҗ, хакимият биеклекләре кирәк. Шөһрәт яратучы Сагрун, үз максатына ирешү өчен галәм киңлекләренә дә ыргылырга әзер: «Для чего я не могу пройти всю вселенную, чтобы насытить свое чистолюбие?», «Простирай свою власть во все концы вселенной» (13 б.). Теләгенә ирешер өчен ул теләсә нинди әхлаксыз һәм җинаятьчел

ысуллардан баш тартмый: хәйлә җәтмәләре үрә, коткы һәм гайбәт тарата, ялган эчтәлекле патриотик чыгышлар ясый, буш вәгъдәләр бирә, бүләкләр өләшә, Шаһгалине Казаннан кудырта, казанлыларны Сөембикәгә каршы фетнә күтәртә, Сафагәрәй кабере янына чакырып китереп, ханбикәне үтерергә кешеләр яллый, руслар белән татарларның тыныч яшәү турындагы килешүләренә аяк чала. Казан тәхетенә утырып, Алтын Урда ханнары кебек хөкемдар булырга, дөньяны үзенә баш идерергә теләгән явыз романтик геройның шигаре: «Так, Сагрун, так достигай трона убийствами, коварством, обманом, не страшись ничего» (75 б.).

Сагрун үзен акыл иясе итеп саный. Бөек грек драматургы Софоклның «Антигона» трагедиясендәге «неужели есть кто-нибудь выше человека?» дигән, кешене олылаган фикерне бу явыз романтик герой үз шәхесен күкләргә күтәрү максатыннан файдалана. Әсәрнең азагында Сагрунның Казан ханлыгын таркатуда, аның нигезенә балта чабуда башкарган мәкерле эшләре, Сөембикәне үтерүгә юнәлтелгән мәкерле планнары ачыла. Уңай герой итеп бирелгән Алей явыз Сагрунны гаепләп, түбәндәге сүзләрне әйтә: «…ты противоречил мирным предложениям Иоанна, который всеми силами старался покорить вас без кровополития. Вы не хотели и заставили приняться за оружие. Царица тебе верила, погибла сама и погубила Царство свое. Ты недовольствуясь сими злодействами, хотел умертвить Сумбеку и сделаться Царем Казанским» (106 б.).

М.С.Рыбушкинның явыз романтик герое кылган җинаятьләре өчен вөҗдан газаплары кичерү дигән нәрсәне белми. Сагрун – үз шәхесен бар нәрсәдән дә, барлык кешеләрдән дә өстен куючы кара көчне хәтерләтә. Әсирлеккә төшсә дә, Иоаннга буйсынудан, Алей әмерләрен үтәүдән баш тарта. Казан тәхетенә утыру турындагы идеаллары җимерелсә дә, сугышта җиңелсә дә, Сагрун, трагедия жанры геройларына хас булганча, рухы белән азат калып, горур рәвештә үз-үзен хәнҗәр белән кадап үтерә.

М.С.Рыбушкин Казан ханлыгының тарих сәхнәсеннән төшүен, Шәркый Аурупа киңлекләрендә татар һәм рус дәүләтләренең сәяси, икътисади, мәдәни, дини тартышуларын реалистик алымнар белән гәүдәләндерүдән баш тарткан. Ул Казан ханлыгы белән рус дәүләте арасындагы мөнәсәбәтләрне романтикларча яктыртуны кулайрак күргән. Татарларның дәүләтчелеге җимерелүне ул бер кешенең явызлыгына – Сагрун кебек гыйсъянчы геройның казанлыларны азатлык, ирек турындагы ялган сүзләр белән алдавы, башларын әйләндерүе нәтиҗәсе итеп яктырта. Адашев диалогларында бу фикер аеруча ассызыкланып әйтелә: «…Казань будет находиться под скипетром Российских Государей» (108 б.). «…Сагрун обольстив вас свободою, преклонил на свою сторону и погубил вас… Не дерзайте помышлять о свободе…» (109 б.).

Ханбикә Сөембикә Османга булган мәхәббәтеннән уңга-сулга бәргәләнсә дә, вакыты-вакыты белән ул уянып киткәндәй була, ханлык алдында торган бурычлар, Ватанны ничек итеп руслар кылычыннан коткару турында уйлана башлый: халыкны дошманга каршы күтәрү өчен боерыклар да бирә; кирәк булса, Казанның җир-сулары өчен үзен корбан итәргә

дә әзерләнә: «Я готова пожертвовать жизнью для блага отечества» (13 б.), ди ул Сагрунга. Урдалыларның, ягъни казанлыларның үз илләре, үз диннәре өчен шәһит китәргә һәрвакыт әзер булуларын патша Иоанн да белә: «Каждый готов впасть за веру и отечество» (30 б.).

Әсәрдә берничә мәртәбә Иоанн исеменнән Казан шәһәренең матурлыгына игътибар ителә: «великолепные чертоги врагов наших» (30 б.); «Посмотрите, посмотрите на эти великолепные башни, освещаемые лучами солнца» (34 б.). Шул ук Иоанн, Алей – «татарин»ның хыянәт итү ихтималы булу турындагы ялган хәбәрне ишеткәч, Казан ханлыгындагы барлык шәһәр-авылларны җимереп бетерергә дигән әмер бирә: «разрушить все жилища», «превратить в пепел города и селы и не оставить камень на камени» (48 б.). Казанны алгач та, Курбский Иоаннга Кремльнең, иске мәчетнең, күп биналарның җимерелүе, халыкның кырылып бетүе турында хисап бирә.

Иоанн гаскәренең шәһәргә бәреп кергәнен, каты сугышлар башланганын күргән Сөембикә Казанның һәлакәте өчен үзен җаваплы дип саный, рухи җәзалана. Нәкъ менә шушы урында әсәргә трагедия жанры өчен хас «гаебеңне тану» («трагическая вина») мотивы килеп керә. Ул ханбикәнең түбәндәге монологында аеруча ачык чагыла: «Я недостойна Божеского гнева. Я – убийца! Я погубила тысячу народов, вкушавших несколько веков бывших ужасом Вселенной. О, Казань покорена? Кем? О судьба! Иоанном, нашим данником» (91 б.).

Ханлыгын, халкын, тәхетен, таҗын руслар афәтеннән коткарып кала алмаган Сөембикә, Кремль диварларының шартлатылганын күргәч, хәрабәләр өстенә ташланып һәлак була. С.Н.Глинка әсәрендә дә очраган, романтик геройларга хас булган бу фаҗигале үлем Казан ханлыгының җимерелү билгесе булып тора. Гомумән, рус авторларының барысы да диярлек үзләренең әсәрләрендә Сөембикәнең Казаннан әсирлеккә озатылу да ханбикәнең фаҗигале үлемен дә Казан ханлыгының инкыйразы, рус дәүләтенең зур җиңүе рәвешендә гәүдәләндерәләр.

## 7. В.И.Лапинның «Казанның алынуы» трагедиясе

XIX гасыр рус әдәбиятында Сөембикә турында язылган әсәрләрнең соңгысы – В.И.Лапинның «Взятие Казани» («Казанның алынуы») (1855) трагедиясе[118]. Лапин Василий Иннокентьевич (1823–1886) – Пермь губернасында туа, Икенче Казан гимназиясендә белем ала һәм Казан университетының тарих-филология факультетын тәмамлый [119] . Университетны тәмамлап (1847), берничә ел Казанда эшләгәннән соң, Петербург округы мәктәпләре буенча инспектор итеп билгеләнә һәм гомеренең соңгы елларын башкалада үткәрә. Белгечлеге буенча тарихчы булган бу авторның татар тарихы белән бәйле булган

[118] Лапин В.И. Взятие Казани. – СПб.: тип. Г.Трусова, 1855. – С.89.
[119] Языков Д.Д. Обзор жизни и трудов покойных русских писателей. – СПб.: тип. А.С.Суворина, 1885. – С.64.

«Историческая повесть из времен татарского погрома» (1880) дигән тагын бер әсәр язуы билгеле.

В.И.Лапинның «Казанның алынуы» әсәре – сәхнә өчен язылган 10 бүлектән торган драматик поэма. Беренче тапкыр ул 1854 елның 27 октябрендә Петербургның Александрия театры сәхнәсендә уйнала.

Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге XIX гасырның уртасы һәм икенче яртысына туры килгән В.И.Лапинның «Казанның алынуы» әсәре реализм ысулы белән язылган. Мәгълүм булганча, Аурупа әдәбиятларында реализм ысулы XIX йөзнең уртасыннан үсеп китә (Г.Флобер, У.Теккерей). Россиядә исә ул беркадәр алдарак формалаша башлый. Реализм ысулының үсеп китүендә Н.В.Гоголь аеруча зур өлеш кертә[120]. Романтизмга алмашка килгән бу иҗат ысулын аурупалылар классик реализм дип атасалар, Россиядә ул башта «натураль мәктәп», ә соңрак «тәнкыйди реализм» методы дигән атама белән йөртелә. Бу ысул белән иҗат итүче язучыларга «…дөреслеккә, хакыйкатькә туры калу, аны тирәнтен чагылдыру…» хас дип яза Фәрит Хатипов[121]. В.И.Лапинның «Казанның алынуы» әсәре Россиядә реализм методының формалашу һәм тамыр җәюенең башлангыч дәверенә туры килә. Шуңа күрә әле анда элегрәк Сөембикә турында язылган классицизм һәм романтизм ысулы белән иҗат ителгән әсәрләрнең йогынтысы сакланып калуын дәвам итә. Сюжет сызыгы һәм образлар системасы нигездә безгә билгеле булган әсәрләрдәгечә традицион үстерелеш ала.

Әсәр Казан ханлыгы өчен иң авыр сәгатьләр – русларның Казаннан ерак түгел Зөя каласын салып куюлары, Тау ягы чирмешләренең руслар ягына күчүләре, сәүдә туктаган, аксөяк һәм гади халык арасында курку һәм таркаулык хөкем сөргән бер вакытны тасвирлау белән башланып китә. Дәүләт иминлеге өчен куркыныч янаган минутларда Казан аксөякләре ил язмышын хәл итү өчен хан сараена җыелалар. Ханлыкны җимерелүдән, ә халыкны әсирлек богауларыннан саклап калу өчен, Сөембикәне Шаһгалигә кияүгә бирергә карар кылына. Сөембикә исә, Шаһгалигә агулы күлмәк бүләк итеп, аны үтерү һәм Казан тәхетен үз кулында саклап калу өмете белән яши. Әмма Сөембикәнең теләк-ниятләре ачыла. Шаһгали өчен әзерләнгән агулы күлмәк ханбикә яраткан Кошчакка насыйп була, ул үтерелә. Сөембикә исә Мәскәүгә әсирлеккә озатыла. Казан ханлыгы Иван җитәкчелегендәге рус гаскәрләре тарафыннан басып алына.

Моңарчы Сөембикә турында язылган әсәрләрнең традицион сюжеты нигез һәм үрнәк үрнәк итеп алынса да, В.И.Лапин сукырларча ияреү юлыннан китми. Авторның яңалыкка омтылышы, беренче чиратта, булып узган тарихи вакыйгаләрне, аларның үзәгендә торган тарихи шәхесләрнең гамәлләрен тарихилык принцибы нигезендә гәүдәләндерүдә күзәтелә. Реализм методы белән иҗат итүче авторлар турында профессор Н.А.Гуляев болай дип яза: «О методе писателя реалистического направления следует судить по правдивости изображения им действительности, историзму его мышления, по тому, насколько верно он

[120] Аникст А.А., Мотылева Т.А. Реализм // Литературный энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1987. – С.318.
[121] Хатипов Ф. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 277.

понимает объективное движение истории»[122].

В.И.Лапин пьесасы композицион төзелеше буенча ике өлештән тора. Әсәрнең беренче өлешендә, ягъни баштагы биш бүлектә вакыйгаләр хан сарае һәм Сөембикә тирәсендә барса, икенче өлештә Иван образын, рус гаскәрләренең татарлар белән бәрелешләрен гәүдәләндерү үзәккә куелган. Алда тикшерелеп киткән рус авторлары трагедияләрендә кульминацион нокта – Сөембикәнең әсир китүе һәм Казан ханлыгының рус гаскәрләре тарафыннан басып алынуы белән тәңгәл килә иде. Тарихи дөреслеккә туры килмәсә дә, күпчелек әсәрләрдә бу ике вакыйга бер-берсенә үрелеп, аерылгысыз рәвештә бәйләнеп килде. В.И.Лапин пьесасында кульминацион нокта әсәрнең исеменә туры килгәнчә, Сөембикә Мәскәүгә озатылгач кына, Казанның рус гаскәрләре тарафыннан басып алу вакытына туры килә. Бу ягы белән дә автор тарихи вакыйгаләр барышын дөрес тәртиптә чагылдыруга ирешә.

В.И.Лапин әсәрендә төрле социаль катлам вәкилләре – ханнар, патшалар, хәрбиләр, чит ил инженерлары, сарай һәм дин әһелләре, Казан аксөякләре, гади халык, сугышчылар катнашалар. Пьесада геройлар саны да моңа кадәр күзәтелмәгәнчә күп. Аларның саны 29 га кадәр җиткерелә, моннан кала әсәрдә күп санлы Казан халкы, Сөембикә белән Сәлимәнең кәнизәк кызлары, рус әсирләре дә катнаша. Төрле сыйныф вәкилләренең тарихи вакыйгаләргә мөнәсәбәтен күрсәтү нәтиҗәсендә, автор XVI гасыр татар җәмгыяте тормышын шактый тулы күз алдына китереп бастыра алган. Пьесаның алгы планына ханнар, патшалар түгел, ә төрле социаль катлам вәкилләре чыгарыла.

Чын тарихи фактларга һәм вакыйгаләргә мөмкин кадәр объектив якын килүне максат итеп, автор пьесадагы геройларның исемнәрен дә билгеле реаль чынбарлыктагыча үзгәртмичә бирә. Русча яңгыраштa бирелгән татар лагеры геройларының исемнәре түбәндәгеләр: Кощакъ (Кошчак), Кульшериф (Колшәриф), Селима (Сәлимә), Чура, Епанча (Япанча), Корачъ Зониешъ (Зәйниеш), Муралей (Мурали).

Иван патша образын тудырганда В.И.Лапин рус әдәбиятында формалашкан традициягә тугърылыклы булып кала. Ул акыллы идарәче, батыр һәм зирәк полководец, мәрхәмәтле патша буларак сурәтләнә.

Классицизм һәм романтизм әсәрләрендә без Явыз Иванның якын дусты, русларга җаны-тәне белән хезмәт итәргә тырышкан, акыллы киңәшләре белән рус патшасына һәрдаим ярдәм иткән Али-Алей-Шаһгали образы белән очрашкан идек. Шаһгали образын гәүдәләндерүдә В.И.Лапин үзенең элгәреләреннән аерыла. Ул бу образны уңай итеп тасвирламый. В.И.Лапинның Шаһгалие хаин патша «царь – изменник», ерткыч хайван «лютый зверь», ханлыкны сатучы, үтерүче «убийца» итеп бирелә. Казан тәхетен ничек кенә булса да үз кулында калдыру максатыннан Шаһгали ханлыкның аксөякләрен юк итүдән дә курыкмый. Аның бу вәхшилегенә Казаннан кайткан рус хәрбие Хабаров та гаҗәпләнү белдерә:

Куда не хорошо. А виноват

[122] Гуляев Н.А. Теория литературы. – М.: Высшая школа, 1977. – С.237.

Сам Шигъ-Алей – куда как лют!

Ну как же – перерезал всех бояр

Казанских, пригласив их в гости[123].

Абызларның берсе үз татарларын үтереп, илгә хан булып килгән Шаһгалине «ерткыч хайван» белән тиңли. Кешеләрнең үлемен, газаплануларын күрү аның өчен бер шатлык һәм бәйрәм, ди:

О Казанцы! Лютый зверь

Вами властвует теперь!

Для него одно веселье –

Видеть пытку, смерть людей (40 б.).

Сөембикә дә аны «царь-изменник», «уродъ и телом и душою» дип атый. Казан халкы да Шаһгалине ерткыч хайван белән тиңли, аның идарә итүенә ризасызлык белдерә («Как зверь лютует над Казанью», 35 б.). Гади халык арасында Сөембикәне Мәскәүгә әсирлеккә җибәрү карары Казан һәм казанлыларны сату итеп кабул ителә:

И впрям что зверь! Месть Шигъ-Алею!

Он продал Русским нас! Убийца он!

Он опозорил царский трон! (41 б.)

Әйтергә кирәк, автор Шаһгалинең хан буларак вәхшилекләрен, русларның турылыклы дусты булуын сурәтләгәндә дә, аның Сөембикәгә тискәре мөнәсәбәтен белдергәндә дә тарихи чынбарлыкка турылыклы булып кала.

В.И.Лапинның «Казанның алынуы» пьесасында Сөембикә уңай образ итеп гәүдәләнгән. Бу юнәлештә беренче адымны Г.Р.Державин «Грозный» операсында ясаган иде. В.И.Лапин Сөембикә образын бары тик бер яссылыкта гына – илен, халкын сакларга һәрдаим әзер торучы, ханлыгының иминлеге өчен тырышучы ханбикә итеп сурәтли.

Әсәрнең беренче биш бүлегендә Сөембикә образы үзәк фигура булып тора. Ул «Прекрасная царица!» (12 б.), «Мудрая царица» (27 б.), «Звезда – красавица Востока» (29 б.) эпитетлары белән сыйфатлана. Аның эш-гамәлләре дә тулысы белән автор биргән билгеләмәләргә туры килә. Сөембикә Казан аксөякләре кабул иткән солых шартлары белән ризалашмый. Ханбикәләрен әсирлеккә җибәрергә, ә руслар дусты Шаһгалине Казан ханлыгының яңа ханы итеп кабул итәргә әзер торган Казан аксөякләрен Сөембикә үгетләп тә, куркытып та русларга каршы көрәшкә, кирәк булса сугышка да күтәрелергә өндәп карый. Ләкин күпчелек тавыш белән кабул ителгән солых шартларына ул буйсынырга мәҗбүр була:

Решил совет, что будетъ мир.

---

[123] Лапин В.И. Взятие Казани. – СПб.: тип. Г.Трусова, 1855. – С. 42. – Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

Его решенье неизменно (10 б.).

Башка авторлардан аермалы буларак, ханбикәнең Мәскәүгә әсирлеккә җибәрелү сәбәпләрен В.И.Лапин реалистларча аңлата:

Торговля – вот их идол! Для нее
Они готовы всех предать!
Чтобы казну свою умножить,
Залить готовы кровью мир (12 б.).

Мисалдан аңлашылганча, Сөембикә буржуаз җәмгыятенә хас акча-товар мөнәсәбәтләре корбаны икән. Аның дошманнары сәүдә өлкәсендәге өстенлекләрен, кесәләрен акча белән калынайтуны Сөембикә язмышы белән уйнаудан өстен күрәләр. Шуңа күрә дә «нам нельзя пренебрегать торговлей» диләр (9 б.).

Рус әдәбиятында үзенә күрә бер традициягә әйләнгән Сөембикә – Осман (Кошчак) мәхәббәт сызыгы В.И.Лапин тарафыннан башкача яктыртыла. Алда тикшерелгән әсәрләрдә, «Казан тарихы» авторы артыннан ияреп булса кирәк, бу мәхәббәт сызыгы «О любви блудной со царицею улана Коцака» рәвешен алып, рус телендә язылган барлык әсәрләрдә дә «уйнаш» (блудство) итеп сурәтләнеп килде. В.И.Лапинның «Казанның алынуы» пьесасында Сөембикә Кошчакны батыр ир, ханлыкны сакларга һәрвакыт әзер торган хәрби җитәкче һәм сугышчы булуы өчен хөрмәт итә һәм мәхәббәте белән бүләкли дә:

Любила, я за то, что ты герой;
И если, славу воина любя,
Ты хочешь жертвовать собой;
Не удержу тебя отъ битвы (13 б.).

Ә менә татар иленең хаине булган Шаһгалине Сөембикә күрә алмый. Шаһгали хатыны булуга караганда, ул үлемне өстенрәк күрә:

Скорей решуся умереть,
Чем быть изменника женою! (13 б.).

Сөембикә–Кошчак–Шаһгали мөнәсәбәтләренең азагы бик тә фаҗигале рәвештә тәмамлана. Үзенә үлем янаганын сизенгән Шаһгали Сөембикә әзерләгән бүләк-күлмәкләрнең берсен әсир төшкән Кошчакка кидертә. Шул рәвешчә, дошманы Шаһгалигә дип аталган агулы күлмәк ханбикә яраткан Кошчакның үлеменә сәбәп була. Яңарак төсмердә бирелгән күлмәк мотивы белән автор Сөембикәнең шәхси фаҗигасен тагы да арттыра һәм тирәнәйтә алуга итешә.

Сөембикәнең психологик халәте, аның уй-фикерләре, теләк-омтылышлары татар халкы һәм сөекле Казаны белән саубуллашу күренешендә бик тә ачык итеп сурәтләнгән. Ханбикә

үзе әсир булып китсә дә, халкының азат булып калачагына ышана. Аның сыктавы да алда тикшерелеп киткән елау-сыктаулардан үзенең оптимистик рухы белән аерылып тора. Сөембикәнең саубуллашу монологы илен азат күрергә, халкын иректә яшәтергә омтылган ханбикә сүзләре. В.И.Лапинга кадәр язган авторлар Сөембикә сыктавында өметсезлек, борчу, әрнү катыш сагыш, үкенечне чагылдыралар, «Казанның алынуы» драматик поэмасында Сөембикәнең саубуллашу монологы күтәренке романтик рух белән өретелгән. Сөембикә үзен руслар богауларыннан азат кош итеп күрә һәм «Полетела бъ я как птица», ди. Иртәме-соңмы ханбикә килеп ирешәчәк халкының азат яшәве турындагы хәбәре аның йөрәк тибешен тизләтеп, тормышын җанландырып һәм нурландырып җибәрәчәк:

Сердце радостно забьется;

Озарится жизнь моя (39 б.).

Бу шатлыклы хәбәрне ишетү белән коллык богауларына уралган Сөембикәнең җаны бәхетле халкы, яраткан ватаны янына очачак:

Из дали, из полону,

Въ вечно милую страну

Полечу душою я! (39 б.)

«Казан тарихы»ннан башлап, Сөембикәнең Казан белән саубуллашуы нигездә бик борынгыдан килгән төрки сыктаулардагыча, татар халкының бәет-мөнәҗәтләрендәгечә яктыртып килендә. XIX гасыр уртасына, реализмга таба хәрәкәт башланган чорга килеп кергәч тә, Сөембикә сыктауларының бирелү рәвеше борынгы калыплашкан традицияләр басымыннан арынып, яңача оптимистик яңгыраш алган. Ханбикә сөекле Казаннан аерылса да, җаны белән анда мәңге калачагы, аңа кош булып очып кайтачагы турында вәгъдә бирә. Җан кошы булып туган илгә кайтачак Сөембикә образының тамырлары фольклорга, борынгы традицияләргә барып тоташа, татар халык җырлары аһәңнәре аеруча ачык ишетелгәндәй була.

Пьесада тарихи шәхесләрнең барысына да (Шаһгали, Колшәриф, Сөембикә) гади халыкның мөнәсәбәте белдерелә, аларга уңай яки тискәре характеристика бирелә. Казанлылар ханбикәләрен бик хөрмәтлиләр һәм зурлыйлар. Гүзәллеге, киң күңелле, мәрхәмәтле, Казанга тугрылыклы булуы кебек сыйфатлары өчен аны яраталар, үз итәләр:

Жаль ее. Она была

Добра и ни казнила ни кого (35).

Царица! Бедная царица!

Как хороша и как добра она,

И как Казани предана! (40 б.)

Сөембикәне саклап калмыйча, дошман кулына биреп җибәрүнең бөтен татар милләтенә гасырлар дәвамында төшәчәк хурлык һәм гарьлек булып торачагын аңлап өлгергән халык

ханбикәләрен саклап калырга да тели:

Зачем ее мы отпустили!
И в самом деле стыдъ и срамъ
Теперь навеки будет нам:
Царицы мы не защитили (40).

Чит җирләргә әсир булып китәргә әзерләнүче, ләкин җаны кош булып Ватанга кайтачак Сөембикә образында рухи күтәренкелек чагылса да, аны озатырга килгән гади халык ханбикәләренең Мәскәүгә озатылуын авыр кичерә. Сөембикә язмышы аның йөрәгеннән мәңге китмәс сагышка әверелә, тарихи җәза һәм гаеп төсен ала («стыд и срам навеки»). Боларның барысы да В.И.Лапин пьесасында тормыш дөреслегенә якын булган реалистик эчтәлекле рефлексив психологизм белән сугарылып бирелә.

Пьесага урыс егете Артемьевның татар кызы Сәлимәгә булган икенче мәхәббәт линиясе килеп керә. Казанда күп еллар әсир булып яшәгән һәм шуңа күрә дә татар телен һәм йолаларын (гореф-гадәтләрен) яхшы белгән Артемьев XVI гасырда «Казан тарихы» әсәрен язучы авторны – рус әсирен хәтерләтә. Христиан динен кабул иткән Сәлимә дә Артемьевны ярата, аның белән бергә булу, кавышу теләге белән яши.

Христиан динен тотучы рус егетенең һәм мөселман кызының, төрле сәяси, дини һәм мәдәни каршылыкларга карамыйча, бергә калулары, кавышулары XIX гасыр уртасы өчен бөтенләй чит күренеш булган, әлбәттә. Әйтергә кирәк, В.И.Лапин реалист язучы буларак, мондый мәхәббәткә үзенең уңай мөнәсәбәтен белдерә. Әсәр тукымасына катнаш никах мотивының килеп керүенә, бәлки, ул вакыт халык арасында таралган бәетләр дә этәргеч ясагандыр.

М.М.Херасков белән С.Н.Глинка әсәрләрендә кара буяуларга манчылып, явызлык һәм караңгылык символы итеп бирелгән Колшәриф образы В.И.Лапин әсәрендә икенче төрле эчтәлектә яктыртыла. Татар халкы вәкилләрен бары тик тискәре яктан гына чагылдыру традициясеннән В.И.Лапин аңлы рәвештә читләшә. Язучы Колшәрифне «Благославенный Кульшериф» (18 б.) дип атый. Казан халкы арасында Колшәрифнең абруе зур, халык аңа ышана, аны изге зат итеп саный, ди. Колшәриф җитәкчелегендә бөтен казанлылар рус гаскәрләренә каршы көрәшкә күтәреләләр:

В народе Кульшерифа почитают
Святым избранником пророка.
И ежели его коснуться –
Возстанет весь народ Казанский (26).

«Казанны алу» пьесасында аз-аз автор башка геройларга да характеристика биреп китә:

Алимердинъ
Труслив и потому не страшенъ,

Корачъ–Заньешъ торговлей занят,

За Муралеемъ надобно смотреть,

Мирза Касим, Салтыкъ Гирей.

Кучумъ Темиръ, Решидъ-Арсань

Къ Ногаямъ письма написали (26).

Тагы шуны да әйтеп үтәргә кирәк, М.М.Херасков, С.Н.Глинка, А.Н.Грузинцев, Г.Р.Державин әсәрләрендә сурәтләнгән образлар төрле психологик кичерешләр, фикри үзгәрешләр, рухи чистарынулар аша уздырылалар иде. Мәсәлән, Сөембикәнең Османга мәхәббәте нәфрәт белән алышынып, берникадәр вакыттан соң яңадан үзгәрешләр кичереп үтте. Тышкы вакыйгаләр – сюжет образның эчке халәте белән бик тыгыз бәйләнештә булды. Сөембикә образы мисалында гына берничә мәртәбә акыл һәм тойгы, бурыч һәм хисләрнең ялкынлы бәрелеше күзәтелде. В.И.Лапин әсәрендә исә без статик – рухи халәте мгърифәтчелек реализмындагыча үзгәрешсез калган образлар системасы белән очрашабыз. Әсәр барышында мондый төр образларның теге яки бу вакыйгаләргә мөнәсәбәте үзгәрми, пьесаның азагына кадәр алар автор биргән характеристика кысаларында калалар. Образларны катып калган – үзгәрешсез халәттә бирү классицизм әдәбияты әсәрләре өчен дә хас иде.

В.И.Лапинның «Казанның алынуы» пьесасында инде шул чор рус әдәбиятында кануни төс алган «натураль мәктәп»нең, ягъни критик реализм методының тернәкләнеп килүе сизелә. Мәсәлән, әсәрдә турыдан-туры Казан ханлыгының авырая төшкән икътисади халәтенә игътибар ителә, Казан байлары, сәүдә мәнфәгатьләре күзлегеннән беренчел итеп куеп, Сөембикә ханбикә өчен авыр солых шартларына кул куела. Шаһгалине Казанга хан итеп чакырырга, Сөембикәне аңа кияүгә бирергә, чирмеш ягын русларга тапшырырга карар кылына. Мәскәү белән озакка киткән каршылык ике күрше дәүләт арасындагы сәүдәнең туктaлуына китерә һәм татар сәүдәгәрләре өчен файда китерми башлый:

Не выгодна для нас война

Съ царем Московским. Он не пустит

Въ Казань своих купцевъ, и мы

Отъ этого потерпим много (8 б.).

Рус-татар сәяси, иҗтимагый мөнәсәбәтләренә бу рәвешчә социаль-икътисади күзлектән якын килү тәнкыйди реализм әдәбиятына таба хәрәкәт итү дигән сүз иде. Рус авторлары арасында В.И.Лапин Сөембикә образын көчле ихтыяр көченә ия булган патшабикә итеп сурәтли. Һәр адымда диярлек язучының татар ханбикәсенә һәм ул идарә иткән Казан ханлыгына, аның үткән тарихына ихтирамы сизелеп тора. В.И.Лапин – күренекле тарихи шәхес – Сөембикә ханбикәнең эчке кичерешләрен, Казан татарларының психологик халәтен тирәнтен аңлаган, туып килә торган капиталистик мөнәсәбәтләр яктылыгында шул чорның сәяси һәм

икътисади вәзгыятен реалистларча дөрес чагылдыра алган беренче автор.

* * *

Моннан тыш хатын-кыз авторларның да, аерым алганда, М.М.Херасковның хатыны Елизавета Васильевна һәм Казан университеты ректоры һәм тарихчы К.Фуксның хатыны, язучы А.А.Фукс та татар ханбикәсе Сөембикә турында әсәрләр иҗат иткән дигән фаразлар очрый.

1832 елда Санкт-Петербург театры сәхнәсендә дүрт бүлектән торган «Сумбека, или Покорение Казанского ханства» дигән героик эчтәлекле балет та куела. Анда да төп образ итеп татар ханбикәсе Сөембикә алынган. Петербург театры сәхнәсендә зур уңыш белән барган бу балетта Сөембикә образын атаклы рус балеринасы Истомина башкарган[124]. Балетны сәхнәләштерүче граф Кутайсов булган. Ул М.М.Херасковның «Россиада» поэмасы тәэсирендә иҗат итела. Бу хакта либреттоның кереш өлешендә искәрмә дә бар. «Автор балета, – диелә анда, – следовал за поэмой «Россиада», а не за историей Русскою»[125]. Балетның музыкасын күренекле рус композиторы А.А.Алябьев (1787–1851) язган дигән фикер дә бар.

Шунысы да игътибарга лаек: рус сәнгате һәм әдәбияты әсәрләрендәге Сөембикә – Осман, Сөембикә – Алей мәхәббәте үзәккә куелган барлык әсәрләрдә грек мифологиясеннән, борынгы грек һәм урта гасыр рус әдәбиятыннан, төрки-татар фольклорыннан алынган традицияләр бергә килеп очраша һәм укмашып яши.

XVIII йөз азагында – XIX йөзнең беренче яртысында рус әдәбиятында Казанны яулау, Иоанн (Явыз Иван) белән Сөембикә турында язылган әсәрләрдә традиционлылык көчле. Бер үк темалар, мотивлар, сюжет җепләре, жанр сыйфатлары, композиция, образлар системасы, сурәтләү чаралары бер язучысы иҗатыннан икенчесенә күчә, кабатлана һәм күпмедер дәрәҗәдә яңартыла. Кайбер рус әдәбиятчылары, мәсәлән, В.А.Бочкарев Шәрекъ әдәбиятларында нәзыйрәчелекне хәтерләтә торган бу күренешне эпигонлык, ягъни ияреп язу дип атый. Әдәбиятчы В.Е.Хализев эпигонлыкны «нетворческое следование традиционным образцам, и добавим, назойливое повторение и эклектическое варьирование хорошо известных литературных тем, сюжетов, мотивов, в частности – подражание писателям первого ряда», дип бәяли[126].

Безнеңчә, Иоанн һәм Сөембикә турында язылган тарихи-героик һәм тарихи-драматик трагедия жанрында язылган әсәрләргә эпигонлык тамгасы сугу белән генә чикләнү бик үк дөрес булып бетмәс иде. «Традиционализм, – дип яза Р.К.Ганиева, – типологическая черта не только средневековых, но и западных литератур»[127]. Соңгы вакытта рус әдәбияты үсешендәге бу дәвер «әдәби традиционализм чоры» («эпоха словесного

[124] Әмирхан Ф. Халык кызлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 4.
[125] Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве. – СПб., 1905.
[126] Хализев В.Е. Теория литературы. – М.: Высшая школа, 2000. – С.133.
[127] Ганиева Р.К. Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань. Изд-во Казанского университета, 1988. – С. 66.

традиционализма»)[128] дип тә атала башлады. Шулай итеп, XVI йөзнең икенче –XIX йөзнең беренче яртысындагы рус әдәбиятында Казан ханбикәсе турында язылган әсәрләрнең күпләп барлыкка килүе, Сөембикә шәхесенең рус-татар сәяси мөнәсәбәтләре тарихында тирән эз калдыруы һәм бу милли-тарихи теманың рус әдәбияты өчен үз заманында актуаль һәм традицион күренешкә әйләнүе турында сөйли.

[128] Аверинцев С.С., Андреев М.Л. и др. Категории поэтики в смене литературных эпох // Историческая поэтика. – М.: Высшая школа, 1994. – С.24.

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## XX гасыр башы татар әдәбиятында Сөембикә ханбикә образы

### 1. Әдәби-тарихи җирлек һәм татар әдипләре

Моннан дүрт йөз илле еллар элек Казан ханлыгын басып алу нәтиҗәсендә дәүләтчелеген югалткан һәм изелеп яшәргә мәҗбүр ителгән татар халкының мәдәнияты һәм әдәбияты яшәеше өчен шартлар гаять авыр булды. XIX гасырның икенче яртысында – XX гасыр башында Россиядәге сәяси, социаль-иҗтимагый үзгәрешләр, феодализмнан капитализмга күчеш татар дөньясын да уятып җибәрә: мәгърифәтчеләр мәйданга чыга, милли тәрәккъыять, шәхес иреге мәсьәләләре көн тәртибенә куела, дәүләтчелегебез, милли тарих, милли каһарманнар турында китап һәм мәкаләләр дөнья күрә.

Халыкның милли аңын тәрбияләүдә тарих фәненә олы вазифа йөкләнә. Мәгълүм булганча, XIX йөзнең икенче яртысында Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Хөсәен Фәезханов (1828–1866), Каюм Насыйри (1825–1902) кебек галимнәрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә татар тарихы фәнни нигездә оеша һәм үсә башлый [1]. Мәгърифәтче галимнәребезнең иҗтиһады белән барлыкка килгән тарих фәне XX гасыр башында яңа үсеш баскычына күтәрелә[2]. Казан ханлыгы тарихы, аның ханбикәсе Сөембикә язмышы тарихчы галимнәребезне аеруча җәлеп итә һәм халыкның милли аңын уятуда әһәмиятле тема булып санала.

XX гасыр башындагы вакыйгаләр, аерым алганда, рус-япон сугышы, 1905–1907 елгы революция, милли-азатлык хәрәкәтенең яңа чоры башлану милли тарих белән кызыксынуны бермә-бер арттыра. Татар тарихы өлкәсендә эшчәнлек күрсәтүче галимнәр төркеме мәйданга чыга. Ризаэтдин Фәхретдин (1859–1936), Гайнетдин Әхмәрев (1864–1911), Һади Атласи (1876–1938), Габдулла Баттал (1893–1959), Газиз Гобәйдуллин (1887–1937), Әхмәтзәки Вәлиди (1891–1970) кебек тарихчылар хезмәтләрендә Казан ханлыгы һәм Сөембикә образына шактый урын бирелә.

Гасыр башында татар тарихының мөһим мәсьәләләре белән кызыксыну «Шәрекъ» клубы эшчәнлегендә дә күзәтелә. Анда милли тарих сәхифәләренә багышланган лекцияләр укыла. Болгар һәм Казан ханлыклары тарихы турында лекцияләр укучыларның исемнәре

---

[1] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы / Һади Атласи. Сөембикә. – Казан: Җыен фонды, 1992.– Б. 64.

[2] Бу турыда: Шакуров Ф. Развитие исторических знаний у татар до февраля 1917 года. – Казань: Изд-во Казанского университета, 2002. – Б. 128.

матбугат битләрендә игълан ителә, милли тарихны сөючеләр утырышларга чакырыла. Мәсәлән, «Йолдыз» гәзитәсе Гайнетдин Әхмәрев чыгышлары турында игъланнар бирә. Аның Казан ханлыгы һәм Сөембикә ханбикә турындагы лекцияләре татар халкы өчен «һәм дәрес һәм тарих китабы» дәрәҗәсендәге кыйммәтле чыгышлар дип бәяләнә («Йолдыз», 1909, 12 февраль, №303). Аның 1910 елның 4 мартында «Шәрекъ» клубында укылачак лекциясе хакында шул ук көндә чыккан «Йолдыз» газетасында: «Тарихымызның иң әһәмиятле йире, шөбһәсез, ошбу Сөембикә хакындагы кыйсемедер» диелгән. Гомумән, татар милли матбугаты Сөембикәне татар хатыннары арасында иң бөеге һәм дәрәҗәлесе рәвешендә, зур ихтирам белән искә ала.

1913 елда хатын-кызлар өчен ике атнага бер «Сөембикә» журналы нәшер ителә башлый. Ул үзенең мәсләген татар хатын–кызларының иҗтимагый–сәяси һәм гаиләви тормышын яктырту дип билгеләсә дә, төп игътибарны мәгърифәтчелек максатларына – балалар тәрбиясенә һәм «милләт аналары җитештерү» мәсьәләсенә юнәлтә[3]. «Сөембикә» журналы сәхифәләрендә мөселман татар хатын-кызларының хокукларын яклаган мәкаләләр, язмалар зур урын били. Анда Аурупа һәм Россиядәге феминистик хәрәкәтләрне яктырткан, төрле милләт хатын-кызларының яшәешен тасвирлаган, аларның үз хокуклары өчен көрәшләрен яклаган мәкаләләр дә дөнья күрә. Журналдагы материалларның байтак өлешен көнкүреш һәм хуҗалык эшләрен алып бару турындагы язмалар да алып тора. Журналда мәшһүр хатын-кызларның, танылган ир-ат әдип һәм шагыйрьләрнең әсәрләре басылып чыга, тәнкыйть мәкаләләре урнаштырыла.

«Сөембикә» журналы битләрендә ханбикә турында да берничә язма нәшер ителгән. Болар – шагыйрь Г.Рәшидинең «Сөембикә бәете» (1912), Һади Атласиның «Сөембикә» әсәренә Зәки Вәлиди язган тәнкыйть мәкаләсе (1914), Шәһит Әхмәдиевнең «Мәшһүр хатын-нардан Сөембикә» (1916) дип аталган романтик нәсере.

Гасыр башында олы әдәбиятка килгән Г.Тукай, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимов кебек шагыйрь һәм язучылар милли тарихыбыз турында да фикер йөртәләр. Аларның борчулы язмаларында татар әдәбиятында тарихи темага караган әсәрләрнең азлыгына, бу жанрның гомумән сүлпән үсешенә игътибар ителә, бу юнәлештә дөнья әдәбияты, рус классиклары тәҗрибәсен өйрәнү кирәклеге турында әйтелә. Әйтергә кирәк, болар үзләре дә, башка кайбер авторлар да бу юнәлештә уңышлы гына иҗади адымнар ясыйлар: шактый дәрәҗәдә тарихи материалга нигезләнеп язылган берничә хикәя, пьеса, повесть (роман) татар укучысы кулына килеп керә. Татар әдәбиятында тарихи мотивлар да яшәүгә тулы хокук алалар дияргә мөмкин.

Татар матур әдәбиятында исә Сөембикә темасына беренче булып мөрәҗәгать итүче автор – безнең тикшеренүләр күрсәткәнчә, классик язучыбыз Гаяз Исхакый. Аның ярым публицистик, ярым әдәби «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1902–1904) исемле анти-

[3] Әмирханов Р. Изге исеменә лаек-муафыйк булып… // Сөембикә. – 1991. – №1. – Б. 6-7.

утопиясендә[4] Сөембикә образына да урын бирелгән. Төш күрү, саташу кебек шартлы алымнарга таянып, язучы аны дүрт яссылыкта чагылдыра, тарихи һәм милли эчтәлек салып бирә, күпмәгънәле романтик символ дәрәҗәсенә күтәрә. Беренчедән, Сөембикә – әсәрнең баш герое, тарихчы-галим Җәгъфәрнең хатыны буларак антиутопия рәвешендә язылган әсәрнең контекстына килеп керә. Мәгърифәтчелек әдәбиятындагыча, Гаяз Исхакый Сөембикәне белемле, акыллы, сөйкемле, аш-суга, һәртөрле эшкә оста, әхлаклы бер хатын итеп идеаллаштырып тасвирлый. Шул ук вакытта автор бу образга символик мәгънә дә өсти: Сөембикә – татар (әсәрдә: болгар) милләтенең яшәү хосусиятләрен, рухи кыйммәтләрен үзендә туплаган җыелма образ да. Икенчедән, Сөембикә – татар халкының олы тарихын, милли-азатлык көрәше сәхифәләрен, Казан ханлыгы фаҗигаләрен искә төшерүче ханбикә дә. Өченчедән, Сөембикә – татар халкының архитектура сәнгатендә милли символ буларак мәңгеләштерелгән – Сөембикә манарасы да. Дүртенчедән, «Инкыйраз»да ханбикә театр һәм музыка сәнгатенең күренекле әсәре – «Сөембикә» операсының исемләнешендә чагылыш таба. Г.Исхакый болгар-татарларның «Сөембикә» исемле операсы бар дип яза. Әдипнең олы хыялы бер гасыр чамасы гомер үткәч кенә тормышка ашар кебек тоела. Әдәбият галиме Назыйм Ханзафаров шул ук исемдәге операның либреттосын тудырды, ә композитор Бату Мулюков исә аның музыкасын иҗат итте. Кызганычка каршы, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә операның яңгыраганы, тамашачыга барып җиткәне юк юк әле.

Гаяз Исхакый моннан соң да Сөембикә язмышы турында уйланган, аның образын үзәккә куйган әдәби әсәр иҗат итү хыялы белән яшәгән. Әмма 1917 елның октябре вакыйгаләре язучының бу изге ниятенә аяк чала. Мөһаҗирлек дәверендә дә татар халкының дәүләтчелек тарихында тирән эз калдырган күренекле ханбикә шәхесен язучы исеннән чыгармый. Мәсәлән, «Дулкыннар» драмасында әдип аны тагы бер мәртәбә искә төшереп үтә. 20–30 елларда тарихи темага язылган публицистик мәкаләләрендә дә Исхакый Сөембикә шәхесенә әледән-әле мөрәҗәгать итә. Мәсәлән, «Яңа милли юл» журналының 1935 елгы 11 нче санында аның «Казан китүгә 383 ел үтте»[5] дигән мәкаләсе дөнья күрә. Анда ул, Казан ханлыгы дәверендәге кебек, большевиклар заманында да татар җәмгыятен ике төркемгә бүленгән итеп күрүен яза. Беренчесе – «Олугъ Мөхәммәд вә Сөембикә»ләр төркеме. Бу төркем «халкыбызның динен, милләтен саклап, халкыбызны иленә, суына хуҗа итеп, үз мәдәниятен саклап, мөстәкыйль бер халык, мөстәкыйль бер ил итеп яшәтүне максат» итүчеләрдән тора. Әлеге «саф агымның» нигезен халкыбызның бөек шәхесләре – Олугъ Мөхәммәд һәм Сөембикә кебекләр тәшкил итәләр. Икенче төркемдә – Шаһгали варислары. Бу төркем – «383 ел эчендә халкыбызның һәрбер тартышында турыдан-туры русларга сатылып эш иткән хаиннар – милли тартышыбыз вакытында эчке сафыбызны эчтән кимерүче-җимерүчеләрдер». Гаяз Исхакый фикеренчә, Олугъ Мөхәммәд, Сөембикә

[4] Исхакый Г. Әсәрләр: Унбиш томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1998. – 1 т. – Б. 154–270.
[5] Кабатлап басылды: Исхакый Гаяз. Казан китүгә 383 ел үтте // Шәһри Казан. – 1998. – 10 октябрь.

варислары тоткан юл мәгънәви яктан бик тә куәтле. Гаяз Исхакый татар халкының озакка киткән рус золымыннан арыначагына, «Идел-Урал байрагы астында үзебезнең бабайларның мирасын алачагына» ышаныч белдерә. Мәкаләнең соңында янә Сөембикә манарасы образы калкып чыга. Автор милли символыбызга әйләнгән бу манараны 383 ел элек тартып алынган дәүләтчелегебез кайчан да булса кире кайтарылып, милли байрагыбызны шул Сөембикә манарасына элеп кую кирәклеге мөнәсәбәте белән телгә ала.

Сөембикә темасын шагыйрь Мәҗит Гафури да читләтеп үтми. 1907 елда «Милләт мәхәббәте» исемле милли хисләр белән үтәли сугарылган җыентыгына «Сөембикә манарасы» исемле шигырен урнаштыра. Әсәрнең икенче исеме – «Хан мәсҗеде». Унынчы еллар дәвамында шигырь берничә мәртәбә басылып чыкса да, Октябрь инкыйлабыннан соң әдипнең бу әсәре җыентыкларына, томнарына кертелми. Сәбәбе аңлашыла, «Сөембикә манарасы»ның миллилек белән сугарылган эчтәлеге совет чоры идеологиясенә туры килми. Бары тик XX гасыр азагында гына шигырь кабат халыкка әйләнеп кайта: «Идел» журналының 1990 елгы 2 нче санында беренче мәртәбә рус графикасында татар укучысына җиткерелә.

Романтик әсәрләргә хас булганча, шигырьдә манара образы геройның киеренке психологик кичерешләре белән сугарылып тасвирланган. «Сөембикә манарасы»нда кеше җаны яши: ул күз яшьләре коя, аның һәр ташы шикаять, моң-зар белән тулган. Аның «биек булып күкләргә чыкмыш» башы кәлисәләр, чиркәүләр уртасында ялгыз утырып калган, чөнки шималь төркиләренең, ислам мәдәниятенең үзәге булган Казан башкалар – руслар тарафыннан үзләштерелгән, аның бөеклеге, даны юкка чыккан:

Бер вакытта синдә торды әһле ислам гаскәре,
Шәүкәтең бетте бүгендә, калмады меңнән бере.
Башкаларның йире булды ошбу көн ислам йире,
Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Югалган дәүләтчелекне һәр даим искә төшереп торучы Сөембикә манарасы авторның үз образына тәңгәл килгән лирик герой җанында гына түгел, ә бөтен мөселманнар йөрәгендә хәсрәтле кичерешләр уята («Әһле ислам кальбенә син хәсрәтне салдың ни өчен»).

Ә бит татарлар һәм башка төрки кавемнәр яшәгән Казан мәсканенең – җирләренең үткәне гүзәл булган:

Бер заманда синдә намаз укыганнар хан иде,
Кауме татар һәм төрекнең мәскәне Казан иде.
Ул вакытны тасвир итсәк, ни гүзәл заман иде! –
Кальбеме мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде.

Шул рәвешле, Мәҗит Гафури идеаллаштырып тасвирланган Казан ханлыгының шанлы, данлы үткәненә бүгенге колониаль яшәешне каршы куя, кайчандыр «әһле ислам гаскәре

торган, татар һәм башка төркиләрнең кыйбласы булган Казанның шәүкәте бетеп», «башкаларның йире» булып китүенә ачына, өзгәләнә. Бу өзгәләнү мотивы шигырьнең буеннан-буена кабатланып килгән «Кальбемне мең парә кылды шул гүзәл Хан мәсҗеде» рефрены белән ассызыкланып бара. Шагыйрьнең ачышы булган бу рефрен – нәфис яңгырашлы һәм тирән мәгънәле. Ул үткән тарих белән бәйле иминлек, гүзәллек турындагы кичерешләрне бүгенге ямьсезлек, фаҗигале яшәеш белән янәшә куя һәм шагыйрьнең милли азатлык турындагы уй-хыялларын лирик-психологик кичерешләр белән сугара.

Күренгәнчә, Мәҗит Гафуриның «Хан мәсҗеде» шигыре романтикларча контраст фикерләүгә корылган. Анда татар тарихына тәнкыйди караш та белдерелә: «җаһил булган бер заманда» Сөембикә манарасының «кыйммәтен белмәүгә», аны милли азатлык өчен көрәштә файдалана алмауга үкенеч тә чагыла.

Әмма ничек кенә аяныч булмасын, татар халкы тыштан (заһирән) сабыр, басынкы күренсә дә, кальбендә аның ут яна, ул азатлык идеалларын онытмаган:

Син өмид өзсәң дә – без өмидне өзмәдек,
Заһирән түзсәк тә безләр – кальбемездән түзмәдек.

«Сөембикә манарасы» шигыре жанр ягыннан да үзенчәлекле. Ул шәрык әдәбиятларында киң кулланылышта булган робагыйның бер төре – мөрәббәгъ рәвешендә иҗат ителгән. Шигырь юлларындагы иҗекләр саны – 15, рифмалашу (кафияләнү) рәвеше аааб; төп мәгънәне аңлатучы дүртенче юл рәдиф вазифасын да үти.

«Сөембикә манарасы» – татар халкының басып алучылар тарафыннан инкыйразга дучар ителгән Казан ханлыгына реквием. Анда ханбикә заманында югалган дәүләтчелегебезне сагыну да, киләчәктә аны кайтару һәм торгызу өмете чаткылары да бар. Башы һәм ае белән күкләргә, илаһи биеклекләргә омтылган Сөембикә манарасы бу изге тарихи хәтеребезне оныттырмыйча, милли символга әйләнеп, саклап тора.

Мәҗит Гафуриның Казан ханбикәсе Сөембикә турында язылган икенче әсәре 1910 елда язылган «Тәэссоратым. (Әдәбияттан бер кисәк)» дигән шигырьләр җыентыгында урын алган. Соңрак ул М.Гафури 1918–1920 елларда үзе төзегән «Мәҗмуга асар»енә «Сөембикәнең соңгы сүзләре» исеме белән кертелә (басылмый кала). Туксанынчы еллар башында галимнәребез тырышлыгы белән «Сөембикәнең актык көне» дигән бу романтик эчтәлекле шигырь, ниһаять, татар укучысына яңадан әйләнеп кайтты[6]. Үзенең эчтәлеге һәм төзелеше белән Сөембикә турындагы бәетләрне, тарихи җырларны хәтерләткән бу шигырь ханбикә биографиясенең иң фаҗигале мизгелен – Мәскәүгә әсир булып җибәрелү вакытын тасвирлый. Шагыйрь Сөембикәнең Казаннан китүен бәетләрдәгечә «мәхшәр көне» белән тиңли. Алай гына да түгел, Сөембикәнең туган-үскән, суын эчкән җирләреннән китүен автор Казан ханлыгыннан «тәхет китүнең билгесе», ә тәхет белән бергә «казанлылар кулыннан шәүкәт китүнең билгесе» дип саный. Аның Сөембикәсе «халык өчен көя», күз яшьләрен дә

[6] Мәҗит Гафури. Сөембикәнең актык көне // Сөембикә. – 1992. – №8.

үзе өчен түгел, ә Казан халкы «мәңге коллыкта калыр дип» борчылып түгә. Мәҗит Гафури Сөембикә образын Казан тәхетен үз кулында тотып торган гадәти ханбикә итеп кенә күзалламый, бәлки татар халкының азатлыгы өчен көрәш символына әверелгән ханбикә дәрәҗәсенә күтәрә.

Галимҗан Ибраһимов та «Татар шагыйрьләре» китабында Сөембикә исемен телгә ала[7]. Әдип Тукайның баштарак бөтендөнья мөселманнары хакында кайгыртуын, гыйлем һәм мәдәнияттә урта гасырларның Париж һәм Лондоны саналган Багдад, Кордова хәлифәлекләре турында язуын, ә соңрак төрки-татарларның шанлы тарихын яктыртуга күчеп, татарларның да тарихта тирән эз калдырган дәүләтле, мәдәниятле, ханнары да булган халык дип яза башлавын искәртеп китә. «Моңлы азан шагыйрьне тарихка алып китә, ләкин инде аның тарихында Һарун әр-Рәшидләр, Габдрахман Салислар юк – анда хәзер Сөембикәләр – иске шаннар, татар дәүләтләре...»[8]. Мисал өчен Г.Ибраһимов Тукайның «Кечке азан» шигыренә мөрәҗәгать итә. Тукай анда төрки-татарларның милли каһарманнары турында түбәндәге юлларны язган иде:

Ханнарга и-
реште хизан,
Җылый-җылый
Бирделәр җан:
Сөембикә
дә Чыңгыз хан;
Нә дәүләт кал-
ды да, нә шан! [9]

Гомумән алганда, Г.Ибраһимов Тукайның милли хисләр белән сугарылган, ханбикә Сөембикәбезне искә төшергән романтик шигырьләрен югары бәяли. Октябрь инкыйлабыннан соң исә Г.Ибраһимов милли тарихны, шул исәптән, Сөембикә образын, пролетар идеология күзлегеннән аңлатуны таләп итә башлый. Мәсәлән, ул 1924 елда Ленинның «Идите во все классы населения» дигән сүзләренә таянып, «Пролетариат әдәбияты» дигән хезмәтендә милли-дини каһарманнар тарихын пролетариатның сыйнфый көрәш турындагы карашлары күзлегеннән чыгып язарга кирәклегенә басым ясый. Аныңча, совет чоры татар әдәбияты барлык сыйныфлар һәм аларның каһарманнары турында яза ала. Ләкин язу белән язу арасында аерма бар. Милли-дини, тарихи каһарманнар образларын милләтче язучы идеалистик күзлектән гәүдәләндерәчәк, ә марксист исә үткәндәге «зур

[7] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Т. 5. – Б. 121.
[8] Шунда ук. – 121 б.
[9] Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Т. 1. – Б. 121.

куәтләрне» «сыйнфый каршылыклар ачып», «иҗтимагый-сәяси факторлардан» чыгып сурәтләүне төп максат итеп куячак[10].

XX гасыр башында Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе турында берничә сәхнә әсәре дә иҗат ителү мәгълүм. Шуларның берсе – 1910 елда язылган Казан ханлыгының соңгы көннәрен тасвирлаган, Сөембикә ханбикә турындагы җиде пәрдәлек тарихи пьеса. Бу хакта «Вакыт» газетасының 597 нче санында кыскача хәбәр басылып чыга. Әмма пьесаның тексты һәм авторы кем булу билгеле түгел. Хәбәрдә бары тик Казан яшьләреннән булган ике авторның күңел биреп эшләве, мөстәкыйль рәвештә иҗат итүләре турында искәртелә. Сөембикә турындагы безгә хәтта исеме дә мәгълүм булмаган бу пьесаның тарихи дөреслекне ничегрәк чагылдыруын күренекле тарихчы Гайнетдин Әхмәров тикшереп, карап чыкканлыгы да әйтелә. «Вакыт» газетасындагы кыска гына бу белдерүдә «Сөембикә» пьесасының беренче тарихи әсәр буларак театр сәхнәләрендә дә куелырга тиешлеге искәртелә, киләчәктә бу темага пьеса һәм романнар язылачагына ышаныч белдерелеп, тарихчыларга һәм әдипләргә иҗади уңышлар теләп калына.

Вакытлы матбугат битләрендә шагыйрь Фазыл Туйкинның да «Сөембикә» драмасын язып бетерүе турында хәбәр ителгән[11]. Хәбәрдә милли һәм иҗтимагый үзгәрешләргә бай булган тарихыбызда драма һәм фаҗига язар өчен әллә никадәр материал һәм каһарманнар булу турында сөйләнә, мондый пьесаларның театр сәхнәләрендә куелырга тиешлегенә басым ясала. Дүрт пәрдәле бу драма авторның милли каһарманнар турында язган әсәрләренең икенчесе (әсәрнең тексты югалган). «Сөембикә» драмасы сәхнәгә куелу уңае белән «Вакыт» газетасында бер рецензия дә пәйда була (1914. – 17 декабрь, №1657).

Сөембикәгә багышланган өченче әсәр – төрек офицеры Гали Хәйдәр тарафыннан язылган «Шаһгали хан» исемле фаҗига. Бу трагедия дә (татарчага тәрҗемә ителеп) «Сәйяр» труппасы артистлары тарафыннан Казанда 1918 елның 4 маенда сәхнәгә куелган (басылмаган, кулъязмасы сакланмаган). Әсәрдә Шаһгали ролен мәшһүр Габдулла Кариев, Сөембикә ролен Фатыйма Ильская башкара. Спектакльгә Фәтхи Бурнаш (Номерсыз урындык) уңай рецензия язып бастырган («Кояш», 1918, 22 май, № 1237).

Татар халкының милли хисләре бик тә югары ноктага күтәрелгән унынчы елларда ханбикә турында берничә драма әсәре дә языла, сәхнәләштерелә. Бу хакта рецензияләр дә басылып чыга. Кызганычка каршы, әлегә аларның текстлары бүгенгә кадәр табылмаган, шуңа күрә дә, безнең көннәргә килеп җитмәгән бу пьесалар турында тәфсилле, дәлилле фикер йөртү мөмкин түгел.

Шулай итеп, Казан ханлыгы җимерелүгә 350 ел үткәч тә, XX гасыр башы татар иҗтимагый һәм әдәби фикерендә Сөембикә ханбикә образы калкып чыга. Аның турында дистәләгән фәнни мәкалә, тарихи-публицистик, әдәби һәм сәхнә әсәрләре, шигырьләр иҗат ителә. Ихтимал, аның турында беренчеләрдән булып «Инкыйраз» антиутопиясендә авыз

[10] Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. – Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 446-447 («Пролетариат әдәбияты турында» исемле 1924 елда язылган мәкаләдә).

[11] “Сөембикә» драмасы язылып тәмамлануы турында” // Вакыт. – 1914. – 17 декабрь (№1657).

тутырып сүз әйтүче Гаяз Исхакый булгандыр. Нәкъ менә бу чорда Сөембикә тарихи шәхес һәм әдәби каһарман гына булып калмый, ә татар халкының милли азатлык идеалларын үзендә гәүдәләндергән күп мәгънәле, романтик эчтәлекле милли символга әверелә.

1900–1918 еллар аралыгында Казан ханлыгы һәм Сөембикә ханбикә турында шактый санда тарихи хезмәтләр һәм әдәби әсәрләр язылуның сәбәбе бу чорда татар халкының милли Яңарыш юлына аяк басуы һәм аның җир шарының башка халыклары белән бергәләп, ирекле яшәешкә һәм тәрәкъкыяткә лаек милләт икәнлеген раслауга юнәлтелгән омтылыш иде.

## 2. Татар халык авыз иҗаты әсәрләрендә Сөембикә

Милләтебезнең асыл затлары халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас хатирә булып яши. Кадерле ул-кызларының исемнәре бәет һәм тарихи җырлар, легенда һәм риваятьләр булып татар халкы күңелендә саклана. Халкыбызның хәтерле, нечкә күңелле, сизгер булуына ишарәләп, Тукай да: «Иске, күчмә заманнардан калган гадәтме, нидәндер, безнең халык – шигырь вә җыр-бәетләр чыгарырга бик маил халык», – дип язган иде[12]. Бәетләр тарихи яки тормыш-көнкүреш вакыйгаләре артыннан ук, ә инде сүз төрле сугышлар, баш күтәрүләр кебек зур вакыйгаләр турында барса, шулар белән бер үк вакытта иҗат ителәләр[13].

«Сөембикә бәете» – татар тарихының иң фаҗигале чорын чагылдырган халык әдәбияты җәүһәрләренең берсе. Сталин тоталитаризмы дәверендә урта гасырлардагы дәүләтчелегебез тарихына, ханнарыбызга багышланган чыганакларны, фольклор һәм язма әдәбият әсәрләрен өйрәнү мөмкинлеге булмады. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы 9 август карары белән аларны өйрәнү тыелган иде. Шул сәбәпле Сөембикә турындагы бәетләр, мөнәҗәтләр, тарихи җырлар да фәнни әйләнешкә кертелмәде. Бары тик үзгәртеп кору еллары килгәч, 90 еллар азагында гына, бу хакта берничә фәнни хезмәт дөнья күрә.

«Сөембикә бәете»нә беренче мәртәбә күләмле һәм төпле анализ 1997 елда «Казан утлары» журналында профессор Фатих Урманче тарафыннан бирелә. Мәкаләдә бәетнең язылу тарихы, Сөембикәнең кайчан тууы, Җангали һәм Сафагәрәй ханнар белән Казандагы тормышы, алар үлеменнән соң ил башы булып Казан ханлыгы белән идарә итүе, тәхет тирәсендә барган ыгы–зыгылар, рус дәүләте белән мөнәсәбәтләр, ханбикәнең улы белән әсирлеккә Мәскәүгә җибәрелүе, Үтәмешгәрәй язмышы һәм Сөембикәнең калган гомере кайгы–хәсрәттә Касыйм шәһәрендә үтүе турында сөйләнә. «Сөембикә бәете»ндәге мәгълүматларның тарихи дөреслеккә якын килү-килмәү мәсьәләләре дә конкрет мисаллар белән дәлилләнә[14].

---

[12] Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. – Т.4. Проза. Публицистика (1907–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 175.
[13] Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары. – 1997. – №8. – Б. 162.
[14] Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары. – 1997. – №8. – Б. 161-170.

Фольклорчы Айсылу Садыйкованың «Сөембикә бәете»ндә шигъри аһәңнәр», «Гасырлардан килгән моңнар» исемле мәкаләләрендә исә бәетнең сәнгатьчә эшләнеше тикшерелә. Аларның һәр икесендә «Сөембикә бәете»нең эпиклыкка корылган, контраст алымнар кулланылган тарихи бәет булуына, бәет башламында Орхон-Енисей, болгар-татар кабер ташларына хас язу традицияләренең сакланып калуына, хикәяләүнең беренче зат исеменнән алып барылуына, бәеттәге сыктау жанры элементларына бәйле рәвештә лирик башлангычның һәм фаҗигалелекнең зур урын алып торуына басым ясала[15].

Күренекле тарихчы Михаил Худяков үзенең «Казан ханлыгы буенча очерклар» (1923) исемле хезмәтендә Сөембикә турындагы легендаларның әле ханбикә үзе исән чагында ук барлыкка килүенә игътибар иткән иде. Алар Казан елъязмасы («Казан тарихы») авторы тарафыннан аерым мотивлар рәвешендә теркәлеп тә калынган. М.Худяков болай дип яза: «Легенды о ней начали появляться еще при жизни: составитель «Казанского летописца» изобразил Сююн–Бике как непримиримую противницу русских; она предсказала Сафа-Гирею падение Казанского ханства, она посылала к оракулу узнать о судьбе государства, она же поднесла ненавистному Шах-Али ядовитое кушанье и отравленную рубашку»[16]. Шунысы игътибарны җәлеп итә: Сөембикә турындагы бу фольклор мотивларының барысы да Казан ханлыгының иминлеген саклап калу мәсьәләсе белән тыгыз бәйләнгән.

Сөембикә турындагы бәетләрнең берничә варианты барлыгы билгеле. Әмма аларның кайчан барлыкка килүләре турында фикер аныклыгы юк. Танылган фольклорчы Хәмит Ярми татар фольклорының, шул исәптән бәетләрнең борынгы үрнәкләре XVI гасырда язылган «Казан тарихы»нда сакланып калган дип исәпли. Аныңча, бу рус авторы «тарихи вакыйгаләрне, төрле легендаларны язып ала һәм аларны үзенең елъязмасында теркәп калдыра. Менә бу материалларны да борынгы татар фольклорының язма чыганаклардагы кызыклы үрнәкләре дип санарга мөмкин»[17].

Флора Әхмәтова фикеренчә, урта гасырларда Сөембикә турында бәетләр чыгарылганмы, юкмы – бу хакта төгәл генә әйтү кыен. Ләкин шулай да, аныңча, XX гасыр башындагы шагыйрь һәм драматургларның элекке риваять, бәет, эпос әсәрләренә таянып, яңа әсәрләр иҗат итүләре (Ф.Бурнаш, К.Юлдаш, М.Фәйзи һ.б.) «Сөембикә бәете»нең киң таралуына китерә[18].

Ф.Урманче «Сөембикә бәете»нең «XVI гасырның икенче яртысында иҗат ителгән дип кистереп әйтеп булмый», дип яза[19]. Галим бәет «гүзәл ханбикә вафат булып, берничә гасыр үткәч барлыкка килгән булса кирәк», дигән фикерне алга сөрә[20]. Бу фикерне кабул итү кыенрак. Бәет жанрының эчке табигате шундый ки, ул тарихта һәм яшәештә булып үткән вакыйгаләрне бары тик гасырлар үткәч кенә искә төшерә һәм чагылдыра торган җанр түгел.

---

[15] Садыйкова Айсылу. «Сөембикә бәете»ндә шигъри аһәңнәр» // Мөслимә. – 1998. № 2. – Б. 2; анык ук. Гасырлардан килгән моңнар // Татар иле. – 1998. – №2. – Б. 37-38.
[16] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – М.: Инсан, 1991. – С.182.
[17] Ярми Х. Татар халык иҗаты. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – Б. 10.
[18] Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1983. – Б. 295.
[19] Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары. – 1997. – №8. – Б. 162.
[20] Шунда ук.

Бәетләрнең бик тә җитез, сизгер, көн пафосына сугып бара торган оператив жанр икәнлегенә игътибар итеп, Тукай болай дип язган иде: «Чү, аз гына бернәрсә «шылт» иттеме, инде аның тугрысында иртәгә урамга бәетләр чыга»[21].

«Сөембикә бәете»ндәге төгәлсезлекләрне, мәсәлән, Сөембикә Казанга Кырымнан килде дигән ялгыш фикерне истә тотып, Фатих Урманче бәетнең кайчанрак барлыкка килүе турында мондый фаразны да тәкъдим итә: «Ә бәлки ул (ягъни бәет. – *И.Р.*) берничә йөз ел буена, язма рәвештәме, яисә күңелдә йөрепме, төрле үзгәрешләр кичергәндер, еллар–гасырлар үткән саен, аның нигезендә яткан тарихи вакыйгаләр, фактлар онытыла баргандыр»[22].

А.Садыйкова «Сөембикә бәете»ндә шигъри аһәңнәр» дигән мәкаләсендә бәеткә кергән сыктауның бик борынгыдан килә торган уртак төрки традиция булуын һәм бу «мотив «Сөембикә бәете»нең XVI гасыр әсәре булуын исбатлый торган дәлил», дип искәртә[23]. «Сөембикә бәете»ндәге мотивлар А.Садыйкованың икенче бер хезмәтендә –«Идеология ислама и татарское народное творчество» исемле монографиясендә ислам фәлсәфәсе яктылыгында тагы да киңрәк һәм тирәнрәк тикшерелә. Алдагы мәкаләләрендә әйткән фикерне куәтли төшеп, ул болай дип яза: «Мотив разговора с покойным» восходит, видимо, к доисламским общетюркским традициям. Древнетюркский мотив – дополнительное свидетельство, что баит или основная часть его, был создан в XVI веке, в эпоху Казанского ханства»[24].

Күренә ки, «Сөембикә бәете»нең кайчан барлыкка килүе турындагы фаразлар шактый каршылыклы. Ул урта гасырларда туганмы, әллә яңа заманда гына барлыкка килгәнме – галимнәр бу хакта кистереп әйтүдән тыелалар. Ләкин шуңа да карамастан, фольклор галимнәре һаман да эзләнәләр, уйланалар, яңадан-яңа фикерләр әйтәләр. Мәсәлән, байтак авторлар сыктауларның XVI гасырга ук каравын кире какмыйлар. Хезмәтләренең берсендә Ф.Урманче «Сөембикә бәете» Казан ханлыгы чорында иҗат ителгән бәетләрнең классик үрнәге дип атый[25]. Безнең уебызча да, Сөембикә турындагы шактый камил эшләнгән бәетнең нигезе Казан ханлыгы тарих сәхнәсеннән төшкәч үк салынган булырга тиеш. Моның шулай икәнлеген «Казан тарихы»нда билгесез рус авторы тарафыннан китерелгән төрле тарихи мәгълүматларның, сәнгатьчә фикерләү алымнарының «Сөембикә бәете» белән бик тә аваздаш булуы, урыны-урыны белән бу охшашлыкларның сүзгә-сүз тәңгәл килүе, фикри уртаклыкларның сакланып калуы да раслый булса кирәк. Мәскәүгә тоткынлыкка алып кителү мәҗбүрияте алдында калган Сөембикәнең эчке кичерешләрен гәүдәләндергән мотивлар моңа ачык мисал була алалар. Мәсәлән, хәсрәтеннән ханбикәнең «тере мәет»кә

---

[21] Тукай Г. Әсәрләр: Биш томда. – Т.4. Проза. Публицистика (1907–1913). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. – Б. 175.
[22] Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары. – 1997. – №8. – Б. 162.
[23] Садыйкова А. «Сөембикә бәете»ндә шигъри аһәңнәр // Мөслимә. – 1998. – №2. – Б. 2.
[24] Садекова А.Х. Идеология ислама и татарское народное творчество. – Казань: Изд-во «Фикер», 2001. – С.175.
[25] Бәетләр. Мөнәҗәтләр // Төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы Ф.И.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 7.

әйләнеп, ләхеткә кереп ятарга да риза булуы; теләктәшлек күрсәтүчеләрнең рус патшасы игелекле дип, аны тынычландырырга тырышулары; Сөембикәне югалту кайгысыннан Казан шәһәренең елау-сыктау авазлары белән тулуы һәм аның тол хатынга, үксез балага охшап калуы. Дәлилләү өчен «Сөембикә бәете» белән «Казан тарихы»ннән түбәндәге мисалларны да китерик:

«Бүген булдык җанлы үлек, алсана, җаным, кабереңә» (32 б.).

*«…и отверзи ми темный свой гроб и поими мя к себе живу» (99 б.).*

«Кайсылары: «Мәскәү ханы рәхимле», дип юата» (32 б.).

*«…самодержец милость велику тебе покажет, милосерд бо есть ко всем» (100 б.).*

«Шәһәр тәмам гөрлидер, җылау-сыктау тавышы» (32 б.).

*«И плакася ея горко весь град и вся земля неутешно» (100 б.).*

«Калды җылап Казаным, охшап үксез балага» (33 б.).

*«…и яко жена худая вдовая явльшися осиротевши» (101 б.).*

Югарыда китерелгән мисаллар типологик охшашлык булып кына калмыйча, «Сөембикә бәете»нең XVI гасырда ук, ханбикә язмышына бәйле фаҗигале вакыйгаләр артыннан ук иҗат ителүе турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирәләр кебек. Ә «Казан тарихы» авторының татар телен яхшы белүе һәм үзенең әсәрендә татар халык фольклоры әсәрләрен – бәет һәм тарихи җырлар, легенда һәм риваятьләрне кулланганы алдарак искәртелгән иде инде.

«Сөембикә бәете» тарихи бәетләр өчен хас традицион башлам – вакыйгаләрнең елын-вакытын күрсәтү белән башланып китә («Мең дә биш йөз унбиштә бу дөньяга килгәнмен»)[26]. Ләкин ханбикәнең туган елы әле бүген дә төгәл билгеләнмәгән. Мәсәлән, Һади Атласи ханбикәнең туган һәм үлгән елларын билгесез дип яза. Күренекле мәгърифәтче галим, тарихчы Ризаэтдин Фәхретдин Сөембикәнең туган елын – 1519 дип күрсәткән[27]. Хәер, бу дата Р.Фәхретдиновның үзендә дә төрлечә бирелә. 1903 елда Уфада басылып чыккан «Мәшһүр хатыннар» китабында ул Сөембикәне 1520 елда туган дип әйтә[28]. Ф.Урманчеев та бу хакта төрле фаразлар булуын искәртеп, ханбикә турында роман язган Рабит Батулланың «1516 еллар тирәсендә туа…» дигән сүзләренә игътибар итә.

Бәеттә Сөембикәнең туган елы гына түгел, туган-үскән җире дә дөрес аталмаган:

«Казаннарга Кырымнан китерде бәне тәкъдирем,
Казанның бер яшь ханы Җангали булды ирем»[29].

Белгәнебезчә, Сөембикә Нугай далаларында Йосыф морза гаиләсендә тәрбияләнеп үсә. Ханбикәнең туган җире Кырым дип күрсәтү, Ф.Урманче фикеренчә, гасырлар дәвамында

[26] Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1983. – Б. 30.
[27] Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары. – 1997. – №8. – Б. 162.
[28] Ризаэддин Фәхретдин. Сөембикә // Мирас. – 1992. – №10. – Б. 27-28.
[29] Татар халык иҗаты. Бәетләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – Б. 30. Моннан соң «Сөембикә бәете»ннән мисаллар бу басманың 30-34 битләреннән китерелә.

Сөембикә турындагы халык хәтеренең тоныклана бару һәм онытыла төшү нәтиҗәсе.

Бәеттә башка даталар – Сөембикәнең Җангали ханның хатыны булып ике ел торуы, Сафагәрәй белән 14 ел гомер кичерүе турындагы биографик фактлар, ханбикәнең дүрт яшьлек улы Үтәмешгәрәй белән әсир ителүе турындагы вакыйгаләр бозылмыйча, төгәл күрсәтелгәннәр.

Бәет жанрына хас булганча, «Сөембикә бәете» ханбикәнең биографиясен яктырту белән башланып китә. Сөембикәнең Җангали ханга кияүгә чыгуы, аның белән ике ел гына яшәп калуы, ханның үтерелүе, тол калуы, кайгылы булуы турындагы хәл-әхвәлләр бик кыска гына – ике бәеттә генә бәян ителә. Ә менә ханбикәнең Сафагәрәй хан белән ундүрт ел гомер кичерүе, аңа нисбәтле вакыйгаләр һәм кичерешләр шактый тулы һәм объектив тасвирланган. Казан ханлыгы белән Сафагәрәй хан идарә иткән елларның ил һәм халык өчен тыныч еллар булмавы турында бәеттә түбәндәгечә әйтелә:

Сафагәрәй вакытында бик күп булды сугышлар,
Һәркайдан яу килгәчтин авыр булды сулышлар.
Шәһәр тышында сугыш, эчендә тулган афәт,
Шул тынычсыз вакытта Сафагәрәем вафат.

Сафагәрәй үлеп киткәч тә, Казан ханлыгында көчәеп киткән сәяси тотрыксызлыкны, тәхет тирәсендәге ыгы-зыгыларны, аерым фиркаләр, төркемнәр, шәхесләр арасындагы каршылыкларны гәүдәләндерүгә бәетнең өчтән бер өлеше диярлек, ягъни 18 бәет (36 шигъри юл) багышланган. Бу болгавыр замандагы күңелсез хәлләрнең барысы да ил башлыгы Сөембикә уй-фикерләре һәм кичерешләре рәвешендә чагыла. Шик-шөбһә, коткы эчендә яшәгән казанлылар Сөембикәнең акыллы киңәшләренә колак салмыйлар, аның һәр сүзеннән, һәр гамәленнән гаеп эзлиләр. Көндәшләре исә Сөембикәне Казан-Мәскәү мөнәсәбәтләрен бары тик сугыш белән генә хәл итәргә тырышучы патшабикә итеп күрсәтергә тырышалар. Вафат булган ире Сафагәрәй кабере өстенә салдырылган манара аеруча күп гайбәтләргә сәбәп була:

«Сугыш өчен Сөембикә манараны салды», дип,
Тагы язган «Кырымнан яңа гаскәр алды», дип.

Бәеттә Сөембикә Казан–Мәскәү дәүләтара мөнәсәбәтләрендә үзара уртак тел табып, килешеп яшәү тарафдары итеп сурәтләнә. Ул зур хәрби көч-куәт туплаган, экспансия юлына баскан рус дәүләтенең Казан ханлыгы өчен зур куркыныч тудырганын яхшы аңлый:

Мәскәү ханы Казанны алмак була үзенә,
Казанлылар фетнә ача, карамыйлар сүземә.

Тәхет даирәсендәге бертөркем морзалар да Русия белән сугыш котылгысыз дип, рус-татар дәүләти мөнәсәбәтләрен кискенләштерүгә этәрәләр. Сөембикә исә, буйсынулы мөнәсәбәтләр урнаштырып булса да, руслар белән тыныч яшәү юлларын эзли:

Морзаларга мин әйттем, Мәскәү белән белешик,
Һичбер җәбер итмәсә, буйсыныйк та килешик.

Казанлылар бу адымга риза булмаса, ханбикәнең альтернатив тәкъдиме дә бар:
Инде алай булмаса, көчле белән көрәшмик,
Солых бозмыйк, мал бирик, сугыш диеп сөйләшмик.

Сөембикә авызыннан әйттерелгән бу сүзләр Казанда үзара тарткалашучы төркемнәр арасында ханбикә русларга таба авышкан идарәче булган икән дип аңлашылырга тиеш түгел. Шундый ук гаепләү сүзләрен:

«Көфер берлә мәмләкәт булмас хәраб,
Золым белән йыкылыр улус йөдәп», –

дигән шигъри юлы[30] өчен Сөембикәнең замандашы шагыйрь Мөхәммәдьярга карата да әйтеп булыр иде. Бу бәеттәге «көфер» сүзе – «христиан», «рус» дигән мәгънәләрне аңлатмый. Мөхәммәдьяр фикеренчә, «көфер»лектән яманрак нәрсә бар, ул – золым, ягъни хаксызга рәнҗетелү, җәберләү, изелү. Мөхәммәдьяр кебек, ханбикә Сөембикә дә Казан ханлыгын руслар золымына дучар итмичә тыныч яшәргә һәм аның мөстәкыйльлеген тәэмин итәргә чакыра:

Тыныч торсак – күп еллар каннарыбыз түгелмәс,
Мәскәү белән сәүдә итсәк – дәүләтебез кимемәс.

Реаль Сөембикә Явыз Иванның мәкерле агрессив сәясәт алып баруын яхшы аңлаган. Бәеттә язылганча, ул рус патшасы татарларга җәбер салмас дигән иллюзия белән дә яшәмәгән, аңа буйсынырга да чакырмаган. Киресенчә, Казан ханлыгын рус баскынчыларыннан саклап калу юлында күп эшләр башкарган. Бу хакта тарихчыларыбыз, әдәбиятчылар тарафыннан байтак фикер әйтелгән.

Бәеттәге Сөембикә исә, рус дәүләте белән төзелгән килешүләргә таянып, аларны бозмыйча, кайбер чикләүләргә, ташламаларга барып булса да, тыныч яшәү ягында. Чөнки илләр һәм дәүләтләрнең үзара уртак тел табып, сәүдә итеп, икътисади мөнәсәбәтләр булдырып, кан елгалары агызуга, шәһәр–авылларны мәгънәсез яндыруга, җимерүгә караганда, бай, мул, тыныч тормышта яшәүләре мең мәртәбә артыграк. Шул максатны күздә тотып, 1549 һәм 1551 елларда, Сөембикә Явыз Иван белән «барышлыкта булырга теләп» (Һади Атласи), Мәскәүгә аерым кешеләр һәм илчелекләр дә җибәрә. Ул җибәргән илчеләр арасында шагыйрь Мөхәммәдьяр да була. Әмма аңа руслар белән килешү төзеп, тынычлык урнаштыру миссиясен үтәп, Казанга әйләнеп кайтырга туры килми. Мөхәммәдьярның кайда икәнлеген белергә теләп, аны эзләп, Сөембикәнең атасы Йосыф морза Явыз Иванга хат та

[30] Мөхәммәдьяр. Нуры содур. Поэмалар һәм шигырь. – Казан: Татар. кит. нәшр., Б. 1997. –178. Улус – олыс.

яза. 1549 елның 8 августында рус патшасы «Казан тылмачы Мөхәммәдьярны безнең кешеләр Муромда үтерделәр» дип, җавап бирә[31].

«Казан тарихы»нда, анда теркәлеп калган татар бәет-легендаларында Сөембикә руслар белән бернинди компромиссларга бармаучы, аларга сатылган Шаһгалине дә агулап үтерергә җыенучы ханбикә итеп бирелгән иде. Шул ук мотив Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе турындагы тарихи җырларда, мөнәҗәтләрдә, риваятьләрдә дә чагылыш тапкан. Христиан руслар белән мөселман татарлар бер-берсенең антиподлары дигән тема рус, төрек һәм татар телләрендә иҗат ителгән әсәрләрдә дә төп мотив булып кала.

«Сөембикә бәете»ндә тасвирланган фетнәчел морзалар, мәскәүлеләр белән солых шартларын үтәп, сугышмыйча яшик дигән Сөембикәнең акыллы киңәшләренә колак салмыйлар. Руслар исә үзләренә каршы чыгуның төп сәбәпчесе итеп морзаларны түгел, ә Сөембикәне гаеплиләр. Озак та үтми, алар Казан ханлыгына яу белән киләләр:

Карыштылар морзалар, Мәскәү сүзен алмыйлар,
Каршылыкны мәскәүләр миннән диеп аңлыйлар.
Казан-Мәскәү арасында тагын бер сугыш булды,
Җиңелгәчтен казанлылар, солыхка киңәш килде.

Руслар кул куярга мәҗбүр иткән бу соңгы солыхның нәтиҗәсе бик тә аяныч була: ул ханбикәне Мәскәүгә әсирлеккә җибәрү хисабына ирешелә:

Казандагы түрәләр солыхка кул куйганнар,
Мине Мәскәүгә озатып, тыныч тормак булганнар.

Шул рәвешчә, ире Сафагәрәй хан үлгәч тә, Казан ханлыгы белән идарә иткән елларда аңа рус дәүләтенең экспансиясе белән дә, Казан татарларының үз араларындагы таркаулык, башбаштаклык белән дә очрашырга һәм көрәшергә туры килә. Ханлыктагы бу иҗтимагый-сәяси вазгыять бәеттә Сөембикә шәхесенә бәйле рәвештә, логик яктан эзлекле һәм тирән драматизм белән гәүдәләнгән. Ханбикәнең халык канын түкмичә, дәүләт иминлеген саклап калу юлларын эзләвен «Сөембикә бәете»нең иң әһәмиятле гуманистик мотивы дип санарга кирәк.

Бәетнең өчтән ике өлешендә Мәскәүгә тоткынлыкка алып кителгән Сөембикәнең эчке кичерешләре гәүдәләнә. Анда фетнәче морзаларның ханбикәнең «башын сатуы», аны әсирлеккә алып китәргә рус илчесе килү, ире Сафагәрәй кабере белән саубуллашу, халыкның Сөембикәне елап озатып калуы, көймә белән башта Зөягә, аннан Мәскәүгә озатылу, Мәскәүнең «Кызлар мәйданы»на килеп төшү, сакчылар куелган йортка ябылу, патша сараенда Явыз Иван белән очрашу, улы чукындырылу, ә ханбикәнең үзен Шаһгалигә кияүгә бирү, Казан ханлыгының руслар тарафыннан яулап алынуы, әле күптән түгел генә

---

[31] Абилов Ш., Әхмәтҗанов М. Мөхәммәдьяр // Мөхәммәдьяр һәм аның чоры. – Казан: Изд-во «Гасыр», изд-во «Рухият», 1997. Альбомда текст татар, рус һәм инглиз телләрендә бирелгән.

Сөембикәгә каршы чыккан морзаларның да башы киселү, әләкче көндәшенең дә тоткынлыкка эләгүе – «Сөембикәне яндырган утта үзе дә яхшы пешүе» турында сөйләнә.

Бәетнең бу өлешендәге үзәк тема – универсаль эчтәлеккә ия булган аерылышу мотивы. Сөембикә ханлыктан, тәхет-бәхеттән, яраткан Казаныннан, сөекле халкыннан, җанга якын каберләрдән аерыла. Гасырлар дәвамында татар ханнары туплаган байлыклар, хәзинәләр дә рус иленә озатыла:

Хан сарайдан дәүләтне, мал-зиннәтне алдылар,

Өч көнгәчә маллар ташып, көймәләргә салдылар.

Сөембикә өчен иң зур югалту – йөрәк парәсе булган улы Үтәмешгәрәйне кулыннан тартып алып, янган утларга ыргытылу:

Ишеттем мин, баламны поплар алганнар диеп,

Гакылы да юк сабыйны диннән чыгаралар дип.

Дәүләттән, илдән-җирдән, газиз баласыннан аерылу мотивы тирән психологизм һәм фаҗигалелек белән сугарылган, гиперболалар белән көчәйтеп сурәтләнгән. Әсирлеккә китү мәҗбүриятенә дучар ителгән Сөембикә өч көн буена канлы күз яшьләрен коя, күзләренең нуры бетә, Сафагәрәй кабере янында такмаклап елау-сыктаудан телләре әйләнмәс хәлгә килә, хәлсезләнеп, тере мәеткә әйләнә. Хан сараендагы оркестрның йөрәк өзгеч җылау көйләрен уйнап озатуы Сөембикәнең хәсрәтен тагы да тирәнәйтә. Шәһәрдәге җылау-сыктау тавышлары кыямәт кубуны хәтерләтә башлый. Ханбикәне көймәгә утыртып алып китү, Казаннан мәңгелеккә аеру мотивы бәеттә аеруча тәэсирле бирелгән:

Көймә китте кузгалып, карчыгадай кошны алып,

Мин гарип-бичарадан акылны алып, һушны алып.

Волгага чыкканда карадым мин калага,

Калды җылап Казаным, охшап үксез балага.

Төрле сәяси төркемнәр арасында барган көрәшләр, замандашларының шәфкатьсезлеге корбаны булган Сөембикә үз башына өерелеп төшкән бәла-казаларны Корьән тәгълиматындагыча – «тәкъдир язуы» дип кабул итә. «Язмыштан узмыш юк» фәлсәфәсенең йогынтысы Сөембикәнең улы Үтәмешгәрәйнең үлеме турындагы авыр хәбәрне сабырлык белән кичерүендә дә күренә:

Гариб балам Үтәмеш алты яшенә җитте,

Фани дөньядан үтте, андан бер кайгым бетте.

Китерелгән мисалда бер төгәлсезлек тә күзәтелә. Үтәмешгәрәй алты яшендә түгел, 20 яшендә (1566) Сөембикә вафатыннан соңрак дөнья куя[32]. Әмма бәетне иҗат итүчеләр

[32] Өч яшьлек Үтәмешгәрәй 1551 елның август аенда анасы Сөембикә белән Мәскәүгә озатыла. 1553

ханбикәне татар җанлы һәм мөселман рухлы итеп күрсәтергә теләү сәбәпле, христиан руслар тәрбиясендә яшәп, теленнән, диненнән биздерелгән, манкорт хәленә төшерелгән Үтәмешгәрәйнең мәңгелек йортка күчүен хәерлерәк санаган булсалар кирәк. Бу хәлләрдән соң Сөембикәгә тәкъдиргә буйсынырга гына кала. Ул Шаһгалигә – «Казанга дошман җанга» көчләп кияүгә бирелә.

«Сөембикә бәете» яшәү фәлсәфәсен гәүдәләндергән, кеше тормышының чикләнгәнлеген белдергән бәет белән тәмамлана:

Дөньяга килгән адәм кайгы күрмичә китми,
Дөньяда шат йөргәннең дә туфрактыр ахыр урыны.

Шул рәвешчә, бәеттә Сөембикәнең дәүләти, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенә нисбәтән Казан ханлыгы тарихындагы киеренке драматик вакыйгалар, төрле фиркаләр арасындагы тартышлар һәм дә ханбикәнең Мәскәүгә әсирлеккә җибәрелүе белән бәйле фаҗигале эчке дөньясы яктыртыла.

Казан ханлыгының таркалу, җимерелү чорларында язылган бу бәеттә Шәркый Яңарыш әдәбияты өчен хас гуманистик карашлар борынгы төрки дәвердән үк килә торган җылау-сыктау жанры традицияләре белән янәшә яши, үзара тыгыз үрелеп бара. Чөнки бәетләр, Фатих Урманче язганча, «язма шигърият белән халык иҗаты очрашкан ноктада торучы иҗат төре»[33].

* * *

Сөембикә ханбикә турындагы фольклор әсәрләре XVI гасырның икенче яртысында ук мәйданга чыккан һәм халык арасында телдән дә, язма рәвештә дә киң таралыш алган. Гасырлар дәвамында бу бәет, риваять, тарихи җыр, мөнәҗәтләргә яңа тарихи мәгълүматлар, фикри катламнар, әдәби төсмерләр өстәлгән, аларның яңа вариантлары барлыкка килгән. Бу уңай белән Гомәр Бәшировның иске китаплар арасында сакланып калган бәет варианты турында берничә сүз әйтәсе килә. Ул күләме ягыннан зуррак, тарихи вакыйгалар да киңрәк итеп, Сөембикәнең уй-фикерләре, эчке кичерешләре дә тулырак тасвирланган. Бәеттә «Сөембикә башыннан узган зуррак вакыйгаләрнең һәркайсы үзенә хас эчтәлекле рефрен (кушымта) белән каймалап, түгәрәкләп бирелә»[34].

Искәртергә кирәк, Сөембикә турындагы бәетләрнең башка вариантларында да рефреннар очрый. 1914 елда ундүрт яшьлек шәкерт Г.Бәширов тарафыннан күчереп алынган бәетнең башкалардан аермасы шунда, андагы кушымталар сәнгати яктан шактый уңышлы эшкәртелеп, лирик җылылык һәм моң-сагыш белән сугарылып бирелгән. Аларда Сөембикәнең Нугай далаларында әти-әнисе янында үткән бала чагын, яшьлеген сагынуы да,

елның январенда чукындырыла һәм 1566 елда Ливон сугышында үлә (Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 399.).

[33] Бәетләр. Мөнәҗәтләр // Төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы Ф.И.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 6.

[34] Бәширов Г. Бу бәет турында берничә сүз // Сөембикә. – 1991. – №1. – 19 б.

ханбикә дәрәҗәсенә ирешкәч, өелеп килгән бәхетсезлекләрдән үрсәләнүе дә, улы белән тол-ятим калуы, ханлыкны, хансарайны, Казанны югалтуы, әсирлеккә төшүе кебек ачы хәсрәтләр дә чагылыш тапкан:

Сөембикә атым, нугай затым, кайда минем яшь дәүләтем,
Сабый чагым, нурлы йөзем, морза кызы булган вакытым?
Сөембикә атым, нугай затым, калды минем хан-дәүләтем,
Күңелем моңлы, күзем яшьле, калды ялгыз әсир-ятим[35].

XVI гасырда, әле Сөембикә үзе исән чакта ук, чыгарылган дип фаразланган бәеттә Сафагәрәй кабере өстенә манара салдыру хакында гына әйтелә. Г.Бәширов язып алган вариантта өр-яңа сигез юл (дүрт бәет) – Сөембикәнең манара белән хушлашу, аерылышу күренеше өстәлгән. Мисал өчен ике бәетне китереп үтик:

Дидем: Ярабби, манарам, белмисең, кайда барам!
Калдырдым инде сәни, тәкъдиргә юктыр чарам.
Хан өстенә корылдың, таштандыр сәниң җисмең,
Җимерелгәнче йөрермез исемен белән һәм исмең[36].

* * *

Шәкерт Гомәр Бәширов «Сөембикә бәете»н нинди кулъязмадан, кайсы китаптан күчереп алуын теркәп калдырмаган. Әмма чагыштырып карагач, ул күчергән бәетнең мәгърифәтче галим, шагыйрь Габделгалләм Рәшидинең «Сөембикә хәлләре» исемле әсәре белән бик охшаш булуы ачыклана. Г.Рәшиди аны 1912 елда «Сөембикә» журналында да, аерым китап рәвешендә дә бастырып чыгара. 1997 елда Г.Рәшиди тексты кабат «Сөембикә» журналында дөнья күрде.

Г.Рәшидинең «Сөембикә хәлләре» күләм ягыннан шактый зур. «Сөембикә бәете»ндә бәетләр саны 66, Г.Бәширов күчергән вариантта 70 булса, Г.Рәшидинең «Сөембикә хәлләре»ндә аларның саны 102 гә җиткерелгән. Г.Бәширов күчермәсендәгечә, бәеттә Сөембикәнең беренче ире Җангали турындагы юллар, морзалар белән ханбикә арасындагы конфликт, манара һәм казанлылар белән саубуллашу күренешләре киңәйтелеп сурәтләнгән. Ә менә Г.Бәширов нөсхәсендә алар төшереп калдырылган, әмма «Сөембикә бәете»ндә булган Сафагәрәй кабере янындагы елау-сыктаулар Г.Рәшиди бәетендә сакланганнар. Алай гына да түгел, аларның саны алтыдан сигез бәеткә, ягъни 16 шигъри юлга җиткерелгән. Сөембикә сыктавына өстәлгән бәетләр түбәндәгеләр:

Без китсәк тә еракка, кызганучы кеше юк,
Атам да, анам да, син дә юк, ишем дә, хушым да юк.
Син үлгәчтән ике ел җылап рәхәт күрмәдем,
Насыйп түгел, булмый икән, яныңа гүргә кермәдем.

---

[35] Сөембикә бәете // Сөембикә. – 1991. – №1. – 18–19 б.
[36] Шунда ук. – Б. 19.

Морзаларның икейөзлелеген, хөсетлеген, сугыш куркынычы янаганда бердәм фикердә булмауларын, руслар белән татарлар арасындагы конфликтны чишүдә дөрес юллар таба алмауларын, моның исә татар дәүләтләренең таркалуына сәбәп булуын күрсәтүгә «Сөембикә хәлләре»ндә күбрәк урын бирелгән:

Морзалар сүз аңламый, көчләре аз сугышка

Ничә кабат сүз бозып, барды алар солыхка.

Солых шартын тагын да бу морзалар боздылар,

Нугай, Кырым, Казанлар төрле җиргә туздылар.

Ил олугъларының мантыйксыз гамәлләре Сөембикә рәнҗүләре рәвешендә дә бирелә: «гаҗизләндем морзаларга йөрәгем-бәгьрем кан булып».

Бәеттә Явыз Иван хөкүмәтенең татарларга карата кулланылган сәяси, хәрби басымына да киңрәк тукталынган:

Мәскәү ханы Казанны алмак була үзенә,

Казанлылар фетнә ача, карамыйлар сүзенә.

Мәскәү ханы үгетли картны-яшьне, егетне,

Бирелегез миңа, ди, тотармын җәбер итми.

Опричнина белән рус илен канга батырган, улын үтергән, «Явыз» дигән кушамат алган Иваннан җәбер-золым көтмәү беркатлылык булыр иде. Казанлыларга «җәфа салу» мотивы да әсәрдә чагылыш тапкан:

Мәскәү әйтә: сугышмагыз, мин Казанны алырмын,

Рәнҗемәгез, ахырында яхшы ук җәфа салырмын.

* * *

Егерменче гасыр башында татарлар арасында Сөембикә турында мөнәҗәтләр киң таралган. Безнең көннәрдә аларның берсенә фольклорчы һәм композитор Котдус Хөснуллин тарафыннан музыка да язылган.

Мөнәҗәттә Сөембикә турындагы бәетләргә хас дөньяви эчтәлек, иҗтимагый-сәяси мотивлар сакланып калган. Әмма ханбикәнең эчке кичерешләре бәетләрдән үзгәрәк ачылган. Алар халык язмышы турындагы хис-тойгылар белән сугарып бирелгән:

Хуш, бәхетсез халкым! Мин калдырам сине,

Алларында торган мең афәтле килеш,

Киләчәксез килеш мин калдырам сине,

Йөзең канлы килеш, җәрәхәтле килеш.

Сөембикә – Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге, иминлеге өчен янып яшәгән шәхес. Фетнәчел морзалар тарафыннан үз башының русларга сатылуны да ул Казан ханлыгының, сөекле халкының шөһрәте-даны тарих сәхнәсеннән төшү, инкыйразга дучар булу кебек кабул итә:

Алар җиңде… Безнең кулдан кылыч төште,

Миңа – әсирәгә әзерләнде бөят.

Алып китә алар мине түгел, халкым,

Китә алар – синең шөһрәтеңне төяп.

Мөнәҗәткә Тукай шигъриятеннән алынган сурәтләрдән тыш (мәсәлән, кылыч образы), Дәрдемәнд лирикасы өчен хас аһәңнәр һәм фәлсәфи мотивлар да үтеп кергән:

Утлы кузлар ятып ята мәгърур кала,

Елантауда кешни яралы яу аты.

Безнең язмышларны әрдәнәләп өеп,

Безнең данны шул учакка атты.

Сүз дә юк, Казанның фаҗигасе символик сурәтләр ярдәмендә бик тә сәнгати тасвирланган. Жанр кануннары таләп иткәнчә, Сөембикә турындагы мөнәҗәт «бисмилла» сүзе белән башлана, тәкъдиргә буйсыну – «күркәм сабырлык» дигән дини-әхлакый күрсәтмә белән ачылып китә:

Дидем: Рабби, башыма төшкәндер бу авырлык,

Тәкъдиргә буйсынуда биргел күркәм сабырлык.

Сабырлыкка өндәү Корьән тәгълиматының үзәген тәшкил итә. Юкка гына ул изге китапта күп мәртәбәләр кабатланмый. Мөнәҗәттә сабырлык кешене җәннәткә илтүче зур рухи байлык (дәүләт) рәвешендә тәкъдим ителә. Сабыр булган очракта фаҗигале язмышлы Сөембикә дә Алланың яраткан бәндәсе булачак:

Сабырларны Аллаһы сөя,

Сабыр бирсен Тәгалә Алла.

Сабырга дәүләтем диди,

Сабырга җәннәтем диди,

Сабыр бирсен Тәгалә Алла.

Сабырлар җәннәткә керер,

Сабырсызлар җәһәннәмдә,

Сабыр бирсен Тәгалә Алла.

Сабырлык турындагы бу юллар бүгенге көнгә кадәр халык арасында мөстәкыйль мөнәҗәт буларак та башкарылып килә. Шул рәвешчә, Сөембикә турындагы мөнәҗәт бик тә үзенчәлекле мөнәҗәт эчендә мөнәҗәт рәвешендә язылган булып чыга. Бәетләрдәге кебек, мөнәҗәтнең азаккы юлларында кешеләрнең, шул исәптән Сөембикәнең дә җан хәрәкәте, шатлык-кайгы антиномиясе шәкелендә гәүдәләнә:

Дөньяга килгән адәм кайгы күрмичә тормый,

Дөньяда шат йөргәннәрнең дә туфрактыр ахыр урны!

Әмма Алла – гадел. Ул бу капма-каршылыкларны берләштерү кодрәтенә ия. Шатлыкка күмелеп яшәсәң дә, кайгы-хәсрәт эчендә гомер кичерсәң дә, Алла барысын да тигезли: бәндәләр яшәешендәге ахыр урын – туфрак. Димәк, җир тормышы – фани, кыска һәм чикләнгән. Бер уч туфракка әйләнү белән ул тәмам була.

* * *

Бәетләр дә, мөнәҗәтләр дә Сөембикәнең соңгы еллары турында артык мәгълүмат бирмиләр. Ә менә тарихи җырларда ханбикәнең Касыйм шәһәрендәге тормышы, Шаһгали хатыны буларак кыерсытылып яшәгән еллары тулырак итеп гәүдәләнгән. Мәсәлән, «Сөембикә китеп бара» җыруында иленнән, тәхетеннән аерылган ханбикәнең кайгы-хәсрәт эчендә яшәве, Казан каласы һәм халкы белән кан яшьләре түгеп саубуллашуы турында сөйләнелә. Аңа халык җырларында еш очрый торган агымсу – Идел елгасы образы да килеп кергән:

Идел ага яр кагып,
Уңга-сулга чайкалып.

Бу өзекне укыгач та, үзеннән үзе Мәхмүт Кашгари сүзлегендәге – «Әтил суы ака торур / Кыя төбе кака торур» дигән юллар искә төшә. Әмма инде бу Иделдә борынгы заманнардагы кебек балык мыжгып ятмый. Ул үзгәргән. Идел кешеләр, ханнар язмышы белән уйный:

Ут көймәсе китеп бара
Сөембикәне алып.

Су буе, чишмәләр адәм баласының кайгы-хәсрәтен таратуга ярдәм итүче символик сурәт буларак кулланылалар[37]. Күләме ягыннан зур булмаган романтик эчтәлекле бу тарихи җыр әсирлеккә китеп баручы Сөембикәнең кайгы-сагышын, җаны өзгәләнүләрен бик тә киеренке итеп тасвирлый:

Сөембикә ак яулыгын
Тоткан учлап кулына.
«Хуш, Казаным, каласың», – дип,
Үкереп елый буена.

Сөембикәне Мәскәүгә озату күренешләре XVII–XIX йөз рус драматургиясе әсәрләрендә дә чагылыш тапкан иде. Ләкин татар фольклоры үрнәге булган тарихи җырлар белән рус авторлары әсәрләре арасында җир белән күк аермасы. Мәсәлән, М.М.Херасковның «Россиада» поэмасында Сөембикәнең руслар башкаласына әсирлеккә баруы барокко стилендә, күтәренке

---

[37] Яхин А.Г., Мәһдиев М.С. Халык иҗаты әсәрләрен система итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 1982. – Б. 71.

рух һәм купшы сурәтләр белән бирелеп, ханбикә образы хозурлыкка чыккан рәвешен ала иде. «Сөембикә китеп бара» дигән җырда мондый идиллик церемониал тасвир юк. Анда бөтенләй башка эстетик үлчәм – күз яшьләре белән сугарылган җыр жанры өчен хас фаҗигалелек өстенлек итә.

«Тоткын Сөембикә җыруы»нда ханбикәнең әсирлектәге авыр тормышы, кара көннәре бәян ителә. Халык арасында киң таралыш алган бу җырның вариантлары да байтак: «Мәхбүс патша», «Тоткын Сөембикә бәете», «Зинданда ятучы патша мөнәҗәте», «Мәхбүс Сөембикә» һ.б. Аерым кулъязмаларда ул исемсез генә бирелә. Халык арасында аны гадәттә «Тәфтиләү» көенә җырлыйлар[38].

Егерменче гасыр башы татар поэзиясендә зиндан темасына бик күп әсәрләр языла. «Тоткын Сөембикә җыруы»на төрмә лирикасының йогынтысы да сизелә. Аның ханбикә зары рәвешендә язылуы, беренче зат исеменнән бәян ителүе, өслүбе, мотивлар, образ-сурәтләр шул хакта сөйли. Җырның «Ничә еллар бу бинада ялгыз утыра башым, / Бер савыт су, бер телем икмәк – бәнем ашаган ашым», дигән башламы үзе үк төрмә темасына язылган шигырьләрне искә төшерә[39].

Сөембикәнең Касыйм шәһәрендә сөйкемсез сөяк булып Шаһгали йортында бикләнеп яшәве төрле төсмерләрдәге «ут» гиперболасы ярдәмендә белдерелгән:

Хәсрәт утының сөреме каплады күзләремне,
Ут кабынган йөрәгемә, тышка да чыга аһым.

Тоткын ханбикә күңелне тынычландыручы, хушландыручы хәтфәдәй яшеллекне күрүдән дә мәхрүм. Дошманнары яккан хәсрәт утыннан аңа бөтен җир йөзе көйгән, янган кебек тоела:

Катыйфәдәй яшел улуб тора микән җир йөзе,
Яндырып бетердеме әллә аларны да дошманым?

Романтик әдәбияттагыча, Сөембикәнең аһ-зары планетар масштабларга күчерелә, хәтта бакчадагы сандугачлар да тоткыннар, сагыш җырларын көйләүчеләр кебек тоела.

«Тоткын Сөембикә җыруы»ның икенче өлешендә Сөембикәнең атасы Йосыф мирза йортында үткән күңелле яшь вакыты, ханбикә булып Казанда яшәгән бәхетле еллары тасвирлана. Ул алтыннар белән бизәлгән тәхеттә утырган, башына таҗлар киеп ауга чыккан, ул атланган атның бәясе дә «йөз мең алтын торган»; һәр тарафта аңа кәнизәкләр хезмәт иткән, баш вәзирләре тиешле киңәшләрен биреп торган:

Йөз мең алтын торыр иде
Бәнем атланган атым.

---

[38] Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар // Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Надиров И.Н. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – Б. 9.
[39] Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. – 3 нче том. XX гасыр башы. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1986. – Б. 224-225.

Әмма хәзер инде бу байлыклар һәм дәрәҗәләр хакында сагынып сөйләргә генә калган.

Күренә ки, «Тоткын Сөембикә җыруы» кискен романтик контрастларга корылган. Аның беренче өлешендә мәхбүс Сөембикәнең Касыймдагы аһ-зарлары, борчулы эчке дөньясы сурәтләнсә, икенче өлештә ханбикәнең күңелле бала чагы, яшьлеге һәм Казанда патшабикә булып бәхетле яшәгән еллары каршы куела.

«Тоткын Сөембикә җыруы»ның тоткынлык чорына багышланган өлеше Галиәсгар Камал әсәрләре җыентыгында «Мәхбүс шаһзадә» исеме белән бирелә. Ләкин аның Г.Камалныкы булуы бәхәсле. Чөнки бу текст әлегә даталары ачыкланмаган борынгырак кульязмаларда да очрый[40]. «Тоткын Сөембикә җыруы»ндагы:

Чыга торган идем аугa
Башыма таҗлар киеп;
Инде таҗ урынына калды
Бу озын кара сачем, –

дигән юллардагы таҗ образына игътибарны юнәлтәсе килә.

Таҗ образы беренче мәртәбә авторы билгесез дип саналган «Казан тарихы» әсәрендә кулланылышка кертелә: «Уже спаде венец з главы твоея».

Югалган дәүләтчелек хатирәсе булган бу образ татар фольклорында егерменче гасыр башында кабат күренә башлый. Мәсәлән, Г.Рәшиди белән Г.Бәширов вариантларында бер үк эчтәлектәге түбәндәге юллар бар:

Дидем: «Мескен, Казаным, төште таҗың башыннан,
Калдың бүген дәүләтсез, чишмә агар яшеңнән.

Таҗ образы Һади Атласиның Сөембикә турындагы хезмәтендә дә очрый. Ул аңа турыдан-туры «Казан тарихы»ннан килеп керә, чөнки автор моның шулай икәнлеген астөшермә дә күрсәтә.

Егерменче гасыр дәвамында чит илләрдә татар диаспорасы вәкилләренең Сөембикә турында язган әсәрләрендә таҗ сурәте югалган дәүләтчелек турындагы тарихи хәтер һәм әдәби образ буларак еш очрый. Ләкин бу авторларның барысы да диярлек сюжет сызыгының үстерелешендә дә, таҗ образын биргәндә дә Һади Атласи әсәренә таяналар.

«Казан тарихы» әсәрендә, Һади Атласи хезмәтендә, бәетләрдә, тарихи җырларда телгә алынган бу татар ханнары таҗы (XIV гасыр) Мәскәү Дәүләт корал палатасында саклана. XX гасыр азагында ювелир-рәссам Шамил Хәялиев җитәкчелегендәге төркем Казан ханлыгының әһәмиятле атрибуты булган бу таҗ-алтын бүрекнең күчермәсен эшләде. Ул

[40] Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар // Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Надиров И.Н. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1988. – Б. 379.

бүгенге көндә, бик тә кыйммәтле һәм кадерле экспонат буларак, Казан милли мәдәният үзәгендә тарихи хәтеребезне яңарту өчен хезмәт итә[41].

Сөембикә манарасының салыну вакыты һәм аның нинди вазифа үтәве турында галимнәр арасында төрледән-төрле фаразлар, фикерләр яшәп килә. «Сөембикә бәете»ндә исә бу таш манараны «үзем үлсәм дә, исемем күп елга бара» дип, хан кабере өстенә ханбикә үзе кордырып куйган диелә:

Хан кабере өстенә кордырдым таш манара,
Дидем: «Үзем үлсәм дә, исемем күп елга бара».

Билгеле булганча, Сөембикә Казан ханлыгы белән илнең эчке һәм тышкы халәте бик тә авыр кризис кичергән чорда идарә итә. Ханлыкны фетнә баскан, руслар сугыш белән янаган елларда ханбикә шөһрәткә омтылган, үз исемен мәңгеләштерү турында гына уйлаган, хыялланган дип уйлау башка да сыя торган нәрсә түгел. Ире Сафагәрәй кабере өстенә салдырган бу корылма дошманнарын күзәтеп тору, «сугыш өчен Сөембикә манара салды» дигән гайбәтләргә сәбәп була. Чынбарлыкта исә Сөембикәнең бөтен уй-фикере Казан ханлыгының иминлеген һәм бөтенлеген саклап калуга юнәлтелгән иде.

Кайбер чыганаклар, Сөембикә рус патшасына әсир ителгәннән соң, халкы белән саубуллашкан җирдә аның истәлегенә соңрак манара корылган, диләр. Коточкыч колониаль изү елларында руслар татарларга сөекле ханбикәләре хөрмәтенә манара салырга рөхсәт иткәннәр дигән фикергә ышану бик тә кыен. Галимнәрнең бер өлеше бу корылманың соңрак заманнарда рус патшалары тарафыннан дошманнарны күзәтү өчен салдырылган дигән фикердә тора. Мондый карашларны архитектура фәннәре докторы Нияз Халитов та куәтли. Аныңча, «…башня Сююмбеки возникла как один из элементов большой конструкций оборонительных сооружений Казанского кремля в первой половине 18 века…». Галимнең бу фикере белән килешәсе килми. Татар, рус, хәтта чит ил чыганаклары да манараның урта гасыр татар һәйкәле, татар архитектурасы үрнәге булуын раслыйлар. Сөембикә манарасы турында язылган күп санлы мәкаләләрдә дә шул ук фикер өстенлек итә. Шунысы ачык, Сөембикә манарасы гасырлар дәвамында татарлар тарафыннан бик кадерле бер истәлекле, хәтта изге булып санала. Габдулла Тукай сүзләре буенча да, Сөембикә манарасы изге булып саналган, манара күренеп торырлык җирдә булганда, балаларның йөзләрен аңа таба борырга өйрәткәннәр.

1552 елда руслар Казанны яулап алгач та, мәчетләр җимерелә һәм Сөембикә манарасындагы ай алып ташлана. 1918 елның 8 мартында ул кабат манара башына күтәрелә. Айны манарага татар артисты-акробат Минһаҗетдин Салтыковский куйган[42]. XX гасыр башында милли азатлык символына әйләнгән Сөембикә манарасына ай кую зур вакыйгагә әйләнә, шул заман вакытлы матбугат битләрендә дә киң яктыртыла. Бу вакыйгагә багышлап, «Сөембикә манарасы» дип аталган бәет тә барлыкка килә. Анда мондый юллар бар:

Әй манара, шатлан бүген – шатлана торган көнең,

---

[41] Шәфигый З. Казан бүрке – Идел йорт күрке // Мәдәни җомга. – 2001. – 6 июль.
[42] Ханзафаров Н. Сөембикә манарасына – ярым ай // Социалистик Татарстан. – 1990. – 11 май; аныкы ук. Символы Татарстана (мифы и реальность). – Казань: Фикер, 2001. – Б. 9-29.

Чөнки синдә гает укый татар гаскәре бүген!

Әй манара, кайтты бүген иске шәүкәтең кире,

Тулы өметләргә чумды бүген ислам гаскәре.

Әй манара, ач пәрдәңне, кара монда бер балкып,

Дошманнарның кулларыннан алдык сине без тартып[43].

1918 елда татар гаскәрләре катнашында Сөембикә манарасына тантаналы рәвештә ай күтәрү «Сөембикә китеп бара» исемле тарихи җырда да чагылыш тапкан:

Дүрт йөз ел буе ким-хурлыкта,

Торсаң да син, әй Казан!

Сөембикә манараңда әйтелә бу көн азан.

«Милләтләр эше халык комиссариатының Сөембикә манарасын хезмәтчел мөселман халкы карамагына тапшыру турында»гы карары 1918 елның февраль аенда кабул ителә. Ләкин большевикларның демократия уеннары озакка бармады, илдә дингә каршы рәхимсез көрәш башланды, Сөембикә манарасы башындагы ай да юкка чыкты.

Ничәме-ничә легендалар тууга сәбәп булган бу мәһабәт һәм серле манара XX гасырның соңгы чирегендә республикабыз башкаласы Казанның символына әйләнде. Үзгәртеп кору еллары килгәч тә, мөселман диненең символы булган ай кабат үз урынына кайтты.

Татар халкы Казан ханлыгының фаҗигале язмышын уртаклашкан Сөембикә исемен һич тә хәтереннән чыгармаган. Дәүләте һәм халкы өчен үзен корбан иткән ханбикә турындагы тарихи хәтерне җырлар, мөнәҗәтләрдә мәңгеләштергән. Сөембикә турындагы фольклор әсәрләре, XVI гасырның икенче яртысында ук мәйданга чыгып, халык арасында телдән дә, язма рәвештә дә киң таралыш алган була. Гасырлар дәвамында бәетләргә яңа тарихи мәгълүматлар, фикри катламнар, әдәби төсмерләр өстәлеп, аларның яңа вариантлары барлыкка килгән. Әле XVI гасырларда, Сөембикә ханбикә чорында ук барлыкка килгән бәетләр, XX гасыр башында, язучы һәм шагыйрьләребез тарафыннан яңадан эшкәртелеп, алар нигезендә Сөембикәнең фаҗигале язмышы турында эчтәлеге һәм әдәби эшләнеше ягыннан тагын да тулырак һәм баерак әсәрләр барлыкка килә.

Безнең тарафтан анализланган бәетләр өчесе дә (төп вариант, Г.Рәшиди һәм Г.Бәширов язып алган һәм эшкәрткән вариантлар) Казан ханлыгы белән рус дәүләте арасындагы киеренке мөнәсәбәтләрне, ил эчендәге сәяси каршылыкларны, Сөембикә биографиясен чынбарлыктан әллә ни ерак китмичә, реаль җирлектән әллә ни аермыйча, объектив һәм дөрес чагылдырган фольклор реализмы әсәрләре булып торалар. Романтик тенденцияләр исә бәетләрдә Сөембикә сыктаулары белән бәйле рәвештә генә биреләләр. Ә менә тарихи җырларның барысы да диярлек романтик эчтәлекле. Аларда ханбикәнең эчке кичерешләре үзәккә куелып, сәнгати уйдырмалылыкка да өлеш чыгарылган. Кыскасы, XX йөз башы татар

[43] Мөнәҗәтләр, борынгы җырлар // Татар иле. – 1996. – №46-47. – декабрь.

әдәбиятында активлашып киткән фольклор әсәрләре татар халкының тарихи хәтерен уятуга, милли аңын тәрбияләүгә хезмәт иткән.

### 3. Татар тарихчылары Сөембикә турында (1903–1914 еллар)

XIX гасыр азагында – XX гасыр башында милләтебез тарихы белән кызыксыну бик тә арта, тарихны чагылдырган фәнни хезмәтләргә дә ихтыяҗ үсә. Бу зарурияттне сизеп, аңлап алган шәхесләр арасында **Ризаэтдин Фәхретдиннең** (1859–1936) аерым урын алып торуын әйтергә кирәк. Бу күренекле дин әһеле, журналист, язучы, энциклопедист галимнең Казан ханлыгы тарихы, аның данлыклы ханнары турындагы хезмәтләре дә әһәмиятен югалтмаган. Галимнәребез бу киң эрудицияле белем иясен XIX йөз азагы – XX йөз башларында татар тарихи әдәбияты, иҗтимагый фикер үсешендә һәм мәдәнияте тәрәккъыятендә үзәк урыннарның берсен биләп торды дип саныйлар.

Галимгә, тарихи хезмәтләр язганда, төрле чор һәм төрле характердагы чыганакларның бөтен бер комплексын җәлеп итү хас[44]. Ул көнчыгыш авторларының хезмәтләренә генә таянмыйча, Көнбатыш, шул исәптән рус галимнәре язмаларына да нигезләнеп иҗат итә.

Р.Фәхретдиннең ханбикәгә багышланган беренче мәкаләсе «Мәшһүр хатыннар» дигән китабында дөнья күрә[45].

Ризаэтдин Фәхретдин Сөембикәне гүзәл, акыллы, мәшһүр хатын, Казан ханлыгының күп кенә тарихи вакыйгаләренә катнашкан ханбикә дип тасвирлый. Аның биографиясенә караган фактлар һәм тормыш баскычлары да нигездә дөрес күрсәтелә. Әмма бу мәкаләдәге Сөембикәнең кияүгә чыгу, тол калу, үлү еллары белән бәйле кайбер даталар һәм «ханбикә Шаһгалигә кияүгә бирелгәч Казанга кайтарылды» дигән фикере бәхәс тә тудырырга мөмкин.

Р.Фәхретдиннең Казан ханнары турындагы язмалар циклында чыккан «Сөембикә»[46] һәм «Үтәмеш Гәрәй хан вә Сөенбикә»[47] исемле мәкаләләре дә[48] әһәмиятле мәгълүматларга бай. «Үтәмеш Гәрәй...»не автор Сафагәрәйнең үлеме һәм аның улы Үтәмешгәрәйнең Казан тәхетенә хан итеп билгеләнүен тасвирлау белән башлап җибәрә. Бишектә генә яткан ике яшьлек сабый баланың Казан тәхетенә хан итеп игълан ителүнең сәбәпләрен аңлатырга тырышып, галим болай дип яза: «Анасы Сөенбикәне яратканы өчен, Сафагәрәй хан (тәхетне) Үтәмешкә васыять иткән иде, шул җәһәттән Сафагәрәйнең өлкән угыллары ханлыктан мәхрүм булып, сабый бала хан булды»[49]. Бу фикерне Р.Фәхретдин Н.М.Карамзин хезмәтенә нигезләнеп әйтә булса кирәк, чөнки рус тарихчысының «История государства

---

[44] Әмирханов Р. Галимнәр галиме // Ризаэтдин Фәхретдин. Казан ханнары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 21.

[45] Мәшһүр хатыннар: Ислам әсәрләрендә вә әһле Исламга күп хезмәт күстәрән хатыннарың тәрҗемәи хәлләре бәян иделән бер китаптыр.– Оренбург, 1903. – Б. 240-242.

[46] Шура. – 1910. –№6. – Б. 183-184.

[47] Шура. – 1908. – №22. – Б. 681-682; шунда ук. – №23. – Б. 713-716.

[48] Бу мәкаләләр Р.Фәхретдиннең «Казан ханнары» исемле китабына да (1995) кертелгән.

[49] Ризаэтдин Фәхретдин. Казан ханнары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – Б. 131. Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

Российскаго» хезмәтендә Үтәмешгәрәйнең хан булып билгеләнүе болай дип аңлатыла: «Сафа-Гирей пьяный убился во дворце и кончил жизнь внезапно, оставив двухлетняго сына, именем Утемишь Гирея, коего мать, прекрасная Сююнбека, дочь ногайскаго Юсуфа, и была ему любезнее всех иных жен»[50].

Ләкин болай язуның тарихи дөреслеккә туры килеп бетмәвен аңлаган Р.Фәхретдин икенче җөмләсендә үк «Нугай фиркасе вә анасы Сөембикә тырышлыгы белән Үтәмешнең хан булуы хәтергә килер» дип искәртә. Чыннан да, тәхеткә кемне хан итеп утырту мәсьәләсе тулысы белән теге яки бу фирка-партияләр кулында булып, Үтәмешгәрәйнең хан булып билгеләнүе, ә аның анасы Сөембикәнең, улы кечкенә булу сәбәпле, ханлык белән идарәне үз кулына алуы, шул вакытларда әле бик көчле булган нугай һәм кырым партияләренең эшчәнлеге, алып барган сәясәтләре белән бәйләп карау дөресрәк булыр.

Ризаэтдин Фәхретдиннең Сөенбикәне «Казан ханнары гаиләсендә вә хан сарае эчендә хөсне җәмал, ягъни искиткеч гүзәл, гакыл вә тәдбир белән (алдан күрү, уйлап эшләү. – *И.Р.*) иң шөһрәтле хатын булган кебек, рус тарихларында да мәһшүр бер хатын» (131 б.) дип атый. Р.Фәхретдин үз хезмәтендә Н.М.Карамзинның да Сөембикәне «Прекрасная Сююнбека» дип атавын билгеләп уза.

Сөембикә Сафагәрәй белән «гүзәл тормыш итеп, хан каршында башка хатыннарының барысыннан да игътибарлы вә якыны булмыштыр» (132 б.) дип искәртә автор.

Казан ханлыгы Сафагәрәй кебек акыллы һәм көчле ханын югалтканнан соң, Иван Грозный «инде Казан алынырга форсат килде» дип шатланып, басып алу сугышына хәзерлек эшләре башлап җибәрә. Үтәмешгәрәй бишектәге сабый бала гына булганлыктан, аның васыйсы (регенты) итеп әнисе Сөембикә билгеләнә.

Сөембикә таянган «Кырым мирзаларының Казан халкыннан тәмам өметләре өзелгәч, үз араларында сүз беркетеп», каланы калдырып чыгып китәләр. Шулай итеп, Казан 20000 кешелек гаскәре генә булган хәлдә, көчле хәрби җитәкчесез кала. Сафагәрәй үлгәннән соң төзелгән хөкүмәтнең башында торган Кошчак угъланның руслар кулына эләгүе Казан һәм аның халкын «тәмам михнәт астында калдыра». Казан тәхетенең көч-куәте тәмам какшый диярлек. Хакимият Мәскәү тарафдарлары кулына күчә. «Казанда вакытлы хөкүмәт төзелә, аның башында Ходайкул угълан белән Нурали Ширин тора. Яңа хөкүмәт шунда ук сөйләшүләр башлап җибәрә, Зөя каласына сәет Колшәриф, кенәз Бибарс Растов җитәкчелегендәге депутация юл ала. Алар тәхеткә Шаһгалине чакыралар»[51]. Казан мирзалары руслар белән солых төзиләр. Телгә алынган солых шартлары буенча «Сөембикә вә Үтәмешгәрәй хан һәм дә алар тарафында булган Кырым халыклары һәм аларның балалары вә нәселләре – һәммәсе әсир сыйфатында Мәскәүгә җибәрелергә» тиеш булалар (140 б.).

---

[50] Карамзин Н.М. История государства Российскаго. – М., 1903. – Т.8. – С.58.
[51] Равил Әмирхан искәрмәсе.

Сөембикәнең Казаннан аерылу, ире Сафагәрәй кабере янында елау–сыктауларын, казанлылар белән саубуллашу мизгелләрен Р.Фәхретдин «Казан тарихы»ндагыча бик тә тәэсирле һәм фаҗигале итеп тасвирлый. Сөембикәнең Казаннан китү көне «тәмам кыямәт галәмәте булып», «бөтен халык берьюлы тезләнеп вә бер тавыш белән егъларга кереште» диелә (142 б.). Чыннан да, «кадерле хан хатыны һәм ханнарының әсир сыйфатында Мәскәүгә җибәрелүе өчен Казан халыклары гарьләнделәр, кызгандылар, үз-үзләрен тыя алмый, кычкырып егълаштылар» (142 б.).

Мәкаләсенең азагында Р.Фәхретдин Үтәмешгәрәйнең Мәскәүдә чукындырылып, Александр исеме бирелү һәм Иван Грозный сараенда тәрбия алуы турында яза. Сөембикә исә, мәҗбүри рәвештә Шаһгалигә кияүгә бирелеп, гомеренең соңгы көннәрен Касыйм шәһәрендә үткәрергә мәҗбүр була. Башка авторлардан аермалы буларак, Р.Фәхретдин Сөембикә 1557 елда 57 яшьтә вафат була дип күрсәтеп уза. Сөембикәнең тууы һәм вафат булуы белән бәйле даталар әле бүген дә галимнәребез тарафыннан ачыкланмаган. Шунлыктан Р.Фәхретдинов күрсәткән бу даталар тарихи дөреслеккә якын дип өзеп әйтүе кыен.

Р.Фәхретдин үзенең хезмәтендә Сөембикәнең нәсел башы – Йосыф мирза, аның уллары, бу нәселнең шул чор тарихи вакыйгаләрендә уйнаган роле белән дә таныштыра; аның дәвамы – Русиянең асыл затлары дип саналган Юсуповлар нәселенә нигез салучылар булуы икәнен дә искәртә.

Р.Фәхретдин хезмәтләре XX гасыр башында Казан ханлыгы һәм Сөембикә ханбикә турында язган татар авторларының байтагы өчен үзенә күрә бер фәнни-тарихи-әдәби өлге вазифасын үтәгән. Шул сәбәпле булса кирәк, аның хезмәтләрендә күзәтелгән кайбер тарихи вакыйгаләрне аңлатудагы һәм даталарны күрсәтүдәге төгәлсезлекләр башка авторларда да кабатланып килә. Әмма ничек кенә булмасын, татар тарихи әдәбиятында Сөембикә темасын беренчеләрдән булып ачып җибәргән Р.Фәхретдин хезмәтләре бүген дә зур кызыксыну уята һәм милли тарихыбыз сәхифәләрен өйрәнүдә зур ярдәмлек булып тора.

**Әхмәтзәки Вәлиди** (1890–1970) – төрки халыкларның тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән галим. Аны «төрки халыклар тарихларын өйрәнүчеләрнең атасы» дип йөртәләр.

Кече яшьтән үк Ризаэтдин Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Рәшит казый (Ибраһимов), Муса Ярулла Бигиләрнең хезмәтләре белән танышып үскән бу галим үзеннән соңгы буыннарга бай рухи мирас калдыра.

Казанга килеп «Касыймия» мәдрәсәсендә укыганда, ә соңрак шунда ук мөгаллим булып эшләгән елларда Зәки Вәлиди бик күп кенә Көнбатыш һәм рус галимнәре – Н.И.Кареев, В.В.Радлов, В.В.Бартольд, С.М.Соловьев, Н.М.Карамзин, Л.Каэн, Г.Говарт, Ч.Френ, Н.Я.Аристов, Н.Ф.Катанов хезмәтләре белән таныша.

1909 елда Зәки Вәлидине «Касыймия» мәдрәсәсендә төрек тарихы һәм гарәп әдәбияты тарихы буенча мөгаллим итеп калдыралар. Нәкъ менә шушы елларда ул лекцияләр уку белән

параллель рәвештә «Төрек вә татар тарихы» исемле беренче хезмәтен яза башлый. Бу китап 1911 елның азагында Казанда дөнья күрә[52].

Төркиядә Йосыф Акчура «Төрек йорты» журналында, Кырымда Исмәгыйль Гаспралы «Тәрҗеман» гәзитәсендә, Казанда профессор Н.Ф.Катанов белән шәркыятьче Емельянов рус фәнни журналларында бу хезмәт турында рецензияләр язып бастыралар. Немец шәркыятьчесе М.Хартман, Венгриядән профессор А.Вамбери Оренбургта чыккан «Вакыт» гәзитәсе битләрендә китапка уңай бәя бирәләр[53].

Зәки Вәлиди «Төрек вә татар тарихы» китабында Казан ханлыгының мәшһүр ханбикәсе Сөембикә шәхесенә дә беркадәр тукталып китә, аның сәяси зирәклеге, рухи батырлыгы турында соклану белән яза. З.Вәлиди Сөембикәне «гаять акыллы һәм эшлекле хатын» дип атап, аның бу сыйфатларына кат-кат басым ясый. Идарәче буларак зирәклеге һәм акыллылыгы буенча аны Казан ханлыгының иң мәшһүр ханы Олуг Мөхәммәд белән тиңли. «Олуг Мөхәммәдтән кала бу сыйфатлар бер ханга да насыйп булмаган иделәр», ди автор.

Зәки Вәлиди язганча, Сөембикә – батыр һәм гайрәтле хатын да. 1550 елда Иван яу белән килгән вакытта Сөембикә шәһәрне саклаучылар белән бергә русларга каршы сугышта катнаша, «крепость өстенә менеп, үзе кумандалар биреп йөри». Белгәнебезчә, ханбикәнең полклар белән идарә итүдәге рухи батырлыгы турындагы мотив рус язучысы А.Н.Грузинцевның «Казанның буйсындырылуы…» әсәренә дә үтеп керә. Әсәрдә Сөембикәнең батырлыгына соклану белдергән патша Иван Грозный «мужеством души ты правила полками» дигән сүзләрне әйтә.

Иван «Казанны акыллы падишаһы Сөембикәсеннән аермаган сурәттә» ханлыкны буйсындыру мөмкинлеге булмаганлыгын бик әйбәт аңлаган. Ул 1550 елда Казанга оештырылган хәрби походыннан уңышсыз кире әйләнеп кайтуы Сөембикәнең «сәясәте сәбәбеннән» булуына бик әйбәт төшенгән. Ләкин фикри бердәмлеген югалткан һәм хәрби куәте кими төшкән Казан ханлыгы русларга каршы тора алырлык хәлдә булмый: «Казан халкы егерме меңнән артык гаскәр торгыза алмыйлар иде, үзләре икегә бүленгәннәр иде», ди галим.

Ханлык эчендәге бу тәртипсезлекләр, башбаштаклыклар аркасында түрәләр «тирә-яктагы чирмеш һәм чуаш халыклары өстенә күп ясаклар күтәрткәннәр иде». Шуңа күрә дә «Казанның Тау як кыйсеме дә бер ук атмый рус кулына керде», дип аңлата автор.

Зәки Вәлиди төрек солтаны Сөләйман Кануни һәм аның пашаларының Казан ханлыгына мөнәсәбәттә алып барган сәясәтләренең сәбәпләрен дә аңлатырга тырыша. Сөләйман Кануниның Кырымга билгеләнгән пашалары Иван яклы булып, аның мәнфәгатьләрен яклап эш итәләр – «Сәхипгәрәйнең үзене гаепле итеп күрсәтә», аны үтереп, Казанга хан булып килергә тиешле Дәүләтгәрәйне Кырымда калдыралар. Бу сәбәпле Казан хансыз кала. Өстәвенә, Солтан Сөләйман Кануни Кырым белән Казан дуслыгы көчәеп китеп, Кырымның

---

[52] Вәлиди Ә. Төрек вә татар тарихы. – Казан: Миллият, 1912. – 280 б.

[53] Әмирханов Р. Халыкка әйләнеп кайткан мирас / Вәлиди З. Кыскача төрек-татар тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 148.

да Казан кебек үк бәйсезлек игълан итәчәгеннән куркып, бу бердәмлекнең ныгуына һәрдаим аяк чалырга әзер торган.

Зәки Вәлиди, «Төрек вә татар тарихы» китабын язганда һәм, бигрәк тә, Сөембикә белән бәйле вакыйгаләрне сурәтләгәндә, билгесез рус авторының «Казан тарихы»ннан («Казанская история»дән) файдалануы турында да мәгълүмат бирә. Ярым тарихи, ярым әдәби әсәрне хәтерләткән бу китапның «мөһим урыннарын һәм ошбу битләрене тәрҗемә иттек, аерым сурәттә нәшер итәрбез, иншаллаһ» дип өстәп тә куя.

Дөрестән дә, Зәки Вәлиди хезмәте белән танышып чыккач, аның Казан ханлыгы һәм Сөембикә белән бәйле хәл-әхвәлләрне «Казан тарихы» һәм Н.М.Карамзин (1766–1826) хезмәтләре йогынтысында язылганлыгына инанырга мөмкин Мәсәлән, Сөембикәнең Мәскәүгә әсир булып китәр алдыннан ире Сафагәрәй кабере янында елау-сыктаулары, Казан белән саубуллашу күренешләре һәм башка урыннар әлеге билгесез рус авторындагыча тасвирланган.

Аерым төгәлсезлекләр Зәки Вәлиди хезмәтенең әһәмиятен киметми, билгеле. Галим Казан ханлыгы җимерелер алдыннан төрки дәүләтләрнең үз эчендәге конфликтларны да, Казан белән Мәскәү арасындагы сәяси тартыш-сугышларның үзәгендә атаклы ханбикә Сөембикә торуны да тирән драматизм белән укучыга җиткерә алган.

XX гасыр башы күренекле татар тарихчысы, җәмәгать эшлеклесе **Һади Атласиның** (1876–1938) Казан ханбикәсе Сөембикә турында, тарихи чыганакларга нигезләнеп, фактик материалларга бай «Сөен-бикә» дигән очерк – «тарихи хикәя» язып бастыруы мәгълүм[54].

Һ.Атласиның егерменче йөзнең унынчы елларында бер-бер артлы тарихи темага язылган «Сөен-бикә»дән тыш, «Себер тарихы» (1911), «Казан ханлыгы» (1914) исемле китаплары да нәшер ителә. Алар, әйтергә кирәк, укучылар тарафыннан көтеп алынып, заманының тәнкыйтьчеләре күзеннән дә читтә калмаган. Күренекле галим-ориенталист В.В.Бартольд Һади Атласиның «Себер тарихы» һәм «Казан ханлыгы» дигән хезмәтләренә язган рецензиясендә, әлеге китапларда очраган кайбер текстологик кимчелекләрне һәм ялгышларны күрсәтү белән бергә, аларның бәхәссез уңай сыйфатларын да билгеләп уза. Автор XV–XVI йөзләрдә яшәгән рус дәүләт эшлеклеләрен дә тиешле дәрәҗәдә объектив бәяләгән дип күрсәтә ул[55].

Һади Атласи хезмәтләре турында икенче зур тәнкыйть мәкаләсе Әхмәтзәки Вәлиди тарафыннан язылып, «Сөембикә» журналының 1914 елгы 4 нче санында басылып чыга. «Сөембикә» әсәренең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтү белән бергә, З.Вәлиди милли тарихыбызның «караңгы җирләрен эзләп, актарып китереп чыгарылган» бу китапны «бөтен кочагыбызны җәеп, бәрәкалла!», дип каршы ала. Шул ук вакытта Зәки Вәлиди Һади Атласи китабының «Ауропаның голум вә әдәбият мәйданында таралган методларга игътибар итмичә, һаман шул шәрык стилендә язылуына» борчу да белдерә.

---

[54] Сөен-бикә. – Казан: «Өмид», 1914. – 62 б.

[55] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы // Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992.– Б. 66.

Соңгы елларда Һади Атласиның иҗаты, фәнни эшчәнлеге, шулай ук «Сөембикә» әсәре турында «Казан утлары» (1986, №11), «Социалистик Татарстан» (1990, 5 август), «Шәһри Казан» (1991, 5 август) кебек газета һәм журнал битләрендә бүгенге тарих фәне һәм әдәби тәнкыйть таләпләре югарылыгында галимнәребез тарафыннан язылган күп кенә мәкаләләр дөнья күрде. Һади Атласиның «Сөембикә» китабы 1991 елда гарәп хәрефеннән хәзерге имляга күчерелеп, академик Ә.Кәримуллинның кереш сүзе белән «Шәһри Казан» газетасы битләрендә басылып чыкты. Соңрак, 1992 елда ул кабат «Аҗаган» журналында һәм аерым китап булып «Җыен фонды» типографиясендә нәшер ителде. Китапта профессор Миркасыйм Госманов тарафыннан Һ.Атласиның тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлегенә тирән һәм тәфсилле анализ бирелә. «Әйтергә кирәк, – дип яза М.Госманов, – бу хезмәтен язган чакта автор шул вакытта фәндә мәгълүм булган чыганакларның һәммәсен дә файдаланган, мөһим документларны җентекләп тикшереп, кайберләрен кат-кат анализлап фикер йөрткән. Шул рәвешчә, Сөембикәнең фаҗигале язмышын шактый тулы, төгәл яктыртуга ирешкән»[56].

Һади Атласи үзенең «Сөен-бикә» хезмәтен беренче кул тарихи чыганаклардан җыелган фактик материалларга таянып яза. Болар – «Воскресенская летопись», «Никоновская летопись», «Руский хронограф», «Продолжение древнероссской вивлиофилии», «История о взятии Казани», «Царственная книга» һәм «Сказания князя Курбского». Әсәрдә бирелгән астөшермәләр буенча, Һади Атласи XVI гасырда яшәгән һәм иҗат иткән билгесез рус авторы язып калдырган «История о Казанском царстве» («Казанская история») дип аталган хезмәттәге фикерләрдән шактый күп файдаланган.

Сөембикә образын тудырганда гына да автор бу чыганакка күп тапкырлар мөрәҗәгать итә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Һади Атласи «Казан тарихы»ның гади бер тәрҗемәчесе генә түгел. Татар кешесе, татар галиме буларак, ул андагы материалларга иҗади якын килә, аларны үз күзаллавы, үз зиһене, үз тоемлавы аша үткәрә. Христиан руслар тарафыннан Сөембикә образына бирелгән бәяләмә һәм тасвирларны тәнкыйть иләге аша үткәрә һәм аларны татар халкының сәнгатьчә фикерләве өчен хас булган эпитет, чагыштыру, метафоралар ярдәмендә гәүдәләндерә. Шуңа күрә, аның тарафыннан ханбикә образына һәм тарихи чорга бирелгән характеристика, шәрехләүләр татар укучысы өчен аңлаешлы. Бу фикерне раслау өчен «Казан тарихы» белән Һади Атласи китабындагы кайбер урыннарны чагыштырып үтик:

1.«Бе бо царица образом красна и в разуме премудра, яко не обрестися такой лепоте лица ея во всех в казанских женах и в девицах, но и во многих в русских на Москве, во дщерях и в женах в болярских и во княжнах». (История о Каз. цар., 99–100 с.)

---

[56] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы // Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992.– Б. 67.

«Сөен-бикә чиктән тыш матур һәм сөйкемле вә шуның илә бәрабәр бик гакыллы бер кыз иде. Нугай кызлары арасында Сөен-бикәгә охшаган кыз булмадыгы кеби, Казан һәм рус йортларында да аңа тиңдәш булырлык кыз юк иде». (Һ.Атласи, 3 б.)

2. Она бо, аки лютая лвица, неукротимо рыкаше, веляще им в Казани крепити и вои многих на помощ отвсюду збирати, отколе поидут к ним, от Нагаи, и от Асторокани, и от Крыма, и от азова, аще недостанет столиких своих вои на противление Руси, и давати им царския казны злата и сребра без скупости наима, елико хотят; царя касимовского Шигалея и воевод московских со всею силою рускою изгнати от зесля Казанския, и град новый отняти, всячески противитися, доколе мочно». (Ист о Каз. цар., 93 с.).

«Ул, Казанны ныгытырга боерып, һәр яктан гаскәр җыярга кушты. Руслар илә сугышырлык гаскәр җыелып йитмәгәндә иректе кешеләрне, акча илә булса да ялларга, шуларга акчаны үз хәзинәсеннән бирергә булды. Зөя каласы булып торганда Казанның русларга китүе билгеле булганлыктан, Сөен-бикә русларны Зөядән каулап, каланы үз кулына алырга, актык көчне куеп булса да шуны эшләргә телидер иде». (Һ.Атласи, 22 б.).

3. «…и умильно с тихостью отвещав варварским языком: «буди воля божия и самодержьцева московскаго», и после заразися о руки рабынь, поддержащих ю, и пусти глас свой с великим плачем и подвизающе с сабою на плач и то бездушное камение». (Ист о Каз. цар., 97 с.).

«Акрын гына тавыш илә: «Тәнренең язмышы, Мәскәү падишаһысының теләгәне булсын» диде. Сөен-бикәнең хәлсезләнгәнлеге сарай кәнизәкләренә дә сизелерлек булганлыгы өчен, аны култык астыннан тотып торалар иде. Теге сүзне әйтү илә Сөен-бикә бөтенләй хәлсезләнеп китте. Ачы тавыш илә кычкырып йиргә егылды». (Һ.Атласи, 29 б.).

4. «О милый мой господине, царю Сапкирее! Виждь ныне царицю свою! Любил еси паче всех жен своих, сведому бываему в плен иноязычными воины на Русь, с любимым твоим сыном, яко злодеица. И не нацарьствовашися с тобою много лет, ни нажившися…». (Ист о Каз. цар., 98 с.).

«И-и, минем сөекле падишаһым Сафагәрәй! Күрәсеңме бөтен хатыннарыңнан артык яраткан хатыныңны? Хәзерендә мин сөекле угылың илә Рус йортына тоткын булып китәмен. Синең илә озак ханлык итмәдем, күп яши алмадым…». (Һ.Атласи, 30 б.).

5. «Горе тебе, горе тебе, граде кровавый, горе тебе, граде унылый, что ли еще гордостию возносишися? Уже спаде венец з главы твоея, и яко жена худая вдовая явльшися осиротевши. Раб еси, а не господин. И преиде царская слава твоя и кончася, ты же изнемогше и падеся, аки зверь, неимуще главы…». (Ист о Каз. цар., 101 с.).

«Кызганыч син, канлы, кайгылы шәһәр! Синең башыңнан таҗың төште. Син хәзерендә тол хатын кебек булып калдың. Син хуҗа түгел инде – кол булдың. Синең атаклылыгың барысы да китте. Син, башсыз арыслан кебек, хәлсез калып беттең…». (Һ.Атласи, 34 б.).

Күренә ки, Һади Атласи, рус авторы кебек үк, Сөембикә образын куркыныч ырылдап торган арыслан образы белән дә чагыштырмый, ул сөйләшкән телне дә «варварлар теле» дип

атамый, Казан шәһәрен башсыз калган «ерткыч» дип хурламый. Ә менә ханбикә сыктаулары, тел һәм стильдә аерымлыклар булуга карамастан, эчтәлек ягыннан шактый охшашлар.

«Сөембикә» китабына җентекле анализында Зәки Вәлиди автор кулланган чыганакларның җитешле булмавы, аларның тагы да баерак, тулырак була алу мөмкинлеге турында искәртеп үтә. Тәнкыйть сүзләренең иң үткене XVI гасырга караган «Казан тарихы»на мөнәсәбәттә әйтелә. Ул Һади Атласиның Сөембикә ханбикә образын тудырганда тулысы белән шул чыганакка таянып иҗат итүе белән ризалашмый. Әйе, Зәки Вәлиди «Казан тарихы»ның күләм һәм тулылык ягыннан Сөембикә турында иң зур әсәр булуы белән килешә. Ләкин шул ук вакытта «егерме ел Казанда әсир булып, Казан тарихын язып яткан мәҗһүл (аноним. – *И.Р.*) урысның әсәре мәэхәзләрнең (чыганакларның. – *И.Р.*) иң ышанычсызрагы булырга тиеш» дип саный. Зәки Вәлиди «Казан тарихы» әсәре турында «летописьләрдә Казан хакында язылган сүзләрне һәм Сөембикә вә гайре Казан каһарманнары хакында татарлар арасында (ихтимал, ул вакытта руслар арасында) йөргән хикәя вә җырларны XVI гасырның ахырында яки XVII гасыр башында бер кеше тоткан да җыйган» дип фаразлый.

Өстәвенә, Зәки Вәлиди фикеренчә, Һади Атласи Сөембикә, аның туганнары, нәселе турында тулы мәгълүмат биргән «О роде князей Юсуповых» (1866) дигән китаптан бөтенләй файдаланмаган, аны игътибарга да алмаган. Шулай ук автор, В.В.Вельяминов-Зерновның Касыйм ханнары турында «Исследование о Касимовских царях и царевичах» китабының беренче томыннан шактый гына файдаланып, аңа нигезләнеп язса да, бу хезмәтне астөшермәдә күрсәтеп бармый: «Моның өстенә мөәллиф (тарихчы) Вильяминов-Зерновның Касыйм ханнары хакындагы әсәренең беренче җилденнән күп истифадә иткән (файдаланган), мәсәлән, Вильяминовның китабыннан ошбу 274–275, 318–326, 335–336, 347–350, 364–367, 368, 399–402 сәхифәләр мөәллифкә мәэхәз булганнар, ләкин мөәллиф үзенең истифадәсе хакында бер сүз дә әйтми…».

Шулай ук Зәки Вәлиди Һади Атласины Сөембикә манарасы турында язганда К.Ф.Фукс һәм С.М.Шпилевский китапларын гына кулланып, башка билгеле хезмәтләрне – Н.П.Загоскинның «Путеводитель по Казани» (1895) һәм П.И.Невзоровның «История Сююмбекиной башни» (1894) кебек хезмәтләрне күрсәтмәүдә, файдаланмауда гаепли.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Зәки Вәлиди Сөембикә манарасының кайчан һәм нинди максаттан төзелүе турында Һади Атласи белән бәхәскә керә. Ул галимнең «Сөен-бикә манарасы диеп аталуы, Казаннан киткән чагында, Сөен-бикәнең шушы манара янында ире Сафагәрәй кабере илә исәнләшүе сәбәпле булырга кирәк»дигән фикере[57] белән килешми. Зәки Вәлиди үзе «Сөембикә манарасының түбәнге өч табакасе (каты) хакында хан заманында сарайга керер өчен капу итеп бина ителгән бер нәрсә димез һәм үз тарафымыздан шул минараның Сөембикә тарафыннан бина ителү ихтималына күрә Сөембикә манарасы

[57] Һади Атласи. Сөембикә. –Казан: Җыен фонды, 1992. – Б. 61. Киләчәктә бу хезмәттән өзекләр, мисаллар, астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

дип соңыннан, урыслар манара сурәтенә керткәч, Сөембикә манарасы дип аталып киткәнен уйлыймыз», дигән фикердә тора.

Тарихчы галим М.А.Госманов Һади Атласиның «Сөембикә» хезмәтенә югары бәя биреп, «үз чорында реаль булган барлык мөмкинлекләрдән максималь рәвештә файдаланып, дөреслеге ягыннан үз намусына тап төшермәслек китап язган»[58] дигән фикергә килә. Әйе, Һади Атласиның XX гасыр башында беренчеләрдән булып, милли тарихыбызның күренекле шәхесләреннән берсе Сөембикә ханбикә турында бер хезмәт язуы зур ихтирамга лаек.

Һади Атласиның «Сөембикә» әсәрен укыгач та, ул тарихи романмы, әллә фәнни хезмәтме дигән сорау да туарга мөмкин. Бу сорауга академик Әбрар Кәримуллин «Бу хезмәт коры тарихи хезмәт кенә түгел, ул галимнең үз милләтенең ачы язмышы турында борчулы хисләре белән сугарылган. Бу әсәр урыны-урыны белән романга да тартым дияргә була, зур кызыксыну белән укыла», – дип яза[59]. Академик М.Госманов исә заманында билгеле булган бөтен фактик материалларга мөрәҗәгать итеп язылган Һади Атласи китабын «Сөембикәнең моңсу хикәяте»[60] дип атый. Гасыр башында «Сөембикә» китабына тәфсилле анализ ясаган Зәки Вәлиди дә автор бу әсәрен «широкая публикага карап язган» һәм «һәр сәхифәсендәге әллә никадәр выноскаларына карамыйча, Сөембикә хакында бер роман булып чыга»[61] дип яза.

Чыннан да, астөшермәдә күрсәтелгән чыганакларның саны, фактик материалларга бик бай булуы бу китапны тирән эчтәлекле фәнни-тарихи хезмәткә якынайта. Әйе, галим «татар тарихчылары арасында XV–XVI йөз русча тарихи истәлекләрдән алынган күпсанлы материалларны беренчеләрдән булып фәнни хәрәкәткә кертеп җибәрә»[62]. Моннан тыш Һади Атласиның рус тарихчылары Н.М.Карамзин, В.Н.Татищев, С.М.Соловьев, В.В.Вельяминов-Зернов хезмәтләреннән файдалануы да билгеле. Моннан тыш татар тарихчысының Европа сәяхәтчеләре Адам Олеарий һәм С.Герберштейн хезмәтләре белән дә якыннан таныш булуы күренә.

Менә боларның барысы да Һади Атласиның Сөембикә турындагы әсәрен документальлеккә нигезләнгән тарихи проза әсәре, тарихи роман дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Юкка гына автор үзе дә Сөембикә турындагы хезмәтен «тарихи хикәя» дип атамаган.

XX гасыр башы татар әдәбиятында проза жанрлары арасында катгый бүленеш юк. Аурупа әдәбиятлары өчен хас хикәя, повесть һәм роман дигән әдәби төшенчәләр әле үзләштерелеп кенә килә. Еш кына хикәя һәм повестьлар роман дип атала, ә романнар хикәя

---

[58] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы // Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992.– Б. 68.
[59] Кәримуллин Әбрар. Һади Атласи һәм аның «Сөен-Бикә»се // Шәһри Казан. – 1991. – 3 август.
[60] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы / Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992. – Б. 71.
[61] Зәки Вәлиди. Китаплар һәм аларга тәнкыйть: «Сөембикә». Һади Атласи әсәре // Сөембикә. – 1914. – №4. – Б. 11; шунда ук. – №5. – Б. 4.
[62] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы / Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992. – Б. 66.

дип йөртелә. Бу традиция егерменче елларның икенче яртысына – Г.Ибраһимовның «Тирән тамырлар» хикәя-романына кадәр дәвам итә. Шуңа күрә Һади Атласиның Сөембикә турындагы әсәрен «тарихи хикәя» дип атавына гаҗәпләнергә кирәк түгел.

Һади Атласиның «Сөембикә» әсәрен роман дип атыйбыз икән, анда экспозиция, төенләнеш, вакыйгаләр үсеше, кульминация, чишелеш тә булырга тиеш. Сөембикә ханбикәнең бөтен биографиясе шушы жанрның сюжет-композициясе таләпләренә һәм кысаларына үзеннән үзе сыешып һәм туры килеп тора. Аның Нугай далаларындагы балачагы, яшьлеге булачак вакыйгаләргә фон-экспозиция вазифасын үти. Ә инде Казан ханлыгына килен булып төшү төенләнеш булып, алда Сөембикә тормышындагы булачак вакыйгаләр үсешенә – аның Сафагәрәй хан белән бергәләп Казан ханлыгы белән идарә итү елларына, руслар белән татарлар арасындагы дәүләти-сәяси мөнәсәбәтләр киеренкелегенә, Сафагәрәйнең кинәт кенә үлеп, ханбикәнең яшь угълы белән тол калуына, Казандагы Кошчак җитәкчелегендә төзелгән хөкүмәткә көчле оппозиция барлыкка килүгә, Төркия белән Кырымга, русларга йөз тоткан төрле фиркаләр арасындагы тартыш-көрәшләрнең кискенләшүенә, көчәюенә юл ача. Романдагы кульминация укучыга үзеннән-үзе аңлашылса кирәк: ул Сөембикәгә «Мәскәүгә әсирлеккә җибәреләсең» дигән коточкыч хәбәр килеп ирешү. Чишелеш исә тагы да фаҗигале һәм күп тармаклы: улы Үтәмешне чукындыру, Сөембикәне ул яратмаган сатлык җанга – Шаһгалигә көчләп кияүгә бирү, Касыймда кыйналып, рәнҗетелеп яшәү һәм үлем.

Исеменнән үк күренеп торганча, Һади Атласиның документальлеккә нигезләнгән романы Сөембикә ханбикәнең фаҗигале язмышын тасвирлауга багышланган. Әсәр Сөембикә исеменең килеп чыгышын, этимологиясен аңлату белән башланып китә. Исем төрле чыганакларда төрлечә – «Сөен-бик», «Сөмбик», «Самбик», «Сөмбек», «Сөенбәк» дип аталып йөртелеп, «... чын исеме «Сөенбикә» булып, калганнары шуңардан бозылган булырга кирәк» дип яза автор (59 б.). Сөен-бикә исеме «сөенбәк масдарыннан» һәм «иркә кыз, бәк хатыны мәгънәсендә булган «бикә» компонентларыннан тора. «Төрки сүзләрдә ирлек-хатынлык булмаса да, «бикә» сүзе «бәк» сүзенең мөәннәсе (женский род) хөкемендә иде» дип искәртә Һади Атласи. Иванның Нугай морзаларына язган ярлыкларында Сөембикә исеме Сююнбек дип аталып йөртелә.

Үзенең тәнкыйть мәкаләсендә Зәки Вәлиди ханбикәнең исеме мәсьәләсенә дә тукталып үтә һәм, Ташкент китапханәсендәге Үтәмеш Хаҗи язма китабына (№21) нигезләнеп: «Моннан башка Казан ханнарының бикә исеме белән аталган һәммә хатыннары да нугай мирзаларының кызлары булганнар. Чөнки Һади әфәнденең (3 б.) «бикә» сүзе хакында биргән мәгълүматы хилафына ул вакытта «бикә» дип фәкать мирза кызларына гына әйткәннәр» дип яза.

М.Госманов Һади Атласи кулланган «Сөен-бикә» вариантының формаль рәвештә дөресрәк булуы ихтималга якынрак» дип, ә хәзерге татар телендә кабул ителгән Сөембикә

рәвешендә әйтү «халык тарафыннан кабул ителүе, үзгәртелүе нәтиҗәсе» дип аңлата[63]. Сөембикә исеменең яңгыравы, телгә ятышлы булуы хәзерге татар теленең фонетик үзенчәлекләре белән аңлатыла.

Һади Атласи үзенең әсәрендә Сөембикә язмышын ике чорга бүлеп өйрәнә. Романның беренче өлешендә (1533–1551 еллар) Казан ханы Җангалигә кияүгә чыгу, ул үтерелгәннән соң, Сафагәрәй хан хатыны булып бергә гомер итүләре, уллары Үтәмешгәрәй туу һәм Казаннан әсир ителеп җибәрелү еллары шактый тулы итеп тасвирлана. Романның соңгы өлешендә исә Сөембикәнең Шаһгалигә кияүгә бирелеп, Касыйм шәһәрендә «ирекле» коллыкта үткәрелгән еллары турында сөйләнелә.

Сөембикә биографиясенең төп этаплары – Җангали хатыны булып Казанга килү; ул үтерелгәннән соң, Сафагәрәй хан белән озак кына гомер кичерү; 1547 елда уллары Үтәмешгәрәй туу; Сафагәрәй үлгәч, Сөембикәнең ил белән идарә итү һәм әсирлеккә җибәрелү вакыйгаләре без алда тикшереп киткән Риза Фәхретдин һәм Зәки Вәлиди хезмәтләрендәге кебек, традицион рәвештә тасвирлана. Ләкин, әйтергә кирәк, автор коры тарихи фактларны күрсәтү белән генә чикләнмичә, Сөембикәнең төс-кыяфәте, холкы, ханбикәнең халыкка, халыкның аңа булган мөнәсәбәтен тасвирлауны да максат итеп куя. Шуның белән бергә, алда каралып киткән хезмәтләрдән аермалы буларак, Һади Атласи Казан ханлыгының эчке халәтен, сәяси фирка-партияләр көрәшен, руслар һәм башка төрки мәмләкәтләр белән сәяси бәйләнышларын, Сөембикә ханбикәнең Казан ханлыгындагы сәясәт мәйданында уйнаган ролен күрсәтүгә дә зур игътибар бирә.

Урта гасыр Шәрекъ әдәбиятларыннан килә торган традиция буенча, Һади Атласи Сөембикә образын гадел патша, акыллы хөкемдар итеп гәүдәләндерә. Соңгы бүлектә генә дә автор ханбикәнең бу сыйфатына өч тапкыр басым ясый: «Ул Казан олугъларыны дәрәҗәләренә карап багышладыгы кеби, Казанның урта һәм түбән дәрәҗәдәгеләрене дә онытмыйлар, һәкайсына үзенең сыеннан өлеш чыгарадыр иде» (59 б.). Сөембикәнең милләте һәм дәүләте бәрабәренә кылган яхшылыклары кояш нуры белән тиңләнә: «Сөембикәнең яхшылыклары кояш нуры кебек Казан халкының һәрберсен каплаган» (58 б.). «Сөембикә анларны күңеленнән чыгармый, анларга җиңеллекләр күрсәтә иде. Аның шушы эшләре Казан халкының күңеленә бик нык урнашкан булганы өчен анлар Сөенбикәне тиз генә оныта алмадылар. Казан ханнарының күбесенең исеме онытылдыгы хәлдә, Сөенбикәнең исеме онытылмады» дип яза Һади Атласи (59 б.). Чыннан да, Казан ханлыгы чорына караган тарихи чыганаклар, мәгълүматлар аз санлы булуга карамастан, татар халкының хәтере Сөембикә исемен милләтебезнең олы тарихи шәхесе итеп гасырлардан-гасырларга тапшырып, бүгенге көнгә кадәр саклап кала алды; үзен һәм аның исемен йөрткән манараны милли символларыбыз дәрәҗәсенә күтәрде.

[63] Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы / Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992.– Б. 70.

Сөембикәнең асыл сыйфатлары арасында тагын берсе – ул «чиктән тыш матур һәм сөйкемле вә шуның белән бер үк вакытта бик акыллы бер кыз» (3 б.) булуы. Һади Атласи Сөембикәне хатын-кызлар арасында матурлыкта һәм акыллыкта тиңе булмаган бер зат итеп күрсәтеп, «дөньяның беренче сөйкемлесе» дип атый (3 б.). Сөембикә тышкы яктан гына гүзәл булып калмыйча, аның гакылы да сокланырлык дәрәҗәдә матур икән. Бу ике үзенчәлекне автор бер-берсеннән аермый, бербөтен итеп куя, ханбикәнең аерылгысыз сыйфатлары итеп күрсәтә.

Һади Атласи Сөембикә образы белән бәйлелектә аның ирләре – Җангали һәм Сафагәрәй ханнарның Казан ханлыгы белән идарә итүләренә һәм сәяси эшчәнлекләренә дә бәя бирә. Сөембикәнең беренче ире Җангали «ирекле хан түгел иде». Ул үзлегеннән эш итә алмаганга күрә, Сөембикәгә өйләнү мәсьәләсе дә рус патшасы Василий рөхсәте белән генә хәл ителә. Сөембикәнең атасы Йосыф мирза, кызын Казан ханы Җангалигә кияүгә биреп, Нугай йортының тәэсирен Казан каласына кадәр җәелдерүне күздә тота һәм бу никахка зур сәяси өметләр баглый. Сөембикәнең Казанга килүе «ике төрки ыругының берләшүенә» ярдәм итә алмаса да, ул «үзенең атаклылыгыны югалтмады». Казан халкы Нугай далаларыннан килгән бу яшь, хөр табигатьле бикәчне яратып өлгерә, аны ихтирам белән каршы ала.

«Мәскәү курчагы» булган Җангали ханның идарә итү еллары санаулы була. Һади Атласи буенча, 1535 елның 25 сентябрендә казанлылар, Җангалине үтереп, яңадан икенче тапкыр Сафагәрәйне хан итеп чакыралар. Сафагәрәй исә, Сөембикәнең чибәрлегенә, зирәклегенә таң калып, «атаклы бер бикәне кулдан ычкындырасы килмәгәенчә аңа өйләнде». Нугай морзалары, Сөембикәнең агай-энеләре Сафагәрәйне бик яратып бетермәсәләр дә, Сөембикә үзе ирен бик яратып тора. Илчеләр җибәреп, Рус дәүләтенә каршы бергәләп чыгарга өндәгән вакытларда да Нугай морзалары Сафагәрәй хан сүзләренә колак салмыйлар, аның әйткәннәрен тыңламыйлар. Киресенчә, 1536 елның көзендә Килмөхәммәд морза белән Исмәгыйль морза, Иван патша белән дуслыкларын ныгыткач, Сафагәрәйгә каршы булганлыкларын раслап, Мәскәүгә ярлык та язып җибәрәләр.

Ханбикә – акыллы идарәче, «ханлык файдасын бик яхшы төшенә, «йорт» өчен ничек эш итәргә кирәклеген бик ачык белә иде» (58 б.) дип яза Һади Атласи. Нигездә, Сөембикә үзе идарә иткән елларда русларга мөнәсәбәттә ире Сафагәрәй алып барган сәясәтне – Казанны бәйсез дәүләт буларак саклап калу юнәлешен дәвам итә: «Казан ханлыгын ирекле бер ханлык итүендә Сөембикәнең бик зур катнашы булганлыгын Иван ачык беләдер иде. Шуңа күрә ул аны яратмый, дошман күрәдер иде» (17 б.). Сөембикә, Иванның гына дошманы булып калмыйча, бөтен русларның да дошманына әверелә. Чөнки ханбикә төрлесе төрле якка таралып беткән төркиләр, русларга ялагай татарлардан бөтенләй үзгә, ханлыгының ирекле һәм азат булуы өчен җаны-тәне белән тырышкан шәхес була. Казанлыларның Сөембикәне руслар кулына тапшыруы, аны тоткын итү рус дәүләте өчен сәяси әһәмияткә ия булган адым була. Беренчеләрдән булып бу фикерне XX гасыр башында Һади Атласи әйтеп калдыра. Билгеле, ул бу фикерне тарихи чыганак вазифасын үтәгән «Никоновская

летопись»ка таянып яза: «Митрополит Макарий 1552 елның 21 маенда Зөядәге рус башлыкларына язган үгетендә: «Тәңре Тәгалә безнең сөекле падишаһыбыз илә аның христиан сөюче гаскәрләренә, һичбер кан түкмәенчә, үзләренең дошманнарыннан өстен булырга, Казан ханлыгын җиңәргә насыйп итте. Казан падишаһысы илә Сөен-бикәне безнең падишаһыбызның кулына бирде» (58 б.). Дөрестән дә, сәясәт мәйданында шактый оста эш иткән Сөембикәнең әсирлеккә озатылуы руслар өчен бик тә зур җиңү була. Бу хакта бераз соңрак рус галимнәре М.Г.Худяков[64] белән Г.Н.Моисеева[65] да язып чыгалар.

Казан ханлыгының иминлеген тәэмин итү өчен Сөембикә Мәскәүгә илчеләр дә җибәреп карый. 1549 һәм 1551 елларда улы Үтәмешгәрәй исеменнән оештырылган бу илчелекләр Казан белән Мәскәү арасында тынычлык урнаштыру, сәүдә итү, дус яшәүне тәкъдим итсәләр дә, ике дәүләт арасында йөреп торган илчеләр генә тынычлык урнаштыра, солых та төзә алмый, дошманлык көчәйгәннән-көчәя. Һади Атласи язганча, «руслар илә татарлар арасында дошманлык бик нык тамыр җәйгән» була. Бу фикерләр «Сөембикә бәете»ндә дә чагылыш тапкан иде.

Һади Атласиның «Сөембикә» әсәрендә Казан ханлыгы язмышы фаҗига белән тәмамлануына сәбәп булган төрле партия-фиркаләрнең икейөзлелеген, мәкерле уеннарын да тасвирлауга зур урын бирелә. Казанда «Алтын Урдадан Олуг Мөхәммәд белән килгән бәкләрнең нәселләре, Шибанилардан (Себердән): нугайлардан, Кырым ханнары (Гәрәйләр) нәселе хан булган чакта алар белән Кырымнан килгән бәкләр, морзалар бар иде. Шуңа күрә алар төрле партияләргә бүленәләр, әмма шул ук партияләр эчендә чын-чыннан Казан истикъляллен, аның мәнфәгатен саклау яклылары гына булмаган… Кырым, Нугай, Шибани, Әстерхан, хәтта Мәскәү яклылары бар иде»[66]. Һади Атласи үзенең әсәрендә Мәскәү хөкүмәтенең астыртын сәясәтен фаш итеп, болай да таркау булган татар урдаларын бер-берсе белән ызгыштыру, сугыштыру сәясәте турында яза.

Сөембикә турында Кошчак белән «уйнаш итә, Кошчакка хатынлыкка бармакчы, аның белән берләшеп угылы Үтәмешгәрәйне үтермәкче» (23 б.) дип яла ягу да, аны халык арасында тарату да шул үзара хакимият өчен талашучы фиркаләр эше нәтиҗәсе була. Казанлылар белән кырымлылар арасы электән дә бик әйбәт булмыйча, ханбикә идарә иткән елларда инде соңгы чиккә килеп җиткәнгә күрә, Кошчак угълан өч йөз кешелек отряды белән Казаннан Кырымга чыгып кача. Ләкин Вятка елгасы аркылы чыкканда рус казаклары һөҗүм итеп, аларның күбесен кырып бетерә, исән калган өлеше әсирлеккә Мәскәүгә озатыла. Алар арасында Кошчак угълан да була. «Ул чакларда руслар кулына тоткын ителгән татарлар үлем җәзасыннан дин алыштырып кына котыла алалар иде» (24 б.). Ләкин Кошчак үзенең илен, динен сатмый, руслар кулыннан шәһид китә. Батыр, акыллы хәрби җитәкче, Сөембикәнең уң кулы булган Кошчакның һәлак булуы Гәрәйләр нәселен Казан

[64] Худяков М. Очерки по истории Казанского ханства. – Москва: Инсан, 1991.
[65] Моисеева Г.Н. Казанская царица Сююн-Бике и Сумбека «Казанской истории» // ТОДРЛ. – М.-Л.: Академия наук СССР. – 1956. – Т.12. – С.184.
[66].Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 123.

тәхетеннән читләштерүгә сәбәп була. Бернинди ярдәмчесе һәм хәрби таянычы калмаган Сөембикә ханбикәне Мәскәүгә әсир итеп җибәрү һәм Казан тәхетенә Мәскәү яклы Шаһгалине китерүгә юл ачыла.

В.В.Бартольд билгеләп үткәнчә, Һади Атласи хезмәтләре «татар патриоты позициясеннән торып язылса да»[67], ул татар-нугай морзаларының эш-гамәлләренә объектив анализ бирергә тырыша. Галим Казан ханлыгындагы киеренке эчке сәяси көрәшне бик оста тасвирлый. Ил иминлеге өчен куркыныч янаган вакытларда Сөембикә ханбикәгә русларга каршы гына түгел, ә Казан ханлыгы тәхетенә күптәннән кызыгып йөрүче башка көчләргә каршы да торырга туры килә. Берләре – Сафагәрәй эзәрлекләвеннән качып, Нугай йортында яшәп яткан Боерган сәед, Илсыман бәк, Габдулла бахши кебекләр Иванны Казан өстенә йөрергә димләп хатлар язалар. «Казан йортыны Иванга алып бирергә тырышалар» (18 б.). Икенчеләре – Мәскәүнең үзендә яшәп ятып, Иванны Казанга таба гаскәр белән кузгалырга котырталар. Бу вакытларда Нугайда качып яткан Хөсрәү бәк хәтта гаскәр белән Казан янына килеп, кырымлылар белән сугышып та китә. «Болар һәрберсе корсак колы булып, һичберсендә йорт кайгысы булмаганлыктан, тамак өчен йорт сатуны бер нәрсәгә дә санамыйлар иде» (18 б.) дип яза Һади Атласи. Нугай морзалары арасында Казан тәхетенә кызыгып йөрүчеләр байтак була. Исмәгыйль белән Арслан морзалар, гаскәрләре белән Казанга таба хәрәкәт итәчәкләрене белдереп, Иванга хат язып җибәрәләр. «Белек-Булат исә Иван күңеле өчен Казан йортына баскынлык иткәнлегене белдерде» (18 б.). Сөембикәнең атасы Йосыф морза үзе дә Казанга йөриячәгене Иванга җиткерә. Болар өстенә Сөембикәнең абыйсы Юныс морза күптәннән бирле Казан бәге булырга хыяллана. Шулай итеп, «Сөембикә бер яктан руслар, икенче ятан, үзенең ыругълары, туган вә якыннары илә орышырга тиеш була» (19 б.).

Сөембикә «бар көче илә тырышса да, казанлылар аны чынлап таный алмадылар» (58 б.). Казанлылар, аның бөекләре Сөембикәне бер хатын итеп кенә кабул итеп, аның тиешенчә кадерен белә алмыйлар. Ханбикәләрен әсир итеп, үз куллары белән русларга тапшыралар. «Сөембикәнең тоткын ителүе бер хатынның тоткын ителүе исә дә, чынлабында, бөтен халыкның тоткын ителүе иде» (58 б.) ди Һади Атласи. Сөембикә киткәннән соң күп тә үтми, дәүләт тә китә. Сөембикә, соңгы мөмкинлекләрдән файдаланып булса да, ханлыкны саклап калырга тырыша. Мәскәүгә илчеләр җибәреп карый, үз акчасын түләп гаскәр тупларга боера. Соңгы чиктә халкының иминлеге һәм дәүләтнең бөтенлеге бәрабәренә үзен фида кыла, ләкин Казан ханлыгын коткарып кала алмый. Шулай итеп, «Казанның башыннан таҗы төшә», заманында күпләрне куркытып һәм кызыктырып торган ханлык, үзара татулык, дуслык, оешканлык, бердәмлек булмау аркасында фаҗигале рәвештә тарих сәхнәсеннән югала, колониаль бәйлелеккә дучар була.

[67] Записи Восточного отделения Русского археологического общества. Т. XXIII, III-IV. – 1916. – С. 421-422.

Алдарак Һади Атласи хезмәтенең «Казан тарихы» тәэсирендә язылуы турында әйтелгән иде. Ләкин шулай да, татар галиме «Казан тарихы» авторына сукырларча ияреп барган дип раслау дөрес булмас. Тарихчы Һади Атласи, «Казан тарихы»нда тасвирланган вакыйгаләрне үз аңы һәм тәнкыйть күзлеге аша үткәреп, документальлектән, тарихи дөреслектән ерак торган фактларны үзенең әсәренә кертми, аларны төшереп калдыра. Мәсәлән, беренчеләрдән булып «Казан тарихы»нда сурәтләнгән, ә соңрак күп кенә рус язучыларының әсәрләренә үтеп кергән Сөембикәнең булачак ире Шаһгалигә агулы күлмәк һәм агулы ризык җибәреп, аны үтерергә теләү мотивы Һади Атласи әсәрендә юк. Ул булырга тиеш тә түгел. Чөнки, алда тикшерелеп киткәнчә, бөтендөнья фольклорында һәм әдәбиятында шактый киң таралган бу традицион әдәби алым «Казан тарихы» әсәренә борынгы грек һәм рус әдәбияты әсәрләреннән, фольклорыннан үтеп кергән сюжет булып тора. Алдагы бүлектә билгеләп үтелгәнчә, «Казан тарихы» авторы Сөембикәнең Казаннан җибәрелү сәбәбен ике дәүләт арасындагы сәяси көрәш нәтиҗәсе итеп түгел, ә Шаһгали белән Сөембикә шәхесләре арасында килеп чыккан гади бер аңлашылмаучанлык дип аңлата.

Кайбер очракларда Һади Атласи «Казан тарихы» авторы белән бәхәскә дә керә. Мәсәлән, ул Сөембикәнең Сафагәрәйгә кияүгә чыгу датасының дөрес күрсәтелмәвенә игътибар итә. «Кайсыбер рузнамәләрдә (бу очракта «Казан тарихы»нда), – ди ул, – Сафагәрәй ханның Сөен-бикәгә өйләнүе Нугай йортына качып баруыннан соң булган идеге язылса да, бу сүз ялгандыр» (11 б.).

Һәм соңгысы, «Казан тарихы»ннан аермалы буларак, Һади Атласи әсәрендә Сөембикә ханбикәнең Касыймда үткәрелгән гомеренең соңгы еллары турында да бик тәфсилле итеп язылa. Автор билгеле булган бөтен имеш-мимешләрне дә кертеп, Йосыф мирза белән Сөембикәнең туганнарының ханбикәне азат итү, Нугайга кире кайтаруны сорап Иванга язган хатларын да телгә алып, рус патшасының аларга җибәргән җавапларын да китереп уза.

Сөембикә Мәскәүдә яшәгәнгә күрә, аны кемгә кияүгә бирү мәсьәләсе Явыз Иван иркендә була. Электән үк Сөембикәнең матурлыгына, чибәрлегенә күзе төшеп йөргән Шаһгали аны үзенә хатынлыкка алырга тели. Шаһгали Казанны алу өчен кирәкле кеше булганлыктан, Иван бик теләп Сөембикәне аның кулына тапшыра. Әсәрдә Шаһгалинең ямьсез рәсеме дә тасвирлана: «Шаһгали кара йөзле, озын, салынкы колаклы, кыска аяклы, зур корсаклы, кәкре үкчәле булганлыгы өчен сөйкемсезләрнең беренчесе иде» (37 б.) ди Һади Атласи. Үз иркендә булмаган гүзәл Сөембикә шул шыксыз затка кияүгә чыгарга мәҗбүр ителә.

Сөембикә әсирлеккә озатылгач та, Нугай йорты белән Мәскәү арасында тагы илчеләр йөри, ярлыклар языла башлый. Йосыф морзаны кызының тоткынга тиң язмышы борчый. Сөембикәне Үтәмешгәрәй белән берлектә үз йортына – Нугай иленә кайтарып җибәрү турында сорап күпсанлы үтенечләр юллана. Исмәгыйль, Юныс һәм башка морзаларның ярлыкларында да сеңелләрен азат итү мәсьәләсе боерык катыш ялвару рәвешендә бирелә.

Иван бу ярлыкларның кайсына алдап, кайсына майлап, хәйләләп җавап биреп тора. Ул Сөембикәне хөрмәтләп, зурлап, төрки халыкларның традициясе буенча Касыйм ханы Шаһгалигә бирелгәнлеге турында да хәбәр итә.

Сөембикәнең Нугай йортына кайтарылмыйча, Касыйм шәһәрендә тоткын рәвешендә яшәтүгә ачуланып, Йосыф морза илчеләрен Мәскәүгә җибәрүдән туктата, улларын һәм туганнарын җыеп русларга каршы зур походка әзерләнә башлый (49 б.). Ләкин аның иң зур ышанычы һәм терәге булган туганы Исмәгыйль морза бу эштә Йосыф морзага ярдәм итми. Киресенчә, ул «Белек-Булат илә Арслан морзаларны да котырта, аларны да үз ягына аударып, сугышка җибәрми» (49 б.). Бер ялгызы гына калган Йосыф морза русларга каршы яу бару фикереннән кире кайта.

Сөембикәнең соңгы еллары сөйкемсез һәм вөҗдансыз, сатлыкҗан Шаһгали янында, Касыйм шәһәрендә үтә. Шаһгали «Сөембикә белән чын татар ирләречә эш итә башлаган иде» (51 б.) диелә әсәрдә: 1553 елның җәендә «Шаһгали Иван кушуы буенча, Сөембикәнең борынын кискән, аңа зур сыйсызлыклар күрсәтеп үтергән икән» (52 б.) дигән хәбәр Нугай далаларына да килеп ирешә. Бу сүзләр Сөембикәнең атасы белән анасын бик тә борчуга сала. Ләкин Сөембикәне кыерсыту дөрес булса да, үтергән дигән сүзләре хак булып чыкмый. Исмәгыйль, Юныс, Касай морзалар бу хәбәрләрне ишетүгә, сеңелләре турында борчылып, Иванга ярлык язып җибәрәләр. Иван, моңа җавап итеп: «Юныс морзаның Зәйн-Гали исемле илчесе илә Гали морзаның Бәхет-Килде исемле илчесен Касыйм шәһәренә җибәреп, үз күзләре илә Сөен-бикәне күрергә боерды» (52 б.), морзаларга исә, ничек кирәк шулай юмалап, алдалап, үз ягына аударып, җавап ярлыклары җибәрә. «Иванның Йосыф, Юныс, Гали, Касай, Шәехгалиләргә язган шушы ярлыклары 1554 елның гыйнварында язылган иде. Шушы елдан соң тарихларда Сөен-бикә турысында хәбәрләр киселәдер» (55 б.). Сөен-бикәнең кайсы елда һәм кайда үлгәнлеге турында Һади Атласи бернинди мәгълүмат бирми.

Һади Атласи «Сөембикә» әсәрендә «чиктән тыш матур һәм сөйкемле», зирәк акыллы идарәче һәм мөлаем хатын образын тудыра алуга ирешкән. Сөембикәнең Мәскәүгә кол ителү, Казан ханлыгының җимерелү, җиңелү сәбәпләрен Һади Атласи шул чорларда дәүләт белән идарә итүдә актив катнашкан «морзаларның һичберендә дин, милләт кайгысы булмадыгы кеби, туганлык кайгысы да» (56 б.) булмауда күрә. Казан дәүләтенең бетүенә, аныңча, бер генә сәбәп булган: Казан татарларының үзара тыныч, тату яшәмәүләре, ызгыш-талаш белән торулары, дәүләт һәм халык турында берни уйламаулары, аны сатулары һәм башка шундый начарлыклар хәлиткеч әһәмияткә ия булдылар, ди ул[68]. Бөтен төрки дөнья элеккечә бербөтен булып русларга каршы тупланган булса, «Иванны шактый какшаткан, аны татар ханлыклары илә шаяртудан туктаткан булыр иде» (56 б.) дип борчылып яза автор.

Казан ханлыгының инкыйразга дучар булуы турында бүгенге көндә төрле карашлар яши. Әле гасыр башында ук гаребчелек тарафдары булган Зәки Вәлиди Һади Атласины «һәрвакыт аерым шәхесләрнең эшләренә артык әһәмият бирә һәм аерым шәхесләргә

---

[68] Алишев С. Тарихчының фаҗигале язмышы // Социалистик Татарстан. – 1970. – 5 август.

кайтырга тиешле булган хөкемне бөтен җәмгыятькә хөкем итүендә» гаепли. Зәки Вәлиди фикеренчә, «Казан, Нугай, Себер, гомумән, Алтын Урда һәм андан тәшәккел иткән (барлыкка килгән. – *И.Р.*) вак ханлыкларның 15–16 нчы гасырларда гомуми сәбәпләре бардыр ки, аларны аерым шәхесләрдән түгел, табигатьтән һәм шул җирләрдә искедән бирле бер-берсенә бәйләнеп килгән хәдисәләрнең мәҗмугасыннан (вакыйгаларнең җыелмасыннан) эзләргә тиеш».

Совет чорында Я.Абдуллин, М.Госманов, И.Таһиров кебек галимнәр Һади Атласиның тарихи карашларына методологик җитлекмәгәнлек, тикшерә торган күренешләрнең объектив нигезен ачып бирә белмәү хас дип яздылар. Алар фикеренчә, аның хезмәтләрендә идеалистик күрсәтмәләр өстенлек сөрә, ә бу исә, үз чиратында, тарихи вакыйгалар турында фикер йөртүдә субъективлыкка этәрде [69] . Тарихи барышка Зәки Вәлиди кебек мәгърифәтчеләрчә якын килү дә, совет чорындагыча марксистик-ленинчыл күзлектән якын килү дә артта калды. Бүген без аерым шәхесләрнең тарихтагы урынын һәм әһәмиятен дә кире какмыйбыз, иҗтимагый-сәяси һәм башка факторларның йогынтысын да истән чыгармыйбыз.

Һади Атласиның «Сөенбикә» тарихи романы милли тарихыбызга, халкыбызның атаклы шәхесләренә олы ихтирам белән сугарылган. Әсәрнең буеннан-буена Казан ханлыгындагы вакыйгаларгә бәйле рәвештә Сөембикә ханбикәнең кылган гамәлләре, уй-фикерләре һәм эчке кичерешләре хакында хикәяләү алымы белән сөйләп барыла. Сөембикә кебек уңай каһарманнарның тышкы кыяфәте, рухи дөньясы, эшләгән эшләре идеаллаштырылып бирелә. Сөембикә исеменең этимологиясен ачыклау, «бикә» сүзенең мәгънәсен аңлату да шул максатларга хезмәт итә. Русларга хезмәт итү юлына баскан Шаһгали ханның рәсеме дә, дәүләти-сәяси эшчәнлеге дә кара буяулар ярдәмендә сурәтләнә. «Сөембикә», документальлеккә нигезләнгән тарихи роман булганлыктан, анда булып үткән вакыйгаларгә, каһарманнарның эш-гамәлләренә бәя бирү алымы бик тә зур урын алып тора. Шуңа күрә, теге яки бу чыганакта тарихи фактлар бозылып күрсәтелә дип исәпләнгән очракларда Һади Атласи бәхәс алымына мөрәҗәгать итә, тарихи мәгълүматларның гадел шәрехләнүен, объектив эчтәлекле булуын таләп итә. «Казан тарихы» авторы Сөембикәнең Мәскәүгә әсирлеккә җибәрелү мизгелләре турында хикәяләгәндә фольклор материалларыннан, мәсәлән, төрки халыкларның борынгы сыктауларыннан уңышлы файдалана. Ә менә төрки-татар халык әдәбияты өчен чит дип исәпләнгән, ә грек һәм рус әдәбиятлары өчен традицион дип кабул ителгән «агулы күлмәк» мотивы романның хикәяләү кысасына бөтенләй кертелмичә кала.

XVI гасырда язылган «Казан тарихы» өч гасырдан артык диярлек рус язучылары өчен тарихи чыганак вазифасын үтәде. Татар әдәбиятында шушы ук миссияне Һади Атласи язган «Сөембикә» романына башкарырга туры килә. Октябрь инкыйлабыннан соң СССРда милли тарих һәм аның каһарманнары турында язу тыелды. Әмма җир шарының төрле

---

[69] Абдуллин Я. Госманов М. Таһиров И. Һади Атласи турында // Казан утлары. – 1989. – №11. – 174 б.

кыйтгаларына сибелгән татарлар, аеруча Төркиядә яшәгән зыялылар, үзләренең Сөембикә турындагы тарихи хәтерләрен искә төшергәндә һәрвакыт диярлек Һади Атласи язган тарихи проза әсәренә – «Сөенбикә» документаль романына мөрәҗәгать иттеләр, аның белән рухланып, «Сөембикә» исемендәге җәмгыять оештырдылар, дистәгә якын әдәби әсәр һәм публицистик мәкаләләр яздылар.

## 4. Ф.Әмирхан һәм Ш.Әхмәдиев хикәяләре

XX гасырның унынчы елларында татар әдәбиятында романтик юнәлеш киң колач белән үсеп китә. Беренче рус революциясе дәверендә реалистик сурәтләр кулланып иҗат иткән әдипләр дә романтик яңгырашлы әсәрләр язуга күчәләр. Милли хисләрнең җанлануы, азатлык идеалларының тагы да көчлерәк калкып чыгуы татар халкының үткәне, мөстәкыйль дәүләт булып яшәгән заманнары күбрәк белергә теләү ихтыяҗын арттыра.

Үзенең җисми барлыгы, табигате белән гүзәллек, акыллылык символы булган һәм шул ук вакытта татар тарихының иң драматик мизгелләрен чагылдырган Сөембикә ханбикә образы татар романтиклары иҗатында да гәүдәләнеш таба. Мәсәлән, 1913 елда Фатих Әмирханның «Ай өстендә Зөһрә йолдыз», «Сөенбикә», «Картада оттырылган кыз» исемле романтик хикәяләрне берләштергән «Халык кызлары» дигән җыентыгы дөнья күрде (1925 елда Казанда кабат басылды). Совет чоры тәнкыйтьчеләре тарафыннан Фатих Әмирханга буржуаз-либераль язучы дигән тамга сугылу сәбәпле, андагы хикәяләр озак еллар татар укучысы игътибарына тәкъдим ителмәделәр. Әдипнең Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында әзерләнеп, 1984–1989 елларда Татарстан китап нәшриятында басылган дүрттомлы «Әсәрләр»ендә дә бары тик «Ай өстендә Зөһрә йолдыз» гына урын алды[70].

«Халык кызлары»ндагы «Сөенбикә» – милли тарихыбызның бөек ханбикәсе турында иҗат ителгән беренче проза әсәре. Әдип, үзе үк әйтеп киткәнчә, «әкият вә тарихлардан алып язылган»[71] бу хикәясендә халкыбызның югалган шөһрәте, үткән тарихта калган бөеклеге турында уйлана, Сөембикә ханбикә язмышын бөтен фаҗигалелеге белән күз алдына китереп бастыра.

«Халык кызлары» исемле җыентыкка кертелгән бу өч хикәянең сюжет җепләрен бергә бәйләүче бер образ – Зөһрә образы бар. Ул, җирдәге авырлыкларга, үги анасының тиргәүләренә, рәнҗетүләренә түзеп торырлык хәле калмагач, Айга менә, шунда гына үзенә җан тынычлыгы таба. Ф.Әмирхан «Сөенбикә» хикәясен Зөһрәнең Айдагы бәхетле тормышын тасвирлау белән башлап китә. Җир йөзендәге бер кешене генә булса да бәхетле итәргә тырышып, автор үги кыз Зөһрәне утопик җәмгыятьтә яшәтеп ала: «Ай өстендә рәхәт, анда кайгы-хәсрәтләр, үги аналар юк икән. Анда кешене кыйнаулар, ач тотулар, ябып

[70] Әмирхан Ф. Әсәрләр: Дүрт томда. – Т. 1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Б. 137-140.
[71] Әмирхан Ф. Халык кызлары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – Б. 3. Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар, астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

асраулар – берсе дә, берсе дә юк икән». Зөһрәнең дә «кайгылары онытылган», «гәүдәләре савыккан», «саргайган гөл шикелле мәхәббәтле алсуланган», «керфекләрдән яңадан гөлләр тама башлаган» (10 б.).

Ләкин шул матур, мул тормышта яшәгән Зөһрә «туган-үскән илләрен», «уйнап йөргән болыннарын, кырларын» сагынган. Кыз күзләрен җир өстенә төшерә, ә анда «коточыргыч сугыш, үтереш, кырылыш икән». «Кайчандыр куәтле, иркә Казан Иван Грозный гаскәре белән чорналган». Үзенең азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен көрәшүче Казан шәһәре образын автор тирән драматизм белән сугарып, җанландырып бирә. Казан «елгалар шикелле кан түгеп, сугышып, гаҗәп бер гайрәт белән үз-үзен сакларга тырыша» (10 б.). Шул рәвешчә, Фатих Әмирхан Зөһрәнең Айдагы тыныч тормышына казанлыларның канга батып дошманнарына каршы көрәшү күренешләрен романтикларча каршы куя. Контраст алымнар ярдәмендә ул Казан өчен барган сугышны гаять тә тәэсирле итеп күз алдына китереп бастыра: «туплар шартлыйлар, бөтен җир йөзен төтенгә батыралар, кылычлар ялтырашалар, сөңгеләр йөрәкләргә кадалалар, кешеләр үләләр, кырылышалар, кан елгаларына баталар икән» (11 б.).

Менә шулай «бөтен тирә-якның асты-өскә килгәндә», «җир өстендә кыямәт купкан шикелле булган»да Казан кальгасенә баскан ханбикә Сөембикә күренә. Фатих Әмирхан Сөембикәне романтик әдәбияттагыча идеаллаштырып сурәтли. Ул – гүзәллек алиһәсе, ул – фәрештә, ул – пакьлек һәм батырлык символы: «Ул үзенең ак ефәк киемендә ярдәмгә иңгән фәрештә шикелле күренә» (11 б.). Казан мәликәсе Сөембикә, югарыда тикшерелеп үткән Зәки Вәлиди хезмәтендәге кебек, Казанга яу белән килгән Иван гаскәренә каршы сугышта катнаша. А.Н.Грузинцевның «Казанның буйсындырылуы…» әсәрендәгечә, үзенең рухи батырлыгы белән татар сугышчыларына гайрәт һәм куәт өсти: «Казан гаскәрләренә җан бирә, гакыллы фәрманнары, урынлы киңәшләре белән шәһәргә һәм аның батыр сугышчыларына көч бирә» (11 б.).

Фатих Әмирхан Сөембикәне ир-егетләр кебек батыр һәм «искиткеч гайрәтле» итеп тасвирлый. Ул «сугышның иң куәтле урынына килгән дә, үлем куркынычына да карамыйча, шунда торган» (11 б.). Үлемнән дә курыкмаган батыр йөрәкле Сөембикә «коллыкта тереклеккә караганда» яу кырында «намуслы үлем»не артыграк күрә. Мондый батыр һәм гүзәл ханбикәсе булган каланы беренче килүендә Явыз Иван әле ала да алмый китә.

Фатих Әмирхан, «Сөембикә» хикәясен әкият һәм риваятьләргә охшатып язса да, әсәр тукымасына Ай өстендә яшәгән әкияти, хыялый Зөһрә кыз кебек романтик образны кертсә дә, тарихи вакыйгаләр барышын, реалист язучылар кебек логик эзлеклелек белән бирә алуга ирешкән. Шул заманда мәгълүм булган тарихи материалларга нигезләнеп, автор Сөембикә ханбикә идарәсе, русларның басып алу сәясәте, аларның Казанны буйсындыру өчен сугышка хәзерләнүләре, Казан мирзалары арасындагы ыгы-зыгылар турында да тормыш дөреслегенә зыян китермичә хикәяләп бара.

Казан мирзаларының сатлыкҗан булып, «Сөенбикә сүзләренә колак салмаулары, аны рәнҗетүләре, аның кечкенә угылы Үтәмешгәрәйне хан итеп танырга теләмәүләре, Мәскәүгә

китеп, русларга кушылулары» (11 б.) кебек Казандагы сәяси халәтне автор тирән психологизм белән сугара. Сөембикә исә, кулыннан килгәнчә, булдыра алганча, бу «кабахәтлекләргә каршы» торырга омтыла.

Руслар Казанны яулап алу өчен плацдарм вазифасын үтәүче Зөя каласын салып куялар. Ә татарларның ил агалары илләренә, җирләренә шундый зур куркыныч янаган вакытта да, гауга куптарып, үзара талашып яталар. Ханбикә Сөембикә татарларны «җылап-җылап, берләшергә, русларга каршы торырга өнди»: «Илегез руслар малы, үзегез рус колы булырга торганда, инде йөрәкләрегездә намус, гайрәт кузгалмый?!», дип аларны гарьләндерергә тырыша.

Эчтәлектән күренә ки, Ф.Әмирхан Казан ханлыгы заманындагы тарихи-сәяси вакыйгаләрне романтик әдәбияттагыча, Сөембикәнең эчке кичерешләре рәвешендә гәүдәләндерә. Киләчәктә үзләрен ачы язмыш көткәнен аңламаган татарлар Сөембикә сүзләрен тыңламыйлар, боерыкларын үтәмиләр. Казанлыларның бу эш-гамәлләренә табигать тә аптырый һәм борчыла: «Ай өстендәге тауларның башлары калтыранып киткән», «һавага охшашлы нәрсәләр озын-озын, биек-биек дулкыннар белән дулкынланып күк гөрелдәгән, яшен чалтыраган тавышлар чыгарган». Барысы да Зөһрә кыз белән берлектә «Бетәсез бит! Бетәсең бит, Казан!» диешкәннәр. Ләкин бу тавыш Зөһрә кызның үзенә генә кире кайткан, казанлыларның күбесе «каты йоклыйлар», «күбесе уянмаганнар». Бу очракта да казанлылар фаҗигасе романтик язучылардагыча табигать күренешләре һәм «Бетәсең бит, Казан!» дигән бик тә экспрессив җөмләләр ярдәмендә бирелә.

Реаль тарихтагыча, Ф.Әмирхан хикәясендә дә, Сөембикәнең әсир итеп Мәскәүгә җибәрелүе һәм Тау ягының русларга бирелүе Иван тарафыннан катгый шарт итеп куелуы әйтелә. Әмма Казан ханлыгы өчен килеп туган куркыныч вәзгыять романтик алымнар ярдәмендә сурәтләнә һәм «язмыштан узмыш юк» фәлсәфәсе белән үлчәнә. Сөембикә ханбикә дә, тәкъдиренә буйсынып, руслар кулына бирелергә мәҗбүр була. Ханлыкка һәм Сөембикәгә килгән бу олы хәсрәтне язучы «ут дәрьясы» образы белән чагыштыра. Бу зур кайгыдан Сөембикә хәлсезләнеп егыла, һуштан яза. Ханбикәнең авыр психологик халәте сынландырулар ярдәмендә дә ассызыклана. Бу фаҗигагә түзә алмаган хан сараеның «зиннәтле идәннәре, алтын-көмеш һәм асыл ташлар белән бизәлгән диварлары дерелдәп киткәннәр», «урыннарыннан кузгалган шикелле булганнар», Сөембикәнең улы Үтәмешгәрәй дә «бәхетсезлеген илһам белән сизенгән шикелле ачы җылап җибәргән» (14 б.).

Автор Сөембикәнең Казаннан китү тасвирларын – «Хан мәсҗеденә кереп җылап-җылап намаз укуларын», ире Сафагәрәй кабере янында «сабырсызланып ачы-ачы җылаганын» бәет-риваятьләргә һәм тарихчылар хезмәтләренә нигезләнеп иҗат итә. Руслар кулына әсир булып китү хурлыгын тою Сөембикәгә чиксез авыр. Ул казанлыларны ханга биргән вәгъдәләрен, антларын бозуда, ханбикәләрен руслар кулына тапшыруда гаепли. «Гомер буе Казан өчен яшәп», «аның кайгысы белән яшәгән», «бөтен сулышы, селкенешләре Казан өчен, аның хөрлеге, аның югарылыгы өчен» булган ханбикә әсир булып китәргә мәҗбүр

ителә. Коллыкта яшәүгә караганда, үлемне яхшырак күрә Сөембикә: «бу хурлыкларны, бу газапларны күрүдән кабердә яту мең өлеш артык» (16 б.) аның өчен.

Казан мәликәсе Сөембикә турында язылган бу кечкенә хикәя Ф.Әмирханның үз милләте язмышы өчен борчылу-уйланулары белән тулы. Әсәрдә Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе өчен Зөһрә кыз белән берлектә бөтен табигать елый – таулар, күк йөзе, һавалар, Ай да хәрәкәткә килә. Ул да Казанның бәйсезлеге өчен көрәшә. Милли тарихның бу драматик сәхифәләрен автор һәрбер җөмлә, һәрбер сүз ярдәмендә укучыга җиткерергә тырыша. Мәсәлән, Зөһрә кыз яки Сөембикәнең рухи халәтен тасвирлаганда, автор парлы сүзләрдән уңышлы файдалана һәм, шул рәвешчә, әсәрнең мәгънәви яңгырашын һәм тәэсир итү көчен бермә-бер арттыра алуга ирешә: «эре-эре яшьләр», җылап-җылап намаз уку», «ачы-ачы җылау», «үксеп-үксеп җылау», «озын-озын, биек-биек дулкыннар».

Ай өстендә яшәгән Зөһрә кыз Сөембикәнең китүенә, Казанның ханбикәсез калуына, халкының руслар колы булуына борчылып, үксеп-үксеп елап җибәрә. Ф.Әмирхан бу шартлы романтик образның кайгы-хәсрәтен, аның Сөембикәгә теләктәшлеген гиперболалар ярдәмендә ассызыклый. «Аның (Зөһрәнең. – *И.Р.*) күз яшьләре кечкенә-кечкенә елгалар булып агып, төрле якларга агып киткәннәр» (16 б.). Татар халкының дәүләтчелеген югалту фаҗигасе хәтта «айны да көйдереп җибәрә», «бер минут эчендә ай караңгыланып өлгерә». Шул рәвешчә, Казан ханлыгының инкыйразга дучар булу вакыйгасе, Зөһрә кыз йөрәге аша үткәрелеп, романтиклардагыча галәм киңлекләренә чыгарыла.

Моңа кадәр без тикшереп үткән татар тарихчылары хезмәтләрендә Сөембикә – бөек тарихи шәхес, акыллы идарәче, зирәк сәясәтче буларак ачылган иде. Фатих Әмирхан исә Сөембикәне, бер караганда, «Ходайдан Казанга ярдәм бирергә иңдерелгән рәхмәт фәрештәсе», бер караганда, «бөтен Казанның анасы» итеп сурәтли.

Беренчеләрдән булып, Ризаэтдин Фәхретдинов хатын-кызларны «милләт аналары» дип атаган, бу мәсьәләне «Әсма» романында көн тәртибенә куйган иде. Фатих Әмирхан исә әлеге «милләт аналары» төшенчәсенә тагы да киңрәк эчтәлек салды, аны Сөембикә ханбикә образына карата кулланып, татар халкының Казан ханлыгы заманындагы азатлык өчен көрәш тарихы белән бәйләде.

Фатих Әмирхан хикәясендә урын алган «милләт анасы» образы соңрак төрек әдәбиятына да үтеп керә һәм үзәк образларның берсенә әйләнә. Төркиядә иҗат ителгән әсәрләрнең барысында да диярлек Сөембикә нәкъ менә «Казан анасы», «милләт анасы» итеп күз алдына китереп бастырыла.

* * *

Сөембикә ханбикә турында икенче бер проза әсәре 1916 елда Шәһит Әхмәдиев тарафыннан языла һәм «Сөембикә» журналы битләрендә басылып чыга[72]. «Мәшһүр хатыннардан Сөембикә» исемле бу хикәядә нәсер жанрына тартымлык сизелә. Фатих Әмир-

[72] Сөембикә. – 1916. – №2; №3.

хан кебек Шәһит Әхмәдиев тә Сөембикәнең иркен Нугай далаларында үсеп, гүзәл кыз булып җитешүен, Казан ханы Җангали, соңыннан Сафагәрәй хан хатыны булып тору заманнарын, Казан ханлыгы белән идарә итү елларын һәм русларга әсир итеп җибәрелү күренешләрен романтик буяулар кулланып тасвирлый.

Әсәрдә Сөембикә образы һәрьяктан идеаллаштырып бирелә. «Матурлык, акыл, байлык, дәрәҗә, кыскасы, нинди генә яхшы сыйфатлар бар – һәммәсе дә Сөембикәдә табыла», ди автор. Шуңа күрә Нугай илендә яшәүче бөтен оланнарның, бәкләрнең идеаллары бер Сөембикә була. Сөембикә тышкы ягы белән генә гүзәл кыз түгел. Ул – хөр табигатьле, илен, милләтен сөюче кыз да. Аның көчле рухлы, хөр табигатьле булып үсүендә Шәһит Әхмәдиев аның атасы Йосыф мирзаның өлеше зур булуын билгеләп уза. Чөнки Йосыф мирза хан булып торган «Нугай иле чит падишаһларга һичбер эштә буйсынмый. Бер эштә дә алардан киңәш сорамый». «Көчле атаның көчле кызы» булып тәрбияләнгән Сөембикә, Җангали хатыны булып Казанда тора башлагач та, «яңа ватаны Казанны сөеп, аның матур киләчәге өчен Мәскәүнең нөфүзен (йогынтысын. – *И.Р.*) бетерергә әмәлләр кора». Ул «ире Җангалинең көчсезлегенә, һәр эшне Мәскәү кенәзенең куюы буенча гына эшләвенә риза булмый». Ш.Әхмәдиев Җангалинең «кинәт кенә үлтерелүенә Сөембикәнең дә катнашы барлыгы фараз итеп, сөйләнелә башлый», ди. Гәрчә, тарихи материаллар һәм тарихи хезмәтләрдә бу хакта бер сүз дә әйтелми. Тарихчы галим Равил Фәхретдинов, урта гасырлардагы иң ышанычлы дип исәпләнгән «Воскресенский летопись»ка нигезләнеп, болай дип яза: «После смерти Василия III в 1535 году Гаухаршад вместе со знаменитым карача-бием Булат Ширином повели активную борьбу против московского протектората. «Кавгаршад-царевна и Булат князь и вся земля Казанская великому князю Ивану Васильевичу изменили». Сразу же за этим последовал переворот: 25 сентября 1535 года был убит Джан Али и ханом вновь пригласили Сафу-Гирея»[73].

Татар тарихчылары хезмәтләрендә дә Сөембикәнең ире Җангали үлемендә катнашы булуы турында бер сүз дә әйтелми. Соңрак, төрек авторлары әсәрләрендә бу мотив яңадан калкып чыга.

Мондый төгәлсезлекләр Ш.Әхмәдиевтә берәү генә түгел. Мәсәлән, автор, «Нугай иленә киткәч, Сөембикә шунда бер ир бала тудыра», ди. Үтәмешгәрәйнең кайсы елда тууы турында галимнәр арасында фикер төрлелеге хөкем сөрә. Берәүләре (Риза Фәхретдинов, Равил Фәхретдинов, М.Худяков) аның туган елы дип 1546 елны күрсәтәләр, ә икенчеләр (Һ.Атласи) Үтәмешгәрәйнең тууы 1547 елда, Сөембикә Нугай далаларыннан Казанга әйләнеп кайткач туган дигән фикердә торалар. Төрле карашлар яшәп килсә дә, Үтәмешгәрәйнең Нугайда тууы турында бер генә чыганакта да төгәл мәгълүмат бирелми. Гомумән, автор үзенең мәкаләсендә тарихи вакыйгаләр турында сөйләгәндә күбрәк, «фараз ителә, гөман ителә, сөйләнелә» дигән фигыльләрне куллана, башка авторларның фикерләренә таяна. Автор Сөембикә биографиясен билгеле булган тарихи мәгълүматларга

[73] Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа и Татарстана. – Казань: Магариф, 2000. – С.223-224.

таянып аңлатырга тырышса да, бу әсәр – фәнни мәкалә түгел. «Мәшһүр хатыннардан Сөембикә» – публицистик элементлар белән дә үрелгән нәсер жанрына тартым романтик хикәя. Ә андый әсәрдән тормыш дөреслеген таләп итү бик үк урынлы булмас иде. Ш.Әхмәдиев Сөембикәнең тормышын шартлы рәвештә дүрт дәвергә бүлеп яктырта. Ул дәверләрнең ханбикә өчен иң бәхетлесе – Сафагәрәй хан белән бергә гомер итү еллары. Әсәрдә Сафагәрәйнең максаты изге итеп сурәтләнә. Аның «ничек булса да Казанны мөстәкыйль бер ханлык итәсе килә». Сафагәрәй кебек «үткен табигатьле, тәдбирле, үз илен сөюче бер зат»ның максатлары Сөембикәнең рухи дөньясына, иҗтимагый-сәяси карашларына туры килә. Шәһит Әхмәдиев, романтикларга хас булганча, Сөембикәне гадәттән тыш сыйфатларга ия итеп сурәтли. Аның гүзәллеге гади бер гүзәллек кенә түгел, ханбикә – «матурлык тәңресе». Бу – татар әдәбиятында Сөембикәнең матурлыгына бирелгән иң югары бәяләмә. Өстәвенә ул – «гакыллы ханбикә». Татар әдәбиятында урта гасырлардан килә торган традициягә бәйләп һәм Һади Атласиның Сөембикә турындагы документаль романына таянып, автор ханбикәнең гадел ханбикә, акыллы идарәче һәм зирәк сәясәтче булуына кат-кат басым ясый.

Шәһит Әхмәдиев тудырган Сөембикә – тырыш һәм батыр ханбикә дә. Зәки Вәлиди, Фатих Әмирхан әсәрләрендәгечә, Сөембикә «Мәскәү патшасы үзе килеп сугышкан сугышта искиткеч гайрәт күрсәтә. Ул төнен-көнен йокламыйча, сугыш хәҗәтләрен карый, сугыш сафында үзе торып, гаскәрне рухландырырлык сүзләр сөйли һәм гаскәрне үзе идарә кыла».

«Мәшһүр хатыннардан Сөембикә» хикәя-нәсеренең зур бер өлеше Сөембикәнең ханлыкны һәм мәмләкәтне саклап калу өчен башкарган эшләре турында сөйләүгә корылган. Сөембикә «ханлыкны һәм мәмләкәтне саклар өчен гаскәри көчне арттыра», «халыкның төрле сыйныфы белән дә якыннан ук катыша», төрле «сыйныфларның күңелләрен табарга һәм үзенә мәхәббәтен җәлеп кылырга тырыша», «сугыш кирәкләрен тикшерә, сугыш әсбапларына һәм башкача халык эшләренә хәзинә акчасын гына түгел, үз малын да тарата». Сөембикә бөтен халыкны бердәм көч булып туплап, «бер төргәккә бәйләп һәм дошманнарына каршы торырга зур көчләр хәзерли». Хикәя-нәсернең буеннан-буена Ш.Әхмәдиев Сөембикәнең азатлык сөюче ханбикә булуына, милләтпәрвәрлегенә, кыскасы, Казан ханлыгын, аның халкын яратучы изге һәм батыр шәхес икәнлегенә басым ясый. Шул ягы белән Ш.Әхмәдиев хикәя-нәсере Ф.Әмирхан хикәя-әкиятеннән күпмедер дәрәҗәдә аерылып та тора.

Казанлыларның бу каршылыкларыннан курыккан Кошчак үзенең якыннары белән Кырымга качарга мәҗбүр була. Кошчак угъланның Казаннан китү сәбәпләрен автор «Казанны коткару өчен» башкарылган адым дип аңлата. Ә менә аның руслар кулына әсир төшү урынын Шәһит Әхмәдиев дөрес күрсәтми. Автор фикеренчә, Кошчак «юлда хәзерге Зөя каласының урынында руслар кулына әсир төшә». Тарихи материаллар (Р.Фәхретдинов, М.Худяков, Һ.Атласи) Кошчак угъланның руслар кулына әсир төшү урынын Вятка (Чулман) елгасы тамагы дип күрсәтәләр.

Сөембикә идарәсенең соңгы дәвере – Казаннан әсир булып китүе, Казан каласы, казанлылар белән саубуллашу күренешләре Һади Атласи тарихи романы тәэсирендә язылган. Моны раслау өчен берничә мисал китереп үтик:

1. Сөекле падишаһым! Минем ачы хәсрәтләремне, зарларымны ишетсәнә? Ач ләхетеңне! Ул икемезгә дә якты сарай, хан урындыгы булсын, матур ханбикәңне үз яныңа кабул итсәнә! (Шәһит Әхмәдиев).

Сөекле падишаһым! Минем ачы егълауларымны ишетсәнә! Үзеңнең караңгы ләхедеңне ачып, мине үзеңнең яныңа алсана! Синең ләхедең сиңа һәм миңа хан урындыгы, якты сарай булсыннар (Һади Атласи, 30 б.).

2. Ай, Алла! Безне бу хәлгә төшерүче көнчебез, дошманыбыз булган Шәехгалине үзең хөкем ит (Шәһит Әхмәдиев).

Әй Алла! Безнең көнчебез һәм азгын дошманыбыз булган Шәехгалигә үзең хөкем ит, үзең җәзасын бир! (Һади Атласи, 34 б.).

3. Ул миңа Мәскәү кенәзен ачуландырып, безне үзебезнең падишаһлыгыбыздан каулатты. Әгәр миңа Казаннан бер өлеш җир бирелсә, үлгәнчегә кадәр шунда торыр идем (Шәһит Әхмәдиев).

Ул миңа олугъ князьне ачуландырып, аның боерыгы буенча, безне, һич гөнаһсыз, үзебезнең падишаһлыгыбыздан каулатты. Ул миңа Казанда кечкенә бер өлеш җир бирсә, мин шуннан артык нәрсә теләмәс идем (Һади Атласи, 35 б.).

4. Минем өчен әллә кемнәрдә мыскылланып яшәүдән, ачы үлемне тату яхшырак булыр иде (Шәһит Әхмәдиев).

Мәскәүгә баруга, рус йортында мыскылланып, көлке ителеп яшәүгә караганда, миңа ирем янында булу артыграк, ачы үлемне тату яхшырак булыр иде. (Һади Атласи, 35 б.).

Күренгәнчә, Шәһит Әхмәдиев Сөембикәнең елау-сыктауларын, Казан белән саубуллашу мизгелләрен Һади Атласиның «Сөен-бикә» әсәреннән кыскартып, үзенең иҗат принципларына яраштырып, иҗади эшкәртә. Ә Һади Атласи исә бу сыктау күренешләрен тасвирлаганда XVI гасырда язылган «Казан тарихы»на нигезләнгән иде. Сөембикәнең сыктауларын сурәтләгәндә дә, Ш.Әхмәдиев ханбикәнең Казан ханлыгына, халкына, аның җир-суларына олы мәхәббәтен гәүдәләндерә, ватанпәрвәрлек хисләрен үзәккә куя.

Казан белән аерылу күренеше Ф.Әмирхандагыча гиперболалар һәм сынландыру алымы ярдәмендә җанландырыла. Ханбикәнең Казаннан китү хәбәреннән бөтен тирә-як кан-яшь агыза, кайгыдан бер өзлексез елый: «аның өчен сарай бианалары, мәсҗитләр, мәдрәсәләр, мәктәпләр, сәетләр, шәехләр, мөридләр, шәкертләр – һәммәсе, һәммәсе егълый». Сөембикәнең Казан белән саубуллашкандагы борчылуы, газаплануы бөтен Казан халкына искиткеч начар тәэсир итә». Ханбикәсе белән саубуллашырга килгән «иге-чиге булмаган халык, йөзтүбән егылып, үкереп елыйлар». Хәтта «таш күңел, сатлык бәкләр, мирзалар да егълыйлар».

Шәһит Әхмәдиевнең «Мәшһүр хатыннардан Сөембикә» нәсере – XX гасыр башы татар

әдәбиятында Сөембикә ханбикә турында безгә билгеле булган әсәрләрнең соңгысы һәм гыйбрәтлесе: бөтен татар милләтенең сөекле кызы, «киң яланнарның бәлләүләп үстергән чәчкәсе», «матурлык Тәңресе», горур һәм батыр, «хан-мирзаларның табынган» Сөембикәсе белән автор баш иеп саубуллаша.

XX гасыр башы – татар халкының иҗтимагый-мәдәни тормышында, сәнгатьчә фикерләвендә зур алгарыш һәм яңарыш кичергән чор. Милли тәрәкъкыять идеяләренең ялкындай кабынып китүе урта гасырларда юкка чыккан дәүләтчелек тарихына игътибарны бермә-бер арттыра, колониаль изелүдән котылу, милли азатлык турындагы уй-фикерләрне көчәйтеп, үткенләндереп җибәрә. Шул изге максатны күздә тотып, зыялылар һәм әдипләр үткән тарихтагы Сөембикә турындагы бәет, легенда, тарихи җырларны «эшкә җигәләр», аларның яңа вариантларын вакытлы матбугат битләрендә бастырып чыгаралар (Г.Рәшиди); документальлеккә нигезләнгән Сөембикә турында беренче тарихи роман иҗат итәлә (Һ.Атласи); милли хисләр белән сугарылган романтик эчтәлекле хикәяләр мәйданга чыга (Ф.Әмирхан, Ш.Әхмәдиев), бер пьеса сәхнәгә куела, рус тарихи чыганакларына нигезләнеп язылган Р.Фәхретдинов, Зәки Вәлиди, Г.Әхмәрев кебек тарихчыларның Сөембикә турындагы хезмәтләре дөнья күрә.

Төрле жанрдагы әдәби әсәрләр, фәнни-тарихи хезмәтләр арасында рус елъязмаларына һәм «Казан тарихы»на таянып иҗади язылган Һади Атласиның «Сөембикә» романы күренекле урын алып тора. Беренчедән, бу тарихи роман Казан ханлыгының рус дәүләте һәм башка төрки мәмләкәтләр белән мөнәсәбәтләрен, аның эчке каршылыклар нәтиҗәсендә инкыйразга таба хәрәкәт итүен объектив гәүдәләндерә алган. Икенчедән, Һади Атласи, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, Сөембикәне тарихи шәхес кенә итеп түгел, ә әдәби образ буларак та тасвирлауга ирешә. Автор аның шәхси һәм җәмгыяви тормышына, психологик кичерешләренә, рухи халәтенә тулы анализ бирергә омтыла.

Тарихи шәхесне әдәби образ итеп сурәтләү типиклаштыруның бер төре булып санала. Ф.Хатипов билгеләп үткәнчә, тарихи шәхесләрне әсәрләренең герое итеп сурәтләгән автор «халыкның иң күренекле, асыл сыйфатларын үзендә туплаган, дәртен, омтылышын, зирәклеген, талантын гәүдәләндергән, тарихи хәтерендә саклаган, анда мөһим урын алган күренекле затларны әсәр герое итеп сайлый»[74]. Дөрестән дә, Һади Атласиның Сөембикә образы – типик һәм индивидуаль сыйфатларны үзендә туплаган, шул ук вакытта реаль тарихи прототибына якын торган әдәби каһарман. Романтик рухта иҗат ителгән Ф.Әмирхан белән Ш.Әхмәдиев әсәрләрендә Сөембикә әдәби образ буларак «милләт анасы» бөеклегенә күтәрелә.

Сөембикә образын бу рәвешчә татар милләте язмышы белән бәйләп карау XX гасыр татар һәм төрек әдәбиятларында Сөембикә ханбикә образын татар милләте язмышы белән бәйләп бирү әле яңа заманда да классицизм әдәбияты өчен хас традицияләрнең әдәби барыштан төшеп калмавы, иҗади дәвам итүе турында сөйләде.

---

[74] Хатипов Ф. Әдәбият теориясе. – Казан: Мәгариф, 2000. – Б. 156.

## ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

### Төрек әдәбиятында Сөембикә ханбикә образы

Казан ханлыгы үзенең мөстәкыйльлеген, азатлыгын югалтканнан соң, патша Россиясе вакытында да, совет чорында да рәсми төстә халкыбыз тарихын, аның бай әдәби һәм мәдәни мирасын бөтен тулылыгы белән өйрәнү мөмкинлеге булмады. Татар халкының урта гасырлардагы тарихы, аның күренекле шәхесләренә багышланган әсәрләр бөтенләй диярлек язылмады. Әйтелгәнчә, XX гасыр башында гына татар тарихы һәм әдәбиятында Сөембикә исеме белән бәйле фәнни хезмәтләр, шигырьләр, тарихи романнар, сәхнә әсәрләре иҗат ителә. Октябрь инкыйлабыннан соң илдә урнашкан тоталитар режим милли тарих һәм милли каһарманнар турында язуны катгый рәвештә диярлек чикләп килә. Икенче бөтендөнья сугышы бетәргә бер ел вакыт калгач, Сталин фәрманы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 август карары белән «Идегәй» дастанына, гомумән, Алтын Урда тарихына кара мөһер сугыла. «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеологик эшләрнең торышы һәм аларны яхшырту чаралары турында» дигән карар татар халкы тарихын яктыртуда җитди ялгышлар булуга «игътибар итте», «Идегәй» эпосын Алтын Урда чорын идеаллаштыручы әсәр дип таныды. Каләм әһелләренә күп милләтле совет халкының чит ил илбасарларына, царизмга, алпавыт-капиталистларга каршы көрәше, социалистик Татарстан, аның атаклы кешеләре, Бөек Ватан сугышы геройлары турында гына язарга кушылды.

Бөек Ватан сугышының азагында СССРның Германияне җиңәчәге ачыклангач та, егерменче еллардан ук милләтара мөнәсәбәтләр теоретигы булып танылган Сталин башка милләт халыкларын эзәрлекләү, аларны юк итү, сөргенгә, ГУЛАГларга озату юлына баса. Казан татарлары да шундый куркыныч алдында калалар.

Әмма чит илләрдә гомер кичерүче татар диаспорасы вәкилләре асыл Ватаннарында коммунистик идеология оештырган һәртөрле өркетү, тыю, куркытулардан азат иделәр.

Туган илләреннән читтә гомер кичерүче милләтебезнең асыл затлары, Һади Атласи һәм Фатих Әмирханнар традицияләрен күтәреп алып, Төркия җирлегендә татар тарихы һәм аның каһарманнары турында үз сүзләрен әйтә алдылар.

СССРда яшәүче вак милләтләрнең эзәрлекләнү сәясәте турында чит илләрдә яшәүче татарлар матбугат, радио һәм башка каналлар аша яхшы таныш булалар. Нәкъ менә шушы «Идегәй» дастанын бастыру һәм Алтын Урда тарихын өйрәнү тыелган елны, Совет илендәге рус булмаган милләтләргә начар мөнәсәбәткә җавап рәвешендә, татарларның милли азатлык хәрәкәте юлбашчысы Гаяз Исхакый 1944–1947 елларда Казан ханлыгы, аның беренче

ханнарыннан исәпләнгән Олуг Мөхәммәдкә багышланган тарихи драмасын яза. Алтын Урданың таркалу һәм Казан ханлыгының төзелү чорына багышланган бу драмада Гаяз Исхакый рус-татар иҗтимагый һәм сәяси мөнәсәбәтләрен бөтен каршылыклары белән гәүдәләндерә алган. Алда искәртеп үткәнебезчә, Гаяз Исхакый XX гасыр башы татар әдәбиятында һәм соңрак мөһаҗирлек дәверендә диаспорада яшәп иҗат итүчеләр арасында милли тарих һәм Сөембикә образына мөрәҗәгать итүчеләр арасында беренчеләрдән була.

Иленнән, халкыннан аерылып чит мәмләкәтләрдә яшәгән татар диаспорасы вәкилләрендә туган илне сагыну хисе бик тә көчле иде. Халыкка һәм туган-үскән җиргә мәхәббәт, милли хисләр Сөембикә шәхесенә бәйле рәвештә аеруча үткен чагылыш таба. Бөтендөнья тарихы кискен борылышлар кичергән бер дәвердә татар халкының милли азатлык символына әверелгән Сөембикә образына мөрәҗәгать итү тарихи бер ихтыяҗ рәвешен ала. Бер-бер артлы Казан ханлыгы тарихын һәм Сөембикә ханбикә язмышын яктырткан фәнни-публицистик мәкаләләр, тарихи романнар, шигырь һәм поэмалар барлыкка килә.

## 1. Илгаз Ваһап Нәүрүзханның «Сөембикә» тарихи романы

Данлыклы ханбикәбез турында Төркия җирлегендә иҗат ителгән әсәрләрнең берсе – чыгышы белән казанлы булган, гимназия укытучысы Илгаз [1] Ваһап Нәүрүзханның «Сөембикә» исемле тарихи романы. Бу әсәр беренче тапкыр 1945 елда Истанбулда «Бурак» нәшриятында дөнья күрә, ә 1992 елда татарчага Рәис Сабиров тарафыннан тәрҗемә ителеп, «Камаз» нәшриятында басылып чыга[2]. Романның авторы турында мәгълүматлар бик аз. Илгаз Ваһап Нәүрүзхан 1979 елда вафат булган, үзеннән соң озакламый ире дә дөнья куйган. Үзе Себер татары булып, Төркиядә югары белем алган, гомер буена шунда яшәгән, лицей-гимназияләрдә укыткан. Истанбулда башта «Тукай яшьләре түгәрәге», соңрак «Казан төркиләре» исеме белән эшләгән татар оешмаларының җыелышларына актив катнаша торган булган[3].

Исеменнән үк күренеп торганча, романның төп герое – Сөембикә. Ханбикә язмышындагы төп этапларга белән бәйле рәвештә әсәр өч бүлеккә бүленгән. Романның беренче өлешендә Сөембикәнең туган-үскән төбәге – Нугай даласы, атасы Йосыф морза йортында үткән бала чагы, яшьлек еллары турында сөйләнелә. Икенче бүлектә Сөембикәнең Казан ханы Җангалигә кияүгә чыгып, аның белән яшәве, тормышка мөнәсәбәтләре, ил белән идарә итүгә карашлары, уй-фикерләре тулысы белән формалашып беткән чорлар турында бәян ителә. Өченче бүлек Сөембикә язмышының иң бәхетле еллары – яраткан ире Сафагәрәй хан белән бергәләп яшәве, уллары Үтәмешгәрәйне тәрбия кылулары һәм шул ук вакытта

[1] Төрекчә бу исем Ылгаз дип әйтелә.
[2] Нәүрүзхан И.В. Сөембикә. – Чаллы: «Камаз» нәшрияте, 1992.
[3] Ибраһимова С. «Сөембикә» журналында Сөембикә ханбикә темасы: төрек әдәбиятына мөрәҗәгать // Сөембикә ханбикә. – Казан: Иделпресс, 2001. – Б. 263.

ханбикә язмышының иң борчулы, фаҗигале дәверләрен тасвирлауны үз эченә ала.

Автор романның беренче юлларында ук Казан ханлыгының булачак ханбикәсенең нинди тәрбия алуы, нинди идеаллар һәм идеяләр белән яшәве, хисси кичерешләре, яшерен хыяллары турында сөйли. Сөембикә бала чагында атасы Йосыф морза йортында алган милли һәм дини тәрбиягә турылыклы булып кала, атасы «сызган эздән, гореф-гадәтләр кушкан юлдан тайпылмыйча» бара. Иркен Нугай далаларында урнашкан Сарай шәһәрендә яшәгән, «юмартлыгы һәм шәфкатьлелеге белән дан тоткан атасыннан да киң күңеллерәк һәм юмартрак» булып үсеп җитешә Сөембикә. Булачак ханбикә яшьлек вакытын атасы йортында чигү чигеп, китаплар укып, ауга йөреп, Сабан туйларында катнашып үткәрә.

Романда Сөембикәнең җыйнап бирелгән портреты күренми. Ханбикә гүзәллеген чагылдыручы кыска-кыска тасвирлар әсәрнең буеннан-буена таратылган, чәчелгән. Шуңа күрә дә әсәрнең ахырына таба гына Сөембикәнең тулы бер портреты күз алдына килеп баса. Ул – зур кара күзле, ефәк чәчле, киң ак маңгайлы, нәфис сынлы, сөйкемле, елмаючан һәм сөйкемле иренле, татлы тавышлы бик чибәр кыз булып җитешә. Хәтта атасы Йосыф морзаны өнәп бетермәүче туганы Исмәгыйль морза да Сөембикә турында: «Машалла, Аллаһы Тәгалә яратса да яратыр икән, кыз түгел, фәрештәдер бу», – диюдән тыелып кала алмый[4].

Кыз яшьтән әнисез кала. Шуңа күрә дә Сөембикә күбрәк әтисенә ияреп, идарә эшләре белән кызыксынып, дәүләт белән идарә итәргә өйрәнеп үсә. Әтисе кызына исә яшьтән үк урысларның төрки халыкларга куркыныч дошман булуларын, милләтне алардан күз карасы кебек сакларга кирәклеген аңлата. Әтисе сөйләгәннәрдән Гәүһәршад турындагы дастан Сөембикәнең күңеленә бигрәк тә сеңеп кала. «Исеме тарихка алтын хәрефләр белән язылырга тиешле», «һәр төрки гаиләсендә кыз балага беренче чиратта әйтелергә кирәк» бу ханбикә тормышы каһарманлык дастаны булып яңгырый. Аның турында балаларга сөйләү – ата-ананың баласы каршында үтәлергә тиешле иң зур вазифасы булып тора. Үз Ватанын урысларга буйсынып яшәүдән, ә милләтне коллыктан коткарган Гәүһәршад бикә образы Сөембикәнең киләчәгенә, аның язмышына тәэсир итмичә калмый, әлбәттә. Язучы Гәүһәршад турындагы дастанны юкка гына әсәренә кертеп җибәрмәгән. Чөнки Сөембикә биографиясе үзенең кайбер яклары белән аның язмышын хәтерләтә. Сөембикә дә, Гәүһәршад кебек, Нугай йортында туып үсә, икесен дә саф һава, хөр тормыш тәрбияли, икесе дә үз заманнарының гүзәл хатыннары булып җитешәләр, затлы ханымнарга хас күркәм сыйфатларны үзләрендә гәүдәләндерәләр. Сөембикә белән Гәүһәршад бикәне берләштерүче уртак сыйфат – ул үз милләтеңә мәхәббәт, гомерләренең соңгы минутларына кадәр Ватан, халык азатлыгы өчен көрәшү.

Сөембикә, үсеп буйга җиткәч тә, Исмәгыйль морзаның улына гашыйк була. Бу мәхәббәт яшь морза тарафыннан да җавапсыз калмый. Сөембикәне күреп бер сөйләшү өчен ул Йосыф

[4] Нәүрүзхан И.В. Сөембикә. – Чаллы: «Камаз» нәшр., 1992. – Б. 7. Киләчәктә бу әсәрдән өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

морзаларның бакчаларына хезмәтче булып яллана. Шул көннән башлап Сөембикә гел аның турында уйлый, кавышу көннәрен көтә башлый. Атасының Исмәгыйль морзаны урыслар җырын җырлап йөргәне өчен яратмаганын белә торып та, Гәүһәршад бикә кебек, егетне үзгәртеп, милли җанлы итә алырмын дип ышанып яши. Әмма әтисенең «Үзебезгә тиң булмаган кешеләр белән булышуыңны теләмим» дигән сүзләре аның Исмәгыйль морза улына булган өметен бөтенләйгә өзә (12 б.).

Әйе, язмыш Сөембикә өчен бөтенләй башка юллар, башка үрләр әзерләгән була. Аны яшь ханга димләр өчен Казан каласыннан яучылар килеп төшә. Бу уңай белән Сөембикәгә мөнәсәбәт тә үзгәрә. Аңа булачак «Казан халкының анасы»на булган илтифат, ихтирам күрсәтелә башлый. Ул инде атасы каршында да, туган-тумачалары арасында да бер бикә генә түгел, ә Казан тәхетенең солтаны вазифасын үтәүче ханбикә буларак күзаллана. Атасы Йосыф морза да «карачылар, бәкләр, морзалар минем гүзәл кызыма сәлам биреп башларын иячәкләр» дип горурлана, аның өчен куанып, шатланып яши башлый.

Ләкин бу күтелгән дәрәҗәләр, байлыклар яшерен гыйшык утында янган Сөембикәнең күңелен юата алмыйлар. Исмәгыйль морза улы турында хыялланган Сөембикә алдында ике юл: «Берсе – атасы йортын ташлап китеп, чит җирләргә качу, икенчесе – тәкъдимне кабул итү» кала (22 б.). Качу Сөембикәнең табигате өчен «ят, оят бернәрсә, ул үзеңнең дәрәҗәңне, кешелегеңне югалту» димәк. Ә Казан ханы Җангалинең тәкъдимен кабул итү – «сөю хисеңне, бәйсезлегеңне корбан итү дигән сүз». Казан ханының теләгенә каршы бару – акыл кабул итә алмаслык эш. Нәкъ менә шул көннән башлап, Сөембикә үзенең хис-тойгыларын йөгәнләп, мәхәббәтеннән ваз кичеп, үзенең һәр адымын акыл белән үлчәргә мәҗбүр була. Чөнки Сөембикә аңына кече яшьтән үк «бикә, ул үз-үзенеке түгел, милләтнеке. Ул үзе өчен түгел, милләте өчен яшәргә тиеш» (22 б.) дигән фикер сеңдерелә. Нәүрүзхан романының шушы урынында Аурупа һәм рус әдәбиятларында инде XVII–XIX гасырларда ук шаулап үткән, совет чоры әдәбиятында да чалымнары сакланып калган классицизм методы (Ю.Борев) өчен хас сыйфатлар килеп керә. Акыл культына өстенлек бирелеп, акыл төп каһарман Сөембикәнең хисләренә каршы куела башлый. Шул рәвешчә, бикәгә гыйшык-мәхәббәттән күп тапкыр мөһимрәк, өстенрәк вазифалар йөкләнә. Йосыф морза да кызына «Гыйшык – ул эшсезләр шөгыле» (22 б.) дигән фикерне әйтә. Рус әдәбиятының Сөембикә турында язылган әсәрләрендә көчле рухлы геройлар авызыннан мондый фикерләр яңгыраган иде инде. Мәсәлән, С.Н.Глинканың «Сөембикә, яки Казанның буйсындырылуы» әсәрендә ханбикәнең җавапсыз мәхәббәтеннән соң, аннан ваз кичкән Асталон да: «Любовь есть слабых душ ничтожная мечта!» дигән иде. Рус авторлары тарафыннан язылган классицизм әсәрләрендә дәүләтчелек мәнфәгатьләрен өстен күреп, якыннарына – хатынына, баласына карата ярату хисләрен кире каккан Иоанн патша образы һәм аңа контраст рәвештә мәхәббәт хисләренә бирелеп, тәхетен, халкын оныткан, хәтта аны һәлакәткә дучар иткән ханбикә образы белән без еш очрашкан идек. Диаспорадагы татар авторлары әсәрләрендә, бу очракта И.В.Нәүрүзхан романында, бөтенләй икенче яссылыкта – Ватанына һәм милләтенә

сүнмәс һәм үлмәс мәхәббәт белән яшәгән, аның иминлеге һәм бөтенлеге өчен җанын да фида кылырга әзер торучы Сөембикә образы иҗат ителә.

Нәүрүзхан романында сурәтләнгән төркиләр инде элеккеге төсле бердәм түгелләр. Татар ханлыклары арасында үзара дуслык какшаган, Казан ханлыгы өстендә мәет эзләүче козгын өерләре төсле урыслар шаулашкан еллар бу. Төрки бердәмлекне ныгыту, ватанын, халкын саклап калу өчен Сөембикә Җангалигә кияүгә чыгарга ризалык бирә. Казанга китәр алдыннан атасына ант итә: «Сүз бирәм, сез кәнагәть калачаксыз. Халкымның миңа ихтыяҗы бар икән, мин тәкъдимне кабул итәм. Соңгы көнемә тикле шул юлда тырышачагыма, Ватанымның иминлеге, милләтемнең бәхете өчен, кирәк булса үлү, хәтта үтерү алдында да тукталып калмаячагыма сезнең алда ант бирәм. Тик шуны гына телим, мин китерәчәк бу кечкенә генә корбан ул зур һәм мәшһүр илне, ул изге идеалларны коткарып калырга җитәрлек булсын иде» (24 б.). Гомеренең соңгы көннәренә кадәр Сөембикә антына һәм әйткән сүзләренә турылыклы булып кала. Күргәнебезчә, монда Сөембикә, классицизм әдәбияты геройларына хас булганча, үз шәхси бәхете турында уйламыйча, беренче чиратта илнең бәхете өчен кайгыртачагы, үзен корбан итүдән дә тукталып, куркып калмаячагы турында ант итә.

Казан ханы Җангали урысларга җаны-тәне белән бирелгән бер зат булып чыга. Хәер, шулай буласын белеп килә бит Сөембикә Казан каласына. Хан Сөембикәгә карачылар теләге, алар тарафыннан хуп күрелеп, сайланып алынганга өйләнгән иде: «Чөнки нугайларның иң дәрәҗәле һәм иң йогынтылы кешеләреннән саналган Йосыф морзаны кулга төшерү – ихтимал булган куркынычлар алдында аның ярдәменә таяну мөмкинлеген тәэмин итә» (35 б.). Кенәз Василий III дә бу никахны уңай күрә, чөнки ул бу никах ярдәмендә «Сөембикәне дә үз кулында тотарга һәм аны бик куркытып торган нугайларның үзенә яхшы карашын яуларга өметләнә» (35 б.).

Яшь килен Сөембикә мәхәббәттә дә, дәүләт эшләрендә дә ире Җангали белән уртак тел таба алмый. Хан кәеф-сафа корудан, бөек кенәз җибәреп торган рус кызлары белән типтерүдән, рус воеводалары белән күңел ачу, бәйрәм итүдән бушамый. Сөембикә исә кайчандыр Гәүһәршад үзе белән Казанга алып килгән китапларны уку, Казан тарихын өйрәнү белән көннәрен уздыра. Шулай ук «бер яктан сарайны өйрәнергә, икенче яктан, андагы игътибарга лаек кешеләр белән танышырга тырыша» (37 б.). Олугъ карачы Сөембикә турында: «Яшь кенә булса да, милли хис бик тирән үзендә, һәрнәрсә турында тирән фикер йөртә. Нәкъ этисе кызы инде» (43.б.) дигән уңай бәяләмә бирә. Сөембикә белән очрашуга килгән русларның Казандагы вәкиле кенәз Морозов һәм Җангалинең киңәшчесе Пинков-Боруславский да Сөембикәнең матурлыгына, акылына соклану белән бергә, анда төрки дәүләтчелек хисләре көчле булуга игътибар итәләр: «ата-бабаларына лаек, төркиләргә хас вәкарь кыяфәттә» басып торган ханбикә гүзәллеге һәм зирәклеге белән аларны да таң калдыра. Бөек кенәзгә язган хатларында алар: «Бу краличе[5] яше белән бер баланы, белеме

[5] Краличе – королева (романны тәрҗемә иткән Рәис Сабиров искәрмәсе).

белән укымышлы дин әһелен, зирәклеге белән шайтанны, гүзәллеге белән фәрештәне хәтерләтә. Яшь кенә булуына карамастан, үзенә карата гадәттән тыш ихтирам уяту сәләтенә ия. Хан белән икесен чагыштырып караганда, шәхесне урын түгел, урынны шәхес бизи икәнлегенә инанмау мөмкин түгел. Ул үз вакытына күрә бик кыю милләтче. Үз милләтеннән булмаганнарны түбән итеп күрә, үзенең төркилеге белән горурланучы кеше күренә. «Төрки булырга кирәк» дип әйтергә теләве һәр хәрәкәтеннән сизелеп тора. Әгәр хәзердән үк чарасын күрмәсәк, бу хатынның киләчәктә безнең өчен бик куркыныч затка әверелүе ихтимал», дип хәбәр итәләр (36 б.). Дошман тарафдарлары рәтендә тасвирланган геройларның да Сөембикәнең төрки җанлы милләтче икәнлегенә басым ясаулары Нәүрүзхан романының классицизм принципларына корылу турында сөйли.

Җангалинең гел урыслар белән буталуы, ханлыкта чит гаскәрләр йөрүе Сөембикәне бик тә борчый. Шулай да ул Җангалигә кияүгә чыгуы белән үзен бәхетле дип саный. Сөембикәнең бәхете, аның «бар теләгәне – милләтенең бәхете, ватанының иминлеге». Ханбикә үзенең вазифасын ханга тәэсир итүдә, хан сәясәтен Мәскәү коллыгыннан арындырып, милләт мәнфәгатенә таба юнәлдерүдә күрә. Җангали өчен хан булу – ул «һәркемнән өстен булып, һәркемнән рәхәтрәк яшәү өчен, меңнәрчә кешене үз кәефемә эшләтү өчен. Җаным теләсә, кояшны сүндерү, күңелемә хуш килмәсә, давылны туктату мөмкинлегем булсын өчен» (41 б.). Сөембикә фикерләвендә исә, «хан – бөтен барлыгы белән милләтенә бирелгән җан дигән»не аңлата. Җангали белән Сөембикә арасындагы бу фикри каршылык рухи каршылыкка сәбәп була. Автор раславынча, үзгәрешсез калган тәкъдирдә Сөембикә Җангалине юлдан алып ташлау ихтималын да бөтенләй үк чит итми, бу мәсьәләдә башкалар фикеренә кушыла[6]. Сөембикә: «Инде бүген дә иманга китерә алмасам, үләргә генә кала», ди (53 б.). Халкы мәнфәгатьләре өчен тол калачагы уена килү белән ул кайгыга төшә. Тол калу, аныңча, хатын-кыз өчен һич ярамаган бер халәт. Шулай да: «Ватан гына тол калмасын. Мин корбан булсам да, Ватан ханлы булачак», дип үз-үзен юата (53 б.). Күренә ки, Сөембикәнең рухы нык, ул авырлыкларга бирешми, Ватанының иминлеге өчен җанын да фида кылырга әзер тора. Мәгълүм булганча, классицизм геройлары өчен турысызыклылык хас. Нәүрүзханның һәрьяктан камил бер образ итеп сурәтләгән Сөембикәсе дә бу берьяклылыктан азат түгел. Табигый хисләрен акылга буйсындырган ханбикә бары тик бер юнәлештә – Казан ханлыгының иминлеген рус баскынчыларыннан саклап калу турында гына уйлый.

Вакытлар үтү белән Җангали хан үзенең сараенда яшәгән Сөембикәгә – сылу хатынга игътибар итә башлый, тиздән бикәгә гашыйк та була. Сөембикәнең тиңсез гүзәллеге, акылы, миллилеге Җангалине үзенә җәлеп итә. Ләкин чын мәгънәсендә Сөембикәне үзенә каратыр өчен аңа рус воеводаларын Казаннан куып чыгарырга, «чит ил гаскәриләренең шәһәрдә йөрүенә» чик куярга кирәк була. Сөембикә ярдәмендә Җангали русларның кем булуларын, «дустым дип санап йөргән кенәз һәм аның кешеләре»нең чын йөзләрен таный. Соң булса да,

---

[6] Хатипов Ф. Романнарда – Сөембикә образы // Казан утлары. – 1993. – №3. – Б. 154.

Җангали Сөембикәнең «дошман сезне солтан иткән икән, ул моны үзенә олтан кирәк булган өчен генә эшләгән», дигән сүзләрендә никадәр хакыйкать ятканлыгын аңлый башлый. Сөембикәнең ягымлы карашы, җылы сүзләре тәэсирендә Җангали хан киңәшчесе һәм дусты дип саналган Пинковны юк итүгә бара. Ләкин Казанның атаклы бәкләре, морзалары, угланнары яшь ханның руслар белән уңышсыз сәясәт алып баруын өнәмиләр, аны Булат бәктән үтертәләр.

Сафагәрәй хатыны булгач та, Сөембикәнең ханлык белән идарә итүдәге роле, дәүләтнең эчке һәм тышкы сәясәтенә тәэсире тагы да көчәя. Хатын-кызның, бигрәк тә Сөембикә кебек милләт анасының, җәмгыятьтә уйнаган ролен әйтеп бетергесез зур бәяли автор. Казанга хан булып килгән Сафагәрәй дә Сөембикәне беренче күрүендә үк, «Чыннан да, ханбикә булырга лаек бер хатын бу: үзе чибәр, үзе мәһабәт, үзе укымышлы-белемле» диюдән тыелып кала алмый. Җангали хатыны булып ике ел Казанда торган чагында Сөембикә халык арасында мәрхәмәтлелеге белән таныла, эш-гамәлләре белән халык күңеленә кереп кала. Ул «һәрвакыт фәкыйрьләргә, ятимнәргә кием-салым, ашау-эчү өләшә; күп балалы гаиләләрдән налогны азрак алырга дип тәкъдим кертә; килгәненә ике ел булыр-булмас, мәктәбе булмаган авылны калдырмый; Казанның үзендә дә зур мәчет һәм мәдрәсә салдырачак имеш» (65 б.).

Сөембикә ире Сафагәрәй ханга да акыллы киңәшләре, урынлы фикерләре белән һәрдаим ярдәм итә. Русларга каршы сугышта батырлык күрсәтүләре өчен гаскәриләргә бүләкләр таратырга – бер айлык хезмәт хакы бирергә, ә башлыкларына тун кидерергә куша.

Сөембикәнең халык, гаскәриләр тормышындагы әһәмиятле социаль мәсьәләләрне бу рәвешчә уңай хәл итәргә тырышуы, халыкның рухи-мәдәни яшәеше турында кайгыртучанлык күрсәтүе, мәктәп-мәчетләр салдыруы аны мәгърифәтчелек реализмы геройларына якынайта. Бер үк вакытта иҗтимагый тирәлек белән береккән эшлекле актив герой классицизм әдәбияты өчен дә чит түгел. Ханбикәнең барлык эш-гамәлләре дәүләтчелекне ныгытуга, аның эчке иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Күренә ки, бу очракта Нәүрүзханның Сөембикәсе, классицизм әдәбияты каһарманнарыча, дәүләтчелекне ныгыту, халык һәм гаскәриләр мәнфәгатьләрен кайгырту күзлегеннән фикер йөртә.

И.В.Нәүрүзхан, XX гасыр башы татар мәгърифәтче әдипләре традицияләрен дәвам итеп, Сөембикә образы мисалында хатын-кызның гаиләви һәм җәмгыяви тормышта тоткан урыны, милләт язмышын хәл итүдә хатын-кыз һәм аналарның роле мәсьәләсенә дә тукталып китә. Автор уенча, хатын-кызның җәмгыятьтәге беренче бурычы – акыллы, милли җанлы балалар тәрбияләү. Шуңа күрә И.В.Нәүрүзхан «Бала – гаиләнең көзгесе» дип яза, баланың ата-ана юанычы булып кына кылмыйча, милләт һәм җәмгыять тормышы өчен файдалы шәхесләр тәрбияләүне максат итеп куя. Бу фикерне автор Сөембикәнең атасы Йосыф морза өендә алган тәрбия аша һәм ханбикәнең үз улы Үтәмешгәрәйгә биргән милли һәм дини тәрбия мисалында укучы аңына җиткерергә тырыша.

Нәүрүзхан Сөембикәне милли тәрбия алган ана буларак сурәтли. Сөембикә

Үтәмешгәрәйнең «тәрбиясен һичкемгә ышанмыйча, бар нәрсә белән дә үзе шөгыльләнә». Баласының кечкенә генә уңышлары өчен шатланган, куанган бикә «калалар яулаган бер баһадирдай, үз-үзеннән канәгать хәлдә баласын күкрәгенә кыса» (79 б). Ул баласын «Иң элек Тәңрене, пәйгамбәрләрне, аннары илемне, аннары әтиемне, аннары инде әниемне» ярат дип өйрәтә (80 б.). Бала чактан ук Сөембикә улын илен яратырга, кирәк булса, аның иминлеге һәм бөтенлеге өчен көрәшергә әзер булырлык шәхес итеп тәрбияләргә тырыша. Автор бала тәрбиясе турындагы мәгърифәтчел карашларының тамырларын классицизм әдәбиятындагыча дәүләтчелек идеяләренә буйсындыра.

Казан ханлыгына килен булып төшү белән Сөембикә хан сайлау гадәтен бетереп ташларга тырыша. Сафагәрәй хан улы Үтәмешгәрәйнең тәхет варисы итеп билгеләнүе өчен карачылар җыелышында карар кабул иттерә. Сабый вакытыннан ук Сөембикә үз улын хөкемдар булырга әзерли, аны тәхет варисы итеп игълан иттерергә ниятләнә (80 б.). Аныңча, Казан ханлыгы тәхетенә төрле төрки ханлыкларыннан хан китертү һәм аны сайлап кую эше үзе генә дә дәүләтнең йомшаруына, иминлеге какшавына, бәйсезлеге зәгыйфьләнүгә, үзләрен Алтын Урда варислары дип санаган Мәскәү кенәзләренең Казан ханлыгы эшләренә бертуктаусыз тыкшынуларына сәбәп була. Тәхеткә «хан күтәрү» уңае белән туган ыгы-зыгылар ханлыкның бәйсезлеген зәгыйфьләндергән. Тарихи вакыйгаләр агышына тискәре йогынты ясап торган хан сайлап кую тәртибен үзгәртү, яңарту кирәклеген Сөембикә яхшы аңлаган. Чөнки Казан ханлыгы тәхете тирәсендә барган алыш-бирешләр, тартышлар, сугышлар – моңа ачык мисал. Шуңа күрә булса кирәк, язучы романга классицистларча төрки халыкларның дәүләтчелеген ныгытуга бәйле төрледән-төрле фикерләр кертеп җибәрә.

«Сөембикә» романы – чит мәмләкәттә, туган-үскән туфрактан еракта, үзенең милли тамырларыннан аерылып яшәгән татарлар өчен язылган әсәр. Шул сәбәпле, күрәсең, кысалы кыйсса алымына мөрәҗәгать итеп, Нәүрүзхан әсәрнең милли тәрбияви ягын бик тә көчәйтә. Шул ният белән ул Сөембикә турындагы әсәр тукымасына Гәүһәршад бикә, Сәхибгәрәй хан, Олуг Мөхәммәд ханнар турында кечерәк тарихи хикәяләр дә урнаштыра. Тарих эчендә бирелгән тарихлар яшь буынга Казан ханлыгында яшәгән милли каһарманнарны һәм мәшһүр ханнарны белеп тору кирәклеген күздә тотып сөйләнелә.

Шунысы да игътибарны җәлеп итә, Алтын Урда, Нугай, Кырым, Казан ханлыклары – боларның барысы да гомумтөрки тарих. Шул рәвешчә, И.В.Нәүрүзхан әсәрендә уртак тарих идеясенә нигезләнгән гомумтөркичелек карашлары да чагылыш таба. Ул төркиләрне «үзе яшел, ботаклы-ябалдаклы, очлары күккә ашкан, тамырларын тирәнгә җибәргән» (23 б.) бер өянке агачы белән чагыштыра. Бу гади генә тоелган чагыштыруга Нәүрүзхан борынгы төркиләрнең яшәү рәвешен чагылдырган «яшел» архетибын да, ягъни яшел дала буенча көтүләрен утлатып, күчеп йөрүче борынгы төркиләр (күк төркиләр) образын да кертеп җибәрә. С.Рәмиевнең «Таң вакыты» шигырендәге тирән тамырлы, яфраклары белән дөньяны каплаган олы көүсәле, символик эчтәлекле агач образын таный алмаслык итеп үзгәртеп, реминисценция рәвешендә иҗади файдалана. Бәлки авторга Г.Ибраһимовның «Тирән

тамырлар» әсәрендә гәүдәләнеш алган, өлкән ботаклары, хисапсыз каты яфраклары, калын, озын тамырлары тирәнгә киткән юан карт имән образы да таныш булгандыр.

Хикәяләү барышында Нәүрүзхан еш кына төркиләр тарихына үз бәясен биреп барган. Автор төркиләрнең бөек, көчле агачының «эчен кортлар кимерә» дип борчыла. Кемнәр бу кортлар? Күрше «рус туганнар»мы?. Әллә төрки дөньяның таркау хәлдә яшәвеме? Язучы боларның икесен дә күздән ычкындырмый. Нәүрүзхан төрки агачның эче милли тойгылар, үзара бердәмлек, татулык кебек хисләр, уй-фикерләр белән баетылган булырга тиеш дип исәпли.

Сафагәрәй хан исән вакытта Казанны «какшаткан-тетрәткән, куркыныч астына куйган, дошманга кыюлык биргән» төрле төркем-фиркаләрнең ызгышына каршы көрәшеп килә. Үләр алдыннан хатыны Сөембикәгә «төркемчелеккә юл куйма» дигән васыять әйтеп калдыра.

Сафагәрәй үлгәннән соң, Сөембикә улы Үтәмешгәрәй белән Казан тәхетенә утыра. Сөембикә тәхетне һич ятсынмый, кешеләр белән сөйләшкәндә һич кенә дә һаваланмый, үзен гади һәм иркен тота, каушамый-каударланмый (89 б.). Ул Казан «тәхетенә менгән беренче хатын-кыз» булып, «башындагы алтын таҗ аңа бик килешеп тора».

Автор Сөембикәне урысларга карата бик тә нәфрәтле, үчле хатын итеп тасвирлый. Мәҗлес әгъзалары алдында тоткан нотыгында да ул төрки-татарларның каннарын түккәне өчен руслардан үч алырга өнди. «Җирләребезгә хуҗа булырга теләүче кан коючыларны үз каннарына батырып үтерү» Сөембикә өчен изге бурыч булып тора. Рус язучысы А.Н.Грузинцевның 1810 елда язылган «Покоренная Казань, или Милосердие Царя Иоанна Васильевича IV, проименованного Грозным» әсәрендә ханбикәнең бу сыйфатына басым ясалган иде. А.Н.Грузинцевның классицизм рухында язылган трагедиясендә үлгән ире Сафагәрәй, шәһит киткән туганнарының рухлары, хәтта җимерелгән тәхет тә Сөембикәне үч алырга чакыра. Ул үзен йә тәхеттә, йә табутта булырга тиеш дип кенә күзаллый; үлсәм дә Россия дигән илнең терәген – Иоанны үзем белән бергә өстерәп мәңгелек дип аталган караңгылык дөньясына алып китәм, ди. Иоанн күкрәгенә нәфрәтле хәнҗәр кадау – Сөембикә өчен изге гамәл. Дәүләтчелекне саклап калу идеаллары белән сугарылган шуңа охшаш фикерләр Нәүрүзхан романында да гәүдәләнә. Аның да Сөембикәсе, классицизм әдәбиятындагыча, сәяси омтылышларны гәүдәләндерүче уңай каһарман буларак югары куелган.

Рус телендә язылган әсәрләрдә рус-татар каршылыгы аерым шәхесләр – Сөембикә һәм Иван, Сөембикә һәм Алей мөнәсәбәтләре, алар арасындагы конфликт яссылыгында бирелгән иде. И.В.Нәүрүзхан әсәрендә исә, Сөембикә – бөтен милләт язмышы өчен җаваплы хөкемдар. Сөембикәнең үз ватаны бөтенлеген һәм сәгадәте турында яклап әйткән милли рухлы чыгышына «йөзләрчә аксөякләр, аягүрә баскан килеш башларын иеп, чын йөрәктән килгән бер ихтирам белән ханнарын (Сөембикәне. – *И.Р.*) сәламлиләр» (90 б.).

Нәүрүзхан романының буеннан-буена Сөембикә образы идеаллаштырып бирелә. Ул Казан ханлыгының иҗтимагый-сәяси тормышы белән берегеп яши, авыр хәлләрдә дә сәяси-әхлакый югарылыкта кала. Ә менә тәхет тирәсендәге аксөякләр автор тарафыннан каршылыклы, төгәлрәк әйткәндә, тормышчанрак итеп сурәтләнәләр. Алар Сөембикәнең акыллы, милли-патриотик чыгышын аягүрә басып тыңласалар, аның гүзәллегеннән әсәрләнеп, тән мәхәббәте турында уйлый башлыйлар.

Сөембикәнең гаҗәеп гүзәллеге, «үз дәрәҗәсенә лаек вәкарь бер кыяфәте» мәҗлес әгъзаларын таң калдыра. Бәкләр, морзалар Сөембикәне бик ошаталар, «башка хатын-кызлардан өстен саныйлар». Шул ук вакытта аның «башындагы алмазлы таҗның, зиннәтле тәхетнең балкышы күңелләрендә җанлану белән, хыяллары хәрәкәткә килә дә, хыял хирысны уята, алар шушы хирыска биреләләр, башларында аны фина итү (якынлык кылу. – *И.Р.*) теләге уяна» (90 б.).

Бу уңайдан шуны да искәртергә кирәк, Нәүрүзхан сурәтләгән аксөяк геройлар дәүләтчелек идеяләре белән генә яшәүчеләр түгел. Алар Сөембикәне акылы, миллилеге өчен хөрмәт тә итәләр, аңа булган хирысларын да яшермиләр. Кыскасы, автор аксөякләрнең акыллары белән хисләрен бер-берсен» каршы куеп, күпмедер дәрәҗәдә әсәрдәге психологик кичерешләрне дә куерта. Аксөяк образларын турысызык буенча гәүдәләндерүдән баш тарту классицизм өчен дә, мәгърифәтчелек реализмы өчен дә хас күренеш.

Төркиядә яшәгән һәм иҗат иткән Нәүрүзханның «Сөембикә» тарихи романына рус авторлары әсәрләреның тәэсире булуы турында да искәртергә кирәктер. Хикәяләү барышында ул кайсыбер рус авторларын, аерым алганда, Нырков белән Глинканы искә алып үтә. Патша сараенда Сөембикәнең килүен көтеп торучылар үзара сөйләшкәндә рус авторларының Казан ханбикәсе турында әсәрләр иҗат итүләрен телгә алалар. Алар: «Нырков белән Глинканың үз әсәрләрендә аңа туктаучыз мәдхия укулары тикмәгә түгелдер» (104 б.), диләр. Бу очракта Нәүрүзхан беркадәр төгәлсезлек тә җибәрә. Чөнки бу телгә алынган рус авторларының әсәрләре Сөембикә әсир ителеп Мәскәүгә китерелгәннән соң, өч гасыр үткәч кенә язылалар бит. Ләкин шулай да бу факт авторның рус телендә Сөембикә турында иҗат ителгән әсәрләр белән күпмедер дәрәҗәдә таныш булуын дәлилли.

Нәүрүзхан романында Сөембикәнең илтифатын үзләренә җәлеп итә алмаган аксөякләрнең бер төркеме аның дошманнарына әверелә. Алар арасында Сөембикәнең «үзенә генә түгел, ул ярата торган һәрнәрсәгә дошман булып» китүчеләр барлыкка килә. Ахыр чиктә Казан тәхете тирәсендә өч төркем оеша:

Беренчесе – «Сафагәрәйнең изгелеген онытмыйча, аның хатирәсен исләрендә саклаучылар», ханбикәгә тугрылыклы кешеләр.

Икенчесе – Сөембикәне «бик тә яраткан хәлдә, дошман явыннан куркып, көчлерәк булу нияте белән солтан Сөләйманнан яңа бер хан җибәрүен үтенергә ниятләүчеләр».

Өченчеләр – «омтылыш-хирыслары тормышка ашмаганлыктан дошман булучылар» һәм Сөембикәгә «каршы бер фронт оештыручылар». Болар арасында Булат бәк тә булып, ул

бикәне бәреп төшерү өчен урыслар белән бәйләнешкә керә.

Һади Атласи кебек үк, Нәүрүзхан да Казан ханлыгын һәлакәткә китергән сәбәпләрнең иң куркынычлысы итеп төркиләр һәм Казан ханлыгының үз эчендә бердәмлек, татулык булмауны атый. Шуңа күрә автор хикәяләү барышында турыдан-туры үз мәнфәгатьләрен генә күздә тотып, ил һәм халык язмышы турында уйларга теләмәүчеләрне, бердәм көч булып русларга каршы тора алмауны, төрле фирка-партияләрнең үз эчләрендә урын алган таркаулыкны, үзара уртак тел таба алмауларын тәнкыйтьләп чыга.

Эчке һәм тышкы дошманнарга каршы көрәшнең авыр вакытларында Сөембикәгә ярдәм кулын Кошчак суза. Кырымнан килгән дип исәпләнгән, ләкин нинди нәсел-ырудан булуы билгеле булмаган бу аксөякне Сөембикә беренче мәртәбә мәҗлестә күрә. Карашларның очрашуы Сөембикәне сискәндереп җибәрә. Бу очрашу ханбикәнең яшьлегендәге Исмәгыйль морза улына булган беренче мәхәббәте хисләрен, «башлар әйләнү кебек халәтен» исенә төшерә. Бу хатирәләрдән аның «бөтен тәнен-гәүдәсен ут чолгап алган кебек була, күңеле вәсвәсәләнә» (91 б.). Уналты ел элек, дәүләт һәм халык мәнфәгатьләре бәрабәренә Сөембикә Сафагәрәйгә яратып кияүгә чыкса да, чын мәгънәсендә аңа гашыйк булмаганын аңлый. Сафагәрәй хан Сөембикәне «күңеленең җаны, тамырларының каны» дип атаса да, ханбикә күңелендә яшьлек гыйшкы еллар дәвамында Сөембикә йөрәгендә сүнми-сүрелми сакланып килгән икән.

Ләкин кинәт кенә кабынып киткән бу мәхәббәт хисләренең дәвамы юк. Бу очракта да автор ханлык һәм халык мәнфәгатьләрен өстен куя: Кошчак Сөембикәнең уң кулы һәм ярдәмчесе итеп билгеләнә. Русларның 1550 елгы явы вакытында баш командирлык вазифаларын үтәгән Кошчак Казан каласын дошманнан саклап калуда зур батырлыклар күрсәтә, русларны татарлар яшәгән җирләрдән куып җибәрә. Бу очракта да Нәүрүзхан тарихи дөреслектән читкә китми. Кошчак угланның бу сугышта күрсәткән батырлыклары аның замандашы, дин әһеле, тарихчы һәм шагыйрь Х.Шәрифинең «Зафәрнамәи виляйәт-и Казан» (1550) исемле ярым әдәби, ярым документаль әсәрендә теркәлеп калган. Төрек солтаны Сөләйман Канунига юлланган бу әсәрдә Казан ханлыгындагы Мамай бәк, Нур Али мирза, Ак Мөхәммәд углан, Кол Мөхәммәд Сәет, Кошчак углан, Бибарс бәк кебек күренекле шәхесләрнең русларга каршы сугышта күрсәткән батырлыклары турында бәян ителә. Хан капкасы сагында торган Кошчак углан «яу кырындагы турылыклы дус», «батырлык сәнгате арысланы» дип бәяләнә: «Тагын Хан Морҗалыйдагы [7] кала капкасында баһадирлык мәйданының сафдары, егетлек сәнгатенең арысланы Кузыйчак углан, кадере артсын…»[8]. Шигъри юлларда Кошчакның сугыш фәне остасы һәм талантлы хәрби җитәкче булуына да басым ясала: «Он, мастер своего дела, взял к себе молодежь и истинных храбрецов»[9]. Моннан тыш Х.Шәрифи мәдхияне хәтерләткән шигъри юлларда Кошчакның 1550 елдагы

---

[7] Хан Морҗалый. – Хан капкасы (Марсель Әхмәтҗанов искәрмәсе).

[8] Шәриф Хаҗитархани. Казан вилаятенең җиңүе // Идел. – 1995. – №1.

[9] Шерифи Х. Зафернамеи виляйет-и Казан // Эхо веков. – 1995. – май. – С.89. «Эхо веков» журналында рус телендә китерелгән өзек тулырак булу сәбәпле, мисаллар рус телендә китерелә.

русларга каршы яуда күрсәткән каһарманлыкларын ислам динен тарату өчен алып барылган сугышларда атаклы хәрби җитәкче буларак танылган Мөхәммәд пәйгамбәр кияве баһадир Гали (Али) һәм аның сихерле үткен кылычызөлфикяр белән чагыштыра:

Каждый во время битвы с врагом,

Ощутит в себе веру в саблю ислама.

Это же всего раз в жизни человека:

«Муж мужей есть Али, самый острый из саблей есть

Зульфикар».

Казан өстендә кара болытлар куерганнан-куера бара. Руслар белән тагын бер зур көч сынашу булачагын алдан сизенгән ханбикә гаскәрне һәм халыкны сугышка әзерли башлый: «гаскәрне ныклы өйрәнүләр алып барсыннар өчен әмерләр бирә; өйрәнү бүлмәләрен, корал саклау урыннарын үзе тикшереп чыга; туплар азрак дигән нәтиҗәгә килеп, яңаларын табу-китерү чараларын әзерли. Нугай иленә, әтисе янына җайдаклар җибәрә, Кырымга да хәбәр сала» (99 б.).

Казан ханлыгының бәйсезлегенә куркыныч янаган бу көннәрдә Сөембикә ярдәм сорап төрек солтаны Сөләйман Канунига мөрәҗәгать итә. Бу үтенеч белән ерак сәфәргә Кошчак углан җибәрелә: «Тик аның (Сөләйман Кануни. – *И.Р.*) тимердәй каты кулы гына дәрәҗәгә хирыс булган бу ахмакларны тончыктыра алачак та, тик аның җиңелү белмәс гаскәре генә Казанны һәлакәттән коткара алачак (97 б.).

Казан ханлыгының сарай гвардиясе башлыгы Кошчак угланның Казаннан китү сәбәпләре тарихи чыганакларда, фәнни-публицистик әдәбиятта төрлечә аңлатыла. Берәүләр аны Казан өчен иң авыр вакытта шәһәрдән качып китүдә гаеплиләр, икенчеләр китәргә мәҗбүр булуның сәбәпләре тирәндәрәк ятуга ишарәлиләр. Нәүрүзхан Кошчак угланның Казаннан китү сәбәпләрен үзенчә аңлата – Сөембикә Кошчакны олы бер миссия белән Сөләйман Кануни янына Төркиягә җибәрә. Явыз Иван Сөембикәнең руслар кулына бирелүен катгый шарт итеп куйган дип искәртә Г.Н.Моисеева «Казанская царица Сююн-бике и Сумбека «Казанской истории» дигән мәкаләсендә: «Можно полагать, что крымцы и Сумбека были обвинены в чем-то очень серьезном, если только при условии их выдачи Иван Грозный мог согласиться на мирные переговоры. Есть основания думать, что этим общим делом Сумбеки и крымцев была связь Казани с Турцией в надежде получить от нее помощь для борьбы с Русским государством»[10]. Моңа охшаш фикерне икенче бер рус галиме В.М.Жирмунский да үзенең «Ногайские дела» дип аталган хезмәтендә язып чыга: «В эту коалицию мусульманских государств под главенством Турции должны были войти все татарские ханства, которым угрожает наступление Москвы: Казань, Астрахань, Крым, ногайцы. …послы «Турского султана», прибывшие к Юсуфу и Исмаилу, выдвигают широкую политическую программу

[10] Моисеева Г.Н. Казанская царица Сююн-Бике и Сумбека «Казанской истории» // ТОДРЛ. – М.-Л.: АН СССР. – 1956. – Т.12. – С.181.

своеобразного панисламизма и пантюркизма»[11]. Тарихтан күренгәнчә, бу төрки коалиция төзелмичә кала. Бу төрки бердәмлекне булдырмау өчен руслар күп кенә көч тә куялар: берәүләрен сатып алып, икенчеләрен алдалап, өченчеләрен юмалап, Казанның үз эчендә дә, төрки кавемнәр арасында да таркаулык, фетнәчелек орлыгын чәчәләр.

Хәзерлек эшләре тәмамланмаган, беркемнән ярдәм килеп өлгермәгән бер вакытта хисапсыз сугышчылары, «кораллар төялгән арбалары, туплар, герман тупчылары, ауропалы инженерлары» (99 б.) булган рус гаскәре Казан янына килеп туктый. Казанда татар гаскәрләре белән җитәкчелек итәрлек, рус көчләренә каршы сугыш белән җитәкчелек итә алырлык бер кеше дә табылмый. Барчасы да «урысларга каршы тора алмаячакбыз, бирелергә кирәк», дигән фикерне кабатлый (99 б.).

Сөембикә янына улы Үтәмешгәрәй белән бергә әсир төшү тәкъдиме белән урыс патшасы Иваннан илче булып кенәз Серебряный килә. Ул: «әгәр әсир төшәргә риза булсагыз, урыс гаскәрләре Казанга орынмыйча, кире чигенәчәк», дигән вәгъдә бирә. Сөембикә исә тагын каршылыклы уй-фикерләр алдында кала. Нәүрүзхан фикеренчә, Мәскәү патшасының «тәкъдимен кабул итсә, үзе һәм улы дошманга әсир төшәчәк, кире какса, баш тартса – йөз меңнәрчә кешенең каны түгеләчәк. Бизмәннең бер ягына әсирлек, икенче ягына милләтнең каны салынган иде» (100 б.). Еллар буе, кече яшьтән үк милләт һәм дәүләт мәнфәгатьләрен үзенекеннән күпкә өстен куеп килгән Сөембикәдә бу юлы да «шулкадәр җан иясен коткарып кала алу» мөмкинлеге фикере җиңеп чыга. Ул үзенең иң явыз дошманы булган рус патшасы кулына әсир төшәргә ризалык бирә.

Сөембикәнең «елый-елый Тәңрегә ялварулары», ире Сафагәрәй кабере янында үзен-үзе белештермичә үрсәләнеп елау-сыктаулары, Казан халкының кычкырып-үкереп елый-елый ханбикәләре белән саубуллашу тасвирлары И.В.Нәүрүзхан әсәренең Һади Атласиның «Сөембикә» романы тәэсирендә язылган булуына да ишарәли. Белгәнебезчә, Һади Атласи әсәрендә тарихи вакыйгаләрне бәян итүдә һәм Сөембикә образын тудыруда документальлек, ягъни рус тарихи чыганаклары, «Казан тарихы» әсәре белән мөмкин булган кадәр тәңгәллек саклана. И.В.Нәүрүзхан әсәрендә исә матур әдәбият кануннары җиңеп чыга. Автор эмоциональ-экспрессив чаралар, гиперболага корылган образ-сурәтләр ярдәмендә Сөембикә ханбикәнең Казаннан китү фаҗигасен тагы да көчәйтә, тагы да тәэсирле итә алуга ирешә. Сөембикә «әсир төшеп, дошман сараенда яшәүгә караганда» «үз ватанының каберендә ятуны артыграк күрә» (101 б.). Беркемгә ышанычы, таянычы калмаган ханбикә «кабер туфрагына тырнакларын батырып, кабер ташын күтәрергә тырыша» (102 б.). Ире кабере өстендә елый-елый хәле беткән Сөембикәнең «чәчләре тузгыган-йолкынган, күлмәк итәгенең алды теткәләнеп, телгәләнеп бетә» (102 б.). «Үз җаны кебек яраткан» ватаны һәм халкы белән саубуллашу, аларны соңгы тапкыр күрү хәсрәтеннән Сөембикәнең «нуры качкан, тоныклангын күзләреннән» бертуктаусыз «бер-берсе белән узышкандай» күз яшьләре ага.

---

[11] Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. – Л.: Наука, 1974. – С.458.

Сөекле ханбикәләре китү хәсрәтеннән бөтен Казан халкы «чәчләрен, сакалларын йолкый-йолкый, күлмәкләрен ерта-ерта, кайберләре бала-чага төсле җирдә аунап, аяклары белән тибенә-тибенә, елый» (103 б.). Җан өзгеч бу моң-зарны табигать тә уртаклашкандай, кушылып елый башлый – «көчле яңгыр башлана». Шулай итеп, «хөрриятнең, таҗның, тәхетнең бикәсе» «бәгыре янган, йөрәге сызлаган» хәлдә «яна-көя, елый-елый» китеп бара. Күренә ки, автор гиперболаларны мул куллану белән беррәттән, сынландыру алымыннан да уңышлы файдалана.

Һади Атласиның тарихи романындагы Сөембикә образы, бер яктан, рус тарихи чыганаклары, «Казан тарихы» әсәренә нигезләнеп, гүзәл хатын, акыллы идарәче, зирәк сәясәтче итеп, икенче яктан, урта гасыр Шәрекъ әдәбияты традицияләре буенча, халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы гадел хөкемдар, кылган гамәлләре кояш нуры белән тиңләшерлек мәрхәмәтле ханбикә итеп тасвирлана. Нәүрүзхан әсәрендәге Сөембикә исә күз карашы белән үк башкалардан үзгә ханбикә. Ул – акыл белән чибәрлекне, хөкемдар вәкарьлелеге белән ана шәфкатьлелеген бер кешедә берләштергән изге зат – милләт анасы образы рәвешендә гәүдәләнә (65 б.).

Нәүрүзхан милләтпәрвәр әдип буларак, Сөембикә образын моңа кадәр күренмәгән илаһи бөеклекләргә күтәрә, аны һәрьяктан идеаль образ итеп сурәтли. Автор Сөембикә образы белән бәйлелектә татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге, аның хатын-кызлары, милли бәйсезлеге һәм мәдәнияте турында уйлана. Аның бу уй-фикерләре романның соңгы битләрендә – Сөембикәнең Мәскәүдә Кремль сараенда Явыз Иван белән очрашуы күренешендә аеруча отышлы гәүдәләнеш таба.

Явыз Иван белән әңгәмә вакытында Сөембикә үзен бик горур тота. Татар ханбикәсенең әсир ителеп Мәскәүгә китерелүе Кремльгә җыелган бөтен русларның «күңелен күтәрә, барысы да канәгать» күренә. Дин башлыгы митрополит Макарий Сөембикәнең көчле хатын булуына таң калып, болай ди: «Акыл җитмәстәй хатын ул. Ир-атның башына да җитмәстәй зур-мөһим планнар корды, хәтта иң тугърылыклы дусларыбызны да урысларның дошманы итте. Менә хәзер инде халкының каны түгелмәсен дип үзен корбан итә» (106 б.). Митрополитның Сөембикә шәхесенә биргән бәяләмәсе Һади Атласиның «Сөембикә» әсәрендә дә бар. Һади Атласи бу фикерне тарихи чыганак вазифасын үтәгән «Никоновская летопись»ка таянып әйтә: «Митрополит Макарий 1552 елның 21 маенда Зөядәге рус башлыкларына язган үгетендә: «Тәңре Тәгалә безнең сөекле падишаһыбыз илә аның христиан динен сөюче гаскәрләренә, һичбер кан түкмәенчә, үзләренең дошманнарыннан өстен булырга, Казан ханлыгын җиңәргә насыйп итте. Казан падишаһысы илә Сөен-бикәне безнең падишаһыбызның кулына бирде»[12]. Дөрестән дә, сәясәт мәйданында шактый оста эш иткән, акыллылыгы һәм зирәклеге белән күпләрне сокландырган Сөембикәнең әсирлеккә озатылуы руслар өчен бик тә зур җиңү була.

Сөембикәнең бу батыр адымына дошманнары да хәйран кала, алар Сөембикәнең

[12] Атласи Һади. Сөембикә. – Казан: Җыен фонды, 1992. – 58 б.

бөеклеген, олы бер зат булуын таныйлар. Ул гади әсир генә түгел, патша Иван әйткәнчә, «мәшһүр әсир». Сөембикә Иван IV белән сөйләшкәндә дә үзен бәйсез һәм кыю тота. Горур Сөембикәнең рухын сындыра алмаячагын аңлаган рус патшасы ханбикәне хатын-кыз буларак түбәнсетергә, аңа баш иеп, ялвару, газаплану, өзгәләнүләрен күрергә тели. Иван Сөембикәдән үч алуның иң мәкерле юлларын сайлый: башта аны улы Үтәмешгәрәйдән аера, ә аннары җаны сөймәгән Шаһгали ханга кияүгә бирә. Ул «бикәнең Шаһгалигә нәфрәт белән караячагын, бу кешегә кияүгә чыгуның ханбикә өчен зур газап һәм җәза булачагын яхшы аңлый, аңа чыкмас өчен патшаның чабуын үбеп ялварачагын күз алдына китереп, кинәнә-шатлана» (107 б.). Ләкин патшаның сөенүе бушка гына була. Мондый карарны ишетү белән бикә берничек тә үзгәрми: «Патшага ялвару турында әйткән да юк, хәтта карышып сүз дә дәшми» (107 б.). Чөнки Сөембикә карышуның файдасыз икәнен белә һәм берсүзсез язмышына буйсына. Ул ашамый, эчми, үз газабы белән туенып тора. Йөрәге сызлавыннан хәтта ачлыгын да сизми. Шулай итеп көннәр үтә, Сөембикә инде авырып түшәк өстендә ята. Барлык дәрт-омтылышлары сүнә, күңеле берни теләмәс була: «Улы хәсрәтеннән Сөембикәнең эче яна, йөрәге сызлый. Дошманына ялвармады, сөекле улының исемен бүтән исенә төшермәскә тырышты» (108 б.). Саргаеп шиңә, ябыгып шәм төсле булып кала. Үләр алдыннан Сөембикә янына Үтәмешгәрәйне китерәләр. Әмма инде соң була. Баш очында елап басып торган бичара улына бәхетсез Ана соңгы тапкыр булса да күтәрелеп карый алмый, аның күзләре мәңгегә ябыла.

Казан ханлыгының бәйсезлеге өчен соң чиккә кадәр тырышкан, тартышкан, көрәшкән ханбикә Сөембикәнең соңгы көннәрен, ахыр сулышларын үзе дә Төркиядә мөһаҗирлектә гомер кичергән язучы Нәүрүзхан менә шундый йөрәк өзгеч фаҗигале хикәяләү белән тәмамлый.

Нәүрүзханның «Сөембикә» романында татар хатын-кызларының рухи батырлыгына, түземлелегенә, милли җанлы булуларына гаять дәрәҗәдә югары бәя бирелә. Сөембикәләре әсир ителеп Мәскәүгә озатылганда да, алар: «Ханыбызны да, ватаныбызны да без үзебез саклап кала алган булыр идек», – диләр. Явыз Иван, Казанны алу өчен барган сугышлар вакытында, ир-атларның үтерелеп бетүләре турында ишеткәч, хатын-кыз һәм бала-чагаларны юк итәргә боерыклар бирә. «Бу милләтнең хатын-кызлары ирләреннән куркынычрак. Карагыз аны, бер генә хатын-кыз калмасын!», – дип кычкыра ул (116 б.). Казан каласын саклауда татар хатын-кызларының ир-егетләр белән иңгә-иң торып, батырларча сугышулары, һәлак булган ир-ат сугышчыларны алыштырулары турында XVI гасырдагы канлы-дәһшәтле вакыйгаләрнең шаһиты булган «Казан тарихы» авторы да гаҗәпләнү катыш соклану белән түбәндәге сүзләрне язган иде: «...во убитых вместо и избежавших из града, прибираху высокорасленныя жены и девица силныя, и теми число наполняху и множаху и учеваху их копейному бою и стрелбе и битися со стены, и воскладаху на них пансыря и доспехи. Они же яко юноша бияхуся дерзостно, но страшиво естество женские, и мяхко сердце их...» (135 б.).

Бөтен тирә-як ватылып җимерелсә дә, дәүләтләре юк ителсә дә, бөек мәдәнияте, олы шәхесләре булган халыкны үтереп-кисеп кенә бетереп булмый, әлбәттә. Авторның да

халкының якты киләчәгенә өметләре зурдан: «Мондый хатын-кызлары булган милләтне юк итеп була димени? Өстен көчләр ярдәмендә дәүләтләре җиңелсә-җимерелсә дә, аларның миллиятен үтерү мөмкинлеге бармы?» (107 б.).

Нәүрүзхан романының төп каһарманы Сөембикәнең дә бөтен уй-фикере, эш-гамәлләре бары бер олы максатка – ханлыкны саклап калуга, халыкның иминлеген тәэмин итүгә, төрки дәүләтләрнең бердәмлеген булдыруга юнәлтелгән. Моңа ирешүдә ул уңга-сулга чайкалуларны белми, йөрәктә кайнаган табигый җир кешеләренә хас хисләрне онытып, шәхси азатлыкны әсирлеккә алыштырып, милли һәм иҗтимагый идеаллар өчен үзен корбан итә. Дәүләтчелек идеалларының үзәккә куелуы Нәүрүзхан романындагы Сөембикә һәм Казан ханлыгының азатлыгы өчен шәһитләрчә һәлак булган хатын-кыз образларының классицизм әдәбиятындагыча акыл культына буйсындырылып иҗат ителгән дип, нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Нәүрүзхан фикеренчә, татар мәдәнияте хатын-кыз образы аша гәүдәләнеш таба. Ханбикә Сөембикә шәхесенә һәм татар хатын-кызларына бирелгән югары бәя кенәз Серебряный сүзләрендә дә чагыла. Сөембикә, – ди ул, – «бөтен бер милләт кешеләре мәхәббәтенең, рухи бөеклегенең, алар гасырлар буе сөеп-үстереп килгән мәдәниятнең хатын-кыз кыяфәте алган бер гәүдәләнешедер» (104 б.).

«Сөембикә» романының тирән милли хисләр белән сугарылуы, Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген саклап калу өчен руслар белән татарлар арасындагы рәхимсез бәрелешләрне милли һәм дәүләт җанлы Сөембикә образы мисалында онытылмаслык итеп күз алдына китереп бастыруы Нәүрүзханның зур әдәби казанышы булып тора.

Нәүрүзхан Сөембикә образын әле аңа кадәр бер генә рус, татар, төрек язучысы күтәрә алмаган биеклекләргә күтәрә. Ханбикәне автор матурлык алиһәсе, акыл иясе, зирәк сәясәтче, дәүләт белән оста идарә итүче идеаль ханбикә, тарихи шәхес һәм үлемсез Милләт Анасы итеп гәүдәләндерә.

Милли тарихка, милләт язмышына басым ясау, милли тойгыларны, милли хәтерне изгеләштерү, милли мәдәниятне, милли гореф-гадәтләрне яклау, милли тәрбия мәсьәләләренә игътибар итү, Сөембикә образын Милләт Анасы, милли символ, милли байрак дәрәҗәсенә күтәрү Нәүрүзхан романында XIX йөзнең икенче яртысы – XX йөз башы татар мәгърифәтчелек реализмы өчен хас сыйфатларның да калкып чыгуы, көтелмәгәнчә романтик пафос белән яңаруы турында сөйли.

Рус, төрек, татар әдәбиятларындагы Сөембикә турында язылган әсәрләр тезмәсенә күз ташлагач та, аларның һәркайсында үзәктә торучы, каләм әһелләре өчен таяныч һәм этәргеч вазифасын үтәүче берәр күренекле әсәр барлыгы күренә. Рус әдәбиятында ул – «Казан тарихы», XX гасыр башы татар әдәбиятында – Һади Атласиның документаль җирлеккә нигезләнгән «Сөембикә» тарихи романы. Төрек әдәбиятында исә ул – И.В.Нәүрүзханның «Сөембикә» тарихи романы. Бу роман XX гасырдагы Төркия җирлегендә татар яки төрек телләрендә иҗат ителгән бик күп шигырь-поэмалар, тарихи романнар, сәхнә әсәрләре өчен

үрнәк бер өлге вазифасын үти. Нәүрүзхан романына назыйрә рәвешендә Ләбиб Каран Сөембикә ханбикә турында поэма иҗат итә. Нәүрүзханның романы тәэсирендә әдәби әсәрләр генә түгел, хәтта фәнни-публицистик мәкаләләр дә дөнья күрәләр. Безнеңчә, бу йогынтының сәбәбе – әсәрдәге Казан ханлыгы кебек югалган дәүләтчелегебез турындагы тарихи хәтернең һәр татар кешесенең бәгыренә үтәрлек итеп милли хисләр белән үрелеп бирелүендә.

## 2. Төрек вакытлы матбугаты Сөембикә турында

Казан ханлыгы тарихында Сөембикәнең урыны турында Төркиянең вакытлы матбугатында да язмалар, фәнни хезмәтләр басылды. Алар арасында **Мөхәррәм Фәйзи Тугайның «Сөембикә»** мәкаләсе игътибарны җәлеп итә. Ул Икенче бөтендөнья сугышы барган чорда Истанбулда чыккан «Төрек максаты» журналының 1942 елгы 1 нче санында дөнья күрә[13]. Мәкалә фәнни-тарихи аспектта язылып, автор Казан ханлыгы тарихын яктырту белән бергә төрки халыклар тарихына да күзәтү ясый.

Кем ул Мөхәррәм Фәйзи Тугай? Безгә аның татар милләтеннән һәм Истанбулда журналист булып эшләве генә билгеле. Тормыш юлына һәм иҗади эшчәнлегенә караган башка төр мәгълүматлар әлегә табылмады.

Авторы туган илләрдән читтә, еракта гомер итүе, шунлыктан бөтен төр чыганаклар белән эш итү мөмкинлеге чикләнгән булуы сәбәпледер, мәкаләдә кайбер фактик төгәлсезлекләр дә урын алган. Мәсәлән, автор Иван IV не Иван III дип атый; рус дәүләте тарихын яктыртканда да ялгышлар җибәрә. Казан һәм Кырым ханлыкларының руслар белән катлаулы сәяси мөнәсәбәтләрен төрки-татарлар файдасына хәл итүгә зур өлеш керткән Нурсолтан биографиясенә караган фактлар да чынбарлыкка туры килеп бетми. Ләкин мондый кимчелекләр Мөхәррәм Фәйзи Тугай мәкаләсенең әһәмиятен, гомумән алганда, киметә алмый.

Мөхәррәм Фәйзи Тугай Сөембикә турындагы мәкаләсе белән иң элек Төркия һәм башка мәмләкәтләрдә яшәүче татарларның тарихи хәтерен яңарткан, аларның туган ил турындагы өмет-хыялларын канатландырып җибәргән. Мәкалә тарих фәне күзлегеннән дә әһәмияткә ия. Анда заманында руслар белән татарлар арасындагы киеренке сәяси мөнәсәбәтләр, канлы бәрелешләр һәм сугышлар, Казан ханлыгының Болгар, Алтын Урда кебек үткәндәге дәүләтчелек тарихы белән дә, шул замандагы төрки халыклар һәм ханлыклар тарихы белән дә бәйләп карала. Мәкаләнең «Сөембикә» дигән исеме янына «Бөек төрки халыклар тарихыннан өзекләр» дигән искәрмә бирү дә бу фикерне раслый.

Мөхәррәм Фәйзи Тугай мәкаләсе төрки халыклар һәм аларның дәүләтләренә – Нугай, Әстерхан, Кырым ханлыклары тарихына кыскача күзәтү белән башлана. Автор аларның барлыкка килү, географик яктан урнашу рәвешенә тасвирламалар бирә. Бу уңайдан ул халкыбызның дәүләтчелек тарихы, Болгар һәм Алтын Урда дәверләре турында да мәгълүматлар китерә. М.Ф.Тугай Болгар мәмләкәтенең Көнчыгыш Европада икътисади, мәдәни яктан нык алга киткән дәүләт булуына басым ясый. Урта гасырларда гыйльми һәм мәдәни яктан югары үсеш баскычына күтәрелгән Болгар илен Испаниядәге Андалузия, ягъни Кордова хәлифәте, һәм Габбасилар дәверендәге Багдад белән чагыштырып карый.

[13] Бу мәгълүмат Габделбари Батталның «Казан төркиләре» исемле китабыннан алынды (Казан: Татар.кит. нәшр., 1996. – Б. 27, төрекчәдән тәрҗемә). Хезмәт үзе исә 1925елда Истанбулда, төзәтелеп һәм киңәйтелеп 1966 елда Анкарада басылган.

Болгар дәүләте турында сөйләгәндә, Тугай Дунай буена китеп урнашкан болгарлар тарихына да күз ташлап ала, аларның да Европада көчле дәүләт төзүләрен искәртеп үтә.

Мәкаләдә Алтын Урда тарихын, аның ханнары арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне яктыртуга да игътибар ителгән. Чыңгыз яуларының дөнья тарихында тоткан урыны турында сүз йөртеп, автор, монголлар, «русларны һәм башка халыкларны үз бәйлелегендә» тотып, Европаны рус яулары куркынычыннан коткарып калган, дип яза; Алтын Урданың таркалу тарихына тукталып, бу дәүләт гаугалар һәм эчке ызгышлар аркасында таркала дигән нәтиҗәгә килә. Ул Алтын Урданы төрки империя буларак саклап калырга тырышкан ике шәхес – җиһангир Аксак Тимер белән Туктамыш арасындагы катлаулы һәм каршылыклы мөнәсәбәтләрне дә читләтеп үтми. Мәгълүм ки, Алтын Урда кебек зур империянең яшәеше Аксак Тимер һәм Туктамыш кебек көчле шәхесләр ихтыярына гына бәйләнмәгән була билгеле, күп кавемнәрне һәм төрле халыкларны эченә алган империяләр иртәме-соңмы таркалалар. Туктамышка кадәр үк таркала башлаган Алтын Урдадан Нугай, Кырым, Әстерхан, Себер һәм Казан ханлыклары аерылып чыгалар.

Мәкалә авторының төп игътибары Казан татарлары тарихына юнәлтелгән. Казан ханлыгының барлыкка килү тарихын Мөхәммәд Фәйзи Тугай Олугъ Мөхәммәд хан исеме белән бәйли.

Казан ханлыгы тарихын М.Ф.Тугай Болгар һәм Алтын Урда тарихы белән дә бәйләп яктырта. Аныңча, ханлыкның төзелүенә, Иске Казаннан күчеп килгән «болгар төркиләре принцлары» Алтынбәй белән Галимбәй җирлек әзерләгәннәр. Автор Казан ханлыгының зур мәйдан биләп торуы, башкаласының бик җайлы урында урнашуы, Казан ханлыгы белән ничә һәм нинди ханнар идарә итүе турында да сөйләп үтә.

Мөхәррәм Фәйзи Тугай мәкаләсенең үзәгендә ханбикә Сөембикә образы тора. Бу күренекле шәхес образын ул башлыча дүрт яссылыкта – бөтендөнья тарихы, төрки ханлыклар, Казан ханлыгы һәм рус дәүләте белән мөнәсәбәтләрдә күрсәтә.

Соңгы елларга кадәр Казан ханлыгы тарихын күбрәк катлаулы рус-татар мөнәсәбәтләре күзлегеннән чыгып өйрәнеп килделәр. Тугай мәкаләсенең әһәмиятле ягы шунда: автор татар халкы тарихын дөнья күләмендәге вакыйгәләр белән дә бәйләп карарга омтыла.

Тарихчылар Һади Атласи һәм Габделбари Баттал кебек, Мөхәррәм Фәйзи Тугай да Сөембикә образын нугайлар тарихына, аның нәсел-нәсәбенә һәм «Сөембикә» исеменең этимологиясенә бәйләп аңлата. Мәкаләнең башында ул Сөембикәне Казан ханлыгының мөстәкыйльлеген, төрки халыкларның бердәмлеген саклау өчен үзен фида кылган ханбикә итеп бәяли. Тугай фикеренчә, Сөембикә кебек шәхес – бөтендөнья тарихында сирәк очрый торган күренеш.

Дәүләтчелегебезне югалтуга китергән сәбәпләрне ачу белән бергә, Тугай Казан ханлыгының тарихи барышта һәм тәрәккыять мәйданында тоткан урынына да туктала. Казанны ул төрки галәмнең сәнагать, икътисад, гыйлем һәм мәдәният чәчәк аткан мәркәзе һәм төркиләрне бер көч итеп туплаучы үзәк дип саный.

Мөхәррәм Фәйзи Тугай 1552 елда Казан ханлыгы халкының һәм гаскәрләренең Явыз Иван баскынчыларына каршы көрәшен каһарманлыкның мәңгелек мисалы дип бәяли. «Казанлы төрки гаскәр, – ди ул, – 30000 сугышчыдан 2000гә калганчыга кадәр сугыша, ә калганы шәһәрнең тышына чыгып, соң тамчы канына кадәр сугышып шәһит китә». Автор яулап алучыларның ерткычлыгы, кансызлыгы, хатын-кызларның, балаларның кылыч аша үткәрелүе, шәһәрдәге биналар, мәктәп-мәдрәсәләр, мәчетләр җимерелү турында ачынып яза.

Тугай, татарларның Казанны фидакярләрчә саклаулары турында сөйләгәндә, тарихи аналогияләргә дә мөрәҗәгать итә. Казан ханлыгының Явыз Иван гаскәрләренә каршы торуын ул карфагенлыларның Рим империясенә каршы алып барган сугышлары белән чагыштыра. Борынгы тарихтагы Карфаген белән Казан ханлыгы арасындагы охшашлыкны М.Ф.Тугай һәр ике дәүләтнең башында хатын-кыз тору, һәр ике башкаланың да җиңелүе һәм җимерелүе, җиңелгән халәттә дә, аларның соңгы кешеләре калганчы батырлык күрсәтеп сугышуларында һәм шәһит китүләрендә күрә.

Казан ханлыгының русларга каршы каһарманлыгын Мөхәррәм Фәйзи Тугай бөтен төрки халыклар һәм ханлыклар тарихы, алар алып барган сәясәт белән тыгыз мөнәсәбәттә яктырта. Мәкалә дәвамында ул Сөембикәнең Казан ханлыгы, төркиләр һәм бөтендөнья тарихында тоткан урынына югары бәя бирә. Автор Ханбикәнең Казан тарихында тоткан урынын киң планда – төрки халыклар һәм дәүләтләрнең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйләп яктырта. Аныңча, Казан ханлыгының мөстәкыйльлеге, татар халкының һәм төрки халыкларның бердәмлеге өчен Сөембикә кебек ханбикәнең үзен фида кылу мисалы дөнья тарихында сирәк очрый торган күренеш.

Мөхәррәм Фәйзи Тугай хезмәтендә Сөембикә гүзәллек үрнәге, акыл иясе, гадел, алдан күрә белүчән, зирәк һәм тапкыр дәүләт эшлеклесе, батырлыкта ирләргә тиң ханбикә итеп гәүдәләнә. Аның батырлыгына, матурлыгына төрки шагыйрьләр генә түгел, Херасков белән Глинка кебек рус язучылары да мәдхия җырлаганнар, ди автор. Сөембикә – сугышчан рухлы нугай кабиләсеннән Йосыф морза кызы. Ул кечкенә яшьтән үк атта йөргән, сугыш кораллары белән эш иткән; хөрлек яратучы дала кызы, руслар тарафдары булган Җангалигә кияүгә чыккач та, Казан ханлыгы мәнфәгатьләрен бар нәрсәдән өстен куючы ватанпәрвәргә әйләнә, вакытсыз өзелгән гомеренең азагында да төркиләрнең бердәмлеген һәм бөеклеген сакларга тырышучы ханбикә булып кала.

Сөембикәнең асыл сыйфатлары нигезендә, ди Тугай, соң дәрәҗәдә төрки җанлылык – «Казан, Кырым, Әстерханны берләштереп», «Көнчыгышта һәм Көнбатышта бөтендөньяга хаким булуларын тәэмин итү идеалы ята». Сафагәрәй ханга кияүгә чыккач та, Сөембикә иренең турылыклы ярдәмчесе, фикердәше һәм киңәшчесенә әйләнә. Алар икәүләп бергә Казан, Кырым, Әстерханны берләштереп, төркиләрнең «Алтын Урда дәүләтен кабат торгызу һәм яңадан зур бер төрки империя төзү» уе белән янып яшиләр.

Сүз сөрешеннән аңлашылса кирәк, мәкалә авторы Мөхәррәм Фәйзи Тугай ханбикә Сөембикә һәм Сафагәрәй хан алдына олы максатлар куйдырта. Билгеле, Кырым һәм Идел

буе татар ханлыклары дустанә бердәм яшәгәндә, бәлки, Казан бу кадәр олы фаҗигагә дучар да булмаган булыр иде. Мәкаләдә Мөхәррәм Фәйзи Тугай Казан халкының Сөембикәгә олы ихтирамын һәм мәхәббәтен чагылдырган. Ханбикәнең Мәскәүгә озатылуын казанлылар авыр хәбәр, олы хәсрәт итеп кабул итәләр, канлы күз яшьләре коя-коя, Идел ярларына кадәр аны озата баралар. Сөембикәнең Казан, Хан мәчете, ире Сафагәрәй кабере белән саубуллашуы төркиләр тарихында җантетрәткеч гыйбрәтле һәм олы фаҗига итеп күзаллана.

Казанның руслар тарафыннан яулап алыну вакыйгасен Мөхәррәм Фәйзи Тугай бөтендөнья тарихы белән дә һәм төркиләрнең үз тарихлары белән дә бәйләп карый. Аныңча, XV–XVI гасырларда төрки халыкларга бәйле рәвештә Европа һәм Азиядә ике зур глобаль үзгәреш килеп туа. 1453 елда Константинопольне яулап алу төрекләргә Европага юл ачса, 1552 елда Казан ханлыгынын юкка чыгуы Азиядәге төрки дәүләтләрнең бер-бер артлы руслар тарафыннан йотылуына, Россия дигән империянең барлыкка килүенә сәбәп була.

Мөхәррәм Фәйзи Тугай мәкаләсе руслар тарафыннан җиңелгән, әмма тиңсез каһарманлыклар күрсәткән Казан ханлыгына, аның гаскәренә, татар халкының дәүләтчелеген саклап калу өчен үзен фида кылган ватанпәрвәр ханбикә Сөембикәгә мәдхия булып яңгырый..

**Төркия җирлегендә Сөембикә ханбикә турында язылган мәкалә һәм әдәби әсәрләрнең күпчелеге 50–60 елларга** туры килә. Бу еллар, профессор Х.Й.Миңнегулов билгеләп үткәнчә, Төркиядә татар милли тормышының янә активлашуы белән үзенчәлекле. 1955 елда Истанбулда «Идел-Урал төрекләренең мәдәни һәм социаль ярдәмләшү җәмгыяте» төзелә[14]. 1963 елда Истанбулда «Тукай клубы» оештырыла һәм «Тукай бюллетене» (журнал) басылып чыга башлый. Бераздан бу клуб «Казан төрекләре культур вә ярдәмләшмә дәрнәге» дигән исем ала. Ике елдан соң, ягъни 1965 елда, шундый ук оешма Анкарада төзелә[15]. 1950–60 елларда мәйданга чыккан бу мәдәни оешмалар татар халкының тарихы, мәдәнияте, теле, аның күренекле уллары һәм кызлары турында мәкаләләр һәм китаплар бастыру эше белән шөгыльләнә.

Мәсәлән, 1966 елда «Тарих» мәҗмугасының сентябрь ае санында **Гүлчин Чандарлыоглуның «Казан мәликәсе Сөембикә»** исемле мәкаләсе басылып чыга. Бу мәкалә Һади Атласиның «Сөембикә» тарихи романына таянып язылган. Автор татар тарихчысы хезмәтен төрекчәгә тәрҗемә итеп, кыскартып, Сөембикә ханбикә биографиясе белән бәйле иң кызыклы, мавыктыргыч урыннарын сайлап алып, укучыга тәкъдим итә. Мәкаләнең композицион төзелеше, аның кечкенә генә бүлекчәләргә бүленүе, исемләнүе дә Һади Атласи китабындагы бүленешкә туры килә. Тарихи вакыйгаларгә анализ биргәндә, автор тулысы белән Һади Атласи фикерләренә һәм хикәяләү сәнгатенә ияреп бара. Аларны үзгәрешсез диярлек кабатлый.

---

[14] Миңнегулов Х. Аерылмас төшенчәләр // Мирас. – 1997. – №11. – Б. 72.
[15] Шунда ук. – Б. 73.

Гүлчин Чандарлыоглу Төркиядә яшәгән һәм гомумтөрки тарих буенча күп кенә хезмәтләр язган Зәки Вәлидинең 1965 елда «Ислам динен тотучы (мөселман) төркиләр Институты» мәҗмугасында басылган «Казан ханлыгында ислам төрки мәдәнияте» (1965) дип аталган мәкаләсе белән дә таныш булуы күзәтелә. Бу мәкаләдә Зәки Вәлиди 1550 елда Х.Шәрифинең төрек солтаны Сөләйман Канунига атап иҗат ителгән «Зафәрнамәи виляйәт-и Казан» әсәре турында беренчеләрдән булып мәгълүмат бирә. Руслар белән татарлар арасындагы 1550 елгы сугышны тасвирлаган бу әсәрдән Гүлчин Чандарлыоглу уңышлы гына файдалана. Мәкаләнең башында автор кемнең кайсы капкада торып Казан шәһәрен батырларча дошманнардан саклаулары турында язып үтә. Башка каһарман ирләрдән бер дә калышмыйча, бу сугышта каланы руслар явыннан саклауда Сөембикә ханбикә дә катнаша. Г.Чандарлыоглу Сөембикәне рус тарихларында бик тәфсилләп сөйләнелгән, аның турындагы пьесалар Мәскәү сәхнәләрендә озак еллар дәвамында уйналган хатын дип атый[16].

Гүзәллеге һәм акыллылыгы белән бөтен тирә-якка даны таралган Сөембикә, дәүләте һәм халкы мәнфәгатьләрен яклап, руслар кулына әсир китә. Казанлыларның Сөембикәне Зөя каласына кадәр озата барулары, аның белән кан-яшь түгеп хушлашулары ханбикәнең әле ул заманнарда ук халык арасында онытылмас дәрәҗәдә бөек шәхес булуы турында сөйли, ди Г.Чандарлыоглу.

Шул ук 1966 елда **Габделбари Баттал-Таймасның «Казан төркиләре»**[17] дигән китабы басылып чыга. Бу тарихчы галимнең бөтен иҗаты диярлек татар халкының тарихын барлауга, аның зыялыларының тәрҗемәи хәлен өйрәнүгә, төрек укучысын төрки-татар тарихы белән таныштыруга багышланган. «Казан төркиләре» дигән хезмәтенең икенче басмасында галим укучыга Идел буе Болгар дәүләте төзелүдән башлап 1917 елгы революция вакыйгаләренә кадәрге чор турында мәгълүмат бирә. Шулай ук китапта милли тарихыбыз һәм мәдәниятебезнең аерым күренекле шәхесләре турында да сөйләнелә. Г.Баттал татар халкының бөек затларыннан булган Сөембикә шәхесенә дә кыскача гына булса да туктала. Автор аны «гүзәллеге, акыллылыгы һәм ватансөярлеге белән танылган кара язмышлы хатын» [18] дип атый. Беренчеләрдән булып, ул үзенең «Казан төркиләре» китабында Сөембикә турында Төркиядә иҗат ителгән фәнни-публицистик мәкаләләр, шигырь-поэмалар, тарихи романнар белән дә таныштырып китә.

«Ислам энциклопедиясе»нең алтынчы томындагы (Стамбул, 1967) Казан тарихы турындагы мәкалә күренекле галим, профессор **Рәшит Рәхмәти Арат** тарафыннан язылган. Кыска гына булса да, анда Сөембикә ханбикә турында да мәгълүмат бирелә. Мәкаләнең бай библиографик күрсәткечендә Һади Атласиның «Казан ханлыгы» һәм «Сөембикә» дигән хезмәтләре дә бар. Рәшит Арат фикеренчә, Сөембикәнең руслар кулына китүе –

[16] Gülçin Çandarlıoğlu. Kazan melikesi Süyünbike // Tarih mecmuası. – İstanbul. – 1966. – eylül. – S.87.
[17] Battal-Taymaz Abdullah. Kazan türkleri. – Ankara, 1966. Китап татарча да басылды: Баттал Г. Казан төркиләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 192 б.
[18].Шунда ук. – Б.6.

казанлыларның мәмләкәтләре бөтенлеге һәм какшамас берлеге (бердәмлеге) бәрабәренә бирелгән соңгы корбан»[19].

1970 елда Төркиядә яшәүче татарларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүне күздә тотып, матур әдәбият һәм фольклор әсәрләре белән таныштыручы, татар теле һәм тарихы турында кызыклы мәкаләләр бастыручы «Казан» журналы барлыкка килә. Ул читтә яшәүче татарларны үз тирәсендә туплаучы, аларның милли тойгыларын, уй-фикерләрен яңартып яшәртә алучы бер мәдәни-әдәби үзәккә әверелеп китә. Журнал битләрендә татарның үткән тарихы, шул исәптән Казан ханлыгы тарихы һәм аның ханбикәсе Сөембикә турындагы мәкаләләр дә дөнья күрә.

«Казан» журналы битләрендә Наилә Бинарк мәкаләләре еш басыла. Аларда башлыча милләтебезнең танылган шәхесләре, аларның тормыш юлы һәм иҗади эшчәнлеге яктыртыла. Шулай ук Наилә Бинаркның дистәдән артык сәхнә әсәре, күп санлы фольклор һәм сәнгать турында мәкаләләр авторы булуы да билгеле[20].

**Наилә Бинаркның «Тарихның мәшһүр хатыннарыннан Казан мәликәсе Сөембикә»** дигән мәкаләсе «Казан» журналының 1974 елгы 11 санында дөнья күрә. Соңрак бу мәкалә «Төрки мәдәниятләрне өйрәнү институты» басмасы булган «Төрек мәдәнияте» журналының 64 нче санында да нәшер ителә.

Мәкаләнең язылу тарихы турында «Сөембикә» журналына язган хатында Наилә Бинарк болай дип искәртә: «Илгаз Ваһапның 1945 елда басылып чыккан «Сөембикә» исемле тарихи романын уку барышында Сөембикәнең тормышы белән кызыксына башладым»[21]. Шул кызыксыну нәтиҗәсе буларак, «Тарихның мәшһүр хатыннарыннан Казан мәликәсе Сөембикә» мәкаләсе языла да инде. «Шул мәкаләм тәэсирендә, – дип дәвам итә Наилә Бинарк әлеге хатында, – бер язучы аны сәхнә әсәре итеп яңадан үзгәртеп яза, әлеге пьеса бүгенге исеме «Төрек хатыннары мәдәни җәмгыяте» булган «Төрек өй ханымнары мәдәни җәмгыяте» тарафыннан 1970 елларда үткәрелгән сценарийлар ярышында икенче урынны яулаган иде. Мәкаләмнең мондый бер пьесаның барлыкка килүенә сәбәпче булуына шатлык хисләре тоюымны да белдерәсем килә. Бу шәхси мавыгуымның нәтиҗәсе буларак, әлеге сценарий өчен чыганак вазифасын үтәвен дә белдерәм. Татар халкы фаҗигасенең бер чагылышы булган Сөембикә турындагы кайгылы хикәя татарларга милли йөзләрен саклап калу өчен әһәмиятле булган төшенчәне тәшкил итә, бигрәк тә татар милләтенең халыкара бердәмлеге нигезен барлыкка китерә»[22].

Наилә Бинарк үзенең мәкаләсендә Казан ханлыгының эчке һәм тышкы сәясәтенә, руслар белән мөнәсәбәтләренә тәфсилле анализ ясый. Моңа кадәр безгә таныш булган М.Ф.Тугай мәкаләсеннән аермалы буларак, автор тарихи вакыйгаләргә объектив рәвештә бәя бирергә тырыша, алар китереп чыгарган нәтиҗәләрне дә күрсәтеп уза.

---

[19] Arat R.R. Kazan // İslam ansiklopedisi. – Istanbul, 1967. – C.6. – S.512.
[20] Миңнегулов Х. Аерылмас төшенчәләр // Мирас. – 1997. – №11. – Б. 71-83.
[21] Бинарк Н. Тарихның мәшһүр төрки хатыннарыннан Казан ханбикәсе – Сөембикә // Сөембикә ханбикә. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – Б. 111.
[22] Шунда ук. – Б. 111.

Төркиядә яшәп иҗат иткән зыялыларыбыз Казан ханлыгы тарихын башка төрки халыклар, рус тарихы һәм рус патшалары сәясәте белән мөнәсәбәттә генә түгел, ә бөтендөнья тарихы һәм Госманлы империясенең башка төрки халыкларга карата алып барган сәясәте белән бәйләп өйрәнәләр.

Наилә Бинарк Сөембикәне «гүзәллеге телләрдә дастан булып сөйләнелгән, юмартлылыгы, шәфкатьлелеге, акыллылыгы белән күңелләрне яулаган һәм һәр кешенең мәхәббәтен казанган» хатын итеп сурәтли. Кияүгә чыкканда ук Сөембикәгә әһәмиятле милли вазифа йөкләнә – ул, Җангали белән никах кылып, аны руслар курчагы булудан коткарырга тиеш була. Ханбикә халкы алдында торган бурычларын яхшы аңлаган, «Алтын Урда империясе дәрәҗәсендәге куәтле һәм хәтта аннан да көчлерәк дәүләт корырга тели». Ләкин Мәскәү дәүләте алып барган астыртын сәясәт әкрен-әкрен төркиләр берлеген тарката һәм төрки дәүләтләр берәм-берәм рус дәүләте тарафыннан йотыла баралар. Тарих мәйданына чыккан Иван IV гә автор «куркыныч, явыз, кан түгүче, садист, ярым тиле» дигән характеристика бирә. Наилә Бинарк рус патшасы алып барган экспансив сәясәтнең, канкойгыч сугышларның христиан дине идеологиясе белән акланылганын да күрсәтә. Аныңча, рус патшасының төркиләргә карата нәфрәтенең нигезендә христиан диненең мөселманнарны явыз дошман итеп күрү фәлсәфәсе ята. Наилә Бинарк искәрткәнчә, «Казан ханлыгының 1552 елда рус патшасы Иван тарафыннан басып алынуы, ханлыкның бәйсезлеге бетүе белән татар халкының «дәүләтчелеге югалту, көчләп чукындыру һәм Россия тарафыннан колонизацияләү фаҗигасе башлана»[23].

Наилә Бинарк, Һади Атласи традицияләрен дәвам итеп, Сөембикә ханбикәне «арыслан горурлыгына һәм көченә ия булган гүзәл хөкемдар» дип атый. Автор Сөембикәнең Мәскәүгә озатылуын гадәти бер хатын-кызның әсир ителүе генә дип түгел, ә бөтен бер милләткә коллык чылбыры тагу дип саный.

Казан кебек зур мәдәни, икътисади бер мәркәзне кулга төшерү рус дәүләте өчен әйтеп бетергесез зур сәяси әһәмияткә ия була. Казан татарлары өчен исә бу фаҗига мәңге төзәлмәслек, хәтерләреннән җуелмаслык авыр яра булып гасырлардан-гасырларга күчеп килә.

Бөтендөнья татарлары өчен милли символ дәрәҗәсенә күтәрелгән, аларның тарихи хәтерен яңарткан, үзаңнарын билгеләгән Сөембикә Наилә Бинарк тарафыннан изге зат итеп карала, татар халкының горурлыгы һәм каһарманы итеп сурәтләнә. «Казанга сәяхәтем вакытында Сөембикә манарасына да бардым. Сөембикә язмышы турындагы бу хикәянең «үткән тарихлар хатирәсе генә булып калмыйча, бүгенге милли үзаңыбызны билгеләүче мәгънәгә ия» булуына мин тагын бер тапкыр инандым. Хәтта кабере кая булуы билгеле булмаган бу татар хатын-кыз каһарманының газиз хатирәсен бүген кабат хөрмәт белән искә

---

[23] Бинарк Н. Тарихның мәшһүр төрки хатыннарыннан Казан ханбикәсе – Сөембикә // Сөембикә ханбикә. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – Б. 110.

алам»[24], – дип язды ул.

### 3. Ләбиб Каран һәм Музаффер Кая әсәрләре

Татар диаспорасы вәкилләре иҗатында Сөембикә темасы чагылышын күзәткәндә, Әхмәт Ләбиб Каран (5.01.1887 – 30.07.1964) эшчәнлеге һәм иҗаты турында да сүз алып барырга тиешбез. Бу күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим, табиб һәм шагыйрь[25] тумышы белән Казан тирәсендәге Каран авылыннан булып, тәхәллүсен дә шул туган туфрагына нисбәттә сайлаган. Башлангыч белемне туган авылында әтисе укыткан мәдрәсәдә алганнан соң, ул берара Петербургта яши. 1909 елда Истанбулда Вафа лицеен тәмамлый. 1911 елгы Балкан сугышыннан кайтканнан соң, Истанбул университетының медицина факультетында белем ала. Кемал Паша җитәкчелегендә Төркиянең азатлыгы өчен барган сугышларда катнаша, төрле хәрби госпитальләрдә, хастаханәләрендә эшли. Белемен камилләштерү өчен Германиягә китә. Монда Йосыф Акчура белән аралаша һәм Гаяз Исхакый чыгарган «Милли юл» газетасында эшли, үзенең мәкаләләрен бастырып чыгара. Төркиягә кире әйләнеп кайткач та, табиблык вазифаларын үтәү белән беррәттән җәмәгать эшләре белән дә шөгыльләнә. Ләбиб Каран 1955 елда оештырылган «Идел-Урал төрекләренең мәдәни һәм социаль ярдәм оешмасы»ның лидерларыннан берсе була, 1957 елда исә Истанбулда «Сөембикә мәдәни җәмгыяте»н оештыра. «Сөембикә җәмгыяте язмалары» сериясендә аның «Яшь вакытымның җырлары», «Төшенчәмнең җырлары» дип аталган шигырьләр җыентыклары һәм «Сөембикә хан» поэмасы басылып чыга. Аның бу җыентыклары барысы да татар телендә язылганнар[26].

Ләбиб Каранның шигырь-поэмалары, публицистик мәкаләләре тарихчы Һади Атласи хезмәтләренә һәм И.В.Нәүрүзханның «Сөембикә» тарихи романына нигезләнеп иҗат ителә. Нәүрүзханның 1945 елда дөнья күргән «Сөембикә» тарихи романы Ләбиб Каран иҗатына зур йогынты ясый. 1949 елда ул Сөембикә турында беренче шигырен яза. Нәүрүзхан романында Сөембикә татар «милләтенең анасы» сыйфатында гәүдәләнгән булса, Ләбиб Каран әсәрләрендә ул милли символ рәвешен ала. Сөембикә «зур акыллы, сизгер күңелле, чиксез зирәк, бигрәк тә татарларны һәрвакыт урыслардан югары күргән»[27] ханбикә итеп сурәтләнә. Сөембикәнең «Казаннан аерылуы һәм дә урысларга тапшырылуы татар тарихының иң ачы, иң авыр һәм иң фаҗигале вакыйгаседер»[28], дип искәртә Ләбиб Каран. Рус әдәбияты әсәрләрендә хис-тойгылар, «азгын мәхәббәт» корбаны итеп сурәтләнгән Сөембикә Ләбиб Каран мәкаләсендә «бәйсезлек гашыйгы», «татар өлкәсенең тынычлыгы, татулыкта яшәве, иреге һәм бәйсезлеге өчен бирелгән бер корбан»ы рәвешендә сурәтләнә, «татар бәйсезлегенең бер символы» дип игълан ителә.

---

[24] Бинарк Н. Тарихның мәшһүр төрки хатыннарыннан Казан ханбикәсе – Сөембикә // Сөембикә ханбикә. – Казан: Идел–Пресс, 2001. – Б. 111.
[25] Кәримуллин Ә. Ләбиб Каран турында берничә сүз // Татарстан яшьләре. – 1991. – 20 апрель.
[26] Шунда ук.
[27] Каран Ләбиб. Сөембикә һәм татар бәйсезлеге // Казан утлары. – 1992. – №8. – Б. 158.
[28] Шунда ук. – Б, 159.

1952 елда Казан ханлыгының руслар тарафыннан басылып алынуына дүрт йөз ел тулган көннәрдә Ләбиб Каранның «Сөембикә һәм татар бәйсезлеге» дигән мәкаләсе дә басылып чыга[29]. Анда ул Нәүрүзхан романындагы фикерләрне дә китерә, ләкин үзгәрәк, яңарак төсмерләр белән баетып. Мәсәлән, Сөембикәнең Казанга килен булып төшүгә үк төрле фиркаләрнең тәхеткә хан сайлап кую гадәтен бетереп, варис итеп ханның беренче улын билгеләү фикерен автор Нәүрүзхан романыннан ала. Ләбиб Каран да татар хатын-кызларына бөек зат дип карый, аларны олылый, татар милләтенең киләчәген тәэмин итүчеләр буларак, татар анасына зур ышанычлар баглый.

«Сөембикә культур язмалары» сериясендә Ләбиб Каранның күп кенә шигырьләре басылып чыга. Шулар арасында 1959 елда Истанбулда Әхмәт Сәгыйть нәшриятында «Төшенчәмнең жырлары» дип аталган бер җыентыгы дөнья күргән. Бу җыентыкта аның мәшһүр ханбикәбезгә багышланган «Сөембикә хан» дигән шигыре дә бар[30]. Шигърият таләпләре күзлегеннән һәм тел җәһәтеннән анда кайбер чатаклыкларны да сиземләргә мөмкин. Ләкин дистә еллар дәвамында рухи кысрыклауларга дучар булган татар кешесе өчен ярты гасыр элек Төркиядә язылган бу шигырь милли хис-тойгыларны шактый тирән гәүдәләндерүе ягыннан әһәмиятен югалтмаган.

Сөембикә турындагы әсәрләргә хас булганча, Ләбиб Каран да ханбикәбезне матурлык һәм акыл иясе, илен, дәүләтен ирекле яшәтергә омтылучы батыр идарәче итеп тасвирлый. Автор Сөембикә холкындагы батырлык сыйфатларын Чыңгызханга ук барып тоташтыра. Нәсел-нәсәбтәге, аерым кешеләрдәге, әдәби каһарманнардагы асыл сыйфатларны Мөхәммәд пәйгамбәргә, Искәндәр (Александр Македонский) һәм Чыңгыз кебек шәхесләр белән бәйләргә тырышу күренеше дини, фәнни һәм әдәби әсәрләрдә еш күзгә ташлана. Бу күренеш заманының рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә омтылу белән аңлатыла.

Сөембикә образын Ләбиб Каран өч яссылыкта – татар халкының үткәненә, бүгенгесенә һәм киләчәгенә мөнәсәбәттә сурәтли. Казан ханлыгын басып алырга җыенучы руслар өчен шагыйрь Сөембикәне «яндыра торган бер атом» дип атый, ә Казан тәхете тирәсендә сәяси ыгы-зыгылар оештырган, илнең иминлеге өчен ханбикәне Мәскәүгә әсирлеккә китәргә мәҗбүр иткән сатлык морзаларга ләгънәт укый.

Татар телендә иҗат ителгән әсәрләрнең күбесендә урын алган, Һади Атласи хезмәте аша И.В.Нәүрүзхан романына да үтеп кергән таҗ образы Ләбиб Каран шигырь-поэмаларында янә калкып чыга. Һади Атласи әсәрендә Сөембикә әсирлеккә китәр алдыннан Сафагәрәй кабере белән саубуллашкан вакытта башыннан алтын таҗын алып ташлый. Ханбикә Зөя каласыннан Мәскәүгә кузгалып киткәч тә, Казанга әйләнеп карап: «Кызганыч, син, канлы, кайгылы шәһәр, синен башыңнан таҗың төште», ди. Ләбиб Каран шигырендә дә таҗ образы калкып чыга. Ләкин инде анда таҗ образы яңачарак эчтәлек ала: киләчәк буыннар өчен

[29] Шунда ук. – Б. 158-159.
[30] Lebib Кaran. Tüşüncemnin cırları. – Istanbul: Ahmet Sait Matbaası, 1959. – S.9-10.

Сөембикә образын мәңгеләштерү зарурияттен истә тотып, ханбикәбезнең мәрмәр сынын таҗ кидереп ясау кирәклеге уңае белән әйтелә:

Аның зур сынын ясарбыз, башында таҗы – алтын;

Язарбыз данлы тарихын – бер бүләк булып калсын[31].

Ләбиб Каран фикеренчә, легендар Сөембикә образы бүген дә безнең җаныбызда, каныбызда яшәргә тиеш. Ул яшь буыннарда милли хис-тойгыларны уяту, халкыбызның бәйсезлеге, азатлыгы өчен көрәш символы буларак бик кирәкле. Шигырьдә ханбикәбезнең исемен мәңгеләштерү мәсьәләсе дә күтәрелә. Аныңча, Сөембикә тарихын язу, аның турындагы хәтерне буыннан-буынга тапшыру һәм ханбикәбезнең таҗ кигән зур скульптурасын иҗат итү – галимнәребез, язучыларыбыз, сәнгатькярләребезнең изге бурычы.

Күләме һәм эчтәлеге, сәнгати эшләнеше ягыннан Ләбиб Каранның Сөембикәгә багышланган икенче әсәре дә аерым игътибарга лаек. Әсәрнең тулы исеме «Сөембикә хан. Аның тормышы һәм төшенчәләре» (уй-фикерләре. – *И.Р.*)[32]. 45 бүлектән торган бу поэма-дастан, 216 битле китапны тәшкил итеп, 1963 елда Истанбулда басылып чыга. Китапның азагында язучы файдаланган әдәбият исемлеге дә бирелә. Болар:

1. Шиһабетдин Мәрҗани. «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар».
2. Һади Атласи. «Казан ханлыгы тарихы».
3. Габдулла Баттал. «Татар тарихы».
4. Риза Нур. «Төрек тарихы», 2 том ( төрек телендә).
5. Илгаз Ваһап Нәүрүзхан. «Сөембикә».

Сөембикә образын тарихи шәхес буларак тудырганда, Ләбиб Каран Ш.Мәрҗани, Һ.Атласи, Г.Баттал һәм башка татар галимнәренең хезмәтләренә таянса, әдәби-сәнгати эшләнеше буенча ул Илгаз Ваһап Нәүрүзханның «Сөембикә» романына шигъри назыйрә булып тора. Ләбиб Каран Нәүрүзхан әсәренең образ-сурәтләрен аерым детальләрдә һәм төсмерләрдә генә яңарта. Иҗади эш итү иң элек Ләбиб Каранның төш күрү алымына мөрәҗәгать итүендә күренә. Урта гасыр Шәрекъ әдәбияты традициясе буенча, булачак әһәмиятле вакыйгаләр, шатлык-кайгылар турында төшләр аша Сөембикәгә алдан хәбәр бирелә. Үзенең беренче төшен ханбикә Казаннан яучы килер алдыннан, икенчесен ире Сафагәрәй үләр алдыннан, өченчесен Казан алыныр алдыннан күрә.

Сөембикә образына характеристика биргәннән соң, автор әсәрдә булачак вакыйгаләргә фон-экспозиция рәвешендә төрки-татарларның үткән тарихына мөрәҗәгать итә, аларның Алтын Урда кебек бөек империяләре булуын искә ала, аның таркалу сәбәпләренә туктала, Кырым, Әстерхан ханлыкларына, Нугай урдасына үзенең бәяләмәсен биреп үтә. Автор фикеренчә, Кырым ханлыгы исә Төркиягә баш иеп ирегеН югалткан, Әстерхан ханы көчсез,

[31] Lebib Karan. Tüşüncemnin cırları. – Istanbul: Ahmet Sait Matbaası, 1959. – S.10.
[32] Lebib Karan. Süyümbike han. – Istanbul: Tan gazetesi ve matbaası, 1963.

нугайлылар милли хиссез. Сәясәткә мөнәсәбәттә нугайларның төрле ыругларга, төркемнәргә бүлгәләнгән булуларын искәртеп, ул иң көчле саналган Исмәгыйль морзаның урысларның җан дусты булуы турында ачынып яза. Әсәрдә Йосыф морзаның Нугай Урдасында тоткан урынын югары бәяләнеп, Казан татарларына Сөембикә ханбикәне бүләк итүче ата булуы ихтирам белән телгә алына.

Ләбиб Каран Сөембикәне милләтенең ышанычын аклаган, татарларның мәхәббәтен яулаган, русларның нәфрәтеннән курыкмаган, бөтен төрки дөнья хатын-кызлары өчен үрнәк булган Ана образы рәвешендә сүрәтли. Аның Сөембикәсе – хатын-кыз, ана булуы белән горур. И.В.Нәүрүзхан романындагы кебек үк, Ләбиб Каран да әсәрендә Сөембикә образын Милләт Анасы дәрәҗәсенә күтәрә:

Урыслар кул астында җан бирде Сөембикәбез.
Без аны һич онытмабыз! Ул сөекле әнкәбез[33].
Әй, иң олуг әсәре чын ирек булган зур хатын!
Барча татар милләтенең әнкәсе булган хатын! (213 б.)

Татар әдәбиятында хатын-кызны «Милләт әнкәсе» дәрәҗәсенә күтәрүче мәгърифәтчеләр – Ризаэтдин Фәхретдинов кебек язучылар булдылар. Алар башлаган традиция, дистә еллардан соң, мөһаҗирлектә яшәгән татар язучылары Нәүрүзхан, Ләбиб Каран иҗатларында дәвам иттерелде.

Ләбиб Каранның Сөембикә турындагы әсәрендәге әдәби алымнарга күз ташлагач та, аның Шәрекъ һәм төрки-татар әдәбиятлары белән яхшы ук таныш булуы сизелә. Ул сурәтләгән Сөембикә кайсыдыр яклары белән Котбның «Хөсрәү вә Ширин» дастанындагы Ширинны искә төшерә. Белгәнебезчә, Ширин Сөембикә кебек гүзәл дә, белемле дә, акыллы да. Ул, үзе бик яраткан Хөсрәү аңа өйләнгән очракта, кәеф-сафа корырга, хәрәмендәге кызлар белән күңел ачарга яраткан Хөсрәүне турылыклы иргә, гадел патша дәрәҗәсенә күтәрә алачагына ышана. Ләбиб Каранның Сафагәрәе дә Сөембикә белән никахлашуны шул ук мәгънәдә диярлек кабул итә:

Синең белән бергә булгач, олуг хан да булырмын,
Синең төшенчәң белән татар берлеген корырмын!
Мин корычтан бер көч булсам, син дә аның дарысы!
Мин изүче көч булсам, син алга алып баручы (142 б.).

Әмма Сафагәрәйнең монологы шәрык рухында гына бирелмәгән, аңа Ауропа-рус классицизм әдәбиятларын хәтерләткән яңа бер фикер өстәлгән: Сөембикә белән никахлашу төрки-татарларның дәүләтчелеген ныгытуга хезмәт итәргә тиеш.

---

[33] Lebib Karan. Süyümbike han. – Istanbul: Tan gazetesi ve matbaası, 1963. – S.212. Киләчәктә бу поэмадан өзекләр, мисаллар астөшермәдә бирелмичә, текст эчендә генә күрсәтеләчәк.

Берьяктан, Сөембикә Яңарыш әдәбиятларындагыча романтикларча идеаллаштырып бирелә: ул – фәрештә, ул – гүзәл, ул – белемле, акыллы. Шуңа күрә аның бәясе бик тә югары. Кол Гали әсәрендәге гүзәл Йосыфны сатып алырга Мисыр газизенең байлыгы җитмәгән кебек, камил тарихи шәхес Сөембикәне дә алтын-көмеш, алмазлар белән үлчәү мөмкин түгел:

Ул ялгыз бер төсе матур күренган хатын түгел.
Ул бәясе үлчәнерлек бер алмаз, алтын түгел.
Ул акыллы, зирәк, белемле һәм сизгер хатын. (110 б.)

Икенче яктан, Сөембикәнең үтә милли җанлы, дәүләтчелек мәнфәгатьләрен алга сөрүче ханбикә икәнлегенә басым ясала. Аның табигатендәге бу сыйфатка басым ясау Ләбиб Каранның Сөембикә образын классицизм әдәбияты карашлары күзлегеннән дә тасвирлавы турында сөйли:

Ул милләтче, һәм дәүләтче, һәм пакь холыклы хатын.
Ул бөтен яратылышы белән нәкъ бер фәрештә;
Аның белән бергә яшәсәң – уңарсың һәр эштә. (110 б.).

Шул рәвешчә, татар-төрек авторларының Сөембикә турындагы әсәрләренә беркадәр күзәтү ясагач та, аларда шәрык һәм гареб традицияләренең янәшә яшәве, әдәби чылбырның дәвамлылыгы һәм иҗади яңгырашуы күзәтелә. Мәсәлән, Һади Атласиның «Сөембикә»сендә ханбикә образы күбрәк «Казан тарихы»на, рус елъязмаларына, тарихи чыганакларга таянып иҗат ителә, әсәрдә документальлек өстенлек ала. Нәүрүзхан романында тарихи вакыйгаләр чылбырын Һади Атласидагы кебек документаль нигездә бирү саклanса да, анда сәнгати башлангычка шактый урын бирелә, ә Ләбиб Каран дастанына килгәндә сәнгатилек, матур әдәбият кануннары җиңеп чыга.

1914 елда дөнья күргән тарихи романында Һади Атласи казанлыларның Сөембикәгә тискәре мөнәсәбәтләрен – дәүләт белән идарә итәргә лаек булмаган гади бер зат һәм хатын итеп карауларын тәнкыйтьләп чыккан иде. Ләбиб Каран исә, Сөембикә шәхесенә хатын-кыз буларак та югары бәя бирә, аны ирләр белән тигез дәрәҗәдә акыллы идарәче һәм көчле шәхес итеп күрсәтә. Үлеме алдыннан, Казан морзаларына мөрәҗәгать итеп, Сафагәрәй: «Аның башындагы акыл күп ир ханда табылмас», – ди (166 б.).

Ләбиб Каран Сөембикәнең Казан ханлыгы тарихындагы урынын французларның инглизләргә каршы көрәшен җитәкләгән халык каһарманы Жанна д’Арк белән тиңли, кайбер сыйфатлары буенча татар ханбикәсен аннан өстен дә куя:

Син тарихта татар Жанна д’Аркы дип, дан биргәнсең;
Батырлыкта, матурлыкта аннан өскә иргәнсең (214 б.).

Поэманың буеннан-буена, әйләнеп кайта-кайта, Ләбиб Каран Сөембикәнең гүзәл, акыллы, батыр булуы турында яза, аны «татар тарихының зәңгәр гөле» дип атый. Әсәрдә Сөембикәгә бирелгән «татар бәхетенең бер символы», «татар чын иркенең бер символыдыр» кебек бәяләмәләр төрле вариацияләрдә еш кабатланып тора:

Сөембикә бик сөекле тарихи бикәбездер,
Һәр татарның йөрәгендә яшәгән әнкәбездер.
Сөембикә дөньяга килгән ишсез бер барлыктыр,
Аны мәңге яшәтәчәк милли хис – татарлыктыр.

Автор Сөембикәнең тарихи шәхес буларак үлемсезлеген, рухи бөеклеген аның татарлыгында, милли җанлы «әнкә», тиңсез зат булуында күрә.

**1968 елда төрек авторы Музаффер Кая «Казан мәликәсе Сөембикә»** дигән драма әсәрен тәмамлый. Пьесаның язылу тарихын автор мәктәп елларындагы хатирәләре белән бәйләп аңлата. Казанга «Сөембикә» журналы редакциясенә язган хатында ул болай ди: «Беренче укытучым, яшь һәм гүзәл Гәүһәр ханым әфәнде тумышы белән Казаннан булып, озак еллар безләрне андагы хәлләр белән таныштырып, аңлатып килде. Ул аңлаткан-сөйләгән һәр нәрсәдә тирән сагыш, әрнү була иде. Һәм ул һәрвакыт ватан җырларын җырлый иде.

Кайбер көннәрдә бөтен дәрес йөрәге яралы бу кешенең әлеге моңын-зарын тыңлап үтә иде. Ул тынып торган араларда, мин «аһ, тагын сөйләсә иде», дип көтә идем. Аның кайгылы сагышы минем күңелдә сәер бер тойгы уята иде»[34].

Еракта, диңгез аръягында калган ватанын сагынып сөйли торган татар укытучысының хатирәләре кечкенә Музаффернең күңел кылларын дулкынландыра алырлык булган. Еллар үткәч тә, ул Казан татарларының бөек ханбикәләре турында әсәр язу фикеренә килгән. Музаффер Кая Сербиядә туып үсә, соңрак Төркиягә күчеп килә. «Татарович» дигән фамилиясеннән күренгәнчә, Музаффер Каяның нәсел-нәсәбендә татар кешеләре булганлыгы шәйләнә. Музаффер Кая укыганнары тәэсирендә пьеса язу эшенә керешә. Әмма Казан ханлыгы һәм аның ханбикәсе турындагы кирәкле материалларны туплау аның өчен җиңелләрдән булмый. «Кем дә мине аңламый иде, барчасы минем сорауларыма, мөрәҗәгатьләремә игътибарсыз, салкын карады. Хәтта монда (Төркиядә. – *И.Р.*) яшәүче казанлы зыялы ватандашларыбыз да», – дип яза ул бу юлларның авторына җибәргән хатларының берсендә. Бу юлларда сүз Гаяз Исхакый кызы Сәгадәт Чагатай турында бара. Музаффер Кая аның белән очрашып, үзенең Сөембикә турында бер сәхнә әсәре язарга җыенуы турында әйтә. Сәгадәт Чагатай исә Музаффер ханымга: «Мин үзем Сөембикә турында әсәр язачакмын», – дип җавап кайтарган (бу факт турында автор Музаффер Кая безгә үзе сөйләде. – *И.Р.*).

[34] Ибраһимова С. «Сөембикә» журналында Сөембикә ханбикә темасы: төрек әдәбиятына мөрәҗәгать // Сөембикә ханбикә. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – Б. 264.

Музаффер Каяга Казан ханлыгы тарихы, Сөембикә белән бәйле булган материалларны, чыганакларны эзләп табуда Милли китапханә мөдире ярдәм итә. Ул аның өчен татар кешесеннән Ләбиб Каранның «Сөембикә хан» дастанын төрекчәгә тәрҗемә иттерә. Бер дусты Музаффер Каяга татар телендә язылган «Сөембикә» рисаләсен дә табып китерә. Бу китапчыкның Һади Атласиның «Сөембикә» әсәре булу ихтималы зур. Ул Гүлчин Чандарлыоглуның «Тарих» мәҗмугасында басылган «Казан мәликәсе Сөембикә» дип аталган мәкаләсе белән дә танышып чыга. Кыскасы, төрек язучысы Музаффер Кая пьесасы Һади Атласи, Нәүрүзхан, Ләбиб Караннар язган әдәби чылбырының яңа бер дәвамы булып тора.

Сөембикә турындагы драмасын Музаффер Кая биш ел дәвамында яза һәм 1968 елда «Төрек мәдәни җәмгыяте» игълан иткән конкурста катнашып, жюри тәкъдире белән беренчелекне ала. Тагын да соңрак пьеса сәхнәләштерү өчен Дәүләт театрына бирелә. Ләкин бу вакытта билгеле бер сәбәпләр аркасында пьеса уйналмый калган. Еллар үткәч, яңадан күздән кичергәч, пьеса Истанбулдагы шәһәр муниципалитеты театрына тапшырыла»[35]. Пьеса Төркиянең Кайсери шәһәрендә уйнала. 1999 елда драма авторы «Сөембикә» журналы редакциясенең мәртәбәле бүләге – «Сөембикә беләзеге» белән бүләкләнде.

«Сөембикә кебек хатын-кызлар төрки халыкларда күп түгел», – дип яза Музаффер Кая. Шуңа күрә дә аның турында язу, тарихын өйрәнү, «аны яшәтергә омтылу безнең (барлык төркиләрнең. – *И.Р.*) милли вазифабыз»[36]. Автор фикерләвенчә, Нугай далаларында туып-үскән, Казан каласында ханбикә булып торган, гүзәллеге һәм акыллыгы турында даны бөтен-тирә якка таралган Сөембикә бер татар халкының гына түгел, ә бөтен төрки бердәмлекнең ихтирамына лаек ханбикә.

Музаффер Кая үзенең «Казан мәликәсе Сөембикә» әсәрен язганда тарихи дөреслекне саклауны үзмаксат итеп куймый, тулысы белән иҗади эш итә, бай фантазиясенә таяна. Хатларының берсендә ул болай дип искәртеп үтә: «Мин тарих түгел, театр әсәре язганга күрә, вакыйгаләрнең чынбарлыкка туп-туры килүен бөтенләй диярлек теләмәдем. Билгеле булганча, тарихи темага язылган сәхнә әсәрләре өлешчә авторның хыял көченә нигезләнеп иҗат ителәләр. Әмма шулай да, мин кулымнан килгән кадәр шул тарихи вакыйгаләр турында сөйләгән чыганакларны эзләдем, алардан мөмкин булган кадәр кулланырга тырыштым».

Музаффер Кая «Казан мәликәсе Сөембикә» пьесасында рус авторы С.Н.Глинканы да телгә алып уза. Бу хакта әдибә болайрак аңлата: «Сөембикә турында язылган хезмәтләрнең берсендә (Ләбиб Каранның «Сөембикә» поэмасы дип фаразларга мөмкин. – *И.Р.*) хәтта рус язучысы Глинканың да аны (Сөембикәне. – *И.Р.*) күкләргә күтәреп мактавы турында язылган иде». Бу хезмәттә без Музаффер Каяның «Казан мәликәсе Сөембикә» пьесасына

---

[35] Ибраһимова С. «Сөембикә» журналында Сөембикә ханбикә темасы: төрек әдәбиятына мөрәҗәгать // Сөембикә ханбикә. – Казан: Идел-Пресс, 2001. – Б. 264.
[36] Сөембикә ханбикә – төрки халыкларның горурлыгы // Сөембикә. – 2000. – №1.

тулы анализ бирүне максат итеп куймадык, бары тик аның язылу тарихына, нинди чыганакларга таянуына гына игътибар итәргә булдык.

Соңгы елларда Төркиядә иҗат ителгән әсәрләрнең тагын берсе - Хикмәт Туганның «Сөембикә» тарихи романы[37]. Бу роман 1995 елда язылып бетеп, 1999 елда «Төрки әдәбиятлар вакыфы (фонды) басмасы» булган «Байрак» нәшриятында дөнья күрде. Авторның Анкарада яшәве һәм доцент вазифасында булуы билгеле. Хикмәт Туган инде вафат булган, «Сөембикә» романы аның хатирәсенә багышланып чыгарылган.

Сөембикә язмышын тасвирлауны Хикмәт Туган аның дөньяга килүенең беренче сәгатьләреннән үк башлап җибәрә. Акрынлап ул укучыны ханбикәнең нинди тәрбия алуы, ата-анасы кемнәр булуы, туганнары, якын дуслары, эчке кичерешләре, уй-фикерләре белән таныштырып бара. Сөембикә кече яшьтән үк бик акыллы, сөйкемле, бик юмарт һәм мәрхәмәтле булып үсә. Гүзәллектә дә аңа Нугай, Кырым, Казан илләрендә тиңнәр табылмый[38].

Сөембикәнең чибәрлеге, акыллылыгы белән бергә, Хикмәт Туган аның батырлыгын да гипербола ярдәмендә күпертеп, арттырып гәүдәләндерә. Мәсәлән, атасы Йосыф морза кызын егетләр кебек батыр, хәтта ирләр аннан куркып, каршысында тетрәп торырлык итеп тәрбияли. Шуңа күрә атта йөри алган, корал белән эш итә белгән Сөембикәне атасы гасырлар үтсә дә «иң бөек төрки хатын» дип искә алырлык итеп тәрбияли[39].

Романның эчтәлегеннән күренгәнчә, Хикмәт Туганның Казан ханлыгы тарихын шактый яхшы белүе, шул исәптән, Һади Атласиның «Сөембикә» тарихи романы белән дә якыннан таныш булуы турында фаразларга мөмкин. Чөнки автор Казан ханлыгының эчке һәм тышкы сәясәтенә, икътисади халәтенә, дөньякүләм тоткан урынына шактый тулы анализ ясый. Романда Шаһгали ханның тышкы кыяфәтен тасвирлаган, аның килбәтсезлеге турында сөйләгән юллар турыдан-туры Һади Атласи хезмәтеннән алынган булуы аңлашыла: «Кыска аяклы, озын куллы, зур корсаклы, килбәтсез башлы һәм хатыннарныкы кебек нечкә тавышлы Шаһгалине тәхеткә килүенең беренче көннәреннән үк Казанда яратып бетермәделәр[40].

«Сөембикә» романын язганда, Хикмәт Туган, Һади Атласи хезмәтеннән кала, башка татар авторлары хезмәтләреннән һәм әсәрләреннән дә файдаланган булса кирәк. Болар арасында И.В.Нәүрүзханның «Сөембикә» тарихи романы һәм Ризаэтдин Фәхретдиновның «Казан ханнары» китабы да булган кебек. Мәсәлән, автор романда Сөембикәнең үлемен Р.Фәхретдинов хезмәтендәгечә тасвирлый: Сөембикә «…ире Сафагәрәй, бигрәк тә угылы Үтәмешгәрәй хәсрәте белән янып-көеп вафат булды»[41]. Хикмәт Туган да бу версиягә тугърылыклы кала һәм Сөембикә улы Үтәмешгәрәйнең үлеме хәбәрен күтәрә алмыйча, бала хәсрәтеннән вафат була, диелә.

---

[37] Doğan Hikmet. Siyün-Bike. – İstanbul: Bayrak matbaası, 1999.
[38] Шунда ук. – S.58.
[39] Шунда ук. – S.26-27.
[40] Шунда ук. – S.69.
[41] Фәхретдин Р. Казан ханнары. – Казан: Тат. кит. нәшер., 1995. – Б. 144.

Хикмәт Туган Сөембикәне бөтен барлыгы һәм яшәеше белән Казан ханлыгы, ватаны азатлыгы өчен барлык көч-куәтен биргән һәм бу олы максатка ирешүдә бернинди авырлыклардан курыкмаган, акылга сыймаслык батырлыклар, үз-үзен фида кылуга кадәр барып җиткән бер хатын итеп сурәтли. Татар халкының дәүләтчелек тарихында Казан ханлыгын саклап калуда күрсәткән тиңдәшсез фидакарьлеге өчен татар халкы Сөембикәне милли символга әверелдергән. Сөембикә шул ук вакытта бер татар халкының милләтпәрвәр ханбикәсе итеп кенә түгел, ә бөтен төрки берлекнең иминлеге өчен көрәшкән олуг шәхес итеп күз алдына килеп баса. Автор Казан мәликәсе Сөембикәне бөтен төрки халыкларның хөрмәтенә, ихтирамына лаек, төркичелек хисләренә тугърылыклы ханбикә һәм акыллы идарәче итеп гәүдәләндерә. Шуңа күрә дә Сөембикә – гомумтөрки тарихның бөек каһарманы.

Сөембикә образы Төркиядә яшәп иҗат иткән татарлар өчен генә түгел, ә төрек язучылары өчен дә кадерле һәм якын образ. Кыскача гына без күзәтү ясаган әсәрләр һәм хезмәтләр бу фикерне расласа кирәк.

Нәүрүзхан, Ләбиб Каран, Музаффер Кая әсәрләре кебек Хикмәт Туган романы да көчле милли рух, татарчылык һәм гомумтөркичелек идеяләре белән сугарылган. Хикмәт Туганның биографиясе әлегә ачык түгел, ул өстәмә эзләнүләр таләп итә. Милли хисләр чишмә кебек ургылып торган роман, һичшиксез, киләчәктә татарчага тәрҗемә ителергә лаек.

Татар җирлегеннән, татар халкыннан аерылып чит мәмләкәтләрдә яшәгән диаспора вәкилләрендә туган илне сагыну хисе тагын да көчле иде. Рәхимсез тарих җилләре татар кешесен дөньяның төрле кыйтгаларына таратты. Әмма кайда гына яшәмәсен, көн күрмәсен, ул үзенең туган җирен, туган халкын онытмады, милләтенең дәүләтчелек тарихы, аның күренекле шәхесләре турында уйланды, бу хактагы уй-фикерләрен кәгазьгә дә төшерде. Туган ил, туган туфрак сагышы анын йөрәгенә кара кан булып сауды. Һәр мөһаҗир татар киләчәктә туган илен, халкын азат, бәйсез күрү өмете, хыялы белән яшәде. Шуңа күрә дә Төркия җирлегендә иҗат ителгән һәр әсәрдә, һәр публицистик чыгыш һәм мәкаләдә фаҗигале язмышлы ханбикә Сөембикә образы классицизм әдәбиятындагыча татар кешесенең башын һәм йөрәген авырттырган дәүләтчелек – милләт – шәхес өчпочмагы рәвешендә бирелде.

# ЙОМГАК

Кыска гына вакыт аралыгында Казан ханлыгы белән идарә иткән (1549–51), сәяси зирәклеге белән аны рус дәүләте экспансиясеннән саклап калырга тырышкан, халкыбызның горурлыгына, яшәешебезнең милли символына әйләнгән гүзәл һәм акыллы ханбикә Сөембикә (1516 – 1554 дән соң) турында дөнья әдәбиятында йөзләгән шигырь, поэма, хикәя, повесть, роман, сәхнә әсәрләре язылган. Сөембикә шәхесе һәм аның исемендәге манара турындагы хезмәтләрнең саны гына да бихисап.

Рус патшасы Явыз Иванның катгый таләбенә буйсынып, Казан тәхете тирәсендә үзара тарткалашып яткан сәяси фиркаләрнең әмер-теләкләрен дә үтәп, 1551 елның көзендә Мәскәүгә әсирлеккә китәргә мәҗбүр ителгән ханбикә Сөембикәнең фаҗигале язмышы һәм 1552 елда җимерелгән Казан ханлыгы турында күп санлы әсәрләр XVI гасырның икенче һәм XIX гасырның беренче яртысында рус авторлары тарафыннан языла. Аларның барысының да үзәген дәүләтчелек идеяләре тәшкил итә; рус дәүләтенең Казан ханлыгын яулап алуы уңай күренеш итеп бирелә; Явыз Иван образы рус дәүләтен татар-монголлар изүеннән коткаручы акыллы патша итеп идеаллаштырып, ә ханбикә Сөембикә исә хисләр белән генә яшәп, үз халкының мәнфәгатьләрен оныткан сәяси антипод итеп сурәтләнә.

Беренче мәртәбә рус чыганакларында ханбикә Сөембикә образы 1564–1565 елларда язылган «Казан тарихы» дигән билгесез авторның ярым тарихи, ярым әдәби-публицистик рухлы әсәрендә пәйда була. Күпчелек галимнәр аның авторы татарларга әсирлеккә төшкән, егерме ел дәвамында Хан сараенда яшәгән, татарча яхшы белгән, ислам динен кабул иткән Иоанн Глазатый булырга тиеш дип фаразлый. Бу фаразны дөреслеккә якын тора дип тә кабул итәргә мөмкин. Чөнки «Казан тарихы»нда, рус чыганаклары белән беррәттән, Сөембикә Мәскәүгә әсирлеккә озатылгач ук татар халкы тарафыннан иҗат ителгән бәетләр, сыктаулар, җырлар, мөнәҗәтләр, хан ярлыклары, илчелек хатлары, Сафагәрәй ханнан ишеткән мәгълүматлар, авторның шәхси күзәтүләре иркен файдаланыла.

Шул рәвешчә, Казан ханлыгын яулап алуга 12–13 ел үткәч үк язылган әсәрдә Сөембикә шәхесен әдәби образ итеп гәүдәләндерүдә ике традиция барлыкка килә. Аларның берсе – төрки-татар фольклоры йогынтысы, икенчесе – рус әдәбиятының үз традицияләре. Алар үзара керешеп, берсен-берсе баетып, XX гасыр азагына кадәр татар һәм төрек әдәбиятларында яшәвен дәвам итә. Моннан тыш «Казан тарихы» XVIII–XX гасырларда Сөембикә ханбикә турында мәйданга чыгачак күп кенә әдәби әсәрләр өчен елга башы һәм кыйммәтле беренчел чыганак вазифасын үтәячәк, рус әдәбиятында нәзыйрәчелек күренеше туугa киң юл ачачак.

Чын мәгънәсендә тулы канлы образ буларак Сөембикә шәхесен сәнгатьчә гәүдәләндерү XVIII гасырның азагында М.М.Херасковның «Россиада» (1779) дигән эпик поэмасыннан башланып китә. Әсәр классицизм әдәбияты кануннары буенча язылган һәм барокко,

сентиментализм, романтизм өчен хас булган иҗат алымнары белән дә үрелгән. Сөембикә образы төрледән-төрле хис һәм фикерләр бәрелешендә, уңай һәм тискәре сыйфатларның үзара керешүе рәвешендә сурәтләнгән; татар ханбикәсе рус җирләренә килгән афәтләрдә, кан коюларда гаепләнгән. XIX гасырның беренче яртысындагы рус әдәбияты Сөембикә турындагы әсәрләргә аеруча бай. Явыз Иван һәм татар ханбикәсе турында әсәр язуга С.И.Глинка, А.Н.Грузинцев, Г.Р.Державин, М.С.Рыбушкин һәм В.И.Лапин кебек күренекле авторлар алыналар. Сөембикә ханбикә образын алар башлыча өч иҗат ысулы – классицизм, романтизм, реализмга хас дөньяви карашлар һәм сәнгатьчә фикерләү чаралары ярдәмендә гәүдәләндерәләр. Классицизм методы белән иҗат ителгән М.М.Херасков, А.Н.Грузинцев, Г.Р.Державин әсәрләрендә дәүләти мәнфәгатьләр алга чыгарыла, Сөембикә үзенең дошманы Явыз Иванга карата үчле, соңгы сулышына кадәр иле-җире, халкы өчен көрәшүче, кирәк булса, мәкер-хәйлә юлына да басарга әзер торучы патшабикә итеп сурәтләнә. Романтик рухта язылган С.Н.Глинка, М.С.Рыбушкин драмаларында ханбикә тулысы белән хисси кичерешләр колы, милләте, халкы мәнфәгатьләрен онытkан ханбикә итеп тасвирлана.

Ә менә «Казанның алынуы» пьесасы авторы В.И.Лапин ханбикә Сөембикә һәм дин эшлеклесе Колшәриф образларын уңай эчтәлектә бирә. Бу юнәлештә ул чыгышы белән татарлардан булган атаклы шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Г.Р.Державин традицияләрен дәвам итә. Рус дәүләтенең Казан ханлыгын яулап алуын да В.И.Лапин ул вакыттагы рус әдәбиятында тамыр җәйгән «натураль мәктәп» рухында, ягъни реалистларча – икътисади мөнәсәбәтләр белән бәйләп аңлата. Әсәрдә татар халкына, аның ханбикәсе Сөембикәгә һәрдаим диярлек ихтирамлы караш сизелеп тора.

Казан ханлыгы руслар тарафыннан басып алынганнан соң, татар халкының әдәбияты һәм тарих фәне көчсезләнеп кала, торгынлык чорын кичерә. Бары тик XIX гасыр азагы – XX гасыр башындагы мәгърифәтчелек, җәдитчелек, алгарыш хәрәкәте тарихи хәтеребезне уятып җибәрә, Болгар, Алтын Урда, Казан ханлыгы кебек дәүләтләребез, аларның ханнары турында байтак хезмәтләр дөнья күрә. Казан ханлыгы тарихы, аның ханбикәсе Сөембикә шәхесе белән кызыксыну да бермә-бер арта. «Сөембикә» журналы (1913) барлыкка килү, аның битләрендә ханбикәгә багышланган байтак мәкаләләр басылу, «Шәрекъ» клубында ханбикә турында лекцияләр укылу шул хакта сөйләсә кирәк.

XX йөз башында гасырлар буе Сөембикә турында халык хәтерендә, шәкерт дәфтәрләрендә сакланган риваятьләр, бәетләр, тарихи җырлар, мөнәҗәтләр әле яңа гына мәйданга чыккан вакытлы матбугат битләрендә дөнья күрә һәм милли аңны тәрбияләүгә хезмәт итә башлый. Нәкъ менә шушы чорда Сөембикә турында күпсанлы шигырьләр, нәсер-хикәяләр, драма әсәрләре һәм фәнни-популяр эчтәлекле мәкаләләр языла. Ф.Әмирханның «Сөембикә» (1913), Ш.Әхмәдиевнең «Мәшһүр хатыннардан «Сөембикә» (1916) исемле романтик хикәяләре ханбикә образын сәнгатьчә гәүдәләндерүнең үрнәкләре булдылар. Р.Фәхретдин, З.Вәлиди, Г.Әхмәрев, Ф. һәм К.Туйкиннарның төрки-татарларның дәүләтчелек

тарихын объектив яктырткан хезмәтләре язучыларыбыз өчен фәнни һәм рухи таяныч вазифасын үтәде.

XX гасыр башындагы әдәби барышның иң зур казанышы – ул Һади Атласиның «Сөенбикә» исемле язмасы. Документальлеккә корылган бу хезмәт тарих фәне белән бер дәрәҗәдә татар тарихи романының нигез ташларын салучы уңышлы тәҗрибә һәм фаҗигале язмышлы «Сөембикә турында моңсу хикәят» тә иде (М.Госманов).

Совет власте урнашкач та, Сөембикә ханбикә образына игътибар кими төшә. Тоталитар режим татар язучыларын күпләп кырган утызынчы елларда Сөембикә турында әсәрләр бөтенләй диярлек күренми башлый.

Бөек Ватан сугышы елларында да, XX гасырның икенче яртысында да Сөембикә ханбикә турында әсәрләр языылмады. Посттоталитар дәвернең торгынлык дип аталган елларында Идел буе әдәбиятларында Сөембикә образына мөрәҗәгать итүләр күренә башлый, Ю.Сагановның «Новоград Свияжзский», (1966), А.Крупняковның «Марш Акпарса» (1970) романнары языла. Әмма аларда, совет чоры идеологиясе таләп иткәнчә, ханбикә Сөембикә образы бары тик кара буяулар белән тискәре яктан сыйфатланып бирелде.

Рус һәм татар әдәбиятларыннан тыш, Казан ханбикәсе Сөембикә шәхесе һәм аның дәүләти эшчәнлеге фәнни-теоретик һәм әдәби-эстетик яктан төрек әдәбияты җирлегендә күпкырлы һәм киң чагылыш тапты. Ханбикә турындагы әдәби әсәрләр һәм мәкаләләрнең күпчелеге төрек телендә язылса да, аларның авторлары – диаспорада яшәүче татар зыялылары. Казан ханлыгы һәм патшабикәсенә багышланган беренче мәкаләләр һәм романнарның дөнья күрүе Икенче бөтендөнья сугышы барган елларга туры килә. Сугыш башлангач та, чит илләрдә яшәүче татарларның байтагы туган туфракка, татар халкы яшәгән төбәкләргә кайтып егылу турында уйлангандыр, әле 1917 елда ук көн тәртибенә куелган Идел-Урал буе халыкларының конфедерациясен, татар халкының үз дәүләтен төзү идеясен дә исенә төшергәндер. Мөһаҗирлектәге татар әдәбиятында бу мәсьәлә 1922 елда ук Г.Исхакыйның «Өйгә таба» романында калкып чыга. 1927 елда язылган «Идел-Урал» исемле тарихи хезмәтендә әдип бу мәсьәләне кабат кузгата, 1933–38 еллар аралыгында аны татар, рус, поляк, француз, инглиз, япон телләрендә дөнья җәмәгатьчелегенә дә җиткерә. Кызганычка каршы, Бөек Ватан сугышы елларында, аннан соңгы елларда да СССРда яшәүче татар зыялылары үзләрен борчыган милли тарих, татар дәүләтчелеге белән бәйле темаларга әсәрләр язу мөмкинлегеннән мәхрүм ителгән иделәр. ВКП(б) Үзәк комитетының 1944 елгы 9 август карары белән татар халкының дәүләтчелек тарихын, ханнары эшчәнлеген өйрәнү тыелды. Шунлыктан татар халкының дәүләтчелеген кайтару мәсьәләсен Сөембикә ханбикә образына мөнәсәбәттә Төркиядә мөһаҗирлектә яшәгән һәм иҗат иткән милләттәшләребез генә көн тәртибенә куя алды. Ләбиб Каран тырышлыгы белән «Сөембикә» исемендәге әдәби-мәдәни үзәк оештырыла, аның язмалары чыгарыла. Казан ханбикәсе турында бихисап мәкаләләр языла (Мөхәррәм Фәйзи Тугай, Гюлчин Чандарлыоглу, Ләбиб Каран, Наилә Бинарк, Габделбари Баттал-Таймас, Рәшит Рәхмәти Арат һ.б.). Сөембикә ханбикә турында

Ләбиб Каранның 45 бүлектән торган поэма-дастаны (1963), Музаффер Каяның драмасы (1968), Илгаз Ваһап Нәүрүзхан (1944), Хайрани Илгар (1975), Хикмәт Туганнарның (1983) күләмле, җитди тарихи романнары иҗат ителә. Бу әсәрләрнең барысы да татар халкының дәүләтчелек, төрки бердәмлек идеяләрен яктырта, гүзәл, акыллы, гадел, батыр Казан мәликәсе Сөембикә образы исә төрки-татар галәменең азатлык өчен көрәш символы, рухи терәк вазифасын үтәүче Милләт Анасы итеп романтикларча идеаллаштырыла.

XX гасыр азагындагы үзгәртеп кору еллары башлангач кына Сөембикә ханбикә шәхесе белән кызыксыну артты, аның турында күпсанлы шигырьләр һәм поэмалар барлыкка килде. Р.Батулланың «Сөембикә кыйссасы» (1992), М.Хәбибуллинның «Сөембикә һәм Иван Грозный» (1994) исемле саллы әсәрләре мәйданга чыкты. Рус телендә Е.Суховның «Сююн-Бике, царица Казанская» (1994) романы язылды. Ниһаять , Сөембикә образы сәхнәгә дә менде, аның турында опера да иҗат ителде.

Татар кешесе дөньяның кайсы гына кыйтгасында яшәмәсен, мәшһүр ханбикәне исеннән чыгармаган; үзенең сөекле кызларына Сөембикә исемен кушкан; аның исеме белән газета-журналлар, рисаләләр чыгарган, төрле җәмгыятьләр корган. Туган илләреннән аерылган милләттәшләребез, мәсәлән, Финляндиядә яшәгән шагыйрь Гайсә Хәкимҗан, Хан мәчете-Сөембикә манарасы төбеннән бер уч туфрак алып китеп, фани дөнья белән саубуллашкан; гомеренең азагында үзенең җисми һәм рухи тамырлары Казан татарлары тарихы белән аерылгысыз икәнлеген белдерергә тырышкан. Төркиядә вафат булган милләттәшебез Йосыф Акчура каберенә Сөембикә манарасы макеты куелу шулай ук Сөембикә шәхесенең туган туфрактан аерылган зыялыларыбыз өчен җан азыгы булу һәм милли символга әверелүе турында сөйли. Җир шарының төрле кыйтгаларына сибелгән милләттәшләребез өчен Сөембикә ханбикә образы, авыр язмышка дучар булган бер тарихи шәхес кенә булып калмыйча, газиз Ватан, Туган ил, туган туфрак кебек изге һәм бөек рухи кыйммәт – милли сиволга әйләнде. Төркиядә яшәүче күренекле тарихчы Надир Дәүләт язганча, татар халкы өчен бик тә кадерле ике символ бар. Аның беренчесе – татар халкының урта гасырлардагы дәүләтчелек тарихы һәм аның фаҗигале язмышлы ханбикәсе белән бәйле Сөембикә манарасы. Яңа заман егерменче гасыр белән бәйле икенче рухи байлыгыбыз – ул Габдулла Тукайның халкыбызның күңелендә яшәгән һәм рәсми булмаган гимнына әйләнгән «Туган тел» шигыре: «Чынлыкта, һаман һәр татар өчен аңлаешлы милли символлар буларак, беренче урынны Казан Кремлендәге Сөембикә (Хан мәчете) тотса, икенче урында милли шагыйрь Габдулла Тукай (1886–1913) тора дип әйтергә була»[1].

Сөембикә ханбикә – гомумтөрки тарихның да бөек каһарманы. Аның мөкатдәс образы – төрки дөнья өчен гомумтөркичелек идеяләрен үзенә туплаган олугъ символларның берсе.

[1] Дәүләт Н. Татар диаспорасы һәм Тукай // Казан утлары. – 1997.– №5. – Б. 168.

## БИБЛИОГРАФИЯ*

### Татар телендә


1. Абдуллин Я., Госманов М., Таһиров И. Һади Атласи турында // Казан утлары. – 1986. – №11. – Б. 172–176.
2. Айдаров С. Сөембикә манарасы // Совет Татарстаны. – 1959. – 12 сентябрь.
3. Алишев С. Тарихчының фажигале язмышы // Социалистик Татарстан. – 1990. – 5 август.
4. Алишев С. Тарихыбыз язылган, укып белергә генә кирәк // Татарстан яшьләре. – 1994. – 8 февраль.
5. Алишев С. Казанны алу // Шәһри Казан. – 2000. – 13 октябрь.
6. Атласи Һ. Себер тарихы. Сөен-бикә. Казан ханлыгы. – Казан: Татар китап нәшрияты. 1992. – 448 б.
7. Атласи Һ. Сөенбикә. – Казан: Җыен фонды, 1992.– 72 б.
8. Афзал Г. Сөембикә ае // Социалистик Татарстан. – 1991. – 15 март.
9. Әмирхан Р. Идегәй. Нурсолтан. Сөембикә рухлары эндәшә // Заман-Татарстан. – 1998. – 29 гыйнвар.
10. Әмирхан Р. Легендалар рухын тергезеп // Шәһри Казан. – 1998. – май.
11. Әмирхан Р. Бөек галимнең мәшһүр адәмнәре // Мирас. – 1997. – №10. – Б. 79–94.
12. Әмирхан Ф. Сөембикә // Идел. – 1991. – №2. – Б. 4–6.
13. Әмирханов Р. Сөембикә манарасы // Азат хатын. – 1988. – №8. – Б. 16.
14. Әмирханов М. Изге исеменә лаек – муафыйк булып // Сөембикә. – 1991. – №1.
15. Әхмәт Р. Таң илчесе. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1996. – 288 б.
16. Әхмәтҗан Р. Уян, Сөембикә! // Шәһри Казан. – 1994. – 30 июнь.
17. Әхмәтов С.Ф., Әхмәтова Г.Л. Сөембикә манарасы һәм шәһре Болгардагы хан төрбәсе нинди материалдан төзелгән // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. – Казан: Татар китап нәшрияты, – 1989. – 296 б.
18. Әхмәтшина Ә. Сөембикә азатлыкка өнди // Татарстан. – 1995. – №11–12. – Б. 28–31.
19. Батулла Р. Каракош // Идел. – 1990. – №10. – Б. 2–14; №11. – Б. 10–20.
20. Батулла Р. Сәнгать әсәре – нәрсәгә булса да дәгъва // Мәгърифәт. – 1988. – 4 апрель.
21. Батулла Р. Сөембикәнең тууы // Соц. Татарстан. – 1989. – 6, 8 август.
22. Батулла. Сөембикә. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1992. – 415 б.
23. Батулла Р. Тарих эчләрендә тарих // Мәдәни җомга. – 1997. – 4 июль.


* Библиография 2002 елга кадәрге мәгълүматларны эченә ала.

24. Бәетләр, мөнәҗәтләр / Төзүчесе, кереш мәкалә һәм искәрмәләр авторы Ф.И.Урманче. – Казан: Мәгариф, 2000. – 160 б.

25. Бәйрәмова Ф. Сөембикә каргышы // Шәһри Казан. – 1997. – 7 февраль.

26. Бәширов Г. Сөембикә бәете // Сөембикә. – 1991. – №1.

27. Бәширов З. Мәңгелек манара // Мирас. – 1992. – №2. – Б. 103–107.

28. Булатов Н. Сөембикә манарасында – ай // Социалистик Татарстан. – 1990. – 2 сентябрь.

29. Булатов Н. Сөембикә турында җыр // Социалистик Татарстан. – 1991. – 25 июнь.

30. Вагыйзова Л. Халкыбыз тарихын өйрәнүдә Һади Атласиның «Сөенбикә» әсәре // Каһарманлык гасырларны кичәр, яңа буыннарны уятыр. – Яр Чаллы. – 1995. – Б. 49–53.

31. Ваһапова З. Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1992. – 17 ноябрь.

32. Вәлиди Әхмәтзәки. Төрек вә татар тарихы. – Казан: Милләт, 1912. – 280 б.

33. Вәлиев Г. Сөембикә манарасының серен кем ачар? // Социалистик Татарстан. – 1988. – 29 май.

34. Вәлиев Р. Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1996. – 8 март.

35. Вәлиев Р. Сөембикәне чакыру // Мәдәни җомга. – 1997. – 24 октябрь.

36. Вәлиуллова М. Сөембикә сагышы // Сөембикә. – 1998. – №4. – Б. 29.

37. Газимов И. Өстәлемдә шәмнәр яна // Шәһри Казан. – 1994. – 22 январь.

38. Гайнетдин М. Ил өстендә илле алтын... // Сөембикә. – 1998. – №10. – Б. 6–7.

39. Галимов Г. Бабаларыбыз истәлеген мәңгеләштерик // Шәһри Казан. – 1997. – 10 октябрь.

40. Галимов Илгиз. Сөембикә манарасы // Шәһри Казан. – 1994. – 22 январь.

41. Галимуллин Ф. Сөембикә һәм Каракош шәүләсе // Шәһри Казан. – 1993. – 4 сентябрь.

42. Гарипова Х. Хәерле юл сиңа, Сөембикә! // Мәдәни җомга. – 1999. – 9 июль.

43. Гарифат Ф. «Сөембикә» арияны яклаша // Шәһри Казан. – 1999. – 9 июль.

44. Гафури М. Сөембикә манарасы // Идел. – 1990. – №2. – Б. 38.

45. Гафури М. Сөембикәнең актык көне // Сөембикә. – 1992. – №8.

46. Гафури Мәҗит. Хан мәчете // Мирас. – 1997. – №10. – Б.45.

47. Гаязова М. Халык бәгырендәге ханбикә // Сөембикә. – 1997. – №11. – Б. 20.

48. Гәрәева С. Сөембикә // Татарстан хәбәрләре. – 1994. – 16 сентябрь.

49. Гәрәй Р. Алтын айлы манара // Ватаным Татарстан. – 1995. – 14 октябрь.

50. Гыйләҗев А. Әсәр чын бәясен көтә // Татарстан хәбәрләре. – 1995. – 5 апрель.

51. Госманов М. Һич җуелмас тарихи бу хәтер! // Сөембикә. – 1991. – №1.

52. Госманов М. Авыр тарихның моңлы кайтавазы / Атласи Һ. Сөен-бикә. – Казан: Җыен фонды, 1992. – Б. 64–71.

53. Дәүләт-Болгари Г. Сөембикәне сагыну: Татарстан тарихы // Сабантуй. – 1993. – 18 сентябрь.

54. Дәүләтшин Г. Болгар-татар амазонкалары // Сөембикә. – 1994. – №6. – Б. 26–28.

55. Диндаров И. Сөембикә ядкәре // Ватаным Татарстан. – 1997. – 5 февраль.

56. Зарипов Р. Сөембикә Казанга кайтыр, яки дәүләтебезнең соңгы ханбикәсе каберен Касыймнан үзебезгә күчерү турында // Ватаным Татарстан. – 1994. – 13 декабрь.

57. Зарипов Р. Сөембикә Казанга кайта // Татарстан яшьләре. – 1994. –12 ноябрь.

58. Зәйдулла Р. Бәхетсез ханбикәбезнең үлеменә 440 ел // Идел. – 1997. – №11. – Б. 2-3.

59. Зәйнуллин Җ. Әй манара, аең кайда? // Татарстан яшьләре. – 1990. – 2 август.

60. Зәйнуллин Җ. Фаҗигаи Казан // Сөембикә. – 1994. – 10 октябрь.

61. Зәйнуллин Җ. Фаҗигаи Казан // Әллүки. – 1994. – 30 сентябрь.

62. Зәйнуллин Җ. Сөембикә китеп бара // Әллүки. – 1994. – 30 сентябрь.

63. Зәкиев М. Татарларны гәүдәләндергән әдип // Әллуки. – 1997. – 20 июнь.

64. Зыялы С. Сөембикәнең Казан белән бәхилләшүе // Социалистик Татарстан. – 1991. – 22 ноябрь.

65. Зыятдинов Р. Манарада балкый ярымай // Шәһри Казан. – 1992. – 25 декабрь.

66. Ибрагимова Ф. Сөембикә урамы кирәк // Шәһри Казан. – 1997. –7 февраль.

67. Ибраһимова Ф. Каракошны кемнәр төшергән // Мәдәни җомга. – 1991. – № 32. – 6 август.

68. Исмәгыйлева С. Язмышларың фаҗигале, Сөембикә ханбикә // Мәгариф. – 1999. – №10. – Б. 27–29.

69. Исхакый Г. Казан китүгә 383 ел үтте // Шәһри Казан. – 1998. – 10 октябрь.

70. Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз. Әсәрләр. Унбиш томда. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1998. – Т 1.

71. Йосыпов Н. Безнең куллардан җылы кала // Идел. – 1194. – №3. – Б. 67–69.

72. Камалов Н. Казансу ярында // Шәһри Казан. – 1992. – 21 апрель.

73. Каран Л. Сөембикә һәм татар бәйсезлеге // Казан утлары. – 1992. – № 8. – Б. 158–159.

74. Кашапов Р. Тарих ялгышларны кичерми // Татар иле. – 1994. – № 44. – декабрь.

75. Кәримуллин Ә. Ләбиб Каран турында бер-ике сүз // Татар яшьләре. – 1991. – 20 апрель.

76. Кәримуллин Ә. Татар тарихына килгән әдип // Мирас. – 1997. – №4. – Б. 5-10.

77. Кәримуллин Ә. Һади Атласи һәм аның «Сөен-Бикә»се // Шәһри Казан. – 1991 – 3 август.

78. Кутуй Р. Сөембикә // Мәдәни җомга. – 1996. – № 15. – 12 апрель.

79. Маннап Ш. Аен тапкан Сөембикә // Казан утлары. – 1994. –№ 9. – Б. 90–94.

80. Маски Г. Сөембикә манарасы // Сөембикә. – 1997. – № 8. – Б. 27.

81. Мәүликаева Ф. Сөембикә турында бәет //Казан утлары. – 1998. – №5. – Б. 122–123.

82. Минһаҗ Р. Сөембикә манарасында ай // Социалистик Татарстан. – 1990. – 27 сентябрь.

83. Мирза М. Тәнкыйтьчегә тел ачкычы // Ватаным Татарстан. – 1995. – 24 март.

84. Миңлебаев К. Сөембикәнең иленнән сөрелүе // Татар иле. – 1999. – октябрь. (№ 40-41).

85. Миңнуллин Т. Язылмаган пьесалар // Мәдәни җомга. – 1996. – 30 август.

86. Мифтахова Ә. Сөембикә китапханәсе // Идел. – 1997. – № 11. – Б. 4-7.

87. Мөнәҗәтләр, борынгы җырлар // Татар иле. – 1996. – декабрь. (№ 46–47).

88. Мөхәммәд Г. Ай куелган көн // Шәһри Казан. – 1991. – 12 октябрь.

89. Мөхәммәдиев Ә.Г. Сөембикә манарасы // Эзләнүләр, уйланулар, табышлар. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1989. – Б. 228-233.

90. Мөхәммәдиев Ә. Кире кайтарылган хәзинә // Ватаным Татарстан. – 1994. – 18 март.

91. Мостафин Р. Сөембикә манарасы // Ялкын. – 1999. – №2. – Б. 8-9.

92. Нигъмәтуллина Р. Ханбикәгә игътибарны күпсенмик // Сөембикә. –1999. – №2. – Б. 2–3.

93. Низамов Р. Сөембикә манарасы // Ватаным Татарстан. – 1992. –17 июнь.

94. Поварисов С. Акыл таҗы // Сөембикә. – 1994. – №10. – Б. 6.

95. Рафиков Б. Сөембикә кебек // Шәһри Казан. – 1992. – 20 октябрь.

96. Исмәгыйль Р. Сөембикә // Сөембикә. – 1991. – №4. – Б. 11.

97. Рәмиева И. Мөхәррәм Фәйзи Тугай төркиләр, Казан ханлыгы һәм Сөембикә турында // Мирас. – 1999. – № 9. – Б. 80-82.

98. Рәмиева И. Сөембикә эзләреннән // Шәһри Казан. – 1997. – 17 октябрь.

99. Рәмиева И. Сөембикәне белеп, өйрәнеп үсик // Мәгариф. – 1999. – №7. – Б. 21-22.

100. Рәмиева И. Ләбиб Каран иҗатында Сөембикә образы // Татар теле, әдәбияты, тарихы – үткәне һәм бүгенгесе. – Казан, 2000. – Б.398-404.

101. Рәмиева И. М.М. Херасковның “Россиада” поэмасында Сөембикә ханбикә образы // Татарский государственный гуманитарный институт: Ученые записки. – Вып. 9. – Казань,2001. Б. 40-53.

102. Рәмиева И. Рус язучысы А.Н.Грузинцев иҗатында Сөембикә образы – Сөембикә ханбикә.– Казан: Идел-Пресс,2001. Б. 83-89.

103. Рәмиева И. “Казан тарихы”нда Сөембикә // Сөембикә. – 2001. – №10. – Б. 4-6.

104. Рәмиева И. “Казан тарихы” әсәрендә Сөембикә образы // Сөембикә ханбикә.– Казан: Идел-Пресс,2001. Б. 65-81.

105. Рәмиева И. Рус язучысы С. Н. Глинка иҗатында Сөембикә образының сәнгатьчә гәүдәләнеше // Фәнни язмалар. – 2001. – Казан: Школа,2002. – Б. 269-274.

106. Рәмиева И. Зәки Вәлидинең “Төрек вә татар тарихы”китабыннан бирелгән өзеккә аңлатма // Сөембикә ханбикә.– Казан: Идел-Пресс,2001. Б. 59-59.

107. Рәхим Г. Алтын айлы манара // Ватаным Татарстан. – 1995. – 14 октябрь.

108. Рәхимова Б. 1 май. Ирек мәйданы // Казан утлары. – 1991. – № 12. – Б. 86.

109. Рәшиди Г. Сөем-Бикә. – Казан: Кадыров типографиясе, 1912. – 24 б.

110. Рәшиди Г. Сөембикә // Сөембикә. – 1997. – №10. – Б. 9–10.

111. Садә Г. Сөембикә // Казан. – 1994. – №5–6. – Б. 35–37.

112. Садә Г. Сөембикә // Татарстан. – 1993. – №4 – Б. 21.

113. Садә Г. Сөендерим // Шәһри Казан. – 1991. – 28 сентябрь.

114. Садыйкова А. Гасырлардан килгән моңнар // Татар иле. – 1998. – октябрь. – № 37–38. – Б. 9.

115. Садыйкова А. «Сөембикә бәете»ндә шигъри аһәңнәр // Мөслимә. – 1998. – №2. – Б. 2-3.

116. Сарыймова А. Сөембикә сагышы // Сөембикә. – 1998. – №4 апрель. – Б. 29.

117. Саттар Г. Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1992. – 11 август.

118. Сәлимов Т. Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1994. – 20 май.

119. Сөембикә. Методик һәм библиографик ярдәмлек // Казан. – 1996. – 25 б.

120. Сөембикә бәете // Сөембикә. – 1997. – № 10. – Б. 9–11.

121. Сөембикә бәете // Мирас. – 1992. – № 10. – Б. 38-41.

122. Сөембикә бәете // Татар иле. – 1996. – № 38. – октябрь.

123. Сөембикә сәхнәгә күтәреләчәк // Заман. – 1999. – 23 июль.

124. «Сөембикә» сәхнәдә // Республика.– 1999. – № 5–6.(40–41). – 6–28 июль.

125. Сөембикә ханбикә ядкаре // Ватаным Татарстан. – 1997. – 17 октябрь.

126. Татар халык иҗаты. Бәетләр / Томны төзүче Әхмәтова Ф.В., Надиров И.Н., Җамалетдинов К.Б. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1983. – 352 б.

127. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы Гыйлаҗетдинов С.М. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1987. – 368 б.

128. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар / Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләрне әзерләүче Надиров И.Н. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1988. – 488 б.

129. Тугай М.Ф. Сөембикә // Мирас.– 1999. – №10. – Б. 87–90.

130. Урманче Ф. Кыйсса-и Сөембикә // Мәдәни җомга. – 1995. – 1 сентябрь.

131. Урманче Ф. Сөембикә бәете // Казан утлары.– 1997. – №8. – Б. 161–170.

132. Урманче Ф. Тарихи хәтеребезне терелтүче // Мирас. – 1997. – № 12.

133. Урманче Ф. «Казан тарихы»нда Сөембикә // Ватаным Татарстан. – 1995. – 27, 28, 30 июнь.

134. Урманче Ф. «Шигырь миңа тиңсез кодрәт бирде...» // Мәдәни җомга. – 1997. – 1 август.

135. Урманче Ф. Гүзәл ханбикәнең ачы язмышы // Ватаным Татарстан. – 1994. – 21 декабрь.

136. Урманче Ф. Идегәй Нурсолтан Сөембикә. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1997. – 174 б.

137. Урманче Ф. Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный // Әллүки. – 1996. – 16 август.

138. Урманчы Б. Сөембикә // Татарстан яшьләре. – 1991. – 10 август.

139. Фатих Ә. Халык кызлары. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1995. – 24 б.

140. Фәйзуллин Р. Г. Казан алды // Казан утлары. – 1991. – № 10. – Б. 70–71.

141. Фәхретдинов Р. Г. Сөембикә манарасы // Социалистик Татарстан. – 1990. – 15 июль.

142. Фәхретдинов Р. Г. Сөембикә манарасы // Ялкын. – 1990. – № 10. – Б. 18–20; № 11. – Б. 18–20.

143. Фәхретдинов Р. Г. Сөембикә манарасы // Идел. – 1990. – № 9.

144. Фәхретдинов Р. Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. – Казан: Мәгариф, 1996. – 256 б.

145. Фәхретдинов Р. Г. Сөембикә һәм Сөембикә манарасы // Азат хатын. – 1990. – № 10. – Б. 12–13.

146. Фәхретдинов Р. Болгар вә Казан төрекләре // Шәһри Казан. – 1991. – 17 октябрь.

147. Фәхретдинов Р. Кичке азан. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1997. – 223 б.

148. Фәхретдин Р. Үтәмеш Гәрәй хан вә Сөенбикә // Мирас. – 1995. – № 4. – Б. 96–102.

149. Фәхретдин Р. Сөембикә // Мирас. – 1992. – №10. – Б. 27–28.

150. Фәхретдин Р. Казан ханнары. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1995. – 189 б.

151. Халитов Н. Йөзек кашыбыз // Идел. – 1996. – № 10. – Б. 23.

152. Ханзафаров Н. Йолдызлар иле вә Сөембикә манарасы // Идел. – 1994. – № 5. – Б. 50–54.

153. Ханзафаров Н. Манара серләрен ачармы? // Шәһри Казан. – 1997. – 15 октябрь.

154. Ханзафаров Н. Сөембикә манарасына – ярым ай // Социалистик Татарстан. – 1990. – 11 май.

155. Ханзафаров Н. Хан мәчете мәчетме? // Идел. – 1997. – №11. – Б. 8–9.

156. Харрас А. Айны сәламләү // Социалистик Татарстан. – 1990. – 27 сентябрь.

157. Хатипов Ф. Романнарда Сөембикә образы // Казан утлары. – 1993. –№ 12. – Б. 152–159.

158. Хафизов Л. Казан нигә егылган // Мәдәни җомга. – 1997. – 10 октябрь.

159. Хәбибуллин М. Бөек һәм каһарман Сөембикә // Шәһри Казан. – 1991. – 11 апрель.

160. Хәбибуллин М. Сөембикә ханбикә һәм аның кияүләре // Мәгариф. – 1997. - № 5. – Б. 68-69.

161. Хәбибуллин М. Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1996. – 512 б.

162. Хәбибуллин М. Һәр кешенең үз күзлеге // Әллүки. – 1997. – 22 август.

163. Хәйруллин Д. Ай // Шәһри Казан. – 1992. – 19 март.

164. Хәмид Р. Хан кызы // Мирас. – 1995. – №1/2. – Б. 102–114; №3. – Б. 44–50; №4. – Б. 52–61; №5/6. – Б. 59–72.

165. Хәсән С. Сөембикә ханбикә тарих мөнбәрендә лаеклы урынын алырмы? // Сөембикә. – 1999. – № 12. – Б. 9.

166. Хәсәнов Ә. Сөембикә керде төшемә // Сөембикә. – 1996. - № 8 – Б. 38-39.

167. Хуҗахмәт Фәния. Сөембикә кирәк безгә // Ватаным Татарстан. – 1992. – 27 октябрь.

168. Шагыйрьҗан Л. Сөембикә манарасы // Шәһри Казан. – 1994. – 17 март.

169. Шагыйрҗан Л. С. Сөембикә манарасы // Ялкын. – 1995. - № 7. – Б. 14-15.

170. Шамуков Г. Архитектура сәнгатебезнең бер истәлеге // Казан утлары. – 1968. – №9. – Б. 127–143.

171. Шаһиева Р. Сөембикә – олы да, серле дә алиһә зат // Заман. – 1997. – 10 октябрь.

172. Шаһиева Р. Сөембикә илһам бирә // Сөембикә. – 1991. – № 1. – Б. 24.

173. Шаһиева Р. Сөем-сөем-Сөембикә // Сөембикә. – 1995. – № 4. – Б. 15.

174. Шаһиева Р. Хан тәхете // Сөембикә. – 1999. – №10. – Б. 12–13 .

175. Шәйдуллин Р. Сөембикә манарасы // Аҗаган. – 1994. № 1. – Б. 33.

176. Шәйдуллина Н. Сөембикәне сагыну // Ялкын. – 1997. – № 7–8. – Б. 38–39.

177. Шайдуллина Н. Сөембикә урамы // Сөембикә. – 1992. – № 10. – Б. 2–3.

178. Шәмсетдинова М. Җыр килә тарих эзеннән // Социалистик Татарстан. – 1991. – 24 январь.

179. Шәмси С. Бушка бирелгән корбан // Шәһри Казан. – 1997. – 10 октябрь.

180. Шәмси С. Корбанбикә // Сөембикә. – 1999. – № 6, 7, 10, 12; 2000. – №1, 2.

181. Юзеев И. Сөембикә манарасы янында // Татарстан. – 1997. – №4. – Б. 80–82.

182. Юсупов Д. Байтак сулар акса да… // Сөембикә. – 1997. - № 11. – Б. 21-23.

183. Ягъфәров Р. Сөембикә-ханбикәне олылау // Шәһри Казан. – 1997. – 15 октябрь.

184. Ягъфәров Р. Сөембикәне чакыру // Мәдәни җомга. – 1997. - № 42. – 24 октябрь.

**Рус телендә**

185. Аго В.И. Сююмбеки башня // Казань. – 1927. – С. 27.

186. Айдаров С. Тайна башни Сююмбеки // Вечерняя Казань. – 1989. – 21, 23 октября.

187. Алпаров У. Казанская, как Пизанская? // Советская культура. – 1986. – 1 апрель. – С.2.

188. Ах, вот ты какая, Сююмбике. В Московском районе г. Казани будет проведён конкурс «Сююмбике» // Казанские ведомости. – 1997. – 8 апреля.

189. Ахмеров Г. Избранные труды. – Казань: Татарское книжное издательство, 1998. – 240 с.

190. Ахметзянов М. Золотое наставление // Казань. – 1996. – № 5–6. – С. 48.

191. Ахметшина А. Сююмбике в понимании современных художников // Татарстан. – 1995. – № 11–12. – С. 28–31.

192. Ашрафзянов Х.А. Жанр исторического романа в современной татарской прозе: Автореферат дис. … канд. филол. наук / Казан. гос. ун-т им. В.И.Ульянова-Ленина. – Казань, 1998. – 23 с.

193. Баит Сююмбике // Аргамак. – 1996. - № 7. – С. 19.

194. Батулла Рабит. Образ непокоренной // Казань. – 1998. – № 7–8. – С. 49.

195. Батулла Рабит. Сююм-бике, царица Казанская // Казань. – 1998. – № 7–8. – С. 50–74.

196. Бать-Чернышева О. Башня Сююмбеки // Причал. – 1975. – № 8. – С. 25.

197. Башня Сююмбеки в Казани // История архитектурного памятника. НИВА. – 1982. – №6. – С.136–137.

198. Башня Сююмбике. Легенды и реальность // Вечерняя Казань. – 1988. – 6 мая.

199. Бирин М. «Рецепт» для каменной реликвии // Вечерняя Казань. – 1987. – 6 июня.

200. Бирин М. Башня Сююмбеки не упадет // Строительная газета. – 1987. – 3 сентября.

201. Бирин М. Каменная красавица // Советская культура. – 1987. – 25 июня.

202. Бирин М. Чтобы башня не клонилась // Сельская жизнь. – 1987. – 19 июля.

203. Богданов У. Сююмбеки будет спасена // Социалистическая индустрия. – 1987. – 23 апреля.

204. Булгари Рашид. Вписано золотыми буквами // Болгар иле. – 1991. – №1. – июнь.

205. В совете министров ТССР: об ускорении реставрации башни Сююмбеки // Советская Татария. – 1990. – 9 сентября.

206. Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о Касимовских царях и царевичах. – СПб.: тип. имп. АН, 1863. – Ч.1. – 558 с.

207. Гаврилов С. Истории нужны не иконы, а живые люди // Известия Татарстана. – 1992. – 4 сентября.

208. Гаврилов С. Какой была Сююмбике? // Известия Татарстана. – 1992. – 2 июля.

209. Газизова Л. Сююмбике // Казань. – 1995. - № 9. - № 9-10. – С. 73.

210. Где покоиться праху царицы? // Вечерняя Казань. – 1995. – 20 июня.

211. Герберштейн С. Записки о Московии / перевод с немецкого А.И.Малеина и А.В.Назаренко, вступит. статья А.Л.Хорошкевич, под редакцией В.Л.Янина. – М.: Изд-во МГУ, 1988. – 429 с.

212. Глинка С.Н. Сумбека или Падение Казанского царства. – М.: тип. Бекетова, 1806. – 79 с.

213. Глухов–Ногайбек М. Судьба гвардейцев Сеюмбеки. – Казань: Изд-во «Ватан», 1993. – 288 с.

214. Даутова Р. Возвращение иконы Божией Матери или ислам с католическим лицом? // Вечерняя Казань. – 1999. – 10 ноября.

215. Даутова Р. Для истории важны две ногайские княжны // Вечерняя Казань. – 1999. – 16 января.

216. Девятых Л. Послание потомкам // Казань. – 1998. – № 7–8. – С. 34–35.

217. Грузинцев А.Н. Покоренная Казань, или Милосердие Царя Иоанна Васильевича IV, проименованного Грозным. СПб., 1810.

218. Державин Г.Р. Сочинения / С объяснительными примечаниями Я.Грота. – СПб.: Издание Императорской АН, 1867. – Т.4. – 723 с.

219. Душа Сююмбике просит не беспокоить её прах // Вечерняя Казань. – 1995. – 6 апреля.

220. Евгеньев С. Башня за семь дней // Московский комсомолец. – 1983. – 26 ноября.

221. Егерев В.В. Измерение наклона Сююмбекиной башни // Материалы по охране, ремонту и реставрации памятников ТССР. – Казань. – 1928. – С. 40–43.

222. Ерунов Б. Из жизни «падающей» башни // Вечерняя Казань. – 1993. – 28 июля.

223. Забирова Х. О нераскрытой тайне башни Сююмбеки // Советский Татарстан. – 1990. – 18 августа.

224. Завьялова М. Красноречивые детали. Портрет глазами этнографа // Казань. – 1998. – №7–8. – С.36–40.

225. Ислямова Л. «Тоскуя по Сююмбике» // Татарские края. – 1999. – апрель. – № 14–15. – С. 10.

226. История России с древнейших времен до конца XVIII века. Учебник. – Казань: Издательствово Казанского университета, 1999. – 336 с.

227. Ижболдин Б. Введение в историю татар. – Нью-Дели, 1963. – 178 с.

228. К вопросу о тайне башни Сююмбеки // Вечерняя Казань. – 1989. – 4 ноября.

229. Казанская история / Подготовка текста, вступит. статья и примечания Г.Н.Моисеевой; под редакцией В.П.Адриановой-Перетц. – М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1954. – 195 с.

230. Карамзин Н.М. Завоевание Руси монголами. – СПб., 1889. – 178 с.

231. Карамзин Н.М. История государства Российского. – М., 1903. – Т.8. – 150 с.

232. Когда построена башня Сююмбеки? // Вечерняя Казань. – 1984. – 23 февраля.

233. Кокарев. Хрестоматия по русской литературе. XVIII в. – М.: Просвещение, 1965. – 577 с.

234. Крупняков А. Марш Акпарса. – Йошкар-Ола: Марийское книжное издательство, 1970.– 416 с.

235. Кузнецова В. Многострадальная «Сююмбике» // Молодежь Татарстана. – 1999. – 1 июля. – С. 13.

236. Кунцевич Г.З. «Россиада» Хераскова // Журнал министерства народного просвещения. – М., 1901. – №11. – С.175–178.

237. Кунцевич Г.З. История о Казанском царстве или Казанский Летописец. Опыт историко-литературного исследования. – СПб., 1905. – 618 с.

238. Лапин В.И. Взятие Казани. – СПб.: тип. Г.Трусова, 1855. – 89 с.

239. Лисевич М. Кто такая Сююмбике? // Вечерняя Казань. – 1997. – 29 октября.

240. Малахальцев А. Незабываемая встреча с Сююмбике // Татарские края. – 1999. – №29 июль. – С. 3.

241. Малахальцев А. Семь арий для Сююмбике // Республика Татарстан. – 1999. – 3 июля.

242. Мамлеева-Козлова С., Грязнова Л. Требуется спонсор // Вечерняя Казань. – 1990. – 10 января.

243. Мифтахова Ә. Библиотека Сююмбике // Идель. – 1997. – № 11. – С. 22–25.

244. Моисеева Г.Н. Автор «Казанской истории» // Труды отдела древнерусской литературы (Институт русской литературы АН СССР). – М.-Л.: АН СССР. – 1953. – Т.9. – С. 266–288.

245. Моисеева Г.Н. Казанская царица Сююнбике и Сумбека в «Казанской истории» // Труды отдела древнерусской литературы (Институт русской литературы АН СССР). – М.-Л.: АН СССР. – 1956. – Т. 12. – С. 174–187.

246. Моисеева Г.Н. О некоторых источниках «Казанской истории» // Труды отдела древнерусской литературы (Институт русской литературы АН СССР). – М.-Л.: АН СССР. – 1955. – Т.12. – С.186–197.

247. Морозов Н. Спасают башню // Правда. – 1987. – 6 мая.

248. Мустафин Р. Образом красна и в разуме премудра // Вечерняя Казань. – 1991. – 5 апреля.

249. Мухаметшин Г. Н. Башня Сююмбеки // Проблемы национального в архитектуре России. – М., 1991. – С.25–26.

250. Мухаммадиев А. Раскопки у башни Сююмбеки // Вечерняя Казань. – 1988. – 12 марта.

251. Наурузхан В. Сююмбике // Новое слово. – 1991. – № 38–39 /95–96/. – октябрь.

252. Не падай Сююмбике // Известия Татарстана. – 1993. – 13 января.

253. Невзоров П.И. О Сююмбекиной башне. – Казань: тип. Губ. управления, 1894. – С.16.

254. Нигматуллина Ю.Г. Типы культур и цивилизаций в историческом развитии татарской и русской литератур. – Казань: Изд-во «Фән», 1997. – 192 с.

255. Почему падает башня? // Республика Татарстан. – 1999. – 8 октября.

256. Предложение // Независимая отчизна. – 1996. – № 1.

257. Рамеева И. Образ Сююмбике в русской литературе XVI-XIX веков // Восток-Запад в русской литературе XI-XXI веков. Материалы международной конференции. Стамбул. 2009. С. 144-151.

258. Рецепт для падающей бащни // Труд. – 1981. – 13 февраля.

259. Сабиров А. Почему падает башня // Известия. – 1979. – 7 декабря.

260. Сагитова З. А царица была неприступной // Известия Татарстана. – 1992. – 28 августа.

261. Садеков М. Плач ханши Сююмбике // Эхо веков. – 1998. – № 1–2. – С. 18–19.

262. Салихова Ф. К тайне башни Сююмбеки // Вечерняя Казань. – 1990. – 14 мая.

263. Санникова Р. Сююмбике – символ Казани // Магариф. – 1998. – № 5. – С. 55–58.

264. Соколов А.Н. Очерки по истории русской поэмы XVIII и первой половины XIX века. – М.: Издательство Московского университета, 1955. – 692 с.

265. Соловьев С.М. История России с древнейших времен. – М.: Соцэксиз., 1960. – книга. 3. – Т. 5–6. – 815 с.

266. Соловьева Е. Неустойчивый символ столицы // Региональная экологическая газета. – 2000. – 26 января.

267. Спиридонова Н. Сююмбике, не падай // Известия Татарстана. – 1993. – 30 января.

268. Сухов Е. Сююн-Бике, царица казанская // Молодежь Татарстана. – 1996.

269. Сююмбике должна вернуться // Вечерняя Казань. – 1999. – 12 октября.

270. Тагиров И.Р. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. – Казань: Татарское книжное издательство, 2000. – 310 с.

271. Такташ Р. Трагедия Сююмбики // Вечерняя Казань. – 1999. – 20 апреля.

272. Тарасов А. Сказание О Сююмбике // Идель. – 1992. – № 12. – С. 29.

273. Туманов Д. Далеко видно с башни // Известия Татарстана. – 1992. – 11 июня.

274. Урманчеев Ф. О происхождении и формировании баитов // Советская тюркология. – 1983. – № 5. – С. 26–36.

275. Фахрутдинов Р. Башня Сююмбеки: прошлое и настоящее // Вечерняя Казань. – 1990. – 10 октября.

276. Фахрутдинов Р.Г. В странах Алтынчэч, Сююмбике, Нурсалтан // Вечерняя Казань. – 1988. – 8 декабря.

277. Фахрутдинов Р.Г. О звезды, дочери народа моего! // Вечерняя Казань. – 1993. – март. – № 5.

278. Фролов Ю Душой коснуться неба // Советская Татария. – 1990. – 27 мая.

279. Халиков А. Башня Сююмбике: легенда и реальность // Вечерняя Казань. – 1988. – 24 июля.

280. Халиков А. Что башня в имени твоем // Татарстан. – 1992. – № 11/12. – С. 60–65.

281. Ханзафаров Назыйм. Страна негаснущих звезд // Идель. – 1994. – № 9–10. – С. 57–60.

282. Ханзафаров Н. Башня Сююмбеки в свете истории и мифологии // Идель. – 1990. – № 9. – С. 44–48.

283. Херасков М.М. Избранные произведения / Вступит. статья, подготовка текста и прим. А.В.Западова. – Л.: Сов. писатель, 1961. – 410 с.

284. Херасков М.М. Россиада. – СПб.: Типография Глазунова, 1895. – 289 с.

285. Хованьская О.С. Башня Сююмбеки // Казань. – 1948. – С. 3.

286. Шагеева Розалина. Тайна татарской Мона Лизы // Казань. – 1999. – № 5/6. – С. 49–51.

287. Шакурова И. Развитие жанра исторического романа в турецкой литературе // Казанское Востоковедение: традиции, современность, перспективы. – Казань, 1997. – С. 66-68.

288. Шакурова И. Образ Сююмбике в татарской и турецкой литературах // II Республиканская научная конференция молодых ученых и специалистов. Тезисы докладов. – Казань, 1996. – С. 81.

289. Юсупов Н.Б. О роде князей, Юсуповых. Собрание жизнеописания их, грамот и писем к ним Российских государей, с XVI до половины XIX века. – СПб., 1866–1867. – Ч. 1. – С.191; – Ч.2. – 421 с.

### Төрек телендәге китаплар һәм мәкаләләр


290. Arat Reşit Rahmeti. Kazan // İslam ansiklopedisi. – İstanbul, 1967. – C.6. – S.510-522.

291. Binark N. Tarihin meşhür Türk kadınlarından Kazan melikesi Süyüm-Bike // Kazan. – 1974. – №11. – mart. – S.27-32.

292. Çandarlıoğlu G. Kazan melikesi Süyüm Bike // Tarih mecmuası. – Istanbul. – 1966. – eylül. – S. 86-91.

293. Tugay M. F. Sevim Bike // Türk amacı. – 1942.

294. Lebib Karan A. Tüşüncemnin cırları. – Istanbul: Ahmet Sait matbaası. – 1959. – S. 9-10.

295. Lebib Karan A. Süyümbike Han. – Istanbul, 1963. – S. 216.

296. Doğan H. Siyün Bike. Istanbul: Bayrak matbaası, 1999. – 384 s.

297. Kaya M. Kazan melikesi Süyüm Bike (кульъязма).


### Теоретик әдәбият


298. Бахмутский В.Я. Классицизм // Литературный энциклопедический словарь. – М., 1987. – С. 157–158.

299. Бочкарев В.А. Русская историческая драматургия. – М.: Просвещение, 1988. – 224 с.

300. Валишевский К.Ф. Роман императрицы. Екатерина II. – М.: СП «ИКПА», 1990. – 630 с.

301. Валицкая А.П. Русская эстетика XVIII века. – М.: Искусство, 1983. – 238 с.

302. Ванслов В.В. Эстетика романтизма. – М.: «Искусство». – 1966. – 403 с.

303. Гуковский Г.А. Русская литература XVIII века. Учеб. Для студентов вузов / Вступит. статья А.Зорина. – М.:Аспект Пресс, 1999. – 453 с.

304. Гуляев Н.А. Теория литературы. – М.: Высшая школа. – 1977. – 278 с.

305. Державин Г.Р.: личность, творчество, современное восприятие. Тезисы Международной научной конференции. – Казань, 1993. – 112 с.

306. Әшрәфҗанов Харис. Язучы һәм тарих. – Уфа: Китап, 1998. – 112 б.

307. Жирмунский В. М. Литературные течение как явление международное. – Сравнительное литературоведение – Л.: Наука, 1967. – 492.

308. Жирмунский В.М. Тюркский героический эпос. Изб. труды. – Л.: Наука, 1974. – 224 с.

309. Западов А.В. Поэзия Державина. Автореферат дис. … докт. филол. наук. – М., 1959. – 44 с.

310. Измайлов И. «Казанское взятие» и имперские притязания Москвы // Мирас. – 1992. – №10. – С. 50–62.

311. История русского драматического театра. – М.: Искусство, 1977. – Т.1. – 485 с.

312. История русской литературы. – Л.: Наука, 1980. – Т.1. – 816 с.

313. История русской литературы XI–XX веков. Краткий очерк. – М.: Наука. – 1983. – 478 с.

314. Исхаков Д. Сеиды в позднезолотоордынских татарских государствах. – Казань: Иман. – 1997. – 78 с.

315. Лихачев Д.С. Культура Руси эпохи образования русского национального государства. – М.: Госполитиздат., 1946. – 160 с.

316. Лихачев Д.С. Человек в литературе древней Руси. – М.: Наука, 1970. – 180 с.

317. Миңнегулов Х.Ю. Татар-төрек әдәби багланышлары // Татарстан. – 1993. – № 9. – Б. 50-56.

318. Мифологический словарь. – М.: Просвещение, 1985. – 176 с.

319. Москвичева Г.В. Русский классицизм. – М.: Просвещение, 1978. – 128 с.

320. Муравьев А. «За правду чтить меня ты будешь» // Вечерняя Казань. – 1993. – 9 июля.

321. Муравьев А. «Я в дверях вечности стою» // Казанские ведомости. – 1993. – 14 июля.

322. Мусин Ф. Татар прозасы // Мирас. – 1997. – №6. – Б. 109–131.

323. Нуруллин И.З. Әдәбият теориясе. – Казан: Татар китап нәшрияты, 1977. – 142 б.

324. Олеарий Адам. Описание путешествия в Московию и через Московию в Персию. – СПб.: тип. А.С.Суворина, 1906. – 582 с.

325. Орлов А.С. Героические темы древней русской литературы. – М.-Л.: АН СССР, 1944. – 144 с.

326. Русские писатели, 1800–1917: Биогр. словарь / Гл. ред. Николаев П.А. – М.: Советская энциклопедия, 1989. – 621 с.

327. Русский биографический словарь. – СПб.: тип. Главного управления уделов, 1897. – 756 с.

328. Тәрҗеманов Җ. «Бакыр Бабай» // Ватаным Татарстан. – 1993. – 3 июль.

329. Хализев В.Е. Теория литературы. – М.: Высшая школа, 2000. – 340 с.

330. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе. – Казан.: Мәгариф, 2001. – 350 б.

331. Языков Д.Д. Обзор жизни и трудов покойных русских писателей. – СПб.: тип. А.С.Суворина, 1885. – 140 с.

*Рамеева Ильсияр Равилевна*

**Образ ханбике Сююмбике в русской, татарской и турецкой литературах**

*(на татарском языке)*

*Научное издание*

Коррректоры – *Рамеев З.З., Сайфутдинов Р.Г.*

Оригинал-макет – *Л.М.Зигангареева*

Подписано в печать 17.08.2009 г.

Усл. печ. листов 15,25   Тираж 500 экз.

Отпечатано в множительном центре

Института истории АН РТ

Казань, Кремль, подъезд 5

Тел. (843) 292-95-68, 292-18-09